ISSN 0206-418

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1996



# АЛДАГЫ САННАРДА УКЫГЫЗ!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

***Татар әдипләренең яңа әсәрләре, галим һәм публицистларның кызыклы язмалары алга таба да сезнең игътибарга тәкъдим ителәчәк. Менә арадан кайберләре:***

**Марсель Галиев. «Догалы еллар».** *Эссе.* **Татарның күренекле шәхесләре, әдәби язмышлар, җәмгыятьтәге вакыйгалар турында язма.**

**Фәрит Яхин. «Ахырзаман пәйгамбәре». Кыйссаның икенче кисәге. Әсәрдә Мөхәммәт пәйгамбәрнең дин юлында күргән михнәтләре, көрәше сурәтләнә.**

**Госман Гомәр. «Мөһер».** *Маҗаралы повесть.*

**Суфиян Поварисов. «Пәйгамбәр таңы». Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның яшьлек еллары турында роман.**

**Зәки Зәйнуллин. «Ат караклары».** *Роман.* **Казах җәйләүләрен, Оренбур далаларын, Эстәрлебаш тугайларын кулда тоткан теге заман «мафиозлары» хакында яңа әсәр.**

**Шәриф Хөсәенов. «Газап дингезен эчеп...» Күренекле драматургның бөек композитор Рөстәм Яхин турында истәлек язмасы.**

**Русия чикләре эчендәге беренче төрки дәүләтнең 1450 еллыгы уңаеннан Тәүфикъ Әйдинең атаклы тарихчы, академик Миркасыйм Госманов белән әңгәмәсе.**

**Рафаэль Сибат. Бүгенге татар поэзиясе турында уйланулар.**

**Шулай ук шагыйрьләребездән Ренат Харис, Харрас Әюпов, Мөдәррис Әгъләм, Җәүдәт Сөләйман, Флера Гыйззәтуллина һәм башкаларның яңа әсәрләре белән танышa аласыз.**

**Милләт буларак бердәм, максатчан, гакыллы булыйк дисәк, һәр татар гаиләсенә — «Казан утлары» журналы!**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**(885)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ФӘИЗОВ. Узган гомер — янган күмер. *Документаль повесть* ........ 3
ЗӨЛФӘТ. Төнбоек күз йомган мәлләрдә. *Шигырьләр* ........ 94
Л. ЗАКИР. Бүреләр. *Хикәя* ........ 100
Р. СИБАТ. Тән-җанның берлеге... *Шигырьләр* ........ 113
М. МИНШИН. Дүрт җыр. *Шигырьләр* ........ 149

ОСТАХАНӘ

М. МИРЗА. Кыска шигырьләр ........ 119

ИЛДАР НИЗАМОВКА 60 ЯШЬ

И. НИЗАМОВ. Парчалар ........ 123

ӘДӘБИ МИРАС

Л. ҖАМАЛЕТДИН. Халык иҗаты — үлемсез ........ 134
Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе ........ 135

ДРАМАТУРГИЯ

И. ЮЗЕЕВ. Гашыйклар тавы. *Мәхәббәт кыйссасы* ........ 152

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Р. ВӘГЫЙЗОВ. Татарстанда җинаятьчелеккә каршы көрәш чаралары ........ 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. ЛАИСОВ, Ә. СИБГАТУЛЛИНА. Төркиядән бүләк ........ 169
Т. АЛМАЗОВА. Музыка сүзлеге ........ 187

ХӘТЕР

М. ШАБАЕВ. Сагындыра... *(Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең вафатына ун ел)* ........ 175

Котлыйбыз ........ 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздын... ........ 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: документальная повесть Р. ФАИЗОВА «Ушедшая жизнь — сгоревший уголь»: рассказ Л. ЗАКИРОВА «Волки», стихи ЗУЛЬФАТА, Р. СИБАТА, М. МИНШИНА, М. МИРЗЫ.
«К 60-летию И. Низамова»: миниатюрные рассказы И. НИЗАМОВА.
«Литературное наследие»: статья Л. ЗАМАЛЕТДИНА «Народное творчество — бессмертное».
«Драматургия»: пьеса И. ЮЗЕЕВА «Гора влюбленных».
«Человек и право»: статья Р. ВАГИЗОВА «Меры борьбы с преступностью в Татарстане».
«Книжное обозрение» статьи Н. ЛАИСОВА и А. СИБГАТУЛЛИНОЙ «Подарок из Турции» и Т. АЛМАЗОВОЙ «Словарь музыки».
«Память»: статья М. ШАБАЕВА посвящена к 10-летней годовщине смерти народного поэта Татарстана С. Хакима.
В номере отмечается 70-летие прозаика Г. Шарафи.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сороковой день» — фоторепродукция с картины художника Х. Кульбарисова; известный писатель и публицист Р. Низамиев.

## IN OUR ISSUE

«Prose and poetry»: R. Phaizov's documentary narrative «Passed life — burned coal», L. Zakirov's story «Wolves»; the verses of Zulphat, R. Sibat, M. Minshin, M. Mirza.
«Commemorating the 25th anniversary of I. Nizamov»: I. Nizamov's miniature stories.
«Literary heritage»: L. Zamaletdin's article «Folk art is undying».
«The drama»: I. Yuzeev's play «The Mountain of Love».
«Man and law»: R. Vagizov's article «Measures of prevention of Crime in Tatarstan».
«Book review»: articles of N. Laisov and A. Sibgatullina «The present from Turkey»; T. Almazova's article «Music dictionary».
«Memorry»: M. Shabaev's article devoted to the 10th anniversary of death of the National poet of Tatarstan S. Khakim.
In this issue the 70th anniversary of the prose writer G. Sharaphi is celebrated.
The diary of social and cultural life.
In our covers: Kh. Kulbarisov's picture reproduction «The 40th Day»; well-khown writer and publicist R. Nizamiev.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 3.06.96 ел. Басарга кул куелды 10.07.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 350. Заказ Е-299.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.



**Радик Фәизов**

# УЗГАН ГОМЕР — ЯНГАН КҮМЕР

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

*Бу повестьне яза башлаганчы мин озак вакытлар уйланып йордем. Аңа нинди исем бирергә, ничек башлап китәргә икәнен белмичәрәк аптырадым. Чонки бу доньяда алтмыш елдан артык яшәвем дәверендә миңа бик күп хәлләрне күрергә, күп мажараларны башымнан кичерергә, торле холыклы, торле язмышлы кешеләр белән очрашырга туры килде. Һәм менә боларның барысын да тәртипкә салып, бер җепкә тезеп сойләп бирүе, аеруча берләштерә торган исем табуы, ай-һай, кыен бер эш булып чыкты.*

*Ахырда мин хисапсыз вакыйгаларның укучы очен кызыклы булыр дип санаганнарын гына алып, алар тормышта ничек булсалар, шундый тәртиптә, артыгын бик чуарламый, бизәкләмый гына сойләргә һәм боларның барысына «Узган гомер — янган күмер» дигән гади генә исем бирергә булдым. Чыннан да, сүз бер кешенең үткән гомере һәм тормыш юлында очраган күп торле хәл-әхвәлләр хакында барачак бит. Аннары аның шунысы кызыклы: без, утызынчы еллар башында туганнар, бу доньяга социализмның зур бер адымы булган колхозлар белән бергә яралдык. Без үткән юл, безнең язмыш — аңлы рәвештәме яисә гомуми агымга иярепме, социализм тозергә алынган ботен бер буынның язмышы бит ул әле.*

*Хәзер исә, күрәсез, безнең буын алдына куелган һәм безнең зур күпчелегебез ихлас күңелленнән изге дип санаган максатлар ботенләй үзгәрде, юкка чыкты, без күтәреп йоргән идеяләр чәлпәрәмә килде. Бу бит әле сәясәт үзгәрде, дигән сүз генә түгел, бу бит ботен бер буынның чын мәгънәсендәге фаҗигасе дә. Әлеге фаҗига ул, әлбәттә, үзеннән-үзе генә килмәде. Аны тудырган сәбәпләр булды. Нәкъ менә кешеләр, аеруча җитәкче-коммунистлар китереп тудырган сәбәпләр. Газетадан укыдым: социализмның җиңелүенә кеше рухының, кеше интеллектының, ягъни шәхесенең түбән дәрәҗәдә торуы сәбәпче булды, ди бер акыл иясе. Менә бит ул ничек!*

*Һәм, ихтимал, минем тыйнак кына язмышымда безнең буынның шушы фаҗигасе, аңа китергән сәбәпләр дә чагылыш табар.*

* * *

Үземнең балачагым, нинди ишле гаиләдә, нинди авырлыклар күреп үсүем хакында мин моннан элек язылган «Түбән оч» дигән повестемда шактый тулы сөйләгән идем инде. Тик, язмыш дигән нәрсә, егет булып үзбуйлы яши башлагач та, миңа әлләни рәхим-шәфкать күрсәтмәде. Хәер, монысы өчен гаеп үземдә дә бар һәм зур гына. Яшьлегемдә, хәер, гомер буена дисәң дә ярый, мин артыгын тәэсирләнүчән, йомшак күңелле, кеше сүзенә бик тиз ияргә торган җиңел холыклы, алдын-артын бик уйламый торган җиңел бер җилбәзәк булып калдым. Хәзер, картлыгым биеклегеннән торып уйлыйм да күпләр өчен сәер тоелачак шундый бер нәтиҗә чыгарам: моңа минем китапларны бик яшьләй, тиешеннән артык күп укуым сәбәпче булды бугай. Безнең ишле гаиләдә миннән олылар барысы да укучы иде, шулардан күрмәкче, мин биш яшемнән үк укырга өйрәнеп алдым. Һәм, нинди генә китап табып алсам да, аны бирелеп, дөньямны онытып укый башладым. Ә җидееллык мәктәпне бетергәндә мин инде үзебезнең авыл китапханәсендәге барлык татар язучыларының гына түгел, рус, Европа, хәтта Америка язучылары китапларын да укып чыккан идем. Ничек булгандыр, ул вакытта авыл китапханәсе бай гына иде.

Менә шул китаплар мине тормыш чынбарлыгыннан шактый аерылган, аны идеаллаштырып карый торган, беркатлы кеше итеп тәрбияләделәр. Мин кешеләрдәге киң күңеллелек, яхшылык һәм изгелеккә һәрдаим ышанып, өмет баглап яшәдем һәм бу хәл миңа еш кына үзенең җәфасын сала да килде. Ә шулай да бу — китапларны яшь вакыттан күп укырга кирәкми икән, дип кабул ителә күрмәсен! Һич тә! Беренчедән, китапларны бит әле аларны төрле кеше төрлечә кабул итә. Икенчедән, мин үземнең шулай юаш, беркатлы тәэсирләнүчән кеше булып яшәгәнемә һич тә үкенмим! Дөнья гел зирәкләрдән, усаллардан, нахаллардан гына торырга димәгән. Аның безнеңише хисле, йомшак бәндәләре дә булырга тиештер. Мин, шәхсән, шулай уйлыйм.

Ярый, кереп китик тормышның үзенә. Ул заман урта мәктәптә уку мәҗбүри түгел иде. Җиде классны бетергәч, ундүрт яшьлек үсмер килеш, мин колхозда эшләргә булдым. Бу әле сугыш туктаган гына ел, колхозда автомашиналар турында ишеткән кеше дә юк, хәтта атлар да җитешми, үгезләр, сыерлар җигеп эшлиләр иде. Кәнсәләргә, колхоз рәисе Шәфикъ абый янына мендем. Шәфикъ абый сырхау чырайлы, гомере буена ашказаны белән газапланып, барган җиреннән теләсә кайда тукталып, косып йөри торган кеше. Шул сәбәпле аны сугышка да алмадылар. Шулай да ул өстенә хәрби гимнастерка киеп, биленә дә, иңенә дә каеш салып йөри иде. Иң авыр елларда, сугыш вакытында рәис булды, амбарга җыелган ашлыкны кырып-себереп диярлек дәүләткә озатты, шулай да колхозчыга өлеш чыгаруның да җаен тапты. Иң әйбәте шул: безнең авылда да, нәкъ башка урыннардагы кебек ашлык, салам, печән урлап тотылучылар булгаласа да, Шәфикъ абый бер вакытта да эшне зурга җибәрмәде. Үзе шелтәләде дә, шуның белән йомды. Ә бит күрше авыллардан нинди аянычлы хәлләр ишетә идек. Шуның өчен рәхмәт һәм дан бу рәискә! Менә шушы Шәфикъ абый минем ябык кына гәүдәмә, нечкә беләкләремә кызганулы карап торды.

— Хәбибрахман абыйның Радик атлы малаемы әле син? Өйрәң бер дә куе булмаган синең, энем. Бигрәкләр дә сыек күренәсең бит. Үгез башын борырга көчең җитми дә җитми. Дус кеше генә итеп ат бирербез инде сиңа. Закир абыеңа әйт, Тимеркүкне сиңа бирсен,— диде ул.

Баш конюх Закир абыйны — олпат гәүдәле, калын тавышлы кешене әйбәт беләм. Очраган саен миңа елмаеп, дустанә сүз кушып йөри. Әмма бу юлы, минем ерык авыздан «Тимеркүк» дигән сүз чыккач, агаемның озын борынлы йөзе кисәк бик үзәреп китте, каты мыеклары кабарды. Һәм ул аяктан бәреп егарлык гайрәтле тавышы белән кычкырып җибәрде:

— Кырмыш тәре! Борын астың кипмәгән, сиңа ат бирәләр. Җитмәсә, Тимеркүкне! — диде ул җикеренеп һәм, минем тагын бер кат гаҗәпләнүемә каршы, шунда ук ялынулы пышылдауга күчте: — Энем җаным, зинһар дип әйтәм, атны кыйный күрмә. Ул малкаем болай да кыенны күп ашый. Ичмасам син аңа миһербанлы була бел. Чыбыркы белән бер дә селтәнәсе түгел. Матри, малай...

Менә бит! Кычкырышканда тавышы югары очтагы конюшнядан түбән очтагы өендә яңгырап торган, гаугалы, җанҗаллы бу кешенең атларны шулкадәр ярата, алар өчен җаны авырта икәнен мин һич тә белмәгән идем.

Тимеркүк башкаларга караганда яхшы тәнле, нык ат, әмма менә арт санының бер ягында йоны тәмам коелып, коры тирегә калган, кайбер төшләре хәтта чиләнеп, кан саркып тора. Бу — бичара хайванны имансызларча, ерткычларча кыйнауның эзләре. Чөнки Тимеркүк үз җаена килмәсә, күпме кусаң, чыбыркыласаң да, юыртмый да, сикертми дә торган, бернидән дә куркуны да белмәгән ифрат кире һәм ялкау ат. Шуңа күрә аны беркем дә үзе теләп даими җикми, ул кулдан-кулга күчеп йөри, төрле юньсезләрдән кыен ашый. Закир абый йөгән киертеп араннан алып чыгып биргәч, мин атның киң күкрәген сыйпадым, йомшак иреннәренә кесәмдә үземә дип кенә саклаган икмәк кыерчыгын төрттем. Һәм акыллы хайван үзенең кем кулына килеп кергәнен шунда ук сизеп алды. Ул үзенең зур башын минем иңемә салды, аның нәрсәсе беләндер үземнең мәрхүмә әнкәемнекенә охшаган, сагыш тулы зур күзләрендә өмет чаткылары кабынды.

Авылдан егерме чакрымдагы Шинше урманыннан ботак-санак алып кайтырга! — Безгә фәрман әнә шундый. Җәйнең матур, аяз иртәсендә без Тимеркүк белән юлга чыгып киттек. Мин Тимеркүкне куалап маташмадым. Инде яшелләнгән басулар уртасындагы юлдан ул үз җае белән атлый да атлый. Мин исә арбага чалкан төштем дә, күзләремне зәңгәр күккә текәп, бу тузанлы юлдан, дыңгырдык арбадан, гомумән, бу җирлектән гаип булдым. Мин — очучы. Теге «Чын кеше» китабындагы Алексей Маресьев белән бергә күктә. Без әнә теге ак болытлар арасында атылып йөрибез, немец самолетларын кырабыз. Алар бер-бер артлы түбән мәтәлә. Мин кычкырам, мин шатланам. Әһә, монысы минем Украинада һәлак булган Әхмәт абыем өчен! Монысы Гомәр абый өчен! Моның белән генә немецлардан алган үчем бетми әле. Зәңгәр күкне гизеп туйгач, мин капитан Немоның «Наутилус»ына утырам да, без диңгез тирәнлегенә чумабыз. Капитан Немо киң җилкәле, төз гәүдәле, нәфис, матур йөзле кеше. Ул гаделсезлекне, имансызлыкны күралмый. Без аның белән немецларның су асты көймәләрен юк итәбез... Ә тирә-якта исә бөтенләй икенче тормыш бара. Арттан куып узучы атлылар безне тиргәп, нидер кычкыралар, сирәк-мирәк үткән машиналарның шоферлары кабинадан йодрык күрсәтеп уза. Әмма без төкереп тә бирмибез. Мин үземнең хыялый дөньямда, башымны күтәрмим, ә Тимеркүк исә ялкау, үзенең барган юлыннан бер карыш та читкә алмый, беркемгә дә юл бирми. Берзаман, болай да хәйран салмак барган җиреннән Тимеркүк бөтенләй тукталып калды. Юл буендагы чирәмне йолкый, яшел уҗымнарга да үрелә башлады. Бүтән малайлар булса атны ашыктырырга, акырып-бакырып куаларга, чыбыркы белән селтәнергә керешерләр иде. Мин исә бөтенләй киресен эшләдем. Яткан урынымнан торып төштем дә, атның дилбегәсен бушатып, аркалыгын төшереп җибәрдем. Рәхәтләнеп тамак ялгасын, әйдә! Әле вакыт күп бит. Ни гаҗәп, бераз чирәм ашагач, Тимеркүк үзе юлга кереп басты да, салмак көенә кузгалып та китте.

Урманга барып җиткәч, мин аны бөтенләй тугарып ук җибәрдем, иренмәдем. Урман кисүче, үзләре дә яшь наратлар кебек икесе дә биек, икесе дә төз Ахун абый белән Идрис абый мине әллә нинди урман үләннәре салынган чәй белән сыйладылар. Аннары арбага ботак төйи башладылар. Инде биек булды, ә тегеләр һаман китереп салалар.

— Җитәр инде, җитәр! — дип ялынам мин. Тегеләр исә көлә генә.
— Тимеркүк тарта ул. Трактор кебек ул!
Без салам олавы чаклы итеп төялгән, бастырык бастырылган олау белән кайтыр юлга чыктык. Тимеркүк, чыннан да, бик артыгын көчәнмичә генә дә шушы зур олауны тартып китте. Мин исә дилбегәне бастырыкка бәйләп куйдым да, олау өстенә ятып, йокыга ук киттем. Йокы аралаш ишетәм, тагын безнең олауга машиналар ышкылып үтә, тагын безне тиргәп ау-һаулар ишетелә. Ә безнең кайгы юк, ишетелә бирсен...
Адәм акыллары бар иде Тимеркүктә. Беркөн авылдан чыгып аркылы юлга җитмәс борын туктала башлады бу. Барган җиреннән туктый да артына борылып карый, туктый да карый. Чөңгереп тә, кычкырып та карыйм, һаман үзенекен итә. Аптырагач, үзем дә артка борылып карадым. Күрәм, минем балтам белән солы капчыгы арбадан юл өстенә төшеп калган икән...
Без шулай бер-беребезне яхшы аңлап, тату яшәдек. Әмма безнең бу дуслык озакка бармады шул. Шулай үз җае белән генә йөри торгач, Тимеркүк көзгә таба тәмам көрәйде, ыспайланды. Аңа инде миннән олыларның, көчлеләрнең, дәүләткә икмәк чыгаручыларның күзе төште. Аерылганда мескенем үзенең дәү, авыр башын минем иңемә озак итеп салып торды. Аның да күзенә, минем күземә мөлдерәп яшьләр чыкты. Чөнки ул үзенең һич төзәлмәс ялкау икәнен, моннан ары тагын имансызлар кулына эләгәсен, чыбыркы ашыйсын бик яхшы белә иде. Ә минем исә чыбыркым бөтенләй дә юк. Дөрес, эшкә беренче чыккан көнемдә мин каештан үреп бер чыбыркы алган идем. Әмма аны беренче көнне үземнең иптәш малайлар — әллә Абдул, әллә Мидхәт урлады.
Аттан мәхрүм иткәч, миңа аклы-кызыллы кечкенә генә бер үгез бирделәр. Инде бу көзгә таба иде, басудан әвенгә көлтә кертергә куйдылар. Ярый, чыгып киттем мин шушы үгезне җигеп, болын өстендәге басуга барып төядек кибәннән көлтәләрне. Абдул белән Мидхәт, олаулары өстенә менеп утырып, инде кайту юлына да борылдылар. Ә минем үгез исә, мур кыргыры хайван, бөтенләй кирегә, болын ягына борып алды. Мин дилбегәне аяк терәп тартам, бар көчемә кычкырам, ни эшләргә дә белмим. Үгез исә аның саен киреләнә, башын бер як тәртәгә терәп алды да, болын ягына сыпыртуын белә. Менә без үр башына килеп җиттек, авыр олауның арттан этүе белән таудан очып төшә башладык. Хәзер инде безне бу дөньядагы бернинди көч тә тотып кала алмый иде. Шул килгән шәпкә туп-турыдан Ашыт суына кереп тә киттек. Мин үзем олау өстеннән башта үгез өстенә, аннан суга мәтәлеп төштем. Олау бер якка янтайды, көлтәләр таралып су буйлап агып киттеләр. Үгез мәлгуньгә исә ни пычагым да булмады, ул сырты күмелә язып елга уртасында тора, рәхәтләнеп су эчә.
Бу хәлне тамаша кылып торган яшелчәче хатыннар, болын үре өстеннән Абдул белән Мидхәт, көлтә төяп торучы агайлар — бар халык эчен тотып көлә иде. Мин исә өстемнән шабырдап сулар аккан килеш яр буена чыгып утырдым. Гарьләнүемнән, чарасызлыктан, үз-үземне кызганудан елап җибәрдем. Мин бит күпме халык алдында адәм хуры булдым... Әнә, берсе дә ярдәм итәргә теләми, бары тик көләләр генә. Шунда яныма яшелчәчеләр бригадиры Гыймади абый килде.
— Күрсәтмә күз яшеңне кешегә, егет! Белеп тор: күз яше өчен җәлләмиләр. Болай мәлҗерәп утырганчы урыныңнан торып бас. Әйдә, таралган көлтәләреңне җыеп алыйк! — диде ул кырыс итеп.
Без Гыймади абый белән, көзге көн шактый салкын булуга карамастан, өсләрне чишенеп суга кердек, барча көлтәләрне ярга ташыдык. Берсен генә калдырсаң да башың кәтер китәргә мөмкин. Шуңа күрә камыш төпләрен айкап чыктык. Аннан үгезне арбадан тугарып алдык, арбаны судан чыгардык. Кичкә кадәр азапландык шулай. Гыймади абыйның шул ярдәмен гомергә дә онытасым юк.

Авылдагы гомере буена тәмәке тартмаган, аракы эчми, сүгенә белми торган, изге күңелле кешеләрнең берсе иде ул. Гомере буена яшелчәчеләр бригадиры булды, әмма берничек тә, бер генә карыш та үз ягына каермады. Аның урынында икенче бер адәм булса, үз җаен белер иде. Зур итеп йортын, каралты-курасын торгызып куяр, баеп бетәр иде. Ә Гыймади абый үзенең шактый ишле гаиләсе белән кысан гына йортта, тыйнак кына гомер итте. Аның өчен колхозныкы — үзенекеннән дә изге иде шул. Моның өчен ул хатыны һәм балалары тарафыннан да бик күп тиргәү ишетте. Әмма гомере буена гадел, хәрәмсез кеше булып калды.

Теге үҗәт үгез белән мин тагын байтак мажаралар күрдем әле. Аларның барысын да монда сөйли башласаң, бүтән сүзгә урын да калмас, бары үгез кыйссасы гына килеп чыгар иде. Хәер, ул ачлы-туклы килеш көне-төне җигелү, кыен ашау заманасында үгезләр генә түгел, акыллы саналган хайван — атлар да кайчак адәм баласына аңлы рәвештә каршылык күрсәтәләр иде. Даими кыйналудан, ыңгырчак басудан сырты, яннары чиләнеп беткән Сабир алашасы, йөгәннән бер ычкындырып җибәрсәләр, болынга төшеп кача да, атналар буе беркемгә дә тоттырмый. Шинше урманыннан утын алып кайтырга кирәк булды. Монда инде үгез белән булмый, ат сорадым.

— Атлар юк. Әнә Сабир алашасы — болында. Тота алсаң, шуны җик! — диде миңа Закир абый.

Төшеп киттем болынга курка-курка гына. Әнә ул үзе чем кара, калын койрыклы алаша. Печән эскерте янында гына утлап йөри. Йөгәнемне кулымда әзер тотып, сак кына якынлашам. Исе дә китми, курыкмый, миңа борылып карамый да, утлавын белә, тик койрыгын гына селкеткәләп куя. Мин атка ун адымнар чамасы калгач кына, ул кисәк башын күтәрде, хәтәр итеп зур күзләрен акайтты, сары тешләрен ыржайтты да... туп-туры миңа томырылды! Ярый әле соңгы мәлдә мин печән эскертенә сеңәргә өлгердем. Башын нәкъ кувалда чүкече кебек итеп алга сузган ат минем яннан өермәдәй очып үтте. Читкә тайпылып өлгермәсәм бетерә, башы белән бәреп туп шикелле чөеп җибәрә иде... Атны икенче көнне, кешеләр җыйналып төшеп, муенына ерактан аркан ташлап, тотып мендeләр.

Әнә шундый мажаралар белән колхозда бер ел эшләдем. Урманга барсаң — бер ярка утыны, басудан печән-саламы ияреп кайта дигәндәй, моннан минем укытучы, үзебезнең авылдагы мәктәп мөдире әтием, әнием дә бик канәгать иделәр.

Икенче җәйдә мине урамда Наил Сабиров туктатты. Бөдрә чәчле, зур соры күзле, нык бәдәнле бу малай миннән бер яшькә кече, әле генә җиденче классны бетергән иде.

— Әйдә, Әтнәгә барабыз! — диде ул.

— Ни эшкә?

— Урта мәктәпкә керәбез.

— Укырга?! — дидем мин. — Нигә кирәк ул миңа?

— Гомерең буена син колхозда шушылай үгез артын чабаклап йөрерсеңмени? Ә мәктәптә нинди әйбәт укыдың бит... Күәм юлында безгә нинди кызыклы әкиятләр сөйли идең. Үз башыңнан чыгарып... Беләсеңме, сиңа әбизәтелни укырга кирәк. Ике дә уйлап торма!

Шушы сүзләре өчен мин Наил дустыма әле дә, инде ярты гасыр гомердән соң да рәхмәтлемен. Ул кечкенәдән төпле, акыллы иде шул. Ә кызыклы әкиятләргә килгәндә, чыннан да, юлда барган көйгә үз күңелемнән хәйран күңелле, кызыклы әкиятләр чыгара ала идем. Без дүртенче класстан җиденчегә хәтле үзебезнең авылдан өч чакрымдагы Күәмгә төшеп укыдык. Шул Күәм юлында минем иптәш малайларым ул әкиятләрне бик күп тыңладылар. Бик яраталар, сорап-сорап сөйләтәләр иде.

Минем күңел шунда ук дөрләп кабынды. Укырга! Мин бит бала чактан ук очучы, врач яисә инженер булырга хыялландым. Ерак җирләрне, зур шәһәрләрне күрәсем килә иде. Ә моның өчен бит, җанашым-кара

кашым, укырга кирәк! Тик өйгә кайтып бу сүземне әйткәч, әти белән әни минем өскә салкын су койгандай иттеләр.

— Ул ниткән укып йөрүләр ди тагын... Монда сыер, сарык асларын кем чистартыр? Әле җәен печәне, кашын саламы кайтып тора иде ич. Яхшылап әйт үзенә, барып йөрмәсен! — диде әни.

— Ул Әтнә мәктәбенә ниләр киеп йөрмәкче буласың? Ямаган чалбар, тишек чабатаң беләнме? Сине укытырлык акча миндә юк! — дип кырт кисте әти дә, мыекларын кабартып.

Тик мин дә инде күңел бер кузгалгач, үземнекен итми калмый торган бер үҗәт идем. Тегеләрнең рөхсәтеннән башка гына Наилгә иярдем дә, Әтнәгә киттем. Тәки гариза биреп кайттым. Инде укырга чакырып, Әтнәдән кәгазь килеп төшкәч, әти ничектер каршы килмәде тагын. Тик бер сүзен генә әйтте:

— Ярар, укысаң укырсың инде. Тик, кара аны, миннән ярдәм көтмә!..

* * *

Әй, ул урта мәктәптә укыган елларның авырлыгы! Безнең Дусым авылы белән Олы Әтнә арасы биш чакрым. Болын аша үтә торган юл язын-көзен баткак. Без Наил дус белән көн саен, ары-бире ун чакрым юл үтәбез. Көзге яңгырларда, кышкы бураннарда. Ә аякларыбыздагы чабата аша, юеш җиргә чыгып басуга, шунда ук су үтә. Ул чабаталар шул заманның билгесе, символы иде инде. Юл читенә карасаң шулар ята, хәтта телеграмм баганаларында да тишек чабаталар эленеп тора. Бик күп чабаталар! Әтнә базарына атна саен тирә-як авыллардан, Маридан күп кешеләр килә. Аларның юлда чабаталары тишелә. Алар аякларын чишенеп, яңасын киялә дә, искесен киндерәләреннән бер-берсенә бәйләп, телеграф чыбыклары өстенә чөеп кенә җибәрәләр. Тегеләр шунда асылынып та кала. Ул елларда хөкүмәтнең берсеннән берсе хәтәр, катгый фәрманнары тапшырыла торган чыбыклар өстендә җилдә чайкалып торган бу чабаталар шул чорның әләмнәре булган икән...

Безнең әткәй молодец, үз сүзендә торды. Минем өстә каешланып беткән иске, юка бишмәт. Чалбар нииндидер брезент төсле юка, каты тукымадан. Көн саен ямап торсаң да, һаман да җекләреннән сүтелә. Хасил булган ярыктан минем тезбашларыма, аннан югары әгъзаларыма да каршы искән салкын җил өрә... Ә китапларны исә чүпрәк букчага тутырып йөрим.

Көн дә саен Әтнәгә, тегендә-монда ун чакрым атлый башлагач, минем өчен тагын бер җәфа туды. Сугышның шаукымы, үзе туктагач та, тагын берничә елларча барды бит әле аның. Оят булса да әйтим, ул елларда безнең өйдә ипи юк иде. Гел бәрәңге дә бәрәңге. Мин соңыннан фәнни китаплардан укып белдем, ризыклары гел бәрәңгедән генә торган кешенең канында күпмедер микъдарда спирт барлыкка килә икән. Инде спирт үзе булгач, теге бичара көне буе аз гына кызмача булып, мәлҗерәп йөри икән. Мин иртән йокымнан сәгать алтыда торып, коры бәрәңге белән чәй эчеп чыгам да, ерак юл үтеп, салкыннан җылы класска кереп утырам. Шунда инде минем белән гаҗәеп хәлләр башлана. Такта янында безгә дәрес аңлаткан яшь кенә, чибәр генә, класстагы барлык малайлар яшертен генә гашыйк булган рус кызы Людмила Петровнаның тавышы акрынлап тоныклана, ераклаша башлый... Менә бу чибәр кыз үзе безнең авыл көтүчесе, сугышта алган контузиядән авызын сагыз чәйнәгәндәй гел селкетеп тора торган Кәрим абыйга, ә кулындагы күрсәткеч таягы чыбыркыга әйләнә. Мин инде үземне класста түгел, ә үзебезнең авыл болынында итеп күрәм. Әнә, якында гына сыерлар, сарыклар утлап йөри. Ә мин биектә, йомшак печән өстендә ятам. Шулкадәр рәхәт, җылы! Минем

торасым да, селкенәсем дә килми... Әмма шунда бик еракtан, әллә кайдан Людмила Петровна тавышы ишетелә:

— Фаизов, не спи!

Тавыш килгән якка карыйм, тик берни күрмим. Әһә, минем күзләрем йомык икән бит. Бик тырышып аларны ачмакчы булам. Тик күз кабакларым шулкадәр авырайган ки, аларны һич ачар хәл юк. Шунда инде нык итеп кабыргама китереп төртәләр:

— Йоклама диләр!

Ахырда мин уянып китәм. Карасам, партада янәшә утырган Наил үзенең зур күзләре белән миңа бик шелтәле итеп карап тора. Класста анда-санда көлү авазлары ишетелә.

Тик, күпме генә вакыт үтә икән, минем башым тагын чамасыз авырая, аска иелеп төшә, күз кабакларыма кургаш койгандай була. Людмила Петровна кычкыра, Наил кабыргамны каезлый. Мин үзем дә йокыга каршы актив көрәшеп карыйм, чабата эчендәге аяк бармакларымны селкетәм, ботларымны чеметәм. Әмма боларның берсе дә әлләни ярдәм итми, ярым ач, талчыккан яшь организм үзенекен итә. Беренче дәресне мин яртылаш йоклап үткәрәм. Тора-бара бу хәлгә күнектеләр, миңа әлләни комачау итмәс булдылар.

Наилнең әтисе Закир абый баш конюх, әнисе Нәсимә апай, аннан килеп апайлары — барысы да колхозда эшлиләр. Нәсимә апа, бик йомшак күңелле, күндәм, сабыр холыклы хатын, урак урырга бик оста. Бригада алдынгысы булып, макталып йөртелә. Нәсимә апайның бик серле тоелган, сәер бер гадәте бар. Урак урган яисә бик бирелеп нәрсәдер башка эш эшләгән җиреннән ул кисәк тораташ кебек катып кала һәм бер-ике минут кына йоклап ала. Аннан, берни булмагандай, тагын эшендә була. Соңыннан мин укып белдем: мондый кисәк килеп тоткан йокы бик күп эшләгән кешеләрдә күзәтелә һәм талган организм өчен бик файдалы, табигатьнең аны саклау чарасы икән. Менә шулай барысы да эштә булгач, Наилләрнең йортында ипи өзелмәде. Әмма укулары Наил дуска да бер дә җиңел булмады. Аның да өстендә бишмәт, аягында чабата. Берзаман килеп, Наилгә киез итек алдылар. Көн саен ун чакрым юл йөреп, бу бичара киез итек күпмегә чыдарга тиеш була? Тиз генә тишелмәсен дип, аңа галош та кидереп куйдылар. Шулай барабыз беркөн иртән Әтнәгә. Күрәм, Наилнең бер аягындагы галошы юк — төшеп калган! Киттек кире борылып, галош эзләп. Ул инде чакрым ярымда ук төшеп калган булып чыкты. Шуннан ары үттем бит мин Наил дусның үзәгенә. Азрак барган саен кычкырып җибәрәм:

— Галош!

Дустым сискәнеп китә, ялт итеп аягына карый. Ә анда галошлар һәркайсы үз урынында. Бу провокация кабатлана торгач, дустымның тәмам ачуы чыга, ул мине куа башлый. Әмма бу хәлләр инде онытылгач, икенче көнне, мин тагын кычкырам:

— Галош!

Мин әнә шулай кеше үртәргә ярата торган чуар холыклы идем. Кайчак юл буйлап җай гына сөйләшеп кайтканда мин Наилнең әйткән һәр сүзен кабатлый башлыйм. Тәмам җен ачуларын чыгарганчы шулай кабатлыйм. Шунда инде ул мине куып тотып ала, яхшы гына тукмап ташлый. Тик, мин шаян, бу сабакны бик тиз онытам шул.

Нинди авырлык, җитмәүчелек булса да, без урта мәктәптә дә начар укымадык. Минем акыл укытучыларның дәрестә сөйләгәннәрен шулкадәр җиңел тотып ала, дәрес әзерләп ятуның әлләни хаҗәте дә юк иде. Ә Наил исә шул вакытта ук инде бик җитди, тырыш иде. Ул көн дә кич бик әйбәтләп дәресләрен әзерли, җавап биргәндә дә тотлыгып тормый. Без класста алдынгы укучылардан санала идек.

Ул замандагы безнең укытучылар! Бәнәнән апа, класс җитәкчебез Марзия апа, математик Госман абый, тарих укытучысы Мидхәт абый, безнең дәресләргә дә керә торган роно мөдире Абзалов абый... Олы Әтнә

кибетендә бер бөтен икмәк өчен сытыш, яньчеш, гарип итеш бара, көнозын чират торырга кирәк. Укытучыларның хезмәт хакы — символик, аңа күп булса бер айга ике пот бәрәңге сатып алып булгандыр. Ә безнең укытучылар класска һәрвакыт пөхтә, чиста киенеп, яхшы кәеф белән керәләр. Һәр сүзе үлчәмле, урынлы. Алар чын мәгънәсендә зыялы кешеләр иде.

Математик Госман абый олпат гәүдәле, зур башлы, күрер күзгә бик җитди, коры кеше. Математика — җитди фән, кайчан син аны белеп бетермәскә дә бик мөмкин. Шулай такта янына чыгып басасың, Госман абый кашларын җыерып, сиңа текәлгән. Ә син исә ык-мык... Госман абый көтеп тора дә урыныннан күтәрелеп, сиңа якын килә... Хәзер бирә, хәзер бетереп ташлый! Тик Госман абый, тагын да хәтәр итеп сиңа карап тора-тора да, һич көтмәгәндә елмаеп җибәрә.

— Утыр, «икеле» куям. Әлегә журналга төшермим, көндәлеккә генә куям. Киләсе дәрескә әйбәт әзерләнерсең, төзәтерсең! — ди ул. Һәм, чыннан да, киләсе дәрескә бик тырышып әзерләнәсең, әлеге көндәлектәге «икеле»не бетерәсең.

Олы Мәңгәрнең матур гына шигырьләр яза торган егете Вилдан Гарифҗановка икелене Госман абый кайчак журналга да куйгалый. Ул «икеле»ләрне бер-бер артлы янәшә куя да Вилданга хәбәр итә тора:

— Энем, икәү булды.

— Энем, егерме ике булды.

— Энем, ике йөз егерме ике булды инде бу!

Ә Вилданның моңа әлләни исе дә китми, бу уңайдан ул шигырь чыгара һәм тәнәфестә аны кычкырып сөйләп йөри:

Тышта көчле буран бүген,
Яфрак кадәрле кар төшә.
Яфрак кадәрле кар төшми,
Журналга «берле»ләр төшә!

Госман абый барыбер Вилданның да хәлен белә, кичектереп тора, укырга әзерләнергә мәҗбүр итә, дәрестән соң алып кала, әмма чирек ахырында Вилданга да, беркемгә дә «икеле» чыгармый иде.

Абзалов абый исә тәбәнәк буйлы, кып-кызыл йөзле, гаҗәеп терчә, түземсез кеше. Ул дәрескә кергәндә еш кына сизелер-сизелмәс кенә кызмача да була иде. Ул сине такта янына чыгара да үзе тигезләмәләр язып куя. Син инде бик тырышып чишелешне эзли башлыйсың һәм төртелеп каласың, билгеле. Абзалов абый исә синең уйлап азаплануыңны бер минут та көтеп тора алмый.

— Туган, туктале! Алай түгел бит ул! — ди, һәм сине читкә этәрә дә, такта янына үзе килеп баса. Кулындагы акбуры белән тактага шак-шок суккалап, бик кызу-кызу язып, яман ашыгып, тиз арада чишелешне чыгарып та куя.

— Менә болай була бит ул, туган. Бар, утыр, «дүртле» сиңа. Икенче юлы дәресеңне укып кил! — ди. Әмма икенче көнне инде ул синнән сорап та тормый, синең әҗәтне күптән оныткан була. Үзе зур гыйлемгә ия кеше иде Абзалов абый.

Тарихчы Мидхәт абый басынкы, юаш кеше, немец әсирлегендә булып кайткан. Дәресләргә һәрвакыт кара костюмнан, ак күлмәк, галстуктан керә. Ул үзе укыткан тарих фәнен бик тирәнтен белә, бөтен әһәмиятле вакыйгаларны, даталарны яттан әйтеп бирә ала. Мидхәт абый беркемгә дә каты бәрелми, дәресләрне бик тыныч алып бара, дәрес барышында ишекне ачып куеп, кайчак коридорда тәмәке дә көйрәтеп ала иде. Мөндеш авылыннан килеп укучы Тәлгать Мөхетдинов берчак Мидхәт абыйны артык юашка санап, басымчак итмәкче булды, ахры. Үзеннән алдагы партада утырган Зөлфирә белән кычкырып сөйләшә башлады. Мидхәт

абый бер карады моңа, икенче карады, ризасызлык белән тамагын да кырып куйды. Ә Мөхетдинов кылануын белә.

— Мөхетдинов, басыгыз!—диде шунда Мидхәт абый һәм без бөтен класс белән сискәнеп куйдык. Укытучының тавышы моңарчы без ишетмәгәнчә каты, таләпчән һәм рәсми иде.—Куликова сугышы турында сөйләгез. Тулысынча!

Мөхетдинов торып басты, йөзенә зур-зур кызыл таплар чыкты. Кайда ул сиңа тулысынча сөйләү, ике авыз сүз дә әйтә алмады егетебез.

— «Берле» куям мин сиңа, Мөхетдинов! Журналга. Һәм ул чирек азагында да чыгачак!—диде Мидхәт абый.

Бөгелеп төште Мөхетдинов: шуннан соң бер атна Мидхәт абыйга ялынып йөрде.

Марзия апа—безнең класс җитәкчесе. Зур зәңгәр күзле, мөлаем, гаҗәп сабыр холыклы Марзия апабыз класс җитәкчесе генә түгел, безнең турыда чын күңелдән кайгырта белүче киңәшчебез дә иде.

Урта мәктәпне тәмам итеп, кулыма өлгергәнлек аттестаты ала алсам, мин кайсы да булса институтка керергә исәп тота идем. Тугызынчыда укыганда ук җәй көне Казанга барып, медицина институтын таптым. Киләсе елга укырга килү хакында килешеп кайттым. Әйе, минем врач буласым килә иде. Ни өчен? Әнием күкрәк чире белән авырып, нибары 42 яшендә вафат булды. Әткәй дә гомере буена үпкә белән иза чикте. «Укып чыга алсаң, врач булырсың, менә мине дә дәваларсың»,—дип, кат-кат әйткәнен хәтерлим. Булмады! Инде унынчы классны тәмамлыйм дип йөргәндә генә, имтиханнар алдыннан әтиебез вафат булды. Әни тәрбиясендә миннән башка тагын өч бала калды. Үләре алдыннан әти миңа болай диде:

— Булмас, Радик, син инде укып йөри алмассың. Ронога барып үзеңә эш сорарсың, сине укытучы итеп куярлар. Туганнарыңны карарга әниеңә булышырсың. Ә мин... үләм инде.

Шуннан инде бер-ике көн генә яшәде.

Ул елларда, чыннан да, укытучыларга кытлык зур, урта белем белән мәктәптә балалар укытып була иде. Кулга аттестат алгач, без Наил дус белән гаризаˊлар язып, район мәгариф бүлегенә бардык. Мине үзебезнең авылдагы башлангыч мәктәпкә, ә Наилне Ары җидееллык мәктәбенә укытучы итеп билгеләделәр.

Шулай итеп, миңа мәктәптә балалар укытырга туры килде. «Туры килде» дип шуңа әйтәм, мәктәпкә эшкә килеп, тиз арада ук мин үземнең бернинди педагог түгел икәнемне, балалар укыту миңа һич кулай эш булмаганын сизеп алдым. Армия хезмәтеннән соң бу эшне ташласымны күңелемә беркетеп куйдым. Яратмаган теләсә кайсы эшне башкарырга мөмкин, әмма дә ләкин балалар укытуны түгел. Үзең ирексездән, күңел салмый эшләгәч, син бит мәктәптә балалар бозып, аларның гомерен генә рисвай итеп ятачаксың. Шуңа күрә укыту тәҗрибәм турында сөйләп тормыйм. Наил дустым шулай ук педагог булып китмәде. Ике-өч ел укытты да, Әтнәгә комсомол эшенә күчте. Ул, сабыр холыклы, тырыш, яшьтән үк җитди була белгән, яхшы күңелле кеше, үз гомерендә югары дәрәҗәләргә иреште. Комсомолга килеп күп эшләмәде, аны ВЛКСМ райкомының беренче секретаре иттеләр. Аннан соң Олы Мәңгәр авылындагы «Чулпан» колхозына рәис итеп җибәрделәр. Башта мәңгәрлеләр Наилнең яшь булуыннан чыгыптыр инде, аны «тегe шәкерт» дип кенә йөрткәннәр иде, аннан тиз арада нинди җай, шул ук вакытта булдыклы, үзләренә кулай кеше икәнен сизеп алдылар. Минем сабакташым, дустым Наил Закир улы Сабиров гомере буена шул Мәңгәрдә рәис булды. Пенсия яшына чыкканчы. Ул җитәкчелек иткән елларда колхоз танымаслык булып үзгәрде. Наил Закирович үзе орден-медальләр белән бүләкләнде, депутат, республикадагы төрле комиссияләр рәисе дә,

гомумән, республикада абруйлы кеше булды. Сәясәттә нинди үзгәрешләр булмасын, мәңгәрлеләр аны беркая да җибәрмәделәр, беркемгә дә бирмәделәр...

...Миңа солдат хезмәтенә барыр вакытлар җитте.

* * *

Хәрби хезмәт уңаеннан да мин шактый җиңел акыллылык эшләп, зур мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдым. Безне, урта белемле егетләрне, 1951 елның җәендә республика хәрби комиссариатына җыеп алдылар. Кемне кая хәрби училищеларга, офицерлыкка укырга җибәрделәр. Без, урта мәктәптә бергә укыган Олы Мәңгәр егете Таһир белән, Ульяновск шәһәрендәге танк училищесына туры килдек.

Иделнең биек яры өстендә утырган бу матур шәһәр, бу училище безгә бик ошады. Классларда, бик иркен ишегалдында безне кызыктырып, күңелгә серле ашкыну, горурлык биреп, озын пушкалы, куәтле танклар тора. Ашханәдә бик әйбәт ашаталар, без моңарчы бөтенләй күрмәгән сыр, ап-ак күмәч, компот ише әйберләр дә бирәләр. Монда укыган курсантларның киемнәре, погоннары матур... Барысы да ялт та йолт! Безгә дә инде, эшнекен генә булса да, киемнәр дә бирделәр. Ашханә кухнәсенә бәрәңге әрчергә йөрибез. Монда каласы бик килә. Шушы куәтле хәрби машиналарны йөртергә өйрәнәсе, киләчәктә офицер буласы килә!

Тик, булмады! Көтмәгәндә юлга киртә куелды. Без килеп бер атна үтте микән, училищега кайдандыр көтүе белән кып-кызыл погонлы суворовчылар килеп төште. Аларны исә училищеларга бернинди чиратсыз, имтихансыз кабул итәләр икән. Безне ишегалдына тезеп куйдылар.

— Суворовчылар килү сәбәпле, кайберәүләр безнең училищега кабул ителми! — дип игълан итте, кулына кәгазьләр тоткан ялтыр итекле офицер һәм кайтып китәргә тиешлеләрнең фамилияләрен укый башлады. Шунысы гаҗәп, артына тибелгәннәрнең барысы да диярлек татарлар иде. Моңа күбесе авылдан килгән татар егетләренең русчаны такы-токы гына белүе, сынаулар вакытында, диктант язганда бик күп хата ясаулары да сәбәпче булды бугай. Кайтып китәр алдыннан безне училище начальнигы — генерал погоны таккан, богыл чаклы бер адәм янына чакырып алдылар. Ул безгә, авылдан килгән ябык кына, юаш кына кыяфәтле егетләргә, үзенең чиркана төшүен яшермичә карап алды.

— Сезне быел көзгә үк барыбер армиягә алачаклар. Тегендә-монда киләп сарып йөрисе юк. Әнә сезгә урам аша — элемтә училищесы. Барыгыз да керегез шунда! — диде ул, кулы белән тәрәзәгә күрсәтеп.

Генерал яныннан чыккач, егетләр киңәшә, уртак фикер эзли башлаганнар иде. Мин шунда үземнең бер дә урынсызга такылдый торган телем белән һич тә кирәкмәгән сүземне әйттем:

— Һе, гомер буена телефончы булып йөрергә? Багана башларына менеп, чыбык сузып. Рәхмәт инде, монысы безгә бармый! — дидем мин, башкалар алдында үземне тапкыр итеп күрсәтәсем килеп. Адәм баласы кайчак әнә шулай кеше алдында үзен күрсәтү өчен генә һич тә уйланмаган, акылы аша үткәрелмәгән, ахмак сүзләр сөйләп ташлый. Бер-ике егетне санамаганда, бүтәннәр дә минем коткыга бирелделәр. Ә теге бер-ике егет элемтә училищесында калдылар. Анда керү сынаулары да юк иде.

Республика хәрби комиссариатында безгә тагын тәкъдим ясадылар:

— Әнә Чиләбе шәһәрендә авто-трактор училищесы бар. Тотыгыз да шунда китегез!

— Нәрсә, тракторчы булып, майга буялып йөрергә?! Кирәкми! — дидек без.

һәм бик зур хаталану эшләгәнбез. Бу ике училище һәркайсы иң беренче чиратта югары белемле, зур белгеч-инженерлар, офицерлар әзерли икән. Хәрби хезмәтне калдырып, гражданскига чыккан тәкъдирдә дә, бу һөнәрләр бик ярап куясы икән...

Дөрестән дә, безне шул көздә үк армиягә алдылар. Хәзер инде бернинди өстенлек бирмичә, Татвоенкоматның караңгы казармаларына кертеп тутырдылар. Өч көн буена кайнар ризык күрмичә, ялан сәкеләрдә урын-җирсез йоклап, шунда тереклек иттек. Ниһаять, хәбәр килде: безне каядыр Себер ягына озатачаклар икән. Менә команданы алырга Себердән кайткан мәһабәт гәүдәле, озын буйлы яшь кенә лейтенант Румянцев безне тигез сафка тезеп, казармадан Казан тимер юл вокзалына алып төшеп китте. Анда да поездны ярты көн көттек. Алай да безне терлек вагоннарында түгел, пассажир вагоннарына утыртып җибәрәселәр икән. Инде поезд килеп, вагоннарга утыра башлаган идек, лейтенант Румянцев каядыр юкка чыккан. Вокзал бетереп эзлибез тегене. Иң ерактагы караңгы бер почмакта, кечкенә генә чемоданын кочаклап, рәхәтләнеп йоклап ята. Аны уятып, аңына китереп торырга инде вакыт юк иде. Башлыгыбызны вагонга күтәреп кенә кердек. Яхшы егет булып чыкты бу Мәскәү урысы. Үзе дә юл буе баш күтәрми эчте, безгә дә бернинди күзәтчелек, комачау итмәде. Ә без барыбыз да урта белемле, моңарчы инде каядыр эшләгән, барыбыз да акчалы егетләр идек... Без, авылныкылар, ул чакта бозылмаган идек әле, аракыны бик чамалы эчтек. Әмма аның каруы үзебез моңарчы әллә нигә бер, калага баргач кына күрә торган мороженоены теттек инде! Мин аны вагон сәндерәсенә чалкын яткан көйгә, көненә унбишәрне ашадым бугай. Ул заман аның мороженоесы да гаҗәеп тәмле иде, каһәре.

И киттек без Себернең ераклыкларына! Омск, Томск, Новосибирск, хәтта Иркутскины, Байкал күленең үзен дә үтеп киттек. Бу инде кыш башы, ул якларда кар яткан, чатнама суыклар иде. Ахырда Читаны да үтеп, Шилка елгасы буендагы кечкенә генә Сретенск шәһәренә килеп җиттек. Вагоннан төшкәндә инде караңгы булган иде, Байкал артының кырык градуслы салкыны шунда ук куырып алды. Авылныкы төсле бер катлы, капка-коймалы агач йортлар, ка́р баскан тар урамнар. Тирә-якта, кап-кара болытларны хәтерләтеп, урман үскән бөкре сопкалар күтәрелеп тора. Безне хәрби шәһәрчеккә алып кайтып, бик калын таш стеналы, ике катлы казарманың түбәнге катына керттеләр. Белдек: бу казармаларны әби патша заманында ук салганнар икән. Ә без үзебез аерым сапер батальоны сугышчылары икәнбез. Ягъни мәсәлән, сугышның шахтерлары, җир казучылары, күперләр сугып, офицерлар өчен блиндажлар салып йөрүче балта осталары, юлларга мина куючылары. Менә сиңа — элемтәче яисә шофер буласың килмәсә!

Безне икенче көнне үк мунча керттеләр. Мунчаның бер башыннан үзебезнең киемнәрне салып кердек, икенче башыннан инде солдат киемнәре киеп, солдат булып чыктык. Барыбыз да шинель, кирза итек, бер төсле бүрек киеп, иңбашларына аркылы-торкылы көрәк белән кирка рәсеме төшерелгән кара погоннар да тагып алгач, гаҗәеп дәрәҗәдә бер-беребезгә охшап калдык. Казармада безгә урын-җир бирделәр, ике катлы аслы-өсле тимер караватларга урнаштык.

Солдат хезмәте, шәхсән, минем өчен уңышсыз башланды. Икенче көнне үк иртән одеал астында җылынып, тәмле төшләр күреп йоклап ята идем, көчле-хәтәр тавыш белән «Подъем!» — дип акырып җибәрделәр. Әле генә тын казарма шунда ук хәрәкәткә килде. Солдатлар урыннарыннан сикереп торып, яман ашыгып, киенә башладылар. Әнә, безнең взвод инде киенеп сафка да басты, ә мин һаман әле аякка итек киюгә килеп җитә алганым юк. Шулай итеп, взвод минс байтак көтеп торды, физзарядкага бүтәннәрдән соңга калып чыкты.

Безнең взвод командиры украинлы сержант Брейнич гаҗәеп тә дәрәҗә ярата торган бер бәндә булып чыкты. Ул безне сафка тезеп, казарма

янындагы мәйданда марш атлатып йөрткәндә ничек команда биреп, ничек кычкырганын, көязләнгәнен күрсәң! Әгәр дә шунда якындагы торак йортлардан берәр офицер хатыны яисә кызы килеп чыкса, ул вакытта бетте инде... Безнең сержантыбыз тәмам ата казның үзенә әйләнә. Гәүдәсен уклау йоткандай гайре табигый итеп турайта, башындагы бүркен төшеп китәрлек итеп кырын сала, үзе сафның әле бер ягына, әле икенче ягына чыга. Ни эшләргә, әлеге хатын-кызның игътибарын үзенә ничек җәлеп итәргә белми.

Каныкты бит шушы сержант Брейнич миңа. Мин иртән әле һаман да өлгермим. Взводның данын артка сөйрәп, командирның дәрәҗәсен төшерүемне үзем дә беләм дә бит... Брейнич көн саен диярлек чираттан тыш нәрәт ябыштыра үземә. Бүтәннәр рәхәтләнеп ял иткәндә мин идән себерәм, тәрәзә рамнарын сөртәм. Ә иртәгесен зарядкага басарга тагын өлгермим... Сержант мине рота командиры капитан Громга әләкләгән.

Капитан Гром безне фортификация, миналар кую һәм алу эше сугыш әмәлләренә өйрәтә. Кып-кызыл юка йөзле, үзе дә юка гына, әмма бик әйбәт күңелле кеше. Ул класска еш, бик еш тагын да кызарып керә... Ярый, алар сержант Брейнич белән көпә-көндез мине казармага алып керделәр. Капитан үзенең кул сәгатенә карады да миңа кискен итеп команда бирде: «Отбой!» Мин үзем булдыра алганча җәһәт чишенеп, караватка яттым. Шунда ук яңа әмер: «Подъем!» Мин инде җан-фәрманга киенәм. Берничә кат эшләтте капитан миңа бу әкәмәтне.

— Әйе, өлгермисең икән син, рядовой Фаизов! — диде ул ахырында миңа, бернинди шелтәсез һәм шунда торган сержантка карады.— Беләсеңме, сержант Брейнич, син инде бу егетне ашыктырма. Син зарядкага аны көтеп торма, ул үз җае белән чыгып басар. Минем иң алдынгы укучым ул, әйбәт егет ул! — диде капитан көлеп һәм минем аркамнан кагып алды. Күзләремә атылып яшьләр чыкты шунда.

Тора-бара бу сержант Брейнич бөтен взводның нәфрәтен уятты. Һәм без аны кызык итәргә булдык. Менә бер иртәдә безне тренажга алып чыгып, мәйданга тезеп куйды бу. Ягъни, без җиргә ятып, мылтык төбәргә өйрәнергә тиеш. Ә җир, дөресе ком, бик дымлы, әле генә яңгыр явып үткән. Һәм сержант бугазын ярды:

— Ложись!

Шунда армиядә бөтенләй булырга тиеш булмаган, күрелмәгән, ишетелмәгән хәл килеп чыкты. Беркем ятмады, саф селкенмәде дә хәтта. Сержант, үз күзләренә үзе ышанмагандай, безгә текәлеп, беразга тынып торды. Аннан инде кызарынды-бүртенде, тәмам ярылырдай булып акыра башлады:

— Ложись! Ложись!

Ник бер хәрәкәт булсын. Взвод тораташ булган да каткан. Брейничның күзләре маңгаена сикерде. Нәрсә бу?! Хәрби приказны үтәмәү! Моның өчен бит сугыш вакытында баскан төштә атканнар. Әле хәзер дә — трибунал, зур сроклы төрмә. Үтәмәү коллектив рәвештә булса да, барыбер — һәркемгә төрмә.

Болай булдыра алмагач, сержант безгә икенче әмер бирде:

— Направо! Бегом марш!

Саф сулга борылды, әмма алга таба чабып китмәде. Саф башындагы солдат, Түбән Көек авылыннан бик озын буйлы Равил Хәйретдинов, хәйләкәр түгел диген, аягын бик югары күтәрә дә, бер карыш алга китмичә, шул урында ук дөпелдәтеп җиргә төшерә. Аннан үрнәк алып башкалар да. Кызык килеп чыга, бер карасаң взвод йөгерә дә кебек, аякларын дөпелдәтә, әмма алга бармый, бер урында таптанып тик тора. Сержантыбызның инде тавышы елак, ялынулы:

— Бегом, бегом!..

Шунда безне сискәндереп, капитан Гром тавышы ишетелде:

— Сержант Брейнич, отставить!

Иртән өеннән чыгып казармалар ягына килгән капитан бу хәлне күреп, читтән күзәтеп торган икән. Сержант атылып аның янына килде.

— Иптәш капитан, батальон тарихында булмаган хәл... Болар хәрби антны боздылар. Болар приказны үтәмәделәр... Мин бу хәлне часть командирына җиткерәчәкмен. Барысын да трибуналга, судка!

— Судка кирәкми, сержант. Пожалуйста, бу эшне син минем үземә генә калдыр. Әләкләп тә йөрмә, үзеңне көлкегә калдырма. Мин үзем хәл итәрмен...— диде капитан.

Капитан Гром безне тиргәмәде, бер сүз дә әйтмәде, хәтта йөзендәге елмаюы да сүнмәде. Иртәнге чәйдән соң ул взводны үзе тезеп куйды да Шилка елгасы буена алып төште. Анда бала башы чаклы түгәрәк ташлар ята иде. Капитан солдат биштәрләренә шушы ташларны тутырырга кушты, һәркемнең ташлы биштәрен үзе күтәреп, тикшереп чыкты. Без аркаларга авыр биштәрләр астык, муенга ат камыты кебек итеп бәйләнгән шинельне киеп куйдык, бил каешына сапер көрәге эләктердек, кулга мылтык алдык — тулы хәрби әзерлеккә килдек. Шул әзерлектә сафка тезелдек.

— Ә-ә-нә теге биеклекне күрәсезме? — диде капитан, кулындагы чыбыгы белән моннан өч-дүрт чакрымдагы сопкага күрсәтеп.— Сезнең бурыч — сопканы атакалау. Алга, Суворов батырлары! Короткими перебежками!

Солдатта булган кеше тулы хәрби йөк белән короткими перебежками, ягъни бер ятып, бер сикереп торып йөгерә-йөгерә алга баруның нәрсә икәнен бик яхшы белә. Аллам күрсәтмәсен! Без утыз-кырык адым йөгереп киләбез дә, гөрселдәп җиргә егылабыз. Биштәрдәге ташлар арканы дөмбәсли, шинель-камыт муенны кыса, кырып авырттыра, кулдагы мылтык терсәккә, тезбашларына бәрә... Җитмәсә өстән рәхимсез рәвештә кояш кыздыра. Яман эссе, күзләрне маңгайдан аккан тир ачыттыра, авыз-борыннарга тузан тула... Син килеп егылышка янәшәдәге иптәшең күтәрелә, аннан икенчесе, өченчесе. Аз гына алырга өлгермисең, нәүбәт тагын сиңа җитә... Ә капитан Гром акрын гына безнең уртадан бара. Чыбыгы белән ялтыр итегенә суккалый, авыз эченнән ниндидер көй сызгыра.

Теге сопка итәгенә кадәр беребез дә, хәтта арабыздан иң гайрәтлебез Равил Хәйретдинов үзе дә барып җитә алмады. Тәмам хәлдән таеп, инде атсаң да алга бара алмас хәлгә килеп, җиргә егылдык. Ятабыз Байкал арты чирәмендә таралышып, усал Себер кырмыскаларының тешләвенә түзеп. Капитан безгә шактый вакыт ял бирде, безгә комачау итми генә бер кырыйда тәмәке тартып утырды. Аннан Шилка ярына кире алып төште. Биштәрләрдән теге имансыз ташларны бушаттык, рәхәтләнеп су коендык, чистарындык. Аннан соң гына капитан безне сафка тезеп куйды.

— Ну, бөркетләр, ничек ул?.. Моннан ары хәрби приказны үтәрсезме? — диде ул елмаеп.

Без барыбыз беравыздан, бөтен тирә-якны яңгыратып кычкырып җибәрдек:

— Так точно, иптәш капитан. Үтәрбез!

Аннан соң да әле капитан безне казармага алып кайтмады. Болынга алып чыкты да, көтүне тараткандай, безне таратып җибәрде. Байкал артында кыш бик салкын, ә менә җәй эссе була. Үләннәр әйбәт үсә, төрле җиләк-җимеш бик уңган.

— Һәркемнән бер пилотка җиләк! — дип боерды капитан.

Тиз арада пилоткаларны тутырдык. Капитан белән бергә түгәрәкләнеп, җиләк ашадык. Капитан Гром кырыс, әмма гадел, әйбәт күңелле кеше иде.

Мин, гомумән, армиядә бөтен устав таләпләрен үтәп, яхшы солдат булып хезмәт итә алмадым. Төрле хәлләргә тарыдым. Берчак үземне гауптвахтага ябылганнарны сакларга куйдылар. Кыш көне иде бу. Тоткыннарга рәхәт, алар эчтә, җылыда. Ә мин исә тышта, утыз градуслы

салкында, кулыма мылтыгымны тотып басып торам. Бу юлы солдат төрмәсенә пешекчеләр эләккән икән. Пешекче халкы беркайда да югалмый бит ул, төш вакытында иптәшләре тегеләргә ашханәдән бер бачок итле ботка алып килделәр.

— Әй, солдат! Торма анда ишек төбендә катып. Кер монда, аша кайнар ботка!—диде миңа пешекчеләрнең берсе. Мин, югыйсә, устав буенча алар белән сөйләшергә дә тиешле түгел. Әмма... ботканың исе бик тәмле иде шул... Тәвәккәлләп кердем дә киттем. Мылтыгымны ишек төбенә сөяп куйдым да, тоткыннарым белән бергә утырып, рәхәтләнеп ботка ашадым. Әгәр дә бу хәлне берәр начальник күреп алган булса...

Әмма эш моның белән генә дә бетмәде әле. Казармада без аскы катта, ә өстә артиллеристлар тора иде. Утыручыларның берсе шул артиллеристлардан булып чыкты. Мине таный, хәтта исемемне дә белә икән. Шул миннән үтенде:

— Казармага кайтып, минем матрацны гына алып килик әле, Радик. Юкса, аска бит каты икән монда,—диде ул.

Монысы да уставка һич сыя торган эш түгел. Әмма дә мин... мин кеше үтенеченә каршы килә аламмы соң? Киттек казармага. Теге алдан атлап, мин артыннан мылтык төбәп. Баскыч төбенә генә җиткән идек, минем ашыгыч рәвештә туалетка барасым килде. Ни эшләргә? Мин күп уйлап тормадым, мылтыгымны тоткынга тоттырдым да, үзем якындагы туалетка йөгердем. Кире килсәм... алланың рәхмәте! Баскычтан безнең батальон командиры майор Сулоев үзе төшеп килә. Ул карчыга күзләре белән бер генә карады да, хәлне шунда ук төшенеп алды.

— Рядовой Фаизов!

— Так точно, иптәш майор.

— Монда кем кемне саклый әле? Яле, әйтеп бир әле шуны?—диде ул, минем мылтыкны тоткан артиллеристка күрсәтеп.

Мин коелып төштем. Хәзер бетерә. Төрмә, һич югында ун көнлек гауптвахта миңа... Майор Сулоев бик таләпчән, гайрәтле, коры кеше. Үзе майор булса да, аның буйсынуында ике подполковник эшли. Майор үзенең чәнечкеле күзләре белән миңа текәлеп торды-торды да, һич көтмәгәндә көлеп җибәрде.

— Йә, Фаизов, нәрсә аласың инде синнән? Үзең әйбәт егет син. Шуңа гына бер юлга гафу итәм,—диде ул һәм китәргә рөхсәт икәнен белдереп, кулын селтәде.

Хәзергә кадәр шунысын аңлый алмыйм, батальондагы йөзләгән солдат арасыннан аерып майор мине ничек белде дә, бөтен устав таләпләрен бозып, ничек гафу итә алды икән?

Армиядә бөтен командирлар да һич тә болай түгел, араларында бик имансызлары, юньсезләре дә бар иде. Батальонның комсомол җыелышы бара. «Әгәр дә империалистлар яңадан да сугыш башласалар...» дигән мәсьәләне тикшерәләр. Бу көн тәртибе буенча чыгышлар башланды. Шунда учебная рота курсанты Калмыков урыныннан торды.

— Әгәр дә дошманнар сугыш башлыйлар икән, минем беренче пулям менә моңа!—диде ул һәм ротаның старшинасы, украинлы Дзыкка төртеп күрсәтте. Колгадай озын буйлы, нәзек гәүдәле старшинаның киң йөзенә аклы-кызыллы таплар чыкты. Инде кызып киткән Калмыков тагын кабатлады.—Иң беренче эшем итеп мин менә шушы хәшәрәтне атып үтерәчәкмен!

Иркен Ленин бүлмәсендә утырган йөзләгән кеше, солдатлар, старшиналар, офицерлар тып-тын булдылар. Бар халык аптырап бер-берсенә карап алды. Шунда арттагы рәтләрдән тагын ишетелде:

— Карагыз аны... Дзыкны безнең белән бергә демоблизовать итмәгез. Безнең белән бергә кайтса, без аны вагоннан тотып ташлаячакбыз!

Моны Украинаның Донбасс шахталары егетләре әйтте. Алар исә уйнап сөйләшми. Инде хезмәт сроклары тулгач, башкалар кайтып киткәч тә, старшина батальонда дүрт ай чамасы көтеп ятты. Ул үзенең акыры-

ну-җикеренүләре, бер дә хаксызга бәйләнүләре, чираттан тыш нарядлары белән сержантларның, солдатларның үзәгенә шулкадәр үткән иде ки, аны хәл итеп ташлаулары бик ихтимал иде.

Сапер — сугышның шахтеры, җир казучысы, иң авыр, хәтәр эшләрен башкаручысы. Аны шуңа әзерлиләр.

Кара көз, инде Байкал артының усал кышы куәт алып ята. Шилка елгасының сөзәк яры. Хәрби өйрәнүләр бара. Теге яктагы биек ярда «дошман». Без, саперлар, ажгырып аккан киң Шилка аша понтон күпере салырга тиеш. Ул күпердән полкның удар көчләре — танклар чыгып китәчәк. Суга тигәч үзләреннән-үзләре ачылып китә торган гаять зур, иләмсез авыр понтон-көймәләрне, егермешәр кеше күтәреп, елгага төшердек. Әмма бит аларны елгада бер-берсенә беркетергә, ә моның өчен муеннан диярлек суга керергә кирәк. Шушы боздай салкын, шаулап аккан суга. Без, котлар очып, су буенда бөрешеп калдык. Шунда ажгырып безгә таныш булмаган бер капитан килеп җитте.

— Хәзер үк суга! Сикер суга! Мать твою!..— дип кычкырды ул һәм якаларыбыздан алып, безне берәм-берәм суга элеп атты.

Бу кадәр салкын суда муеннан торып эшләүнең нәрсә икәнен шул суда торган кеше генә белә. Аны бүтәннәргә сөйләп аңлатып булмый.

Ничек салкын тимәде безгә, ничек эчке әгъзаларыбыз бөрешеп, эштән чыгып, гомергә сырхаулы булып калмады? Кайгырмагыз! Бозлы судан тартып алуга, безләрне шунда ук командирлар блиндажы салырга куйдылар. Шул инде туңган, ташлы ярдагы җирне казып кереп блиндаж салырга. Гәрчә безнең карамакта әллә никадәр шартлаткыч булса да, берниндн шартлату эшләре юк. Блиндаж астына гаять зур чокырны кул белән, ягъни көрәк, кирка белән казырга! Җирне шартлатып казысаң, теге ярдагы «дошман»ның ишетүе, исәпкә алып куюы бар. Монда инде хет утыз градуслы салкында бер минут эчендә тирләп чыгасың. Бушлатлар, бүрекләр дә бер якка оча. Син җиң сызганып, таштай каты җирне чокыйсың. Тизрәк, җәтрәк!

Менә чокыр әзер булды, блиндаж сала башладык. Менә дигән нарат бүрәнәләрдән, өстенә дә өч кат бүрәнә-накат җәеп, стеналарын, тәрәзәсен, идәнен эшләп, хәтта сәкесенә кадәр җәеп. Күмәк көч тау күтәрә. Без әлләни арада гына блиндажны салып та куйдык. Ишегеннән җил үтә торган түгел, эче җылы, биек, якты, тәмле сагыз исе аңкып тора. Керәсе дә, кайнар чәй йоткалап, рәхәтләнеп утырасы гына. Юк! Без үз эшебезгә үзебез сокланып бетә алмадык, яңа әмер яңгырады.

— Командирлар блиндажын шартлатырга! Юк итәргә! Дошман һөҗүмгә күчте.

Менә сиңа мә! Без, каралты-кураның ямен, кадерен белеп үскән авыл малайлары, беребезнең дә шушы күкрәп утырган яңа йортның көлен күккә очырырга кулы күтәрелми иде. Әмма хәрби приказ аяусыз:

— Тиешле урыннарга тол куярга! Шартлаткычлар. Үзегез тиешле арада читкә китәргә. Җәтрәк!

Әйе, без төзергә генә түгел, җимерергә, юк итәргә дә өйрәтелгән шул. Шартлаткычны блиндаж, каралты-кура, күпер, машина, паровоз һәм башка теләсә нәрсәнең кай җиренә урнаштырырга, ничек шартлатырга икәнен беләбез. Кирәк икән, утырасы эскәмияңне, өстәл өстеннән кулыңа аласы каләм сабын миналыйбыз. Каләм сабына килеп кагыласың һәм... көлең күккә оча! Ике минуттан яңа салынган блиндажның да көле күккә очты. Утлы такталары, бүрәнә башлары сызгырып болытларга кадәр күтәрелде.

Белмим, хәзер ничектер, ул заманда Совет армиясендә мәгънәсезгә юк итү — искитәрлек иде. Әйтик, безнең батальон солдатлары җәенкышын урман кисәләр. Менә дигән, шыңгырдап торган бүрәнәләрне частька ташыйлар. Такта итеп яралар. Аннан Байкал артының кайбер урыннары мәңгелек туң булган каты җирен казып кереп, хәзер үк кеше яшәрлек блиндажлар, коры елгалар өстенә күперләр салалар.

Куперләрне дә соңгы кадагына кадәр кагып, култыксаларын шомартып сугып куябыз. Ә аннары... үзегез беләсез инде. Күз ачып йомганчы аларның көле күккә оча, җирләр генә дерелдәп кала. Әйтерсең, бу вәхшәттән куркып калтырана. Ул кадәрле хезмәт һәм материаллар нигә әрәм ителде икән? Ул блиндажларны, куперләрне тирә-яктагы колхоз-совхозлар өчен дә төзергә була иде бит. Бервакыт коры елга өстенә салынган куперне колхоз рәисе килеп сорады. Солдатларга, хәрби частька ит, сөт бирер идем, дип ялынды. Бирмәделәр. Бичара рәиснең күз алдында көлен күккә очырдылар. Бу кадәр мәгънәсезлек нәрсәгә эшләнгәндер? Шартлатырга өйрәтәм дисәң, аңа иске куперләр дә җитәрлек бит.

Армиядә хезмәт иткәндә үзәккә үткән тагын бер нәрсә — барганнан кайтканчы ашарга җитмәде. Хәтта минем кебек чандыр гына, кечкенә тамаклы егетләргә дә. Бернинди сөт ясә сөт әйберләре юк. Кәбестә дә, ботка, да кәбестә. Кичке аш бигрәк аз: ике кашык кәбестә боткасы, ике шакмак шикәр һәм кечкенә генә бер телем кара ипи. Ул заманда солдатка, хәтерем ялгышмаса, аена ун сум акча түләделәр. Аның да җиде сумын заемга яздырып алып калалар. Кулга — өч тәңкә. Шәһәргә увольнениегә чыккач, без шул өч сумга конверт, теш пастасы, ислемай ише әйберләр сатып алабыз. Ә кайбер егетләр алай итмиләр... Ябынчы авылыннан Мидхәт Габдрахманов — калын җилкәле, озын буйлы чибәр егет — шәһәргә чыккан саен ике булка сатып ала. Аулак бер җиргә утыра да, шуларны рәхәтләнеп суга.

Боларны укыгач, сездә, Татарстаннан килгән урта белемле егетләр армиядә начар хезмәт иткәннәр икән, дигән тәэсир калмасын тагын. Хәрби һәм политик әзерлек буенча безнең взвод батальонга үрнәк булды.

* * *

Армиядән мин, ашказаным авыру булу сәбәпле, үземнең иптәшләремнән бер-ике айга алдан кайтып киттем. Бу — 1953 елның язы иде. Илебезне канлы диктатордан азат иткән, шуның белән бөтен Себерне диярлек үзәккә, Европага, җылы көньякка кубарган яз! Март аенда Сталин вафат булды. Шул уңайдан илдәге хисапсыз төрмәләрдә, лагерьларда утырган уголовный тоткыннарга зур амнистия игълан ителде. Себер киңлекләрендә, Байкал арты салкыннарында дистәләгән еллар буена иза чиккән тоткыннар иреккә чыгып, үзәккә агылдылар. Ул пассажир поездларында — мәхшәр! Мин үземә тиешле вагонга кердем. Күрәм, иң әйбәт урыннарда бар да тоткыннар. Безгә, мондый кешеләргә, яндагы урыннар гына калган. Ә плацкартларда сиңа текәлеп карап та, сине күрмәүче, әллә нинди чирканыч карашлы күзләр, авызлары мәкерле төстә ямьсез чалшайган, аракыдан кызарынган-бүртенгән оятсыз йөзләр. Тоткыннарга лагерь һәм зоналардан чыкканда акча да биргәннәр, күрәсең. Вагондагы һәр өстәл өстендә аракы шешәләре, пешкән ит, ипи. Бөтен вагон дөньясын онытып бәйрәм итә. Әледән-әле исерек тавыш белән бирелгән әмерләр ишетелә:

— Әй, кондуктор! Безгә аракы китер!

— Пешкән тавык!

— Колбаса китер!

Өлкән яшьтәге кондуктор, бер хезмәтче малай кебек, вагон-ресторанга йөгерә. Чөнки монда акчаны беркем дә санап бирми, кондукторның кулына төргәге белән генә ташлыйлар. Ул иркенләп кесә калынайта, билгеле.

Исәп-хисапсыз тотылган акча, мәгълүм инде, әлләни озакка бармый, бетеп тә китә. Тиз арада тоткыннар бер тиенсез калдылар. Шунда инде алар вагондагы кешеләрне талый, бер-берсенә һөҗүм итә, сугыша, чәнчешә, үтерешә үк башладылар. Станцияләрдә, күрәсең, әле теге, әле бу

вагоннан милиция егетләре кулларын артка куеп бәйләгән кешеләрне алып чыга. Бу инде токтыннарның әле генә үзләре чыгып киткән лагерьларына кире әйләнеп кайтып барышлары... Ай алла, бу адәм баласының табигате, ул кылган гамәлләр! Бармакка чорнарлык та акыл юк бит бу адәм балаларында.

Карымское станциясендә торабыз. Инде кара кич, вакыт соң. Шунда станция читендәге куаклар арасыннан куркынган, ачы тавышлы аваз ишетелде. Йөгерешеп шунда барсак, җирдә бер яшь старшина аунап ята. Янәшәсендә кан, мескен егет инде үлгән дә. Кунакка, туган иленә кайтып барышы икән. Аның ниндидер бер хатын-кыз белән куаклар арасына кереп киткәнен иптәшләре күреп калган булган. Тиз арада теге хатынны тотып китерделәр, аның куак астына ташлаган канлы пычагын табып алдылар. Бичара старшинаның күпмедер акчасы булган, бу хатын аны сизеп алган икән. Менә сиңа финал...

Солдатлар теге хатынны итекләре белән туп урынына типкәли, кыйный башладылар. Милиция килеп аралап алганда ул хатынның карарлыгы калмаган иде инде.

Вагонда мин әле Иркутскига җиткәнче үк шундый токтыннарның берсе, казах егете Ильяс белән дуслашырга өлгердем. Ильяс минем кордаш диярлек, япь-яшь үсмер вакытында ул колхоз сарыгын урлап суйган өчен ун елга хөкем ителгән булган, шуның алты елын инде утырып та өлгергән. Менә хәзер амнистиягә эләгеп, өенә кайтып бара.

Иркутскида поездлар алмашына, бер тәүлек чамасы вокзалда көтеп утырырга туры килә. Ильясның кесәсендә ун мең сум чамасы акча бар иде. Айлык хезмәт хакы 700—800 сумнан артмаган ул заманда шактый зур сумма иде бу. Без шәһәр кибетләренә чыгып, Ильяска әйбәт кенә костюм, җәйге пальто, аягына ботинка алдык. Бер ресторанга кереп, боларны тыйнак кына итеп «юдык». Аннары тагын вокзалга кайтып утырдык. Биредәге халык барысы да диярлек шул амнистия белән кайтып баручылар иде. Алланың рәхмәте, кич булып караңгы төшүгә бу халык нигәдер бик тынычсызлана, кыбырсына башлады. Алар тыз-быз йөренделәр дә, инде утлар алынгач, барысы да каядыр шәһәргә таралышып беттеләр. Минем Ильясым да алар артыннан талпына башлады. Мин чын-чынлап куркуга төштем. Баланың өс-баш та яңа, кесәсендә байтак акчасы да калды бит әле.

— Йөрмә, утыр шушында гына. Чишендерерләр, акчаңны да алып калырлар...— мин әйтәм.

— Минеме? Минме?! Теләсә кайсын өркетәм бит мин аларның!— дип шәбәйде бу.

— Алайса, акчаңны гына булса да миндә калдыр. Мин бит инде сиңа карак-угры түгел. Акчаңны алып качмам,— дидем мин.

Кая ул! Минем бу үгет сүзләремә җавап итеп, Ильяс куйныннан бизәкле саплы пычагын гына чыгарып күрсәтте. Аны талау түгел, әгәр дә тели икән, ул үзе башкаларны шүрләтә, янәсе.

— Хәзер әйләнеп кайтам мин. Миңа да бер шәһәр карарга кирәк бит инде... Син бер дә борчылма!— диде ул.

Ярый, чыгып китте бу кичке сәяхәткә. Бер сәгать үтте, ике сәгать. Мин көтәм. Инде төн уртасы да узды, юк Ильяс. Таң алдыннан кайтып керде бу. Өстендә — изүе аерылып төшкән керле күлмәк, калҗаеп беткән иске солдат шинеле, аякта — тишек ботинка. Уң кулы беләзегеннән ак чүпрәк белән бәйләп куелган, аннан кан саркып тора. Кесәдәге акчалардан җилләр искән. Сөйли: шәһәр уртасындагы Ангара елгасы күпере өстендә тотып алалар моны. Кесәләрне әйләндереп салырга, өстәге яңа костюмны, пальтоны чишенеп бирергә боералар. Үзе кебек үк утырып чыкканнар! Бу риза түгел, кесәдән пычагын тартып чыгара... Ул тәкъдирдә моның беләгеннән эләктереп алалар да, анда тамга салалар. Өс-башын, акчасын талап, яхшы гына итеп артына тибәләр. Ярый әле,

кайсыдыр миһербанлы була, салдырып алган пальто өчен моңа әнә шул шинельне ташлый.

Яхшы «йөк» булды бу батыр Ильяс миңа. Үзем дә барлы-юклы акчага, солдат паегына калган кеше, мин тагын Иркутскидан алып Курганга кадәр Ильясның да тамагын туйдырып кайттым. Дөрес, кечедән төрмәдә утырып чаларган Ильяс, калын гына битле, таза, базык гәүдәле бу казах баласы, тамак туйдыруның тагын бер әмәлен тапты. Ул заманда бит Кытай Халык Республикасы белән дуслык бик яхшы, зур Себер тимер юлы «Халыклар дуслыгы юлы» дип атала иде. Ә бу исә буш сүз генә түгел, аның реаль, матди яклары да бар. Юл буе зур вокзаллар рестораннарына аш-суны, беренче һәм икенче блюдоларны ресторан уртасындагы бик дәү, озын өстәл өстенә чыгарып әзер итеп, өстенә ашъяулык ябып куялар. Кеше ресторанга керә, үзенә кирәкне шул өстәлдән алып кына ашый да, соңыннан официант белән исәп-хисабын ясый. Бик ансат һәм культуралы. Бу инде, чыннан да, совет кешеләренең югары культуралы, әдәпле, намуслы булуына, аларга тулы ышаныч белдерелүгә ишарә ясаган гамәл. Һәм, бик ихтимал, совет кешеләренең зур күпчелеге әлеге ишарәне аклаганнардыр да. Әмма, гөнаһ шомлыгына димме, алар арасында Ильяс кеби сарык каракклары, өтермәдә утырып чыкканнар да җитәрлек иде шул. Ә ул мәлгунь, карагыз әле, нишли? Минем чиста солдат гимнастеркасын киеп, ваемсыз гына кыяфәттә ресторанга керә. Бер дә ашыкмый гына, кесәсендә акчасы булган кеше гамәле белән, беренче һәм икенче ашларны ала. Шактый күренекле урынга утыра. Әмма ул икенче ашны бер вакытта да тәмам ашап бетерми. Ашаудан бүленеп, буфетка барып, үзенә папирос сайлаган була һәм... шунда чираттагы кешеләр арасына буталып, җәлт кенә ишектән чыгып тая.

Шулай итеп, казах баласы Ильяс зур шәһәрләрдә шактый тамак ялгады. Курганга килеп җиткәч, без аерылдык. Ильяс үзенең киң, иркен далаларына юл алды. Миңа бик күп рәхмәтләр укып, муеныма сарылып, елап аерылды ул.

Ә бит казах баласының бу алдынгы «тәҗрибәсе» татар улына да бик ярап куйды. Чиләбегә кайтып җиттем. Шунда минем Магнитогорск шәһәрендә яшәп яткан бертуган абыем Фаяз янына керәсем килә башлады. Абыйны күрәсе дә килә, матди ярдәмгә дә өмет зур гына иде. Ә минем солдат билеты — Чиләбедән туп-туры Казанга гына. Бәс, билетта күрсәтелгән икән, син инде ул юлдан бер карыш тайпыла алмыйсың. Ә Магнитогорскига кадәр билет алырга миндә акча юк.

— Мин сиңа бу очракта бернинди ярдәм күрсәтә алмыйм. Ә син бит солдат. Күрсәт тапкырлыгың! — диде хәрби комендант, ярдәм сорап килгәч.

Һәм мин андый тапкырлыкны күрсәттем. Перронда Магнитогорск поезды тора, кеше дә күп түгел. Өлкән яшьтәге бер апа, әллә ничә төргәк әйберләре, ике зур чемодан бар. Мин тәвәккәлләп апа янына килдем.

— Рөхсәт итегез! — дидем һәм ике кулыма ике чемоданны күтәреп тә алдым. Минем беркатлы, юаш, бернинди зыянсыз бер ходай бәндәсе булуым йөземә үк язылган, күрәсең. Беркем дә, беркайчан да миннән шикләнү белдерми. Бик затлы чемоданнарның иясе бу апа да куанулы елмайды гына. Эшне озакка сузмый вагонга атладым. Баскыч төбендәге кондуктор мине туктатты:

— Сезнең билетыгыз?

— Озата керүчеләр без! — дип кенә җибәрдем мин һәм кондуктор юл бирде. Ә вагонга кергәч, теге апаның чемоданнарын урнаштырырга булыштым да, үзем шунда ук исереккә сабыштым. Күзләремне тондырып, бераз алпан-тилпән йөренгәч, әйберләр куя торган иң өстәге сәндерәгә менеп яттым. Сәндерәгә яттым һәм... әле генә батыр солдатны шунда ук куян куркуы тотып алды. Менә хәзер кондуктор сине хәтерләп, эшеңне сизеп алса?.. Бөтен халык алдында рисвай итеп, вагоннан куып төшерсә? Җан атып поездның тизрәк кузгалып китүен көтеп ятам. Ай

аллам, менә тәгәрмәчләр җайлап кына гөжелди башлады. Әмма шунда ук минем бөтен аркам такта кебек булып катты. Күз кырые белән генә күреп алдым, кондуктор, яшь кенә, усал гына кыяфәтле, әмма бик чибәр хатын, билетлар барлый иде. Үрелеп минем кабыргага да төртте. Җилле генә итеп.

— Бер исерек солдат ул. Йоклый,— диделәр аңа.

Бераздан мин, дөрестән дә, йоклап киткәнмен. Кондуктор килеп яңадан минем кабыргама төртте.

— Хәзер үк моннан төш тә, минем купега кереп утыр. Билет тикшерүчеләр килә... Поездда куып төшерәчәкләр үзеңне. Мин синең билетсыз икәнеңне башта ук белдем бит, камыр батыр! — диде әлеге чибәр хатын. Миһербанлы да икән үзе. Ул мине — билетсыз шантрапаны, хәзер якасыннан алып селти торган ревизорлардан купесында яшереп калды. Аннары чәй өлгертте, без юл буе сөйләшеп бардык.

Мин Фаяз абый янында бер атна кунак булдым. Магнитогорск шәһәрен, андагы гигант металлургия комбинатын, зур заводларны, Урал суының уң ягына әле ул заманда төзелә генә башлаган яңа шәһәрне карадым. Ул вакытта шушы шәһәргә тагын килеп урнашырмын, бирегә тугыз ел гомерем үтәр, балаларым булыр дип, һич тә башыма килмәгән иде... Кайтканда Фаяз абый миңа юлга җитәрлек акча бирде.

Минем солдат хезмәтем шуның белән тәмам булды. Теге батыр солдат Швейк хезмәтенә азрак охшый инде ул, әмма ни хәл итәсең. Язмыш!

* * *

Армиядән соң инде укытучы булырга теләмәдем. Ичмасам, шуңа акылым җитте. Урта белем белән, дөресен әйтим, колхозда калып, ат җигәсем яисә дуңгызлар тәрбиялисем дә килми иде. Һәм минем өчен төрле тарафка бәргәләнү, зимагурлыкта йөрү, зур хаталар һәм акылсызлыклар ясау чоры башланып китте.

Кеше, бәхетле булыйм дисә, әти-әнисе булган тигез гаиләдә үссен. Чөнки ул инде үзе җиткән егет булгач та, хәтта өйләнеп үзе гаилә корып җибәргәч тә, кемнеңдер түгел, нәкъ менә әти-әнисенең киңәшенә, үгет-фатихасына мохтаҗ. Хәтта кайчакны каты тиргәү сүзенә дә. Инде әти-әнинең исән булу-булмавы синнән тормый дисәң, ул чакта язмышыңа үпкәлисең. Ул тәкъдирдә син — бәхетсез кеше. Чөнки читләр, үзең якын дус санаган кешеләр дә, бервакытта да сиңа юньле, төпле киңәш бирә алмыйлар. Синең турыңда чын күңелдән кайгыртмыйлар. Болай гына, сүз булсынга гына сөйләнәләр.

Әүвәле мин Олы Әтнәдәге саклык кассасына инспектор булып урнаштым. Аның мөдире, Мөхәм абый Корбанов, базык гәүдәле, салмак, җай гына сөйләшә торган кеше, мине җылы каршылады.

— Мин синең әтиең Хәбибрахман абыйны бик яхшы беләм. Әйбәт кеше иде, мәрхүм. Тырышып эшләсәң, тора-бара менә минем урынымда калырсың. Инспектор — киләчәктә мөдир булырга тиеш кеше инде ул,— диде ул миңа.

Контролер, сугышта бер аягы имгәнгән, шуңа күрә бер якка авып китмәс өчен таякка таянып йөри торган, тапкыр сүзле Камил абый һәм бухгалтер, миннән берничә яшькә генә олы озын буйлы, каратут йөзле чибәр кеше Әхәт Фазылҗанов белән без тиз арада дуслашып киттек.

Башта эшләр әйбәт кенә барды. Мин авылларга йөрим, урыннардагы саклык кассаларында документларның дөрес тутырылуын, калдык акчаларның төгәл саклануын тикшерәм. Күрдең, абыең начальник хәзер! Урыннарда мин килүдән шүрләп, ә кайчак әзерләнеп тә торалар. Әмма иң кызыгы бу түгел әле. Иң кызыгы — миңа махсус кием бирделәр. Өскә алтынсыман ялтыр җиз төймәле, куе зәңгәр төстәге матур плащ, башка

кокардалы, күзеңнең явын алырлык фуражка киеп куям да, минем кем икәнем әллә кайдан күренеп тора. Бервакыт шулай Җөлбигә барам. Каршыга килүче бер төркем хатын-кыз, мине генә күргәннәр иде, кисәктән юл буендагы арыш арасына сибелделәр. Кайсы-кая посты бичараларның. Бу хәлгә бик аптырап киләм. Инде үтеп барышлый арыш арасыннан куркынган тавышлар ишетелде:

— Чукынган!.. Безнең Радик түгелме соң бу? Шул кырмыш тәре бит бу!

— Ай-һай, ул түгел бугай.

— Радик, синме бу?

— Нәкъ үзе, Радик. Ни эшләп әле сез койма аша сәлам бирәсез?— мин әйтәм.

Шунда көлешә-көлешә арыш арасыннан юлга бер көтү хатыннар чыгып басты. Күрәм, үзебезнең Дусым авылыныкылар. Алар мине сырып алдылар.

— Һай, Радик, җаным! Ярыйлар да син икәнсең бит әле бу. Без бит участковой Васил дип торабыз. Котыбызны алдың ич!—дип бик куандылар. Казанга барып, шәл сатып кайтышлары икән боларның. Ул заманда колхоз эшен калдырып, шәһәргә барып йөргән өчен милиция инспекторлары тотып ала, колхозда болай да бушка эшләгән хатыннарга, кычкыртып, зур штраф сала иде. Минем ялтыр плащым, кокардалы фуражкам хатыннарның котын алган икән.

Шунда мин йөземә бик җитди, хәтәр төс чыгардым. Һәм ярып салдым:

— Миңа хәзер бөтен налогларны, штрафларны түләтергә диелгән! Сез шуны беләсезме?! Васил—нәрсә ул минем янда... Яле, әзерләгез акчаларыгызны!

Һәм нәрсә диярсез?! Минем бичара хатыннарым тәмам куркып калдылар. Мине балачактан белгән авылдаш хатыннар. Сүзгә һич кесәгә керми торган чая җаннар. Кайберләре бик нәүмизләнеп, еларга ук итә башлады. Ул чакта төрле түрәләрдән курку халыкның канына шулкадәр сеңгән иде. Мин элекке кыяфәтемә кайтып, елмаеп җибәргәч, чак кына тукмап ташламадылар үземне.

— Карале, шаярта гына икән. Аһ, кырмыш тәре!..

Бу «кырмыш» кушаматы мине гомерем буе озата килде һәм, авылга кайтсам, кайчак әле дә булса ишетелгәли. Аны ишеткәч, күңелне нидер тырмап алса да, мин аңа үпкәләмим. Безнең әти ягыннан Фәйзерахман бабай гаять усал, гайрәтле кеше булган. Берәр хәл чыкса, хәзер җеннәре кузгалып, барысын да кырып ташлаган. Һәм менә сиңа «кырмыш»! Миңа, әни ягына охшап бик юаш, йомшак күңелле булып калган кешегә, бу кушамат ниндидер бер мактау, дәрәҗә кебек ишетелә.

Авылларга чыкмаган көннәрдә мин үзәк кассада утырам. Без—Камил абый, Әхәт һәм мин—эш арасында төрле күргән-белгәннәрне сөйләшеп утырабыз. Дөресрәге, күбесенчә мин сөйлим. Ә минем сөйләргә осталык бар, тегеләр бирелеп тыңлый. Дөресен генә әйткәндә, ул заманда халыкның кассада акчасы әлләни күп түгел, димәк, безгә эш тә шул чамалы гына иде. Кайчак Камил абый янына аның ун яшьлек улы керә.

— Ну, кәефләр ничек соң, улым?—дип сорый аннан әтисе.

— Кәефләр күп лә анысы,—ди малай борынын тартып һәм бик хәйләле төстә елмаеп куя.

— Ничек инде... кәефләр күп. Ә нәрсәң юк соң синең?

— Менә кинога керергә акча юк минем.

Без көлеп җибәрәбез һәм Камил абый кесәсеннән егерме тиен чыгарып, улына бирергә мәҗбүр була.

Бу Әтнә юлын таптау миңа тагын насыйп икән әле. Көн саен авылга кайтып йөрим. Эшләп алган акчаларымны әнигә бирәм, энеләремне, сеңелләремне тәрбиялим. Үземнең өстә—әтидән калган, инде тузып килгән бердәнбер костюм, үземә шактый озын пальто. Үзем турында уйлаган юк әле.

Эшләр шулай җай гына барганда, язмыш минем тормыш тәгәрмәченә тагын таягын китереп тыкты. Район үзәгендә утырган җитәкчеләр хисабына колхозларны ныгыту, дөресен әйткәндә, аларны инде үзләре тырышып, тир түгеп җайга салган эш урыннарыннан кубарып алып, колхоз рәисе яисә бригадир итеп җибәрү кампаниясе башланды. Бу тәртә башы безнең мөдиребез Мөхәм абыйга да килеп бәрелде. Бер көнне иртән эшкә килгән, йөзе кап-кара.

— Мине дә җибәрәләр, егетләр... Их!..—диде һәм кулын селтәде.

Шулкадәр үкенечле төстә, җан авыртуы белән селтәде ки, мин, авылны бик яхшы белгән кеше, эчтән калтыранып куйдым. Бер дә теләмичә, үз шәхесе изелеп, көчләп җибәрелгән шушы кеше колхоз белән идарә итәргә, андагы эшләрне алып барырга тиеш була бит инде.

Мөхәм ага Корбанов күпме сузып, күпме карышып йөреп караса да, райком кушкан үтәлми каламы соң? Аңа үзе бик яратып, белеп эшләгән урынын калдырып китәргә туры килде. Аның урынына икенче Мөхәм — Гобәев Мөхәм килде.

Тәбәнәк буйлы, караңгы чырайлы, бик аз, саран сүзле бу адәм белән, нигәдер, без беренче көннәрдән үк, бер-беребезне яратмадык. Ул мине үзәк кассада булган көнне күп сөйләшүемне, уен-көлкеле, ачык күңелле кеше булуымны өнәп бетермәде бугай. Ул, эш вакытын — тулысынча эшкә, дигән чиновниклардан иде.

Кем белә, бәлки Мөхәм ага Гобәев начар кеше дә булмагандыр, минем үземә аңа яраклашып, тырышып эшләргә кирәк булгандыр. Ул кырыс, вакчыл иде, инструкциядән бер карыш читенүдән дә курыкты. Мин исә төрле читенүләрдән, инструкция бозулардан әлләни шүрләмим. Кешенең хәленә керәм, кирәк урында аңа юл куям. Авыр заман иде ул! Урыннардагы кассир-контролерлар еш кына кассадагы акчаны алып, үз кирәк-яракларына да тоталар. Бу — турыдан-туры инструкцияне бозу. Ә мин шушыларга күз йомам. Чөнки белеп торам, теге мескен кассирның хәле дөрестән дә мөшкел, ул үзе алган акчаны барыбер кассага кертәчәк. Һәм беренче җае булу белән. Уйлап карасаң, шуннан кемгә ни зыян инде, җә? Шуннан совет дәүләте җимерелеп төшәме?

Бер авылга бардым. Контролер өлкән кеше, кассада өч мең тәңкә акчасы җитми. Карт миңа вәгъдә итеп калды:

— Бер атнадан кертәм, энем. Син инде моны рәсмиләштерә, Гобәевкә җиткерә күрмә!

— Ярар,—дидем мин.

Минә кешегә иткән яхшылык һәрвакытта да яхшылык булып кына әйләнеп кайтмый шул ул. Шушы хәлне кайсыдыр үзәк кассага җиткергән. Гобәев мине үз кабинетына чакырып алды.

— Син Түбән Көектә булдыңмы?—дип чекерәйде ул миңа кечкенә кара күзләре белән.

— Әйе булдым.

— Андагы җитмәүчелекне күрдеңме?

— Күрдем, Мөхәм абый. Әмма бит картка зур каза килгән — сыеры басуда күбенеп үлгән. Шуңа, инде соңгы чиккә җиткәч кенә, алып торган ул акчаны. Бер атнадан кертеп куям, диде. Монысын ныклы вәгъдә итте.

— Син инде безнең эштә вәгъдәгә ышанасыңмы? Вәгъдәне документ итеп терки аласыңмы?

— Соң, туктагыз әле, ни эшләп ышанмаска? Шундый олы кешегә?

— Минә нәрсә, Радик! Яз хәзер үк гаризаңны. Иртәгесе көннән син бездә эшләмисең!—диде Гобәев.

— Ярый, мин язармын анысы гаризаны. Әмма син дә кәгазь корты, документ колы икәнсең. Инде, өлкән кешенең хәленә кергән өчен...— дидем мин һәм тагын бер-ике сүз өстәдем. Тозлы-борычлы бу сүзләрдән соң мин бирегә эшли алмый идем инде.

Шулай итеп, миңа, киләчәктә мөдир буласы ихтимал кешегә, саклык кассасы ишегенең кайсы якка ачылганын тиз арада күрергә язган икән.

Шуннан инде китте дә китте... Авылда гына кал, колхозда эшләрсең, әнә кибетче, ферма мөдире булырсың, дип, әни бик үгетләгән, ялынган-ялварган иде, югыйсә. Тик кая ул! Минем чуар җаным, хыялый күңелем еракларга, шәһәргә тартыла иде. Анда дөнья кызыктыр, иркендер, яктыдыр кебек тоела иде. Киттем чыгып Казан калаларына. Анда бертуган Зәйтүнә апам бар, ул төзелештә маляр-буяучы, әле тормышка чыкмаган, тулай торакта яшәп ята иде. Бауман урамының нәкъ урта бер төшендә. Тулай торакта һәрвакыт бер-ике койка буш була, кайчак анда йөргән кызлары янына кереп егетләр төн кунып та чыга. Миңа да сыенып урын табылды. Казанда ул заманда кая гына барсаң да, эш күп иде, әмма пропискага алмыйлар. Шунда каңгырып йөргәндә ишеттем озын колаклардан: тиешле кешеләргә тиешле сумманы төртә алсаң, бик ансат кына үтеп була икән үзе... Тик миндә андый акчалар кайда әле? Шунда инде үзе дә мантый алмыйча Казанда байтак вакытлар каңгырып йөргән туганнан туган абый тиешле Зыя миңа әйтә куйды:

— Әйдә, «Водоканалстрой»га барабыз. Анда прописка да кирәкми, акчаны да шәп түли, диләр...

Киттек без шушы «Водоканалстрой»га. Барсак, бу тагын шул җирдә казына, шәһәрдә сууткәргечләр сала, ә Татарстан авылларында җир астыннан фермаларга су кудыра торган манаралы җил двигательләре корып куючы бер оешма икән. Тәтеш районының бер авылында шундый эш бара дип, безне шунда җибәрделәр.

— Менә сезгә пароходка билет. Ә акчаны урынга баргач алырсыз. Әлегә кассада бернинди акча юк. Кайгырмагыз, артыгыздан ук җибәрәбез! — дип, вәгъдә итеп калдылар.

Иделнең биек ярындагы зур бер урыс авылы. Бу инде көз, басуларда игеннәр, көнбагыш, бәрәңге өлгереп килә. Безне авыл читендәге бер йортка, ялгыз хатын Наташа түтәйгә фатирга керттеләр. Шуннан ерак та түгел сыерлар фермасы, аның янында су скважинасы тишелгән. Без шул скважина өстенә челтәрле тимер манара монтажлыйбыз. Манара җиргә яткызып җыела. Соңыннан аны краннар белән күтәреп бастырасы. Күбрәк Зыя белән икәү генә эшлибез. Кулда зур гайка ачкычы, болтлар, тимер угольниклар, кувалда. Бик акрын үрчесә дә, кызыклы гына эш. Синең кулларың белән җыен тимер-томырдан матур, зифа манара ясала килә. Өченчебез бригадир санала, ул көннәр буе каядыр югалып, кирәк-ярак артыннан йөри. Василий исемле, озын буйлы, күркәм генә бу рус егете гел кызмача була.

Без килгән көннән үзебезгә акча җибәрүләрен көтә башладык. Казаннан алып чыккан ипи, колбаса, шикәр кебек әйберләр аккурат өч көндә бетте китте. Инде ни эшләргә? Ошбу дөньяда ашамыйча бер генә көн дә торып булмый бит.

— Аптырагансыз икән! — диде безгә йорт хуҗасы, әле яшьлек чибәрлеген һәм чаялыгын җуймаган Наташа түтәй.— Әнә бит бакча артында колхоз бәрәңгесе, аның янәшәсендә генә көнбагыш... Сорасагыз, сезгә сөтне ферма кызлары да бирә. Шул ферманы сулы итәргә йөрүегез бит.

Зыя белән без төнлә бәрәңге басуына сәяхәт ясап кердек, ә сөтне, дөрестән дә, сыер савучы кызлар безгә җәлләми бирделәр. Тик бу дөньяда бөтенләй дә акчасыз барыбер яшәп булмый шул. Тәмәкесенә, ял көннәрендә азрак тамак чылатырга, кичләрен кинога дигәндәй... Беркөн кичен Зыя дус идән буйлап йөренә. Үзе шактый моңлы гына итеп җырлый:

Яратам, яратам,
Костюмымны яратам..

— Ну, костюмны яратып булмый инде,— мин әйтәм.

— Була шул менә. Туры килә! — диде Зыя һәм чемоданыннан үзенең кешелеккә генә кия торган, әле яңа диярлек кара костюмын чыгарды. Аны төрле яктан әйләндереп карап, үкенечле тостә телен шартлатты:

— Иллә дә яратып кия идем бу кәчтүмне, җанашымны...
— Соң, кия бир,— мин әйтәм.
— Сатып җибәрмичә булмый бит. Акча юк бит,— диде Зыя.
Ул елларда Идел суы өстенә гаять тә зур Куйбышев гидроэлектрстанциясен төзү бара иде. Су астында каласы авылларны күчерәләр, җимерәләр, урманнарны кисәләр. Безнең белән бер фатирда шундый урман кисүчеләр дә тора. Гаҗәп хәл, бу кисүчеләргә, җимерүчеләргә акчаны шәп һәм вакытында түлиләр. Кич белән без Зыяның яраткан костюмын шул кисүчеләргә сатып та җибәрдек.
Акча күбәйде! Бөтен бер костюм акчасы... Кибеттә аракы, тегесемонысы бар. Кинолар һәр кичне булып тора. Шәп яшибез. Тик, бер-ике атна үттеме икән, акча азайды. Һәм һич тә озакка сузмыйча, бетеп тә китте. Хәзер инде нәүбәт миндә иде. Чемоданымнан Зәйтүнә апа үземә әле монда килер алдыннан гына алып биргән зәңгәр төстәге, өр-яңа, һәйбәт спорт костюмын чыгардым.
— Болай яратып кия идеңме үзең бу костюмны?— дип сорый Зыя авызын ерып.
— Кая ул! Әле киеп бер рәхәтен дә күрмәгән ич аның,— дидем мин, еларга җитешеп.
— Ә шулай да, ә шулай да, сатып ашарбыз аны! — дип көйләп җибәрде Зыя мәлгунь.
Безнең бу җанлы сәүдә ары таба да дәвам итте. Акрынлап Зыяның аклы күлмәге, аның артыннан минем йон свитер, безнең ябык кына чемоданнарыбызда булган юньлерәк барлык әйберләр урман кисүчеләрнең иләмсез зур, симез чемоданнарына күчте. Ә акча җанашымны безгә һаман да җибәрмиләр. Без телефоннан шалтыратабыз, берничә тапкыр ачка үлеп баруыбызны бәян итеп телеграмм сугып карадык. Юк! Җибәрмиләр һәм вәссәлам!
Ул арада, ачлы-туклы эшләп булса да, без җил двигателен корып бетердек. Аны бастырып куйдык, канатларын көйләп, әйләндереп тә җибәрдек. Әйләнеп китүенә биш минут та үтмәде, без куйган двигатель янәшәдәге зур тагаракка, фермаларга сузылган трубаларга су коя башлады. Сап-салкын, чип-чиста су!
— Ура! — дип кычкырып җибәрдек без өчебез бергә һәм кайгы-хәсрәтләребезне, дөньябызны онытып сикерә, кычкыра, шаяра башладык. Уенмыни, без бит җир астыннан су чыгарабыз. Без куйган машина нинди зур фермага су биреп торачак бит!
Ул көнне безне колхоз җитәкчеләре дә килеп котладылар, яхшы гына сыйладылар да әле. Ферма кызлары да сөтне чиләге белән бирделәр. Әмма бәйрәм тиз үтә шул ул. Икенче көнне үк инде без янә сукыр бер тиенсез калдык. Инде сатар әйбер дә бетте... Җитмәсә, безгә Казаннан акча кәгазе түгел, күрсәтмә кәгазе килеп төште. Янәшәдәге колхозда яңа двигатель кора башларга дип. Ә урамда ак күбәләкләр очкалый башлады. Кара көз, салкын кыш якынлашып килә.
— Тайыйк без моннан җәтрәк, Зыя дус. Казанга кайтып китик. Булмый бит болай яшәп,— дидем мин.
— Шулай итмичә булмас, ахры. Соңгы пароход белән ычкынырга кирәк. Аннан соң моннан кайта алмыйча калуың да бар! — дип килеште минем белән Зыя.
— Кайтуын кайтырбыз. Тик менә юлга акчаны кайдан юнәтәбез?— дидем мин. Зыя кулын гына селтәде:
— Ә чемоданнар нәрсәгә? Буш килеш алар безгә ни пычагыма кирәк?
Шулай итеп, әйтергә көлке, без чемоданнарны да урман кисүчеләргә сатып җибәрдек. Тәтеш пристанендә Казан ягына баручы пароходка утырдык. Ә ул, дөрестән дә, соңгы парахад булып чыкты. Ягъни инде елга туңа, башка пароходлар йөрмәячәк. Ай, халык бихисап иде бу пароходта! Кая карама — коридорларга, почмакларда, хәтта капчыклар, баулар өстендә кеше, кеше! Без Зыя белән үзебез каралып, ябыгып

беткән, өс-баш та шактый керле. Кыяфәт бик таушалган, шактый ачулы да. Кая гына барып төртелсәк тә, бездән кешеләр ачыктан-ачык шикләнәләр... Бик тыгыз булса да, утырган җиребездә бераз бушлык хасил була. Бер агай, безгә борылып карый-карый әллә кая, аскы катка ук төшеп китте. Ә без үзебез оялабыз, кешеләрдән качарга тырышабыз. Әкәмәт, кыскасы! Инде төн җитә башлагач, нindидер бау бәйләмнәре артында бераз буш, аулак урын табып, шунда кереп яткан идек. Төне буена бер тамчы йоклый алмадык. Ятуыбыз белән башны, ә тиз арада бөтен гәүдәбезне нәрсәләрдер тешли башлады. Галәмәт каты итеп, чеметеп алган төсле тешлиләр. Ниһаять берәресен тотып алсак, кандала! Галәмәт эре, явыз кандалалар!

Казанга көч-хәл белән кайтып җиттек. Конторага кереп, бөтен моңзарны чәчә башладык. Әмма начальник, бик матур, Ленин бабайныкы төсле борчаклы галстук таккан, күркәм, спай гына кеше, безне тыңлап та тормады. Көлде генә.

— Аһ, анда Тәтештә сез дә бар идегез бит әле. Монда безнең хәтердән дә чыккан ул әле... Сез, егетләр, гафу итегез инде. Әнә барыгыз, кассадан акчагызны алыгыз! — диде ул һәм шуның белән сүзне беткәнгә санап, телефонга үрелде. Кассага барсак, хәлебез тагын нигүзәл. Безгә язылган акча сатып ашаган әйберләребез бәясен дә капламый торган булып чыкты. Бу мыскыллауга тәмам ачуым килеп, мин тагын начальник янына әйләнеп кердем.

— Мин расчет таләп итәм!

Теге кулын гына селтәде:

— Ә нигә таләп? Болай да бирәбез сиңа расчетны. Синең кебек шантрапалар безгә көн саен дистәләп килә!

Шуның белән минем җил двигательләре куючы слесарь-монтажник һөнәре тәмам да булды. Кем белә һәм бик ихтимал, бәлки, миңа алай ук ашыгырга, шундук расчет алырга да кирәк булмагандыр. Әнә Зыя шунда калды бит. Ничектер җайлашты, мастер булды, күп еллар буена зур акчалар эшләп алды. Мин шул алдын-артын уйлап эш итмим. Гомергә шулай булдым.

Ни хәл итәсең, мин тагын авылга әйләнеп кайттым. Теге беркая да кабул ителмәгән сукыр бер тиен кебек. Берничә айлар буена беркайда да эшләмичә, тинтерәп йөрдем. Колхозда эшләп каласы килми генә бит... Колхоздагы минем яшьтәш егетләрнең шул кыстырып кайту хакына гына, бушка диярлек эшләп йөрүләрен күреп торам бит. Ахырда яңадан да бәхетемне сынап карыйсым килде, тагын Казанга сәфәр чыктым. Бу юлы инде Зәйтүнә апай, нindидер танышлары аша эш йөртеп, кемгәдер шактый гына акча да төртеп, мине пропискага кертә алды. Ул заманда самолетлар гына ясый торган егерме икенче заводка, токарь өйрәнчеге булып урнаштым.

Монда зур гына бер чигенеш ясап алырга кирәк. Әле саклык кассасында эшләгәндә үк мин үзебезнең Дусым авылына Арчадан медсестра булып килгән Дамира исемле кыз белән танышкан идем. Дамира — чибәр генә, таза гына бәдәнле, тыныч, нык холыклы кыз, башта мине, ябык кына, җилбәзәк кенә, җитмәсә, ашказаны да сырхау бер егетне, өнәп бетермәде. Моңарчы мин байтак кызлар белән танышып, берсе белән дә юньләп йөрмәдем, бернинди җитди уйга килмәдем. Ә менә Дамираны чынлап торып ярата башладым, чын мәхәббәтнең нәрсә икәнен белдем бит. Минем сөйләшергә тел әйләнә, киләчәктә бик матур тормыш, бик күп нәрсәләр вәгъдә иттем тегеңә. Кызларга, үзегез дә беләсездер инде, шактый ялынырга, тасма тел булырга туры килә. Әмма Дамираны асылда минем киләчәктә берничек тә авылда, колхозчы булып калырга риза түгеллегем җәлеп итте кебек. Ни әйтсәң дә, поселокта туып үскән кыз, аның да тормыш итәргә авылда торып каласы, бер авыл егетенә кияүгә чыгып, әтеки-әнекиләр белән, кемнеңдер терлек-туарын, кош-кортын тәрбияләп көн итәсе килми иде. Мин бит — гидай, кем

әйткәндәй, кашым да күзем... Ә Дамирага кызыгып, аны кулга төшерергә йөрүче егетләр авылда житәрлек иде.

Мин үзем кайда гына булса да, жае чыккан саен авылга, Дамира янына кайткалап йөрдем. Ул хатларны инде, хатларны көн саен диярлек яза идем. Үзем йомшак күңелле, жиңел холыклы егет, мин ниндидер бер эчке сиземләү белән бу кызның киләчәктә үземә яхшы тормыш иптәше, ныклы таяныч та буласын сизенә идем. Инде Казанда егерме икенче заводта эшләгәндә Октябрь бәйрәменә кунакка кайттым. Шунда Дамираны үзем белән язылышырга, ягъни никахлашырга күндердем. Язмыш дигән нәрсә үзедер инде бу, бик матурлап дәлилли торгач, ул ризалыгын бирде. Әле дә хәтеремдә, Октябрь бәйрәменнән соң, көзнең бер кояшлы, матур көнендә Әтнәгә киттек. Дамира белән гел икәүләп кенә. Бернинди озатучы, тантана, берни дә юк. Бу хәлне хәтта беркем дә белми дә. Никахны теркәүче апа, олы гына хатын, безнең гаризаны алды да, болай диде:

— Тагын бер айдан язылышырга килерсез. Аның законы шулай.

— Апа, жаным, зинһар, хәзер үк язып куегыз безне. Зинһар дип әйтәм. Мин — Казанда, икенче кайтып йөри алмыйм! — дидем мин.

Менә, чиновникларның да төрлесе була. Теге апа безгә карап алды да, бөтен законнарны, кагыйдәләрне бозып, безнең никахны теркәп тә куйды.

Шулай итеп, егерме өч яшемдә мин инде өйләнгән кеше идем. Менә кара инде син миндәге жилбәзәклекне, берни уйлап тормыйча эшләүне! Кесәңдә акчаң булмасын, бергә торырга фатирың, гаилә корыр өчен бернинди жирлегең, әти-әниең тарафыннан бернинди ярдәмгә юлың булмасын. Ә син алдан ала никахлашып куй... Хәзер менә уйлыйм, алай да, юләр бул да батыр бул! Әгәр дә шул вакытта Дамираны әнә шулай үземә бәйләп куймаган булсам, минем аны мәңгегә югалтуым бик ихтимал иде. Аны авыл егетләреннән кем дә булса үзенә каратмый калмый иде. Ә минем исәп шушы заводта төпләнү, төшемле һөнәр алу, акрынлап булса да фатирга ирешеп, Дамираны шәһәргә китерү һәм кешеләрчә тормыш корып жибәрү иде.

Ярый, шулай урнашып алдым мин заводка. Без самолетның тәгәрмәчләрен, ягъни шасси ясый торган икенче цехта эшләдек. Мине Иван Зуев дигән бер токарьга өйрәнчек итеп билгеләделәр. Иван миннән берничә яшькә генә олы, кылыч борынлы, бик аз сүзле бер урыс. Ул бик катлаулы һәм жаваплы детальләрне — самолет тәгәрмәченең кеше гәүдәсе кадәр зурлыктагы таяну штокларын ясый. Иван бернинди тәрбияче дә, өйрәтүче дә булып чыкмады. Миңа берни сөйләп тә, аңлатып та маташмады. Газеталарда язылганча «производство серләренә» төшендермәде.

— Алла кешегә күз биргән, колак биргән. Димәк ки, адәм баласы барысына да үзе өйрәнергә тиеш. Менә минем ничек эшләгәнне карап тор. Әнә сиңа штангенциркуль, әнә сызымнар. Аларын үзең өйрән! Аның өчен урта белемле егет син. Без менә биш класс белән дә эшләп йөрибез әле. Начар да эшләмибез! — диде ул һәм аның миңа бирәсе дәресләре шуның белән тәмам дә булды.

Алай да шәхси үрнәк — зур нәрсә! Берничә көннәр мин Иванның янәшәсенә басып, аның станок патронына детальләрне ничек беркетеп куйганын, үлчәмнәрне ничек чыгарганын, кискечләрне ни рәвештә куйганын жентекләп күзәтеп тордым да, тиз арада штокларны беренчел эшкәртүгә өйрәнеп тә алдым. Иванныкы белән янәшәдәге икенче бер станокта үзбуйлы эшли дә башладым. Акрынлап сызымнарны ничек укырга, үлчәргә, бүтән төрле детальләрне эшкәртергә дә өйрәндем.

Ә эшләве күңелле! Иртән заводка китәсең, проходнойда пропусканны алып, цехның иркен ишегеннән кереп китәсең. Проходной ул үзе бер гажәп нәрсә. Мин анда эшләүнең серенә әле дә булса төшенә алмыйм. Заводка бит күп булса ярты сәгать эчендә меңнәрчә кеше керә. Шул

меңләгән халык эченнән кечкенә тәрәзә янына шәхсән син килешкә анда эшләүче яшь кенә кызлар синең кулыңа ялт итеп нәкъ синең пропускаңны тоттыралар. Хәрәкәттә бернинди тоткарлык булмый, кешеләр елгасы туктаусыз ага. Алар сине ничек таный, меңләгән пропуска арасыннан синекен ничек алай тиз таба? Монысына мин әле дә булса җавап бирә алмыйм. Аннары тагын. Әгәр заводта син үзең өчен нинди дә булса бер әйбер, әйтик пычак ясап, аны куеныңа яисә итек балтырына яшереп алып чыгарга теләсәң, проходнойда сине, һичшиксез, тагын тотып алалар. Алдан килгән кеше бернинди тоткарлыксыз чыгып китә, ә менә сине туктаталар. Яшерелгән әйбереңне эзләп табалар. Мондый очракта эшне зурга җибәрмиләр әле. Каравыл башлыгы килеп, синең әйбереңне ала, үзеңә кисәтү ясый да, шуның белән — вәссәлам. Әмма икенче төрле очраклар да була. Бер инженер цехка төзәтергә дип үзенең фотоаппаратын алып килә. Нәрсәдер, вак кына ремонт. Төзәтә бу аппаратын, объектив аша карап, төзеклеген тикшерә. Һәм, бәхетсезлегенә каршы, объективны самолетлар җыю цехы тарафына юнәлткән була... Заводтан, яраткан эшеннән кудылар бичара инженерны! Үзенең бернинди дә дошман агенты түгеллеген, объективны ул якка очраклы рәвештә генә юнәлткәнен юкка гына кат-кат исбатлап маташты. Ярый әле, бу инде Сталин бабай заманасы түгел, ә Хрущев агай вакыты иде. Юкса, теге инженер эшен генә түгел, ә башын да югалтасы иде бит... Алай да ул заманда заводны каравыллаучыларга бу кадәр мәгълүматлылык, сизгерлек кайдан килде икән? Заводта эшләүчеләр арасында тирә-ягын гел күзәтеп торган шымчылар җитәрлек булгандыр. Бер дә бүтән түгел. Моны бит башкача аңлатып та булмый...

Ярый, без проходнойдан цех эченә эшкә дип кергән идек бит әле. Килеп басасың үз станогың янына. Ә инде аны сменадашың чистартып, ялтыратып, майлап та куйган. Ул, гөрләп әйләнә башлыйсы килгәндәй, сине көтеп тора. Болванканы патронга утыртасың да, йомшак төймәгә генә басып, станокны эшләтеп җибәрәсең. Ул үзенең гаҗәп үткер корыч теше белән металлны кимерә, кисә башлый. Күгәреп беткән ямьсез болванка акрынлап ялтырап торган штокка әйләнә. Аны үлчәп карыйсың, исәпләп, илһамланып инде соңгы кат, чистага эшкәртәсең. Монда инде осталык, микронлы төгәллек кирәк. Синең маңгайга тирләр бәреп чыга. Менә, ниһаять, булды! Самолетның бер аягы өчен таяну штогы өзер. Ялтырап торган кайнар штокны кулга эш бияләйләре киеп, кадерләп кенә махсус аслыкка алып куясың да, аңа сокланып карап торасың. Үзең ясаган әйбер, нинди матур, хәтта шәхси әйбереңкебек якын ул сиңа. Һәр эшнең үзенә күрә илһамы, шигърияте бар шул аның! Аннары инде патронга яңа болванка утыртасың. Мин еш кына вакыт табып, самолетларны җыя торган цехка да барып киләм. Әнә ул, биниһая дәү, куәтле машиналар. Илебезнең хәрби калканы, сакчылары! Болын кебек иркен, түшәме күккә ашкан биек цехта канатларын киң җәеп торалар. Аларны инде коралландырганнар, пушкалары кисәтүле төстә алга төбәлгән. Биек тимер рәшәткә аша аларга карыйсың да, күңелгә горурлык килеп тула. Шушы нинди кодрәтле, гаять тә катлаулы, олпат, матур машинаны ясауга, азмы-күпме синең дә өлешең кергән бит!

Мин заводта гомергә калырга әзер идем. Кем белә, югары квалификацияле, оста кадровой эшче дә булып киткән булыр идем, бәлки. Әмма бит, кадалып киткере, бу тормышның үз законнары. Кире беткән, аяусыз, рәхимсез кануннары. Күңелдәге хыяллар, горурлык хисе белән генә тамак туйдырып булмый бит әле. Ә безгә, өйрәнчекләргә, акчаны ашарга да җитмәслек аз түләделәр. Мин Зәйтүнә апам янында туенгалап йөрдем. Җитмәсә, тиздән без бер нәрсәне сизеп алдык. Инде без азрак өйрәнеп, үзлегебездән детальләр ясый башлагач та, башкарылган хезмәт өчен тиешле акчаны безгә түгел, ә өйрәтүчеләргә язалар булып чыкты. Ягъни мин эшлим, ә акчасын Иван ала. Әйтәм җирле аны соңгы вакытта Иван минем һәр адымымны тикшереп, станок янында булуымны күзәтеп тора.

Без нәни генә окладта, ә хезмәт хакын өйрәнчеклектән чыгып, разряд алгач кына язачаклар икән.

Ярый, монысына түздек без. Инде алты ай өйрәнчеклектә йөреп, бушка диярлек эшләп, имтихан тоттык. Разряд та алдык. Шул чагында нәкъ теге танк училищесындагы кебек булды: дөнья миңа янә арты белән борылды. Нормаларны ике тапкыр диярлек күтәрделәр. Ягъни һәр ясаган деталь өчен түләүне ике тапкыр диярлек киметтеләр. Син ике тапкыр тизрәк эшләргә тиеш буласың дигән сүз инде бу. Ә безнең тәҗрибә — чыпчык борыны. Алай да бер ай азапланып карадык. Килдек кассага. Өйрәнчек окладыннан аз гына ару хезмәт хакы бирделәр.

Менә шулай ул, дөнья — куласа!

Мин — җилкуар, тагын әлләни баш ватып, күп уйлап тормадым. Берничә иптәш егет белән җыйналып сөйләштек тә, расчет та сорап тормастан, бу заводтан качып китәргә булдык. Расчетны аны, сорасаң да, барыбер бирмиләр иде. Хөкүмәт дурак түгел бит, сине алты ай өйрәтеп, завод капкасыннан җиңел генә ирекккә чыгарып җибәрергә... Шулай итеп, болай гына ычкындык. Ул елларда хәрби заводтан качып киткән өчен суд җаваплылыгына тарталар иде. Безне ничек эзләмәгәннәр дә, ничек тапмаганнардыр? Монысын бер Алла гына белә.

Миңа, бәлки, бу заводны да алай ансат кына ташлап китмәскә, кыенлыкларга түзәргә, тырышырга кирәк булгандыр. Соңыннан, инде бик күп еллар үткәч, үзем газета редакциясендә эшләгәндә, Казан — Арча поездында кайтып барам. Каршымда утырган үзем яшьләрендәге, өстенә бик затлы костюм, ак күлмәк кигән, галстук тагып җибәргән бер кеше ничектер таныш кебек тоелды. Сөйләшеп киттек. Казанда тора, егерме икенче заводта эшли икән, нәкъ бер елны, бер цехта өйрәнчек булып йөргәнбез икән.

— Да, мин сине күрдем, беләм мин сине. Разряд алып эшли башлагач та, каядыр юкка чыктың,— диде ул.

— Болай акча яклары ничек анда хәзер?

— Ярыйсы гына...— диде ул һәм суммасын атады. Эчләр борып куйды минем шунда. Ул атаган сумма минем айлык хезмәт хакыннан дүрт мәртәбә диярлек артык иде. Заводтан квартир алып, инде күптән җиңел машиналы булып, гөрләтеп яшәп ята икән...

Менә бит!

...Шулай итеп, мин тагын шәһәрдә урнашып кала алмадым. Теге сукыр бер тиен кебек, тагын авылга әйләнеп кайттым. Без инде Дамира белән бергә тора башладык. Ә безнең кысан өйнең эче тулы халык, без Дамира белән идәндә, ишек катында диярлек йоклыйбыз... Шулай да яшь вакыт, аны-моны талымламый торган вакыт.

Мин тагын люмпен пролетариат, колхозда да, дөресен генә әйткәндә, беркайда да эшләмим. Кыш буе шулай селкендем. Бар эшем шул, сыер абзарын чистартып, Түбән Шашы басуыннан, калган эскерт төпләреннән җыйнап, салам алып кайтам. Бервакыт бурында адашып чак кына туңып калмадым.

Икенче бер чакны кара кичтә, Зиннур белән үзебезнең авыл болынына төшеп киттек. Эскерт төбеннән печән урларга. Кышкы кич гаҗәеп тын, җылы иде. Аяк астында кар да әлләни тирән түгел иде, без бер чакрымдагы болынга тиз арада төшеп тә җиттек. Башланган бер эскерттән хуш исле печән алып, икешәр пот чамасы печән бәйләдек. Мондый кәсептә иркенләп йөреп булмый, төн булса да шикләндерә, җәтрәк авылга ашыктык. Ике пот йөк ул әбиеңне өшкерә, тиз арада тирләп чыктык, күзләргә тир кереп ачыттыра. Инде үрне дә менеп җиттек, инде авыл утлары да күренә башлаган иде. Шунда, һич көтмәгәндә, әллә нинди зәхмәтле, куркыныч буран купты. Күктән гаҗәеп куе булып, ишелеп кар ява башлады.

Кар шундый ява иде ки, без аның һавадан ишелеп төшкәнен аермачык ишеттек. Котырып искән җил безне, аркаларыбыздагы печән бәйләме

белән бергә, карга китереп салды. Ятабыз бер-беребезгә һәм печән бәйләмнәренә сыенып. Авыл шунда ук күздән югалды, җил үкерә, ямьсез генә ачы итеп сызгыра. Шунда тагын да гаҗәеп, серле һәм куркыныч хәл булды. Күрәм, Зиннурның киеменә, җиң очларына, бүрек колакларына ниндидер сәер, яшькелт утлар кабынды. Ул утлар җемелдәп, бер кабынып, бер сүнеп, Зиннурдан печәнгә дә күчеп, җил очырган печән бөртекләренә ияреп очып китә башладылар.

— Зиннур, син бит янасың!—дип кычкырдым мин бу хәлдән котым алынып.

— Әә син үзеңне кара!—дип кычкырды ул да.

Карасам, минем дә җиң очларында, итәктә, хәтта үзем ышыкланып яткан печән бәйләмендә дә утлар җемелди. Кайчак алар тәмам дөрләп, тирә-юньне яктыртып җибәрәләр. Әмма үзләреннән берниндн кайнарлык бәрелми. Тик ниндидер бер чытырдау гына ишетелә... Без инде тәмам шыр җибәрдек. Селкенергә дә куркып, кышкы басу уртасында, буран эчендә ятабыз. Торып китәрмен дип тә уйлама, җил хәзер бәреп егачак.

Алланың рәхмәте, буран ничек кисәк башланып китсә, шулай кисәк тукталып та калды. Җил дә тынды, теге утлар да сүнделәр. Тагын тып-тын, җылы, матур кышкы кич.

— Радик, нәрсә булды соң бу? Нинди әкәмәт утлар янды?—диде Зиннур калтыранган тавыш белән.

— Белмим... Әллә безгә болыннан җеннәр ияреп менде инде...— дидем мин.

Һәм бу сәер хәлнең сәбәбен мин әле дә булса белмим, аны аңлатып бирә алмыйм.

Юк, болай итеп, эскерт төпләре җыеп киләчәктә көн итеп булмый иде. Өстәвенә тар гына йортта минем әни, энеләрем, сеңелләрем, анда яшәүләре дә бик авыр. Без Дамира белән тагын авылда торып кала алмадык. Җыендык та, Казан янындагы Васильево поселогына юл алдык. Анда минем мәрхүм әтинең бертуган сеңлесе Әминә апай белән аның ире Сәлих җизни торалар иде. Үз йортлары белән. Аларга рәхмәт, безне сыендырдылар тагын.

Әйбәт кенә урнаштык без монда. Дамира Васильево санаториенда шәфкать туташы булып эшли башлады. Мин агач эшкәртү комбинатына, такта яра торган рамаларга пычкы куючы булып кердем. Шулай итеп, абыегыз хәзер пычкы кайраучы! Нинди калынлыкта такталар ярырга заказ бирелгән булса, пычкылар арасына шундый агач шакмаклар кыстырып, үзебез гали пәкесе кебек итеп кайраган пычкыларны рамнарга тарттырып куябыз. Аннары шунда ук запастагы пычкыларны карарга, кайрарга керешәбез.

Васильевода без ару гына яши башладык. Тиз арада комбинат барагыннан бер бүлмә бирделәр. Бер генә тәрәзәле, тәбәнәк кенә, кысан гына булса да, бу инде үзебезнең куыш иде. Без җизниләрдән шунда күчтек. Мин комбинаттан утынны алып кайтып торам, мичкә ягабыз, җылы. Иң әйбәте, хәзер без кеше өендә түгел, үз куышыбызда.

Васильевода безнең беренче кызыбыз Венера туды. Шулай итеп, без инде гаилә булдык. Ай ул гаиләдә беренче бала! Мин үзем, әти тарафыннан «улым!» дигән сүзне дә ишетмичә, кагылып-сугылып үскән кеше, балаларымны бик яраттым. Гомерем буена. Әле дә булса шулай. Чит җирләрдәге кызларымны кичләр буе уйлап, сагынып ятам. Оныкларым кайтулары белән минем муеныма килеп сарылалар. Балаларны башкаларга сәер тоелыр дәрәҗәдә яратам мин... Эштән кайту белән нәни Венераны кадерләргә, аны багарга керешә идем. Дамира белән чәйнектә су кайнатабыз, кызыбызны көн саен коендырабыз. Аның беренче көлүләре, кулын чәбәкләүләре, кибетләрдән аңа тәти чәчәкле күлмәкләр сайлап йөрүләребез. Аның беренче тапкыр тәпи йөреп китүләре... Юк, алай да бу дөньяда тату, таркалмас гаилә кора алган, балалар үстергән, үз

оныкларын күргән, аларны кулына алып сөйгән кеше генә тулы бәхетле. Мин, шәхсән,шулай уйлыйм.

Идел ярына, урман арасына урнашкан, чиста һавалы, бөтен яктан уңайлы шушы Васильево поселогында безгә гомергә торып калырга, шунда тормыш итәргә бик була иде. Мин инде комбинатта осталардан исәпләнәм, киләчәктә миңа бөтен уңайлыклары булган фатир да вәгъдә итәләр иде. Белмим, бу дөньяда әллә язмыш дигән нәрсә бар микән? Бар ул язмыш, бар! Шул безне теләсә кая кагып-сугып йөртә, барыр юлларыбызны кисә, баштан акылыбызны ала, дөнья буйлап тинтерәтеп йөртә. Минем тормышым — ап-ачык бер мисал моңа.

Шулай җай гына яшәп ятканда безгә авылдан якын тиешле бер агай кунакка килде. Тиктомалдан безнең мондагы тормышны сүгәргә кереште:

— Ятасыз монда... пила чүбе арасында. Шушы баракта пыскып. Авылга кайтыгыз!.. Хәзер бит безнең партиябез төп игътибарын авылга сала... Һи, хәзер авылда! Ике дә уйламагыз, кайтыгыз! — дип кодалап китте бу.

Мин — тинтәккә, чуар йөрәккә шул җитә дә калды. Төн йокыларымны калдырып, хыялланам гына бит. Үземне авылда итеп күрәм. Менә мин бригадир. Минем бригада колхозда, юк, алай гына түгел, районда иң югары уңыш үстереп алган. Зур җитәкчеләр минем кулны кысалар, күкрәгемә медаль, әй, юк ла, орден беркетәләр... Яисә, мин клуб мөдире. Авылда төрле түгәрәкләр оештырып җибәрәм... Егетләрне җыйныйм да, без Ашыт елгасына электр станциясе салабыз. Авылда ялт итеп Ильич утлары кабына! Мин тора-бара сап-сары нарат бүрәнәләрдән алты почмаклы йорт та салып җибәрәм. Ни пычагыма ятарга миңа монда әрәм булып... Дөресен генә әйткәндә, минем Васильевога күңелем дә ятмый иде. Беренчедән һәм иң үкенечлесе, комбинатта пычкы куючылар окладта утыралар, минем эшләп алган акча әлеге дә баягы шул бик аз, бу килештән гомер буе чиләнсәң дә, адәм рәтле яши аласың юк. Икенчедән, туган авыл — туган авыл инде ул. Һаман да сагындыра, үзенә тарта. Кыскасы, Дамираның ай-ваена да карамастан, инде әйтергә дә оят, ничәнче мәртәбә, без тагын авылга борылып кайттык.

Ә анда кайтсак!.. Шайтаным да үзгәреш-фәлән юк икән. Һаман да шул бушка диярлек эшләп яталары. Әле һаман тамагы туйган, өстенә юньле кием кигән кешене күрмәссең. Без шунда ук ник кайтканыбызга үкенә башладык. Ярый әле шунда Магнитогорскидан Фаяз абый кунакка кайтып төште.

— Әй, энем! Болай итеп күпме киләп сарып йөрергә була инде? Бу килештән синнән юньле кеше чыкмас. Бер сукбайга, эшлексез мокытка әйләнеп барасың бит син... Давай болай итәбез. Минем янга Магниткага кил. Эшкә урнашырга үзем булышырмын. Аннан, җай белән гаиләңне дә үз яныңа алдырырсың! — диде ул.

Фаяз абый ул армия чутыннан ФЗӨ мәктәбенә алынып, Магнитогорски шәһәрендә торып калган иде. Шунда комбинатта эшли.

1957 елның җәй башында мин, Аллага тапшырып, тагын авылдан чыгып киттем. Ул көнне әле дә бик яхшы хәтерлим. Бик ямьле, кояшлы, җылы көн иде. Болын үренә җиткәч, авылга таба борылдым да бик озак карап тордым. Әнә, түбән очта безнең өй. Капка төбенә мин үзем бала чакта ук әти белән бергәләп утырткан, көтүдән кайтканда сыерлар ышкынудан бер якка янтаеп үскән тал агачы. Тәрәзә алдында матур рәшәткәләр, түбә астында үзем ясап элгән сыерчык оясы... Инде туган авылымнан мәңгегә чыгып киткәнемне, анда кайтып беркайчан да тормыш итә алмаячагымны күңелем белән сизенә идем. Тормышның рәтсезлеге, колхозның хәерчелеге, беркемгә бернинди игътибар, шәфкать булмау авылның күпме балаларын читкә куды ул елларда! Безнең кебек яшь гаиләләрне генә түгел, инде авылда тормыш итеп картайган, аңа бөтен җаны-тәне белән береккән кешеләрне дә куды. Тыкрык Габделхак

абыйларның Әдһәм исемле олы уллары Чиләбе өлкәсенең бер совхозына барып урнашкан иде. Ул монда кайтып, андагы муллык, әйберләрнең арзанлыгы белән мактанып ташлаган. Киттеләр Габделхәй абый белән Гатүфә апа. Инде авылда торып олыгайган, балалар үстергән кешеләр. Барчасы җыйналып, йорт-җирне сатып киттеләр, И үкенгәннәр үзләре соңыннан! Үлгәнче телләрендә авыл, аның урамнары, болыннары, кешеләре, аларның кызыклы гадәтләре, сөйләшкән сүзләре булган. Гел авылны сөйләшкәннәр, авылны сагынганнар. Үлгәндә дә телләрендә авыл булган...

Ярый, мин дә юлда бит әле. Болынга төшеп җитүемә Үгез елгасыннан каршыма бозау чаклы бер бүре килеп чыкмасынмы! Бүре мин үтәсе сукмак буена иплән кенә килеп утырды. Мин ничектер, һич курыкмадым, тегенең каршысына килдем, хәтта аның турысында туктадым да әле. Без, инде йоннары чаларып беткән карт бүре белән әле яшь кенә кеше, бераз вакыт бер-беребезгә карашып тордык. Бүренең нәкъ кешенеке төсле соры, акыллы күзләрендә: «Нәрсә, тагын китеп барасыңмыни, сукбай? Бәхетеңне әллә кайлардан, чит илләрдән эзлисеңме? Бик булмаган, уңмаган, тәртипсез, төпсез кеше син! Шуңа күрә болай тинтерәп йөрүләрең!» — дигән шелтә бар иде. Ни хәл итим, хаклы иде бүре, башны түбән идем дә, алга атладым. Ашыт елгасында, үзем бөтен тугайларын белгән, яраткан елгамда бер иркенләп, рәхәтләнеп су коендым. Колач салып йөзә-йөзә, суны коча-коча коендым. Судан чыккач, басмага утырдым да, таныш тугайларга, инде яшәреп килгән кашлакларга, акрын искән җилдә чайкалган камышларга карап, бер үксеп еладым. Эчемне бушатканчы. Шунда авыр уйларым да тарала төште. Инде ныклы адымнар белән юлымны дәвам иттем. Алда мине серле, зәңгәр ераклыклар, гөрләп торган зур шәһәрләр, яңа тормыш көтә иде.

* * *

Магнитогорск! Минем өчен әле дә булса бик кадерле, хәтта, әйтер идем, изге бер кала. Ул мине бер дә тарсынмыйча үзенә сыендырды. Зур хезмәт коллективы эченә алды һәм иң кадерлесе, намус белән, тир түгеп, күңел салып эшләргә өйрәтте. Мине кеше итте, шәхес һәм, ниһаять, язучы итте! Меңнәрчә тапкыр кабатланган хакыйкатьне тагын кабатлыйм: кешене намуслы эш, хезмәт коллективы гына чын кеше итеп тәрбияли ала. Мин бу калага мең рәхмәтле.

Магнитогорск — элекке СССРда һәм бөтен Европада иң дәү һәм куәтле металлургия комбинаты булган, бөтен дөньясына мәшһүр шәһәр. Шуңа күрә укучыга аның турында бераз иркенләп сөйлим әле. Шәһәр көньяк Уралда, шактый биек Магнит тавы янәшәсендә. Магнит тавы дип шуңа әйтәләр, бу таудан чыккан тимер рудасында зур тарту көченә ия булган магнит кисәкләре бар. Мондый магнит кисәген учыңа салып зуррак тимер әйбергә якын китерәсең икән, ул синең кулыңнан очып тимергә үзе барып ябыша.

Беренче бишьеллыклар, безнең бабайларның социализм төзибез дип җан атып, үз-үзләрен аямый эшләгән вакытлары! Гаҗәеп вакытлар, кызыклы вакытлар! Киләләр безнең бабайлар 1930 елда Магнит тавы итәгенә. Үзләре өчен палаткалар гына куялар да: «Менә монда тимер юл вокзалы булыр!», «Монда — металлургия комбинаты», «Монда шәһәр сала башларбыз! — дип, казыклар кагып чыгалар. Кулга көрәк, кәйлә алалар да, үзләре торыр өчен бараклар сала, комбинатны, беренче домна мичләрен төзи башлыйлар. Җиңне бик әйбәтләп сызганып, учка төкереп эшлиләр бит әле. Һәм тагын бик кызыклы, гыйбрәтле нәрсә бар. Җирне иң күп казучылар, бетонны иң күп салучылар арасында иң алгы сафта атлаучылар безнең татарлар булган! Норманы берничә тапкыр арттырып үтәү үзе норма булган. Шәһәр халкы арасында татарлар әле дә булса күп, алар биредә әле дә булса ихтирамлы.

Әмма бу — мәсьәләнең бер ягы гына әле. Аның икенче ягына килгәндә, монда беренче көннәрдән бирле үк яшәүчеләр сүз арасында: «Бу комбинат кеше сөякләре өстендә тора инде...» — дип тә сөйлиләр. Комбинатны салучыларның зур күпчелеге Сталин лагерьларыннан бирегә куып китерелгән тоткыннар, уголовный җинаятьчеләр булган. Эшләгәндә кысылып, басылып үлүләр, үзара үтерешүләр тулып яткан. Илнең югары түрәләре төзелештә көчле сак астында гына йөргәннәр. «Нарком С. Орджоникидзе еш кына үзе килеп төшә. Йөри комбинат буйлап. Алдыннан ике кеше, артыннан икәү кулларына наган тотып, аны саклап йөриләр. Ул кешеләр белән дә шул койма эченнән генә әңгәмә кора иде. Аңа якын килә алмадык...» — дип сөйлиләр өлкәннәр. Эшләп алган акчаларын бишмәт җөйләренә яшергән казахларны, кыргызларны уголовный җинаятьчеләрнең талавы, үтерүе, ә тегеләрнең исә алардан җыелышып үч алуы гадәти хәл булган.

Шәһәр үзе Азия белән Европаны аера торган Урал суының ике як ярына урнашкан. Сул як ярда, ягъни Азиядә булып чыга инде бу, Магнит тавы, аның итәгендә иске бараклар, арырак металлургия комбинаты үзе җәелеп киткән. Комбинат бииһая зур, аны әйләнеп йөреп чыгасың булса, кырык чакрымнан да артып китә, диләр. Дистәдән артык гаять биек домна, илледән артык мартен мичләре. Кызган тимерне яньчеп юка ак калай, рельслар, балкалар, тагын әллә ниләр ясый торган, озынлыклары бер километрга җиткән прокат станнары. Комбинат күккә көнетөне кап-кара, сары, хәтта яшел төстәге төтен болытлары бөрки, аның әшәке исе тирә-якка уннарча километрларга тарала. Хәтта самолетта очып килгәндә дә пассажирлар: «Әһә, Магниткага да килеп җитәбез. Аның тәмле исләре монда да менеп иреште!» — дип куялар. Шихта, ягъни күмер, руда кебек нәрсәләр салганда домна мичләренең өске капкачлары ачылып китә. Шунда мич эченнән күк күкрәгән тавышлар белән газ атылып чыга. Аяз көнне әледән-әле күк күкри төсле тоела бу. Төннәрен исә комбинаттан читкә чыгарып түгелгән утлы шлакның яктысы болытларга төшә, шәһәр урамнары да яктырып китә. Шулкадәр яктыра, рәхәтләнеп газета укый аласың. Комбинат эчендә атлаган саен тимер юл, паровозлар, электровозлар йөреп кенә тора. Өстән тимер тузаны ява, гаять авыр, кызыл күгәрекле тузан. Ул шулкадәр мул ява, вакыт-вакыт тимер юлларны тузаннан арчып торырга мәҗбүр булалар.

Уң як ярда, ягъни Европа өлешендә урамнары киң итеп салынган, гөрләп торган хәзерге заман шәһәре. Металлурглар проспекты аеруча матур. Анда машиналар бөтенләй керә алмый, уртада — бакча. Бакчаның рәшәткәләре, йортлардагы балконнар рәшәткәләре дә матур итеп, челтәрләп чуеннан коелган. Шәһәрнең тирә-ягы да бик ямьле. Уң як ярда, шәһәрдән күп булса 10—15 чакрымда Урал таулары башланып китә. Урман каплаган бу борынгы, бөкре таулар, зәңгәр болытларга охшап, ерактан ук күренеп торалар. Инде тау араларына чыгып китсәң, үзәнлекләрдә зур-зур, гаҗәеп матур, балыклы күлләр күп. Сул як ярда исә, Магнит тавын үтеп китсәң, бодай бик уңа торган Оренбур далаларына барып тоташкан тигезлекләр җәелеп китә.

Менә шундый шәһәр ул Магнитогорск.

Әмма минем әлегә шәһәр ямен дә, тегесен-монысын карап йөрергә дә вакытым юк. Миңа ничек тә булса җәтрәк эшкә урнашырга кирәк. Комбинатның үзендә дә, башка заводларда да эш бар анысы, мине, урта белемле кешене, бригадир итеп тә аласылар. Тик менә, якын арада гына бер дә фатир вәгъдә итмиләр. Ә миңа, гаиләле кешегә, җәтрәк фатир кирәк. Абый хатыны белән үзе бер бүлмәле фатирда яши, анда һич сыеныр әмәл юк.

— Син төзү трестына барып кара әле. Анда фатирны озаклатмыйлар иде, — дип киңәш бирделәр миңа.

Бардым. Төзү трестының кадрлар бүлеге мөдире Сало дигән сәер фамилияле, богыл чаклы гәүдәле, ярты метр борынлы бер яһүд икән. Ул

минем язуларымны алып карады да, май баскан күзләрен миңа текәп, мәсхәрәле елмаеп куйды:

— Урта белем белән кара эш эзләп йөрим диген инде, ә? Без, карт большевиклар, өч класс белем белән дә шушы урындыкта әле менә! — һәм Сало, бик горур кыяфәттә, үзенең биниһая зур күн урындыгын киң учлары белән шапылдатып алды.

«Анысы шулай инде. Һәр җылы урынга сез — карт большевиклар кереп оялаган инде. Югыйсә, син капкорсак кара эшкә барып, синең урыныңа менә мин менеп утырырга тиеш тә бит!» — дип әйтәсе бик килгән иде дә, тик ничек йөз ертасың. Шунда ук ишектән кире борып чыгарачак бит.

— Паровозга барасыңмы? Кочегар булып? — диде Сало кинәт.

Әнекәем! Паровозга, кочегар булып... Арча белән Казан арасында ул заманда йөргән поездларның паровозында эшләгән кешеләрне минем күргәләгәнем, кызыксынып карап торганым да бар иде. Караның карасы, пычракның пычрагы инде. Бөтен киемнәре, хәтта битләренә кадәр күмер тузанына, майга буялып беткән, шайтан төсләләр. Мин дә шулай итеп кеше өркетеп йөрермен микәнни? Бик аптырашта калдым мин. Шунда арттан берәү минем кабыргама төртте:

— Син... риза бул, егет. Ничего, әйбәт эш ул.

— Бераздан машинист ярдәмчесе, аннары машинист үзе дә буласың! — дип куәтләде Сало да.

— Ярый, барырмын паровозга... — дидем мин.

Шул көнне үк миңа эш киемнәре дә бирделәр. Икенче көнне иртәгесен эшкә чыгарга куштылар.

Сез инде монда гаҗәпләнерсез. Төзү трестында нинди паровоз булырга мөмкин әле? Мөмкин икән шул. Магнитогорск шәһәрен, андагы комбинатны һәм яңа заводларны төзи торган трест шулкадәр зур һәм кодрәтле ки, аның меңләгән машиналарыннан тыш үз тимер юлы, утыздан артык паровозы бар. Җәмгысе өч йөз километрдан артмаган бу юл ком һәм чуерташ карьерларына, кирпеч заводларына, йортлар төзү комбинатына һәм бүтән шундый урыннарга керә, хәтта җитмеш чакрымдагы урманга бара. Аның металлургия комбинаты эчендә үз депосы, әйткәнемчә, утызга якын паровозы, йөк төяү-бушату службалары, әллә ничә станциясе бар. Боларның бөтенесендә меңнән артык кеше эшли.

Паровоз! Һич кенә дә җансыз тимер тавы, җансыз нәрсә түгел икән бу машина. Минем аңа моңарчы игътибар салып, җентекләп караганым гына булмаган икән. Янына килеп басу белән мин аның никадәр олпат, куәтле машина икәнен тоеп алдым. Ниндидер бер терелек, кайнарлык бәреп тора иде аннан. Гүяки ул баскан урынында тасырдап, алга томырылып китәргә әзер торган ярсу чаптар! Сәер тоелса да әйтим әле, кеше үзенең акча эшләп ала торган эш коралына, җөмләдән, очучы үзе утырып зәңгәр киңлекләрдә очкан самолетына, озын юллар буйлап йөкләр ташыган шофер үзенең автомашинасына, хәтта үз эшенең остасы булган токарь станогына гашыйк булырга мөмкин. Кеше бит үз гомеренең яртысын эш коралы, машиналар белән маталанып үткәрә, аларга инде җансыз әйберләр дип түгел, ничектер, үзен тыңлый, хәтта аңлый торган җан иясе кебегрәк карый башлый. Үзем утырып эшлисе ЭМ серияле зур, куәтле йөк паровозына мин дә беренче күрүдә үк гашыйк булдым. Ялтырап торган озын, сылу, чем кара гәүдәсе, ап-ак кыршаулы кызыл тәгәрмәчләре белән ул миңа ниндидер әкияттәге баһадир кара айгырны хәтерләтте. Бераз алгарак китеп әйтим, паровоз мине иренмәскә, тәртипкә, төгәллеккә өйрәтте.

Өстәвенә, мин беренче көннән үк кызыклы, күпмилләтле, бердәм бригадага килеп эләктем. Безнең машинист Александр Гамп — миннән берничә яшькә генә олы, какча йөзле, урта буйлы, җете зәңгәр күзле кеше, руслашкан немец. Машинист ярдәмчесе, чандыр, җиңел гәүдәле, йөзенә шадра кагылган Иван Чурилов — урыс кешесе. Калын, салынкы

кашлы, караңгы чырайлы, поездлар төзүче Петр Кутько — украиналы. Һәм аларга мин — татар килеп кушылдым. Һәм, соңыннан ничә еллар бергә эшләп, безнең арада милләт аерымлыгын сизүче булмады, бу турыда беркем дә башына да китермәде. Мин үземә кемнең дә булса «татарин!» дип төрттергәнен хәтерләмим.

— Мин — машинист ярдәмчесе! — диде Иван Чурилов, бармагы белән күкрәгенә төртеп. — Ә син, матур егет, — кочегар. Димәк ки, ярдәмченең ярдәмчесе буласың. Димәк ки, син мин кушканнарны берсүзсез үтәргә тиеш! — диде Иван үзенең ачы, кискен тавышы белән һәм мине эшкә өйрәтә башлады. Тендерның як-ягындагы зур тимер кесәләрен ачып күрсәтте.

— Менә монда чүпрәкләр. Алар ни эшкә инде? Алар бөтен машинаны, тәгәрмәчләрне чиста тоту өчен. Кочегар ул вакыты булган саен машинаны сөртеп, чистартып, яшь кызлар төсле матур итеп тотарга тиеш. Чөнки машина аның тамагын туйдыра, аңа акча эшләп алырга булыша! — дип сөйләнде Иван һәр сүзен фәлсәфи төстә сузып. — Менә бу кесәдә инде май савытлары. Кочегар паровозның буксыларын һәрдаим тикшереп тора. Аларда май бетә икән, шунда ук май сала. Буксыларның мае бетә икән, барган көйгә алар кыза башлый, ут кабуы да бик ихтимал. Ул чакта инде күчәрләр кызып, хәтта сынып китәргә дә күп сорамый. Ә нәрсә, була шундый хәлләр! Бу инде — һәлакәт дигән сүз. Бу инде безгә бер дә кирәкле эш түгел. — Иван сүз арасында миңа карап-карап алды. Тавышы бик катгый булса да, аның күзләре көлемсери иде.

Тимер баскычтан будкага күтәрелдек. Монда үзе бер тамаша! Әллә нинди, терсәктәй бөгелгән юан торбалар, нечкә генә, ялтырап торган җиз торбалар, нәкъ сәгать кебек манометрлар, җиз тоткалар, тагын әллә нәрсәләр. Паровоз будкасы үзе вагон эче шикелле чиста, якты, матур, шактый иркен дә икән. Тик менә бик эссе, бөркү. Биек топкадан, торбалардан кайнарлык бөркелә. Топка капкачын ачып җибәргән саен андагы ялкын күзләрне камаштыра...

Бар икән әле күрәселәр!

Иван мине будканың арткы өлешенә алып чыкты. Монда тендердан иркен тимер улак кергән. Улак тулы вак күмер, шунда ук көрәк ята. Кыска саплы, кырыйлары күтәрелеп торган киң, бик җилле көрәк.

— Менә бу инструмент бәлки сиңа таныштыр да. Әйе, көрәк бу! Кочегарның төп эш коралы. Ә ул көрәккә күбрәк тутырып алырга һәм дә ераккарак ташларга! Монысы инде кочегарның төп кагыйдәсе була. Әнә анда өстә — сәндәрә. Бик иркен, җылы, җайлы урын. Туктап торган араларда ял итә аласың. Акыллы кочегар, матур егетем, бу форсатны да кулыннан ычкындырмый, — дип сөйләнде Иван һәм тимер ишекне ачып җибәрде дә мине тендерга алып чыкты. Монда күмер тавы күтәрелеп тора, озын саплы көрәкләр, ломнар ята иде. — Без бер алганда унике тонна күмер алабыз, егеткәем. Бу инде кочегарның байлыгы. Кайчак ул шушы унике тонна байлыкны смена ахырына кадәр улакка ташлап та бетерә. Ул кичне инде аның йокысы, әлбәттә, бик тәмле була. Ә менә бу капкачларны ачып, без тендер багына су алабыз. Безгә, бер алганда, аз да түгел, күп тә түгел, егерме сигез тонна су кирәк. Ә моның чаклы су бер генә авыл коесына да сыя алмас иде... Суны алып бетерүгә, кочегар бер дә онытмыйча бакка антинакипин брикетлары ташлый. Юкса, пар казанына хәзер юшкын утыра!..

Ай-яй! Болар барысы да мин башкарасы эшләр микәнни?!

Ул арада нииндидер кәгазьләр тотып, Петр Кутько станциядән килде. Машинист Сашка ул кәгазьләргә күз салды да, кычкырып әйтте:

— Кузгалдык! Песчанныйга! — һәм каршысындагы озын саплы регуляторны ачып җибәрде.

Паровоз бөтен гәүдәсе белән дер селкенде, гаять зур җанвар шикелле тавышланып, шаулатып топкадан утлы һава тартып алды, морҗадан югарыга ак йомарламнар атылып чыкты, тәгәрмәчләр дөбердәп бер

урында әйләнеп алдылар да, бөтен поезд акрын гына кузгалып та китте. Мин артка шуа башлаган станция биналарына күз салып, тәрәзә янына бастым. Тик шунда ук ачы тавышлы әмер ишетелде:

— Марш тендерга!

Беренче көнне мин үзебезнең кайларда йөргәнебезне, нинди станцияләрдә туктаганыбызны сизмичә дә калдым. Паровозга ниндидер составлар тактылар, поездлар төзүче Петр кискен итеп үзенең сыбызгысын чырылдатты, Сашка гудокны үкертте. Машина көчәнде, чаш-пош килде, бер артка чигенеп, бер алга ыргылып булса да авыр поездларны урыныннан кузгатты. Аннары инде гөрләп, шаулап тизлек алды. Киң күкрәге белән һаваны ярып, югарыга аксыл төтеннәр бөркеп, алга ашыкты.

Ә мин исә боларның барысын да юньләп күрмәдем, бары тик тойдым гына. Мин, тәгәрмәч эчендәге тиен кебек, тендер белән будка арасында әйләнәм. Тендерга чыгып, күмер тавы өстенә үрмәлим, киң улакка күмер ишеп төшерәм. Ә Иван ул күмерне топканың кызыл авызына озата. Бөтен көченә алга барган машина күмерне ашый гына. Монда күмер вагы бураны уйный, барган көйгә тендер як-якка чайкала, аяк өстендә чак кына басып торасың. Кайчак абынып егыласың да терсәкләр, тезбашлары бәрелә. Башны бик югары күтәрсәң, күңелгә шик тула, бау кебек юан контакт чыбыгы шунда якында гына шуа... Ул арада дөбер-шатыр арасыннан Иванның ачы тавышы ишетелә:

— Су алабыз, әзер бул!

Паровоз су алу урынына килеп туктауга, мин авыр тимер җиңсәне тендер коесы авызына тартып китерәм. Җиңсәдән шунда ук коега гөрләп су коела башлый. Бак эченнән минем тирләгән йөземә, күкрәгемә рәхәт салкынлык бәрелә. Анда кайнаган күбекләргә карап, уйга калам. Әмма шунда ук яңа әмер ишетелә:

— Кое капкачын яп. Хәзер кузгалабыз.

Менә шулай икән ул, агаем. Тимер юлда барысы да тиз һәм төгәл эшләнә, һәр минут исәптә икән шул.

Менә паровоз ниндидер станциядә читтәге бер юлга, тупикка килеп керде.

— Хәзер, матур егет, топканы чистартабыз,— диде миңа Иван.

Әбиеңне өшкерим! Моңа кадәргеләре пүчтәк булган икән әле аның. Менә топка чистартулары икән... Иван будкада кулына үзе озынлыгындагы тимер ачкыч алды да шул ачкыч белән дөбер-дөбер итеп топка төбендәге колосникларны селкетә башлады. Ә тегеннән топка астындагы тимер әрҗәгә кайнар көл, утлы шлак коела. Мин исә кулыма озын тарткыч тотып, түшем белән шуышып, машина астына кереп киттем. Шунда яткан көе әрҗәдәге утлы шлакны җиргә тартып төшерәм. Монда көл бураны, биткә шлак ялкыны бәрелә, өстемә кайдандыр кайнар су коела... Тәмуг, теге, әбиләр сөйләгән тәмуг үзе икән монда! Җитмәсә, мине бер курку биләп алды. Андый-мондый ялгыш кына бу паровоз урыныннан кузгалып китсә?! Мине утлы шлакка сылап тәбикмәк ясаячак бит ул! Унбиш минут чамасы дәвам итте бу тәмуг. Көлгә, тузанга коенып, паровоз астыннан чыкканда мин шундый хәлдә идем ки, дусларым күрсәләр, мине танымаслар иде бот чабып көләрләр иде.

Инде смена ахырына таба, тукталып торган араларда Иван мине кочегарның тагын бер зур эшенә — паровозны сөртеп чистартырга өйрәтә башлады...

Сменаны тапшыргач безне, өсте ябулы махсус машинага утыртып, үзебезнең депо каршындагы мунчага алып кайттылар. Мунча кереп, өс киемнәрен чистага алмаштык. Юкса, паровозда эшләгән кием белән ни трамвайга, ни башка транспортка утырырлык түгел. Шәһәр Советы башкарма комитетының махсус карары бар икән. Тимер юлчыларны эш киеме белән шәһәр транспортына утыртмаска! Чөнки аларның бүтән кешеләрне буявы ихтимал.

Беренче тапкыр эштән кайткан көнне мин абыйлар торган йортның баскычыннан көч-хәл белән генә атлап мендем. Аяклар тәмам авырайган, тезләр бөгелеп-бөгелеп китә, баш буш тубал сыман булып, гүләп тора. Никадәрле урыннарда эшләп, беркайчан да бу тикле арыганым, талчыкканым юк иде шикелле.

Тимерюлчылар унике сәгатьле бер сменаны көндез, ә аннары икенчесен төнлә белән эшлиләр. Төнлә эшләүләре тагын да авыр булып чыкты. Төнге сәгать дүрт-бишләр тирәсе җиттеме, үтереп йокы килә башлый. Прәме тәки бер газап. Тукталып торган арада аз гына кая да булса артыңны төртәсең икән, шунда ук йокы басып, күзгә әллә нинди тамашалар, әкәмәтләр күренә башлый.

Алай да мин, акрынлап булса да, бу яңа эшемә күнегә төштем. Инде дә бит эш урынын алмаштырып йөри алмый идем... Әмма, чир китә, гадәт кала, диләр. Миндәге элекке ялкаулык, наянлык тагын баш күтәрде. Аеруча Иванның ачы тавышыннан, һаман саен әмер биреп торуыннан тәмам туйдым. Аннан, кайбер нәрсәләр бер дә мәгънәсезгә эшләнә кебек тоелды миңа. Әйтик, ул тәгәрмәчләрне, пар машинасын алдан-ала ни пычагыма кат-кат сөртергә? Смена тапшырыр алдыннан бер сөртеп кую да бик җиткән бит. Казанны да гел ялтыратып тору кемгә хәҗәт?.. Кыскасы, мин үземчәрәк эш итәргә булдым. Бервакыт Иван Казанны сөртеп төшәргә кушкач, мин бик ашыкмадым.

— Син нәрсә, егеткәем? Ишетмисеңме әллә?—диде Иван, бу хәлгә бик гаҗәпләнеп.

— Ишетәм. Тик мәгънәсезгә селкенәсем генә килми,—дидем илтифатсыз гына.

— Ничек... мәгънәсезгә? Ник мәгънәсезгә?—дип чекерәйде Иван.

— Соң, сменага кадәр өч сәгать бар бит әле. Алай бик ашыксаң, әнә үзең сөрт. Синең дә ике кулың бар бит!—дидем мин кыза башлап.

Иван каршыма ук килеп басты. Карчыганыкыдай җете күзләре белән текәлеп торды да кинәт кенә... яңак төбемә чалтыратып җибәрмәсенме?! Бик җилле итеп селтәнде, күземнән яшел утлар чыкты шикелле.

Мин үзем табигатем белән шактый юаш, басынкы кеше. Әмма, үземне хаксызга рәнҗетелгән санасам, һәр юаш кешеләрчә, минем дә ачуым дөрләп кабына. Аннары инде ни эшләгәнемне белештерми башлыйм. Иванның китереп сугуы булды, мин будка стенасына элеп куйган тимер кисәүне тартып та алдым. Икенче мәлдә үк тегенең эше харап иде. Ярый әле машинист Александр минем кулымнан эләктереп өлгерде. Кисәүне тартып алды да урынына элеп куйды.

— Ну, Радик, болай ярамый! Син үзең әйбәт егет күренәсең, ә менә эшкә ихласыңны күрмим әле мин,—диде ул, зәңгәр күзләрен миңа текәп.—Иван артыгын кызып китте анысы. Әмма мондый хәлгә син аны үзең китердең... Мин бу хәлне начальствога җиткерми торам әле. Тагын шулай кылансаң, әйтми дә булмас...—диде ул.

Икенче сменага мин инде башкачарак уйлар белән килдем: артыгын алай бик акыллы баш булмаска, иренмәскә, үземнән югары торганнарның сүзен үтәргә. Тора-бара әнә шулай булырга күнектем, апакаем. Тора-бара бөтен бригада миңе үз итте.

— Яңа кочегар ничегрәк?—дип сораучыларга, Иван мине мактап:

— Улакта һәрвакыт күмер, бакта су, смена ахырына машина ялт иткән була!—дип кенә җиффәрә башлады.

Ярый, эшләп йөрим шулай бер көе. Инде Магнитогорскига килгәнемә дә бер-ике ай булды. Мин инде авылда калган хатыным Дамира, кызым Венера өчен борчыла, аларны бик тә сагына башладым. Җәтрәк монда китерәсе иде аларны. Әмма бит абыйларның торган фатиры үзләренә дә тар... Киттем шәһәр буйлап фатир эзләп.

Бу калага, металлургия комбинаты төзелешенә 1930—31 елларда «кулак» дигән исем тагып, авыл җиреннән бик күп крестьянны куып китергәннәр. Башта алар палаткаларда, ә аннары ашык-пошык салынган

кысан баракларда көн иткәннәр. Тик бу эшчән, булдыклы, хәйләле кешеләрдә авылның иркен тормышын сагыну, җиргә, туфракка тартылу тойгысы бервакытта да сүнмәгән. Алар ниндидер юлларын һәм җаен тапканнар, начальствоны сыйлап-сыйпаганнар һәм... Урал суының уң як ярында төзелгән яңа шәһәр читенә үзләренә шәхси йортлар салып чыга башлаганнар. Азрак уңдырышлырак һәм комбинат сөременнән дә арырак урында. Йортларны нәкъ авыл җирендәгечә бер катлы һәм бик иркен, ә файда йөзеннән бер стенасын уртак итеп, ике гаиләгә берне торгызганнар. Йортлар янына шактый гына җир бүлеп алуга да ирешкәннәр. Менә шунда инде аларның үз дөньясы, кечкенә булса да үзенең шәхси биләмәсе, үзенең җаны сөйгән шөгыле. Нинди генә җиләк-җимеш, алма-чиянең нинди генә сортларын үстермиләр алар шушы бакчаларында! Хөкүмәт тә бөтенләй ук башсыз түгел бит әле. Әлеге крестьян агайлардан күрмәкче, ул да эшчеләр өчен нәкъ шундый йортлар салдыра башлаган. Шулай итеп, зур бер поселок хасил булган. Хәзер инде бу ап-ак стеналы йортлары чәчәкләргә, алма, чия, груша агачларына төренеп утырган, һәркайда авылның хуш исе аңкыган поселок һәм ул «куркульләр поселогы» дип атала. Куркуль — украинча кулак дигән сүз икән.

Мин бу поселокта фатирны тиз арада табып та алдым. Фатир хуҗалары Петр дәдәй белән Наташа түтәй куылып килгән кулаклар түгел, ә Украинадан үз теләкләре белән күченеп килгән кешеләр иде. Алар үзләренең йортларына терәп, махсус фатирга керту өчен янкорма ясаганнар. Күп булса ун квадрат метрлы, бер тәрәзәле, ашарга әзерләр өчен плитәсе дә булган бу бүлмәдә вакытлыча яшәп торырга бик була иде. Дамирага җәтрәк хат язып салдым. Ул да озак көттермәде, кечкенә кызны һәм юка гына чемоданын күтәреп, килеп тә җитте. Аның эшкә урнашуы белән бернинди тоткарлык булмады. Ул елларда кая гына барсаң да, эшкә чакырып белдерүләр эленеп тора иде. Дамира балалар бакчасына шәфкать туташы булып урнашты. Кызыбыз Венераны да үзе белән шунда алып йөрде. Шулай итеп без, гаилә булып оешып, бергә яши башладык. Безгә ул вакытта артыгы кирәкми дә иде.

Их, безнең татар, безнең бичара татар дип әйтим инде, кайларга гына таралмаган да, кайларда гына юк ул! Шушы куркульләр поселогында ук мин татарларны, хәтта үземнең якташларны очраттым. Кибеттән кайтып киләм бервакыт, каршыма бер агай килә. Татар агае икәне әллә каян күренеп тора инде, башында чигүле кәләпүш, сакалын түгәрәкләп кырган. Мин ике дә уйлап тормадым, агайга татарчалап дәштем:

— Исәнмесез, абзый кеше?

Татарча әйтелгән сүзләрне ишетүгә, абзыемның уйчан, шактый сүрән йөзе бердән ачылып, балкып китте. Ул барган җиреннән тукталып, елмайган күзләре белән миңа текәлеп карап алды. Аннары күрешергә ике кулын берьюлы сузды.

— Исәнме, улым?! Исәнме, балам!

Һәм кулларымны озаклап кысып, җибәрми торды.

Шундагы бер капка төбенә нәкъ авылдагыча озын итеп ясалган эскәмиягә утырдык. Минем бу агайдан сораштырасым, барысын да беләсем килә иде. Шуңа күрә, урам аша туп-туры дигәндәй, сүзне турыдан әйтеп эш итәргә булдым:

— Үзегез болай... гафу итәсез, китерелгән кешеме?

— Ә кәк же! Китерелгән, куып китерелгән кеше! — диде агай ниндидер бер горурлык белән.

Мин инде аңа кызыксынуымны яшермичә, текәлеп карадым. Менә, минем янәшәмдә тере тарих үзе утыра. Ләкин ул мәктәптә укытучылар безгә сөйләгәнчә, авылның канэчкеч бер комсызына, кеше талап баеган бер кулагына бер дә генә охшамаган иде. Инде үзе олы яшьтә булса да, әле нык инсәле, түгәрәк йөзле, спай гына күренә бу агай. Күзләрендә ниндидер хәйләле көлемсерәве дә бар. Исеме Сабир икән.

— Гафу итегез, Сабир абзый... Сез кулакмы? — дидем мин.

— Ә кәк же! Кулак, нәстияшши кулак булабыз без...— диде агай һәм үзенең бөрчекле күзләре белән миңа текәлеп торды. Аннан кинәт көтелмәгән хәл булды. Күңелендәге ниндидер авыр җәрәхәте ачылып, хәсрәте тышка бәреп чыккан кешедәй, агай авыр сулап куйды. Әле генә горур күтәрелеп торган иңнәре салынып төште.— Менә алайса мин дә сиңа бер сорау бирим әле, энем,— диде ул.— Йә, әйт әле, үз көчен куеп алты почмаклы йорт салган, бер сыер, ике ат тоткан кеше кем була ул? Авылның кеше хакына кереп баеган кулагымы, әллә җир хуҗасы булган крәстиянме? Менә шуны әйтеп бир әле син.

— Мин... белмим шул...— дидем аптырап.

— Менә белмисез шул сез. Ә сөйлисез, ышанасыз. Безгә, әти-бабайларыгызга шулай карыйсыз инде аннары...— диде агай ачыну белән.— Җә, әйт инде син, авыл җирендә торып ат-сыер да тота алмаган бәндә кем була инде ул? Дөньяның бер ялкавы, хөрәсәне бит ул. Ә инде ат-сыер тотасың, йорт-җирең юньле икән, син үзең дә яхшы чутта дигән сүз. Син җир хуҗасы, нәстияшши крәстиян бит. Никакуй кулак та, мироед та түгел. Менә бар да шундыйлар монда, энем. Шундый «кулаклар» монда, бик беләсең килсә! — диде ул һәм бик хәтере калган төстә кулын селтәп куйды:— Хәтә, ник сөйләп торам соң сиңа? Сез, хәзерге комсомоллар, барыбер моны аңламыйсыз лабаса...

Сабир агай шулай диде дә, кисәк урыныннан торып, үз юлыннан атлады. Минем белән хушлашмады да, борылып та карамады. Минем әле аның белән тагын сөйләшәсем, нәрсәләрдер сорашасым килә иде. Тик, ни хәл итәсең? Бөтен дөньясына хәтере калган агай артыннан эндәшсәң дә, кабат туктамас иде.

Бераз алга китеп әйтим, икенче тапкыр мин шундый куылып килгән татар агайны больницада яткан чагымда очраттым. Шул, һаман да ашказаны белән эләккән идем. Карыйм, янәшәдәге койкада тагын шундый ук чигүле түбәтәй кигән, кып-кызыл йөзле, базык, нык гәүдәле татар агае. Исеме Хәмит икән. Аңа минем сораулар әзер иде инде.

— Әйе, кулаклар булырбыз. Куылып килдек! — диде Хәмит агай һәм хикмәтле төстә көлемсерәп куйды. Ул кичкә кадәр, ара-тирә нидер әйтәсе килгәндәй, миңа карап-карап алгалады. Ә кичен инде минем янга килеп, янәшә утырды. Тагын сәер генә көлемсерәп куйды.

— Дөресен әйтимме сиңа, энем? — диде ул.

— Нәрсәне... дөресен? Нәрсә әйтәсез миңа? — дидем мин аны аңламыйча.

— Ә теге... кулак турында,— диде ул.

— Әйтеп карагыз.

— Оят булса да әйтим, берниндн хуҗа да, кулак та түгел мин. Бер батрак мин, хезмәтче,— диде ул һәм тагын көлеп җибәрде.

— Ничек инде... батрак? Ярлы кешене ничек сөрсеннәр монда? — дидем мин тәмам аптырап.

— Һе, ничек кенә сөрделәр әле! — диде Хәмит абзый һәм сөйләп китте:— Сүзем хак, чын батрак мин. Бөтен статьялары белән. Гаилә ишле иде, энем, ир балалар күп. Менә шулай итеп, мин үзебезнең күршедәге Гани абзыйларның эшен эшләдем. Ел тәүлеге буена. Җирен дә сөрдем, урагын да урдым, ашлыгын да суктым. Гани абзыйның үзе белән бергәләп инде, яңа ярдәмгә. Үзе дә корсак үстереп тик ята торган кеше түгел иде. Кая ул? Гани абзыйның карчыгы Сәхипҗамал апай сырхап киткәндә бергәләп сыерларын да сава идек. Бик акыллы кеше булды Гани абзый, ай-һай да акыллы кеше булып чыкты,— диде Хәмит абзый һәм башын чайкап, әллә кайчангыларны хәтерләп торды.— Кызык итләр алар сәвитне. Авылларда крәстиянне тузгыталар икән дигән хәбәр чыгуга, ашыгыч рәвештә бар мал-туарны, бөтен мөлкәтне сатты болар. Кара каршы ике йортны да җибәрмәкчеләр иде, тар арада хуҗа гына табылмады. Шунда Гани абзый миңа әйтте, «Бу йорт-җирне карап, бездә яшәп, саклап тор, Хәмит энем. Заманалар тынычланып, исән-сау әйләнеп

кайта алсак, бәхилләтермен үзеңне. Зур өлеш чыгарырмын!» — диде. Шул көнне алар авылдан чыгып юк булдылар. Ә икенче көнне үк өйгә күн киемле кешеләр керергә тулды. Кычкыралар: «Хуҗаларың кайда?» «Әллә тагын, әллә кая китеп юк булдылар алар»,— мин әйтәм. «Юк булсалар, әнә үзең әзерлән. Хуҗаларның исәбеннән без синең үзеңне раскулачить итәбез. Майт якаңны, безгә монда план җиткерелгән. Җыен хәзер үк!» — диләр тегеләр. Кулына алтатар тоткан, күзләрен кан баскан кешеләргә каршы кая барасың? Авылдан бер дә генә китәсем килмәгән иде юкса. Вәгъдәләр куешып йөргән кызым да бар иде... Менә шул фәрман белән мин монда инде. Аллага шөкер, егерме тугызынчы елым,— дип сөйләде Хәмит абзый һәм өстәп куйды:— Ярый әле, шушы Уралга куып китергәннәр. Рәхмәт советларга. Анда бит, колхозда калганнарны шушы көнгә тикле зерә бушка да эшләттеләр. Ә мин монда хәзер үзем Гани абзыйдан ару яшим. Йортым, бакчам, умарталарым — барысы да җитешле. Больнистан чыгу белән безгә кунакка кил! — диде агай кунакчыл итеп.

Кайчандыр бик нык җәберләнгән бу кешеләр сөйләгән нәрсәләр минем өчен моңарчы һич ишетмәгән, башка да китермәгән яңалыклар иде. Вәт сиңа кулаклар, кеше җилкәсен кимереп баючылар! Ай, бик катлаулы, аңлаешсыз бу дөнья.

— Ә үзегез Татарстанның кай тирәсеннән соң, Хәмит абзый? — дип сорап куйдым мин.

— Әтнә районы, Кытаймас...— диде ул.

Шайтан алгыры, бөтенләй дә якташлар икәнбез бит. Кытаймас белән безнең Дусым авылы арасы нибары алты чакрым.

— Ә мин Дусымныкы, Хәмит абзый.

— Шулаймы?! — диде ул бик куанып.— Әйе, Дусым..... Кытаймастан килгәндә Шашы тау башыннан матур булып күренә торган авыл. Безнең Кытаймас юллары... Югары Шашы зираты... Гел күз алдында, гел йөрәктә бит алар...— диде агай калтыранган тавыш белән һәм аның күзләренә яшь бәреп чыкты.— Син мине гафу ит инде, энем. Монда күпме генә шәбәйсәң дә, туган җир сагындыра шул ул. Кара гүрләргә кергәнче бер кайтып күрә аламмы?..

Һәм агай чал башын түбән иеп сүзсез калды.

Икенче мәртәбә без кичкә таба Дамира белән каяндыр кайтып килә идек. Шунда тар гына урамның каршы ягыннан барган, ак яулыгын ияк астына төшереп бәйләгән бер татар хатыны кинәт кычкырып җырлап җибәрде. Гаҗәп моңлы, матур тавыш белән, «Сарман» көенә! Яшь вакытында авылның оста бер җырчысы булгандыр бу апа. Аның җырында, аның тавышында яшьлеген, туган җирне, авылны сагыну, моңлану иде. Менә син, янәшәдә генә урыс дөньясы, урыс тавышы, зур шәһәр гөрли, трамвайлар, машиналар гөрелтесе. Ә монда, тар гына аулак урамда татар моңы — барча татар балачактан ишеткән, кая гына барса да, күңел түрендә йөреткән «Сарман» көен агыла... Без Дамира белән, барган җиребездән тукталып, җырны тыңлап тордык. Күңелләр тулды. Без дә бит туган җирдән аерылып киткән кешеләр.

Бу поселокта яшәп ятканда минем киләчәктәге тормышыма яңа эчтәлек биргән бер вакыйга булды. Яңа уй-хәсрәтләр, мәшәкать-борчулар өстәгән вакыйга. Әле авылда вакытта ук мин үземнең беренче шигыремне язып, аны Әтнәдә чыга торган район газетасына биргән идем. Үзебезнең авылдагы клуб мөдирен тәнкыйтьләп язылган булганга, мин аңа үз фамилиямне түгел, ә «Р. Бикташев» дип имза куйдым. Ул шигырь басылып та чыкты, авылда аны: «Кем язган да кем язган?» — дип, беләселәре дә килеп йөрделәр. Әтнәдә саклык кассасында эшләгәндә без бухгалтер Әхәт Фазылҗанов белән дуслашып алдык. Әхәт, үзе дә чая, үткер егет, ул чакта ук инде кыска гына, үткер генә хикәяләр яза, аны Казан газета-журналларында да бастыра иде.

Шул Әхәт дустан хат алдым. «Монда «Татарстан яшьләре» газетасы кыска хикәяләргә ярыш игълан итте. Темасы: «Яшь эшченең производст-

вога килүе». Син шигырьләр язгалый идең бит. Әйдә, хикәягә дә тырышып кара. Үзең дә эшче кеше, алар тормышын белми калмассың. Сынап кара бәхетеңне!» — дип язган иде ул.

Шунда инде минем тынычлык дигән нәрсәләрем бетте. Җилләр исте күңел тынычлыгыннан! Бик нык уйга калдым. Мин үзем китаплар, аеруча хикәяләр укырга бик яратам инде. Ә менә үзем тотынсам, яза алырмын микән бер хикәя? Нинди вакыйга табарга, төп герой итеп кемне алырга? Күп эзләнә, баш вата торгач, бик гади бер карарга килдем: тотарга да менә үзем турында язарга! Ничек итеп паровозга эшкә килүем, анда беренче көннәрдә күргәннәрем, ару-талуларым, тора-бара ияләнеп китүләрем турында.

Үземнең ял көне, Дамира эштә. Алдым кулга кәгазь, каләм, утырдым өстәл янына килеп. Хәзер хикәя яза башлыйм!.. Уйлыйм, инде язарга дип кулымны да кузгатам, әмма... ак кәгазьгә бер генә сүз дә, җөмлә дә төшерә алмыйм. Нидән башлап китәргә соң бу хикәяне, нинди сүздән, геройны хикәягә ничек алып керергә? Ә үзе нинди егет соң әле ул герой дигәнем? Ике сәгать утырдым, ярты кап папирос тартып бетердем. Булмый гына бит! Бу нинди хәл инде бу?! Әнә кешеләр нинди ансат яза, аларның герое да хикәягә ничек җиңел килеп керә, ничек табигый төстә йөри, сөйләшә... Юк, булмастайга хыялланам икән мин, миннән була торган эш түгел икән бу. Миңа шул әнә тендерда күмер көрәүдән узасы түгел икән... Беренче көнне, беренче талпынуда мин берни дә майтара алмадым. Утыра торгач үз-үземә җенеп чыгып, алдымдагы кәгазьләрне ертып ташладым да, шуның белән эш бетте.

Икенче ялымда ук мин кулга тагын каләм алдым. Чәнчелеп киткере, тагын берни барып чыкмый... Шунда, тар бүлмәдә әрле-бирле йөренгәндә, минем күзем стенага беркетелгән кечкенә көзгегә төште. Аннан миңа авыз-борыны салынган, тәмам сөмсере коелган бер йолкыш бәндә карап тора иде. Шунда... минем баш миендә нәрсәдер «келт» итте, нindидер кискен хәрәкәт, революция булды минем башта! Тукта әле, кайда тора бу кечкенә генә көзге? Юк, кечкенә түгел, зур көзге, кеше буе көзге бу. Тар, тынчу бу бүлмәдә түгел, ә начальникның иркен, якты бүлмәсендә тора ул. Һәм аннан карап торган кеше дә бер йолкыш бәндә түгел, ә оялчан, алсу йөзле, киң иңсәле, таза беләкле яшь бер егет. Яшь эшче! Әһә! Ә нәрсәгә дип кергән әле ул начальник бүлмәсенә? Әлбәттә инде, гариза бирергә, үзен эшкә алуларын сорап. Тукта әле, нәкъ менә минем хикәянең башы түгелме соң бу, шулай яза башласаң, ярый түгелме? Һәм мин, инде шактый җиңел генә һәм тиз тотып, беренче җөмләләрне кәгазьгә төшердем. Аннан инде эш авырайды, тик кармаланып-акрынлап булса да алга киттем. Әлбәттә, вакыйгалар нәкъ тормыштагыча бармады. Әллә кайчан вафат этием терелде, ул укытучыдан карт эшчегә, инде пенсиягә чыккан паровоз машинистына әверелде. Дамира исә әлегә бөтенләй читтә калып торды. Мин үзем дә моңарчы бөтенләй зимагурлыкта йөрмәгән, әле генә урта мәктәпне бетереп чыккан, кыяр кебек чиста һәм ямь-яшел бер егеткә әйләндем. Ә Александр белән Иванны үзгәртеп торуның да кирәге булмады. Алар тормышта үзләре нинди кеше булсалар, хикәя битенә шул килеш диярлек кереп тә киттеләр. Мин әлләни озынга сузмыйча хикәяне язып тәмам да иттем, Казанга җибәрдем.

Җибәрдем дә, өметләнеп көтә дә башладым. Берни барып чыкмагандыр, дигән курку да зур, әмма өмет тә шул чама. Унбиш көн көтәм, бер ай. Көтә торгач, ике-өч ай да үтеп китте. Шунда инде минем өмет тәмам өзелде. Әлбәттә инде, шундый гади бер вакыйгадан нинди хикәя килеп чыксын ди? Әдәби әсәр! Миндә — зимагурлыкта йөргән бер фәкыйрьдә, нинди сәләт булсын. Әдәби әсәрләрне аны табигать анабыз үзе мул итеп талант биргән, бөтенләй үзгә рухлы, икенче калыптагы кешеләр генә яза ала торгандыр. Үземнең ыштыр йөзем белән алар рәтенә мин үреләм тагын. Эшле кешеләрне борчып, Уралдан Казанга тикле хикәяләр җибәргән булып. Бетмәгәндер анда үз язучылары... Һәм мин ни дә булса

көтүләремә, үземнең язу турындагы уйларыма нокта куйдым. Бердән тынычланып, иркенләп тә киттем.

Тик һаман да шул язмыш дигән нәрсә бар бит әле. Язмыш мәсьәләне икенче төрле хәл итте дә куйды. Бер кичтә эштән кайтсам, Дамира мине баскыч төбендә үк көтеп тора, кулында ниндидер газета, үзенең авызы колагына җиткән. Газетаны тиз генә кулыннан тартып алдым. Үземнең йөрәк дөп-дөп тибә. Җәтрәк карыйм: «Татарстан яшьләре»! Әһә, кайда менә дүртенче бит. «Р. Бикташев. Беренче адымнар. Хикәя». Минем хикәя! Газета битендә мин азапланып уйлаган, мин төзегән җөмләләр... Шунда ук баскыч төбендә утырып хикәямне рәттән ике кат укып чыктым. Менә бит, башкаларның хикәясе төсле. Бер җөмләсен дә үзгәртмәгәннәр диярлек, үзем ничек язсам, шулай басканнар да. Нәкъ урта бер төшендә рәсеме дә бар хәтта. Бер яшь егет паровоз топкасына күмер ташлый. Анысы да үземә охшаган кебек...

Бу минутларда мине биләп алган куанычны, шатлыкны сез дә хис итә алсагыз икән! Бу минутларда дөнья минем өчен шулкадәр матур, якты, аның һәр почмагы, хәтта инде безнең тәбәнәк түшәмле кысан бүлмәбез дә иркен, бәхет белән тулы иде. Үзенең беренче әсәре газета битендә басылуның ниндәен шатлык икәнен шул шатлыкка ирешә алган кеше генә тулысынча төшенә ала торгандыр.

Газета белән бергә конвертта тагын бер язу бар иде. Анда бу хикәянең ярышта катнашып икенче урынны алуы, моның өчен миңа дүрт йөз сум бүләк тә билгеләнгәне хәбәр ителгән иде. Монысы өчен инде, үземнән дә битәр, Дамира куанды.

Менә шуннан соң инде мин вакыт тигәндә аз-маз хикәяләр яза башладым. Шунысын да әйтим, әдәбиятка инде мин шактый соңарып килдем. Бу беренче хикәям чыкканда миңа егерме җиде яшь иде. Бераз алгарак китеп әйтсәк, гомерем буе шул, кыска хикәяләр яздым. Язучылык эшен үземә төп һөнәр итмәдем, гомерем буе кайдадыр эшләгән килеш яздым. Алай да бер дистә китап язып чыгардым. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булдым...

Ярый, без Магнитта, мин паровоз кочегары бит әле. Шушы тар фатирда безнең икенче кызыбыз — Светлана дөньяга килде. Тууына ике ай булуга, Дамира аны да култык астына кыстырды да, үзе эшләгән яслегә алып китте. Шулай итеп, безнең татар халкының чын бер фаҗигасе, туган җиреннән кубып читтә яшәргә дучар ителгән татарлар фаҗигасе безнең гаиләгә дә турыдан-туры кагылды. Ягъни татар язучысы гаиләсенә... Ясле дә барысы да рус балалары булганлыктан, безнең кызларыбызның теле ачылганда ук икесенең дә русча ачылды. Менә татарлар да: «Өйдә тәрбия, өйдә таләп!» — диләр. Пүчтәк сүз бу, үз башына төшмәгән кеше сүзләре. Без Дамира белән өйдә бер генә сүзне дә, гомер буена, русча сөйләшкәнебез юк. Һәрвакыт татарча, һәрвакыт тулы тавыш белән. Өстәвенә мин үзем, рус телен болай әйбәт белсәм дә, русча авыр сөйләшәм. Гомер буена акценттан котыла алмадым. Өйдә никадәр татарча сөйләшсәк, җырласак та, безнең балаларыбыз үз ана телләрен ярым-ярты гына белеп үстеләр. Инде үсеп җиткәч тә, тормышка чыгып, рус арасында яшиләр...

Бәхеткә күрә, без Наташа түтәйләрнең ул тар читлегендә озаклап яшәп ятмадык. Минем үземә трест карамагындагы барактан аерым фатир бирделәр. Бу баракларны әсирлектәге немецлар үзләренә торыр өчен салганнар. Гомуми коридор булса да, бүлмәләре шундый иркен, якты, тәрәзәләренә машина кереп китәрлек. Сала белгән немецлар.

Баракта яшәүләре! Гомерендә бер төрмәгә кермәгән кеше чын кеше түгел, дигән гыйбарә бар. Шуның шикелле, баракта яшәп карамаган кеше дә чын тормышны күрмәгән, аның төбенә, тирәнлекләренә төшеп карамаган, дияргә була. Баракта барча гаиләләр бергә яши, бер өстәл янына

утырып ашый, бергә талаша, бергә сугыша дияргә була. Чөнки монда бер гаилә белән икенче гаиләне юка такта койма аерып тора. Монда халыктан бернинди сер дә саклый алмыйсың, аерым гына, культуралы гына, бик инсафлы булып кына да яши алмыйсың. Баракта озак еллар көн итүдән бер аллам үзе сакласын! Ул тәкъдирдә инде ул сине, һичшиксез, эчкече, нервлары тузып, хәзер кабынырга гына торган җәнҗалчы, бер тупас нахал итеп тәрбияләп чыгара. Үзеңне дә, балаларыңны да. Рәсәйдәге барча халыкларның хәзерге бу тикле тупаслыгына, катлы-катлы итеп сүгенүенә, айнымас сәрхүш булуларына илне индустрияләштерү елларында салынган һәр шәһәр, шахта һәм комбинатлар, электр станцияләре янәшәсенә калкып чыккан хисапсыз бараклар да гаепле! Аларның тәрбиясе әле дә булса үзен сиздерә.

Кичләрен, барысы да эштән кайткач, барак кырмыска оясыдай кайный башлый, шау-гөр килә. Һәркем кычкырып сөйләшә, көндезге тәэсирләрне бүлешә, ашарга әзерли, су ташый. Болар барысы да озын бинаның бер башыннан икенчесенә кадәр аерым-ачык ишетелеп тора. Шуннан инде ашау-эчү, кайбер бүлмәләрдә мәҗлесләр, җырлап утырулар башлана, тозлы гына итеп сүгенеп алулар ишетелә... Болары гына пүчтәк әле, әлбәттә. Менә бервакыт:

— Каравыл, үтерәләр! Коткарыгыз, үтерә!—дип ачыргаланып кычкырган тавышлар ишетелә.

Каныңны катырырлык бу тавышка барча халык коридорга йөгереп чыга. Кая, кайдан бу тавыш?! Әһә, сигезенче бүлмәдә. Шәмси тагын Асиясен кыйный. Сигезенченең ишегенә ташланабыз. Бикле ишек, эчтән бикләнеп эш итә, сволочь!

— Ач ишегеңне җәтрәк!

Җавап юк. Үзәк өзгеч тавыш тагын кабатлана:

— Зинһар!.. Үтерә, харап итә!

Юка такта ишеккә җыелган халык төркеме бер орынып кына ала. Ул шунда ук шатырдап ачылып та китә. Идәндә — башын куллары белән каплаган, иң өстеннән күлмәге аерылып төшкән Асия. Аның өстендә — кулына камчы, әйе, каештан үрелгән чын башкорт камчысы тотып, ире Шәмси күтәрелеп тора. Тәбәнәк кенә, ябык, бер күзе кылый, бөтен маңгаен, битен ниндидер касмак баскан. Өтекнең өтеге. Бу мокытны читкә бәреп ташлыйлар, Асияне күтәреп торгызалар. Камчы белән суккан — Асияның иңбашында кып-кызыл эзе ярылып ята. Иреннән шактыйга яшь, гәүдәле, чем кара чәчле чибәр генә хатын тыела алмыйча җылый.

— Ни булды? Тагын ни бүлә алмадыгыз?

— Ачуым чыкты бу тәрегә. Йөрәгемә чыдый алмадым, җеннән туган нәрсә, дидем...

Кайсы да булса якны гаепләп яисә яклап беркем дә бер сүз әйтми. Бу инде — кеше арасына керү булыр иде. Сүзсез генә таралышалар. Җәза бирүченең кулын вакытында тотып калдылар, фаҗига булмады. Шушысы да бик җиткән. Тик шунда, халык арасында йөргән бала-чаганың гына йөзенә нәүмизләнү чыга. Алар бит зуррак, кызыклырак тамаша көткән иде...

Акрынлап барактагы шау-шу басыла төшә. Тиздән йокларга да вакыт. Иртәгә эшкә барасы бит.

— Уф-аһ! Үләм, ярдәм итегез!

Монысы инде уныньчы бүлмәдән ишетелә. Тавыш бик гаугалы, каза күрүченең эше харап булырга охшый, кермичә ярамый. Катя апа белән Михаил Петрович — ихтирамлы кешеләр. Катя апа кибетче, Михаил Петрович конторада эшли. Инде бараклан китәргә дә йөриләр. Ә алай да түзмәделәр, менә истәлек калдырдылар. Кичке ашны ашап утырганда низаг чыккан. Михаил Петрович, шактый кызу, көйрәк кеше, кулындагы чәнечкесе белән Катя апаның авызына тарткан. Апаның затлы күлмәгенә кан тама, өстәлдә башланган яртылы аракы тора.

Монда шәхси тормыш юк, ул була алмый. Монда һәркем уч төбендәге кебек. Мондагы гадәтләр, эчү, сүгенү, кыйналу нәкъ йогышлы авыру кебек, кешеләрдән бер-берсенә бик ансат күчә. Ә гадәтләр, аеруча эчүчелек, буа буарлык.

Дядя Гриша янына шахмат уйнарга керәм кичләрен. Дядя Гриша үзе инженер, әле чагыштырмача яшь кенә, чибәр, карап торырга инсафлы, зыялы гына кеше. Шахматны әйбәт уйный. Аның хатыны тетя Паша, иреннән шактый гына олы, шактый гына ямьсез, әмма телгә бик беткән, һәркем белән дус, әйбәт апа. Инде уллары белән кызлары житеп килә. Алар көн саен кич белән, Паша түтәй үзе әйткәнчә, «бер яртыны бөкләмичә» калмыйлар. Кызылны гына булса да. Әмма кайбер кичләрдә Гриша дәдәй өйдә булмый. Аны эзләп тә, аның өчен борчылып та тормыйлар. Чөнки барысы да белә: Гриша дәдәй Паша түтәй өстеннән йөри, бер яшь, матур хатын белән. Бүген ул сул як ярда, шул хатын янында кунып калган. (Алга китеп әйтим, Гриша дәдәй тиздән гаиләсен бөтенләй калдырып, шул хатын янына күчеп китте.)

Баракта кияүгә чыкмаган яисә чыгып та аерылган тол хатыннар күп. Алар янына кич саен диярлек әллә ниткән, күзләре тонган, кыяфәтеннән үк куркырлык ирләр килә. Кесәләреннән шешә башы күренеп тора. Китә эчү, хихылдап көлүләр, мәгънәсезгә әшәке итеп сүгенүләр... Их, артыгын язып та торасым килми шул барак тормышын. Әйтәм бит, бараклар — Сталин көчләп таккан казарма социализмының нигезе булды инде алар.

Тагын бәхеткә күрә дип әйтим, без ул баракта да озак тормадык. Ул елларда Магнитогорскида бик күп төзиләр, фатирны да дистәләгән еллар буена көтү дигән нәрсә юк иде. Эшли башлаганыма ике ел тулдымы икән, безгә бөтен уңайлыклары булган йорттан ике бүлмәле фатир бирделәр.

Ай ул заманалар! Илленче-алтмышынчы елларда Уралдагы муллык, байлык! Кибетләргә керсәң, колбасаның нинди төре кирәк, ысланган балык, ит, май, җиләк-җимеш — барысы да тулып ята, барысы да арзан. Җитмәсә, бәяләрне әледән-әле төшереп торалар. Инде сөт-катык ише әйберләргә килсәң, алар кибетләргә сыймый. Аларны турыдан-туры урамда, һәр чат саен диярлек саталар.

Заманча салынган шәһәрнең киң урамнарында, проспектларында Европа кешеләрен: французлар, инглиз, немец, болгарларны очрату гадәти бер күренеш. Монголлар, кытайлар да җитәрлек. Алар барысы да комбинатка тәҗрибә алырга, эшкә өйрәнергә киләләр. Кичләрен шәһәр үзәгендәге металлурглар проспектында, Горький исемендәге кино-театр каршынсындагы урамнарда ялт итеп күпсанлы утлар кабына. Алар култыклашып йөргән яшьләр, һава алырга чыккан өлкәннәр белән тулган була. Бу урамнарда бернинди машина йөртмиләр. Һәркайда тынычлык, тәртип. Яшьләр дә тыйнак кына йөриләр, үзара сөйләшәләр, нидер серләшәләр, кайчак көлеп җибәрәләр. Урамнарда затлы хушбуй исләре аңкып тора.

Гаҗәп! Урам тулы халык, ә бернинди исереклек, нахаллык, сүгенү сүзләре, кешегә бәйләнү дигән нәрсә юк. Монда шунысын әйтергә кирәк, Магнитогорск — бөтенләе белән диярлек гади эшчеләр, корыч коючылар, чуен эретүчеләр, транспортчылар, төзүчеләр каласы. Ул заманда төрле вак-төяк тәртип бозучыларны, кесә каракларын, хулиганнарны вакыйга булган урынга җыелган халык үзе генә хәл итә, милиция-мазар чакыртып йөрүләр юк та иде.

Бервакыт трамвайда шундый хәл булды. Чыгу юлында басып торган чибәр генә бер ханым кисәктән үзе янында тугыланган юка йөзле, чандыр гына бер егетнең иңбашыннан эләктереп алды.

— Иптәшләр! Менә бу мокыт минем сумкамнан акча янчыгын алды! — диде ул тавышын әлләни күтәрми һәм каушамый гына.

Теге егет янына шунда ук өч-дүрт ир-ат килеп басты. Аларның тимер бөрчекләре кунган йөзләреннән үк корыч коючылар икәне күренеп тора иде.

— А ну! — диде аларның берсе егеткә. Теге дә эшнең кай тирәдә икәнен шунда ук сизенеп алды. Калтыранган куллары белән кесәсеннән хатын-кыз янчыгы чыгарды да, теге ханымга сузды.

— Гафу үтен! — диделәр аңа.

Егет монысына да каршы килә алмады.

— Гафу итегез, апа...

Бөтен вагон шаулатып көлеп җибәрде. Әмма теге егетне мәсхәрә итмәделәр, ормадылар-сукмадылар. Бары тик трамвайны туктаттылар да, Урал суын кисеп үткән дамба өстендә, ялан кырда төшереп калдырдылар.

Әмма мондый вакыйгаларның зур фаҗига белән беткәннәре дә булгалый иде.

Җәйнең бик матур көне, урамнан яшь егет белән кыз килә. Алар икесе дә шулкадәр чибәр, шулкадәр пар килгәннәр, кулларында — чәчәкләр бәйләме. Үзләре бер-берсенә карап, нидер сөйләшәләр, көләләр, пар күгәрченнәр кебек гөрлиләр. Алар өчен дөнья матур, тыныч, рәхәт, гамьсез. Яннарыннан үткән һәркем бу бәхетлеләргә карап елмая... Шунда, һич көтмәгәндә коточкыч хәл булды. Урамнан зур тизлектә килгән кара төстәге «Волга» машинасы кисәк кенә тротуарга бәреп чыкты һәм... Өлгермәделәр, җанашларым, читкә тайпылып өлгермәделәр! Тирә-яктан кешеләр йөгереп килгәндә асфальтка киң булып кан җәелгән, ике яшь гомер, чәчәктәй ике яшь гомер өзелгән иде инде... Бу хәлдән тәмам тетрәнгән, ярсыган кешеләр шоферны машина эченнән тартып алдылар. Ә ул сүзен дә әйтә алмый, аягында басып тора алмаслык исерек... Милиция килеп җиткәндә кара машина янында беркем дә юк, бары тик өч мәет кенә ята иде...

* * *

Тора-бара Дамира белән без тәмам шәһәр кешеләре булып киттек. Икебез дә эшлибез, акчасы әлләни мактанырлык булмаса да, килә тора. Тормыш та бөтен, күңелле. Ял көннәрендә ике кызыбызны ияртәбез дә Урал суы буена төшеп китәбез. Монда Урал елгасын ике чакрымнан артык озынлыктагы дамба белән бөягәннәр, ул комбинат белән шәһәр арасында киң буа булып җәелгән. Эшче халык ял итсен өчен яр буйларына чуерташ, ком җәелгән. Хисапсыз күп вак кибетләр, ашарга-эчәргә ни телисең, шул бар. Яр буе тулы халык, су коеналар, кояшта кызыналар, салкын сыра эчәләр. Ә без исә су станциясеннән үзебезгә ошаган зур көймә сайлап алабыз. Балаларны утыртабыз да, туйганчы көймәдә йөрибез. Урал буеннан кайтканда инде кинога керәбез.

Ял көннәрендә өйдә ашарга әзерләп маталанасы да юк. Шәһәрдә атлаган саен арзанлы ашханә, кафе, буфет. Ә инде ит, май, колбаса кебек ризыкларны кибеттән алганда да шул көнгә җитәрлек кенә итеп, аз гына алабыз. Өйдә хәтта суыткыч та юк. Чөнки азык-төлекне кибеттән көн саен алып була, ул анда тулып ята. Чират тору дигән нәрсәне ишетмәдек тә без ул вакытта.

Юк, минемчә, хәзер кайберәүләр социализмның төзелеп, күкрәп торган елларын бер дә юкка артыгын сүгәләр. Бар иде, бар иде ул елларда хезмәт кешесе, эшчеләр сыйныфы турында кайгырту! Бер дә сөйләмәсеннәр. Бай, иркен, рәхәт еллар иде ул. Моны беркем дә инкарь итә алмый.

Эшемә дә инде мин тәмам күнегеп җиттем. Кочегар булып, тендерда күмер көрәп нибары бер ел йөрергә туры килде. Икенче елны ук эштән соң укып, машинист ярдәмчесе таныклыгы алдым. Безне депо начальнигы урынбасары Алексей Иванович Шилов укытты. Озын буйлы, каратут йөзле, кылыч борынлы, бик чибәр кеше иде Алексей Иванович. Техниканы барысыннан да яхшырак белә, еш кына депо начальнигы үзе дә киңәш сорап аның янына килә, дип сөйлиләр иде. Тик мена куылып

килгән кулак малае иде шул бу кеше. Әшне һәм паровозларны никадәр әйбәт белмәсен, гомере буена урынбасар гына булырга дучар ителгән иде. Әле ул елларда да, куылып килгәннәрне һәм аларның балаларын да, ул никадәр генә сәләтле, зиһенле булмасын, мастердан яисә бригадирдан ары үстермиләр иде.

Армиядәге капитан Громдагы кебек үк, мин Алексей Ивановичның да иң алдынгы укучысы булдым. Ул да мине бик яратты.

— Ут әрҗәсе астан ничек беркетелә?—дип сорый ул дәрестә.

Егермеләп баш түбән иелә. Беркем белми. Чөнки бик четрекле сорау бу. Бер-ике кешене бастырып, алар ык-мык килгәннән соң, Алексей Иванович елмаеп миңа карый.

— Менә безнең Фәизов нәрсә дияр тагын?

— Төп түгәрәге бар анда. Ул, бер уңайдан әрҗәне беркетү өчен дә хезмәт итә!—дип ярып салам мин.

— Дөп-дөрес! Ансат кына бит, егетләр!—дип шелтәли калганнарны Алексей Иванович һәм дәресне дәвам итә.

Ул миңа берничә тапкыр киңәш биреп карады:

— Син, Радик, башлы гына егет. Техниканың төзелешен, сызымнарны тиз төшенеп аласың. Урта белемең бар. Кер Урал политехника институтына. Имтиханнарга әзерләнергә үзем ярдәм итәрмен. Синнән зур производство җитәкчесе чыкмас анысы, характерың ул түгел,— диде.— Әмма бик яхшы теоретик, инженер, белгеч булып китүең бик ихтимал. Укы, иренмә!— диде. Адәм баласы үз файдасына әйткәнне беләме соң ул. Аеруча минем шикеллесе. Тыңламадым мин бу яхшы кешенең киңәшен, укымадым, ирендем.

Яшьлегемдә, производствода эшләгәндә һәм аннан соңгы елларда да, гомерем буена миңа очраган кешеләрнең күбесе, бик күбесе әйбәт, менә дигән кешеләр булды. Бәлки, мин аларны үзем шулай кабул иткәнмендер. Минем үземнең дә шактый беркатлы, рыясыз, киң күңелле булуымнандыр. Һәрхәлдә, мин гомерем буе кешеләргә ышанып яшәдем һәм яшим. Дөрес, кайчакны хәтеремне калдыручылар, алдалаучылар да булды. Тик мин боларга артыгын офтанмыйм, андыйларга ачу да сакламыйм. Алла үзе ярлыкасын аларны.

Мин укып чыгып, кулга таныклык алып, машинист ярдәмчесе булып эшли башлауга, безгә тагын бер зур җиңеллек килде. Паровозларга күмер ягудан туктадык! Аларны мазутка күчерделәр. Тендерга сигез тонна сыйдырышлы бак куелды. Шуңа кайнар мазут тутырып аласың да, ул сиңа унике сәгатьлек смена буена ягарга менә моннан җитә! Бернинди көрәк, кисәү кебек тимер-томыр кирәки хәзер. Тузан юк, шлак юк. Ә пары! Топкага ялкын бирә торган форсунканың кранын ачып җибәрәсең дә, күзәтеп кенә утырасың. Манометрда пар басымы күзгә күренеп күтәрелә. Авыр составны тартып барабыз, үргә менәбез.

Их, яшьлекнең юллары! Станцияләр аша үтәсең дә, иркенгә, ераклар-га ашкынасың. Юл буендагы кешеләр барган җирләреннән тукталып, безгә кул болгыйлар. Чуерташ карьерларына, урман эчләренә, комбинатка, төзелеш полигоннарына барып керәсең. Син гел хәрәкәттә, синең күз алдыңдагы күренешләр гел үзгәреп, алмашынып тора. Бер сменада гына күпме җирләр, яңалыклар күрәсең. Юк, ни генә әйтсәгез дә, яхшы һөнәр ул тимер юлчы булу!

Әлбәттә инде, тимер юлда күңелсез, хәтәр хәлләр дә булгалап тора. Шулай бервакыт йортлар төзү комбинатына карьердан чуерташ алып менәбез. Юл—үргә таба, тизлекне һич киметмичә куарга да куарга кирәк. Алда—юллар аерыла торган урын. Без уң якка китәсе, икенче юл сулга, икенче станциягә китә. Без паровозда Александр белән икәү генә, хәзер кочегар юк. Күрәм, алда кулына чиләк тоткан бер агай юлларны аркылы чыгып маташа. Безне күрде, борылып та карады бу, әмма сулга керәләр дип хәл итте, күрәсең, Без үтәсе уң як юлның уртасына керде дә басты бит. Багана кебек. Ә ара инде—әнә генә!

— Саша, юлда кеше! — дип кычкырып җибәрдем мин һәм гудок бирә торган тотканы соңгы чигенә кадәр үзем тарттым. Саша аягы белән тормозның тиз туктата торган тоткасын тибеп ачты. Тик кая инде ул хәзер өлгерәсең... Гудогын яман үкертеп, тормозлары белән чыжылдап килгән коточкыч авыр машина агайга китереп бәрде.

Бетте бабай... Минем яктан аның бөтерелә-бөтерелә һавага очкан чиләге генә күренеп калды. Кырык-илле метрлар киткәч, без ниһаять поездны туктата алдык. Минем тез буыннарым калтырый, бик каты туңгандагы кебек, тешләрем тешкә бәрелә иде. Саша да куллары белән йөзен каплаган. Тик, ни хәл итәсең, хәзер үк урыннан торып паровоздан төшәргә, теге бабай янына барырга кирәк бит... Хәзер үк үзебез күрәсе күренешне күз алдына китереп, минем җаннарым өшеп китте, укшыйсы килә башлады. Тик, бәхеткә, безне, дөресе, теге бабайны, Алла үзе саклаган булып чыкты. Машина аны үзе астында калдырып ботарламаган, ә буферы белән сугып, читкә бәреп чыгарган. Агаебыз юл кырыендагы әрем арасында йөзтүбән ята, үзе хәрәкәтсез. Йөгереп килдек тә тиз генә бөтен җирен капшыйбыз тегенең. Йа, аллам, сынган-киселгән төшләре күренми моның. Тик бер колагы артыннан гына бераз кан саркып тора. Җәһәт кенә икәүләп ясалма сулыш алдырырга керештек. Бераздан агай һушына килде, тонык күзләрен ачты. Хәтта торып утырды.

— Соң, нәрсә була инде бу? Ни эшләп ятам мин монда, әрем арасында? — дип мыгырданды ул, бик зур ризасызлык һәм безгә карата шелтә белән.

— Поезд бәрде сине, агай. Юлга үзең кереп бастың бит, юл уртасына, — диде Саша.

— Ә чиләгем кайда минем? Чиләгем? — дип шыгырдады карт, аны тыңлап та тормастан. Тиз генә чиләген табып китердек.

Чиләкне күргәч, бабай тынычлана төште, бераз вакыт хәл җыеп, нидер уйланып утырды.

— Шулай ук юлга үзем барып кердемме, егетләр? — диде ул.

— Үзең барып кердең, абзый кеше. Юл уртасында тукталып калдың бит. Бер-ике генә атласаң, чыгып та киткән идең. Берни булмый да иде, — дидем мин ашыгып.

— Торгызыгыз мине! — дип әмер бирде ул.

Бабайны күтәреп аягына бастырдык. Кулына яньчелеп беткән иске чиләген тоттырдык.

— Ярый инде, егетләр, сез мине гафу итегез. Алай булгач, мин дә жалу биреп тормыйм. Гаеп үземдә икән, — диде һәм көч-хәл белән генә атлап булса да, үз юлына китте.

Без Саша белән җәтрәк будкага йөгердек. Анда менгәч тә әле тиз генә кузгалып китмәдек. Саша кинәт башындагы кепкасын идәнгә атып бәрде дә, бии башлады. Шунда ук мин дә аңа кушылдым. Соң, юләр, биемичә! Бу кадәрле хәвефле хәлдән шушылай ансат кына котыл әле син. Әгәр дә бу бабай безнең эш урынына янсә милициягә хәбәр итсә, бу эшне тикшереп, тормоз юлларын үлчәп, мең төрле провокацияле сораулар биреп, безнең миләрне черетәчәкләр иде бит. Андый хәлләр булгалады инде, без аны бик яхшы беләбез... Мондый чакта синең сүзеңне беркем дә алга алмый, каза күрүче ни әйтсә, шул дөрес була. Кеше бәрдереп, айлар буе милициягә чакыртудан гарык булган, күпме штраф түләгән егетләр бар бездә. Шуңа күрә безнең шатлыклар эчкә сыймый иде. Аларны, казандагы артык пар кебек, тышка чыгарырга кирәк иде.

Ә бервакыт...

...Резервта, ягъни вагоннар такмыйча гына асфальт заводына киләбез. Шәһәр кырые бу, кешеләр йөреп тора. Безнең акрын гына барган паровоз алдыннан килгән бер хатын, кинәт юлга аркылы борылды да, муенын рельска куеп ятты.

— Тормоз! — дип кычкырдым мин. Саша шунда ук кызыл тотканы үзенә тартты. Паровозның аның тормозы бик шәп, яшен тизлеге белән

эшли. Йөз утыз биш тонна авырлыгындагы машина рельслар өстеннән азрак кына шуып барды да, тукталып калды. Тизрәк жиргә сикердек, эчтә жан юк инде. Теге хатынга ярты метр ара кала туктаганбыз. Жирдә, тузанда ауналып ята теге бичара. Ике ягыннан сак кына күтәреп торгыздык. Бик курыккан, күзләре акайган, авызы зур ачылып, ияге салынып төшкән. Үзеннән аяктан бәреп егарлык аракы исе аңкый. Шунда кинәт ул исенә килде, безгә яман ачулы, нәфрәтле итеп карады. Урысча пешерергә тотынды безне:

— Сез... чучмеклар... ник туктадыгыз?! Мин үләргә телим! Яшисем килми минем бу дөньяда. Ә сез... туктадыгыз. Имансызлар! Мин бит барыбер үләм. Барыбер поезд астына керәм!—диде ул авызыннан төкрекләрен чәчеп һәм тагын яман итеп сүгенә башлады.

— Туктагыз әле. Алай бик керәсегез килсә, паровоз астына кермәгез сез. Әнә поезд, вагоннар астына керегез. Болай бит сез безне гаепле итәсез,—дип киңәш бирде аңа Саша.

Ни гаҗәп, теге бичара хатын Сашаның шушы киңәшен үзенә бер ярдәм, яхшылык кебек итеп кабул күрде. Аның ярсулы, нәфрәтле йөзе ачыла төшкәндәй булды.

— Ярый. Мин шулай эшләрмен! Үз үлемемә кешеләрне гаепле итмәм,—диде ул.

Йа, хода, нинди бәндәләрең бар синең. Нинди бәлаләргә, фаҗигаләргә тармый бу адәм баласы. Әле яшь кенә, хәйран чибәр генә бер хатын бит югыйсә. Бу якты дөньядан китәргә исәбе. Ниндидер бер авыр фаҗиганең, газап-җәберләрнең дәвамы бит инде бу. Аз гына рәтле тормышлы кеше мондый адымга барамы?!

Алай да мине Ходай үзе саклады. Тимер юлда тугыз ел эшләп минем сменада, безнең машинадан кеше тапталмады, хәтта имгәнмәде дә. Мин үзем дә зарар күрмәдем. Юкса, безнең трест тимер юлында гына да ай саен диярлек кеше таптыйлар, кайчак үзебезнең паровоз бригадасы кешеләре дә җә тәгәрмәчләр астында калып, яисә вагоннар арасына кысылып, һәлак булгалыйлар иде.

Көлкеле хәлләр дә еш була торган иде. Җөмләдән берсе: Җиңел платформалардан гына торган поезд тагып, урманга керә торган юлдан киләбез. Бу юлда тыныч, синең артыңнан да беркем килми, каршыга хәрәкәт тә юк. Ашыкмыйбыз, җиңел поезд таккан паровоз келтер-келтер җай гына бара. Без дә Саша белән төрле дөнья хәлләрен сөйләшеп, артка борылып карарга да онытканбыз. Бер заман мин тәрәзәдән башымны сузып, артка борылып карасам... әкәмәт! Паровоз артында бернинди поезд юк. Утыз платформадан торган озын поездны каядыр ташлап калдырганбыз. Киттек җәтрәк арткы ход белән. Поездыбызны унике километр ераклыктан, борылышта табып алдык.

Үземнең машинист Саша, ягъни Александр Гамп белән без тәмам дуслашып алдык. Саша биргә очраклы рәвештә килеп эләккән. Алар Казахстанның Алма-Ата шәһәрендә яшәп яталар. Шунда ишетеп алалар: Урал ягында «Чиләбе-40» дигән нииндидер яшерен завод бар, имеш. Анда акчаны капчыгы белән көрилəр, анда оҗмах, имеш. Берничә гаилә, инде иялəнгән урыннарыннан, эшләгән җирләреннән кубып, ерак Уралга сәфәр чыга болар. Әлеге оҗмахның кайда икәнен төгәл белмәгәнлектән, Чиләбе вокзалында кешеләрдән бу хакта сораштырып йөриләр. Ярты сәгать тә үтми, бу мөсафирларны гражданский киемле орган кешеләре чорнап ала. Вокзал артындагы бер аулак бүлмәгә алып керәләр. Стенага терәп куеп, якаларыннан тотып алалар.

— Нинди банда сез? Нинди адәмнәр?

— Банда түгел без, тимер юлчылар, машинистлар. Алма-Атадан килдек.

— Ә «Чиләбе-40»ны каян беләсез? Кем мәгълүмат бирде сезгә, кем коткысы белән йөрисез?

— Коткы белән түгел, эш эзләп килдек без. Шунда озатыгыз безне,— диләр болар.

— Андый урыннарга хезмәт коллективларыннан, иң лаеклы кешеләр генә сайлап алына. Ә сезнең ише «озын берлек» артыннан куган сукбайлар түгел... Аттырыгыз моннан яхшы чакта. Һәм телегезне тыеп тотыгыз! — дигәннәр аларга.

Сашаның инде бер купкан урынга кире кайтасы килмәгән. Ул якындагы Магнитогорск шәһәренә юл алган.

Немецча сыңар сүз белмәсә дә, Саша үзенең немец кешесе икәнен тулысынча аклый иде. Мин еш кына аларның ике бүлмәле фатирларында булам. Безнекеннән артык җиһаз да юк анда. Әмма килеп керү белән үзенә бер зәвык, тәртип, чисталык, пөхтәлек сизелә.

Александр Гамп — безнең трестта иң оста машинистлардан. Аны җыелышларда мактап сөйлиләр, шәһәр газетасында язалар. Әмма мин аның сөйләшүләреннән, бөтен фикер сөрешеннән сизенә идем, шул вакытта ук илдәге хакимияттән, совет властеннан, аеруча коммунистлардан һич тә канәгать булмаган, хәтта аларны яшертен генә дошман күргән бер кеше иде ул. Һәм бу миңа һич кенә дә аңлашылмый иде. Нинди тәртипле, булган кеше, менә дигән машинист, үзен бәялиләр һәм... менә шушындый хәл. Ничек була соң инде бу? Бер җаен туры китереп, мин бу турыда Сашаның үзеннән сорадым. Сашаның чиста зәңгәр күзләрендә олы хәсрәт күренде.

— Их, Радик, син безнең — кайчандыр ата-бабалары Рәсәй җиренә килеп урнашкан немецларның тарихын белмисең шул,— диде ул авыр сулап.— Менә үзең алып кара. Ниләр күрсәтмәде безгә Совет власте. Мин малай чагында без Кара диңгез буенда, Херсон шәһәрендә яши идек. Безнең үз йортыбыз, менә дигән бакчабыз бар иде. Сугыш башлангач, безне немец милләтеннән булган өчен генә аннан бер көн эчендә кудылар. Ерак Казахстанга сөрделәр. Җитмәсә, әтине кулга алдылар. Ул — Сталин лагеренда, Себердә һәлак булды. Мәсхәрә иттеләр бит безне коммунистлар!.. Әгәр яңадан сугыш була икән, мин бу властьны саклап, кулыма корал алмаячакмын! Мин моны ачыктан-ачык әйтәм... Әгәр телисең икән, барып әнә җәвит ит! — диде ул.

— Нинди җәвит ул, син нәрсә? — дидем мин.

Бу Хрущев заманы, инде андый кеше чагулар, кулга алулар беткән иде. Алай да мин ул чакта Сашаны ахырынача аңлап бетермәдем. Шулай да, күпме еллар бергә эшләп, Саша белән без бер генә тапкыр да сүзгә килмәдек. Ул мине ярата, эштә дә булыша, ә инде поездларны йөртүне үзем никадәр теләсәм, шулкадәр рөхсәт итә иде. Без паровозда икебез дә машинист кебек, тигез хокуклы булып эшләдек. Һәм мин җете зәңгәр күзле, чиста, җыйнак йөзле дустым немец Александр Гампны әле дә булса сагынып искә алам.

Безнең поездлар төзүче Иван Кутьконы барысы да, хәтта станция дежурныйлары һәм стрелкачылар да «теге полицай» дип кенә йөртәләр. Кайберәүләр кайчак үзенә үк: «Әй, син, полицай!» — дип эндәшәләр. Салынкы кара кашлы, гел аска гына карап йөри торган бу адәм мондый мөнәсәбәткә ачуланмый да, үпкәләми дә. Чөнки — арты юеш. Сугыш елларында немецлар Украинаны басып алгач, ул чагында да аларга полицай булып хезмәт иткән икән. Артык зур җинаять эшләмәгән, күрәсең. Инде безнекеләр кулына килеп эләккәч, аны атмаганнар, күп елларга Себергә генә җибәргәннәр. Андыйларга, тиешле срокларын тутыргач та, туган җирләренә кайтырга рөхсәт итмәгәннәр. Кайберәүләре шунда — Себердә үк торып калган, кайсылары Уралга кайткан. Уралдан да ары инде аларны чыгармаганнар. Магнитогорскида, безнең тимер юлчылар арасында да андый китек язмышлы кешеләр байтак иде.

Магнитогорск — чагыштырмача бик яшь шәһәр, шуңа күрә аның халкы да төрле җирләрдән җыелган, бик чуар, монда төрле кешеләр бар. Хәер, халык кая гына барсаң да, бик төрле инде ул.

Безнең паровозны ремонтка куйганда мин, әлбәттә, башка кешеләр белән дә эшләдем. Башлыча, «җылытуда». «Җылыту» дигәнем шул: иске машиналарны магистральдән алгач кая да булса, әйтик, үзебезнең депо янына китереп, тупикка куялар. Депоның җылыту торбаларын паровозга ялгыйлар да, без гаять зур бинага җылы биреп торабыз. Монда инде беркая да йөрмисең, бер урында тик утырасың. Эш аз, рәхәт. Төннәрен чиратлап йоклап алырга да була.

Мондый очракта мин еш кына Даниил Вампель белән бергә туры киләм. Даниил әле минем кебек үк яшь булса да, эре гәүдәле, кара кашлы, чибәр, күркәм кеше. Яһүди. Гаҗәеп сүзчән, уен-көлкеле, хәйләкәр төлке. Ул булса инде күмерне улактан топкага һәр көрәген санап ташлый.

— Мин утыз көрәк ташладым, Радик дус. Әйе, нәкъ утыз көрәк. Хәзер сиңа тиеш утыз көрәк! — ди ул, бик җитди төстә һәм, онытмас өчен, бу санны акбур белән будка диварына язып куя. Ну малай!

— Кара инде син бу хәлне! — дип сөйли ул, будка буенча әрле-бирле йөренеп.— Шушы Магнитогорскида ничәме яһүди бар бит. Ә шуларның арасыннан бары бер кеше кочегар. Ул да булса мин! Калганнар кайсы — ресторанда, кайсы — зур начальник, кайсы кибеттә сату итә. Бөтен шәһәренә бары мин генә кара эштә чиләнәм. Ә син шуны беләсеңме, Радик дус. Моның өчен син мине ихтирам итәргә тиеш. Мине сакларга, аз эшләтергә, күбрәк йоклатырга тиеш. Чөнки мин бит — яһүди!

Аның бу сүзләреннән мин көлә башлыйм. Ул үзе елмаймый да. Белмәссең кешене, уйнап сөйләшәме ул, әллә чынлапмы?

— Бер дә көлмә син,— ди ул, чын-чынлап үпкәләгән төстә.— Мин бит синең белән уйнап сөйләшмим.— Һәм үзенең чем кара, зур, матур күзләре белән миңа текәлеп тора да, сүзне кисәк икенчегә бора.— Слушай, байыйсың киләме? — ди.

— Ничек... байыйсың? Ничек итеп? — дим мин, мондый сораудан аптырап.

— Нигә аптырыйсың әле аңа шул кадәр? Менә урындык сатып байыйбыз. Мин хәзер!..— ди ул һәм будкадан чыгып китә. Төн караңгылыгына, комбинат каралтылары арасына кереп югала. Шактый юк булып тора бу. Берзаман шалтырап будка ишеге ачылып китә һәм аннан... урындык күренә. Бер, ике, өч урындык! Ярыйсы гына, начальниклар кабинетларына тезеп куя торган урындыклар. Алар артыннан Даниил үзе дә пәйда була. Мин инде бу хәлдән тәмам аптырап, берни дә аңламыйча, авызымны ук ачып калам. Даниил бик эшлекле, җитди төстә миңа аңлатма бирә:

— Бу комбинат эчендә эшчеләргә баш булып күпме начальник утыра, беләсеңме син шуны! — ди ул имән бармагын югары юнәлтеп.— Ә һәр паразитның аерым үз бүлмәсе бар. Ул бүлмә тулы урындыклар. Шул урындыклар үрчетә начальник халкын. Шуңа кызыгып күбәя алар. Төнлә, сак юк бит анда, ник киметмәскә ул урындыкларны? Шуннан инде начальниклар, әрәмтамаклар саны да кимиячәк. Менә, бик гади бит! — ди ул бик фәлсәфи төстә.

— Ә бу урындыклар ни эшкә сиңа? — дим мин.

— Ну малай, тәки аңламыйсың, ә? Әйтәм бит, байыйбыз дип! Базарда сатам мин аларны,— ди ул, җитди итеп.

— Һе, саттың, ди. Соң, син аларны моннан ничек алып чыкмак буласың? Урындыклар күтәреп проходнойдан кем үткәрә сине?

Даниил миңа үзенең кара кашлары астындагы матур күзләре белән ахмак бер бәндәгә карагандай текәлеп тора, борыныннан һава өреп куя. Аннары, дәрес биргән укытучы кыяфәтендә тезеп китә:

— Тә-әк! Башта ул урындыкларны менә болай итеп сүтәсең. Болар — безнең Рәсәйдә эшләгән нәрсә, алай нык түгел...— ди ул һәм, чыннан да, үзенең көчле куллары белән мескен урындыкны ботарлый да башлый. Башта җиңел генә алгы аякларны тартып ала. Аннан урындыкның төбе

дә артыннан ансат кына аерыла икән. Әлләни арада гына тәмам сүтеп тә бетерә.— Тә-әк, хәзер бу кадерле кисәкләрне бер-беренә китереп бәйлибез,— ди, һәм тимер чыбык алып, кисәкләрне бергә оештырып куя.— Менә, булды да! — ди ул тантаналы төстә.

— Хәзер ни эшлисең инде бу ватык урындык белән? — дим мин әле һаман берни аңышмыйча. Чынлап та, ник сүтте бу утыргычны? Нәрсәгә ярый инде хәзер бу ватыклар?

— Их, син, Радик. Беркатлы кеше син! — ди Даниил.— Соң, шалкан кебек гади бит инде калганы. Бу бәйләмне менә хәзер, караңгыда, комбинат коймасы янына алып килеп, койманың теге ягына, кар эченә атып ташлыйсы гына калды бит инде. Ә иртән ике кулыңны селтәп проходной аша үтәсең дә койма буеннан табышыңны килеп аласың. Сине кем күзәтеп, төпченеп тора. Аннан инде трамвайга утырасың да — өеңә. Ә өйдә бу кисәкләрне клэй белән ябыштырып әр-яңа урындык ясау — унбиш минутлык эш!

Мин авызымны ачып, башымны гына чайкап утырам. Менә кешедәге тапкырлыкны, хәйләне кара син!

Һәм Даниил Вампель, әнә шундый бик гади ысул белән, СССРдагы иң зур металлургия комбинатыннан, төрле рангтагы түрәләрнең арты астыннан байтак утыргычларын үз өенә шудырды. Көлке дә, кызганыч та бит, билләһи! Мондый хәл бары безнең илебездә генә була ала торгандыр.

Тик Даниилның үзенең дә язмышы шактый кызганычлы, үкенечле, әйтер идем, көлкеле дә булды. Ул үзенең гади тимер юлчы булуыннан шулай зарланып, риза булмый йөри торгач, берзаман чынлап та бездән расчет алды. Ит комбинатына эшкә барып кергән бу. Тик анда да аны тагын да карарак эшкә, йөкче итеп кенә алганнар. Белем юк бит. Бервакыт кыш көне машинага каткан үгез түшкәләре төяп каядыр бара икән болар. Кызу килгән машина юл читенә төшеп әйләнә. Даниил мескеннең өстенә авыр түшкәләр тавы ишелә, ул бик нык биртелә. Үлмәде, әмма нинди таза, сылу, чибәр кеше тәмам ямьсезләнеп, зәгыйфьләнеп, юньле эшкә ярамас булып калды. Без шифаханәгә, Даниил янына барып йөрдек. Ул яңадан безгә кайтты, депога төнге каравылчы булып урнашты. Чөнки безнең коллективта аны барысы да үз итәләр иде.

Ул елларда ил башында Никита Сергеевич Хрущев торды. Ә ул исә эшчеләр сыйныфына бик авырттыргыч, җанга барып тия торган удар ясады. Барча эшчеләрнең, хәтта домначылар, корыч коючылар, тимер юлчыларның да хезмәт хакларын кисте. Безнең илдә бит хезмәт хакы болай да, беркайчан да югары булмады. Эшче халкы арасында илдәге хакимияттән, хезмәт хакының түбәнлегеннән, тормыш авырлыгыннан ачыктан-ачык ризасызлык башланды. Шул ук вакытта кешеләр күреп тора: идарә аппараты хисапсыз зур, кая карама шунда әрәмтамаклар тулып ята. Китте каргану, сүгенү, эшкә битараф карау. Күпме тырышсаң да, барыбер әрәмтамаклар ашап бетерә! — Эшче халкы әнә шулайрак фикер йөртте.

Машинист Шнякин белән «җылыту»да эшлибез. Шнякин колга кебек озын, ябык, авыру чырайлы, миннән олырак кеше. Инде поездларда йөри алмый, гел шул «җылыту»да. Билгеле инде, монда хезмәт хакы да аз, бернинди премия-мазар юк. Бервакыт күрәм, Шнякин кулына акбур алган да, будка стенасына нииндидер сызыклар сыза. Өч кысканы сыза да, дүртенчесен озынрак итеп сызып куя. Үзе авыз эченнән мыгырданып нидер исәпли.

— Нәрсә саташып утырасың инде син анда? — дим.

Шнякин кулын гына селтәде. Комачаулама әле, янәсе.

— Менә күр әле син, Радик,— диде ул бераздан, стенадагы сызыкларны күрсәтеп.— Мин үзебездә эшләүче бар халыкның санын алып карадым. Бактың исә, производствода эшләүче һәр өч кешегә бер әрәмтамак туры килә икән бит. Мастер, инструктор, бригадир, хисапчы, бухгалтер,

нарядчы, табельче...—дип тезеп китте ул һәм ачу белән кулындагы акбурны атып бәрде.—Соң, һәр дүрт кешенең берсе берни эшләмичә генә акча алып ята диган сүз бит бу! Бу килештән, без кайчан адәм рәтле яши башларбыз? Шуны әйт син миңа!—дип кычкырды Шнякин ярсулы күзләрен миңа текәп. Әйтерсең, бу хәлгә мин гаепле идем.

«Кайчан адәм рәтле яши башларбыз?!»—Бу сорау бөтен эшче халыкны, һәркемне борчыды. Кибетләрдә азык-төлек тулып ята, әмма тормыш дигәнең һич тә рәтле түгел. Чөнки һәркайда акчаны аз түли башладылар. Менә без тимер юлда, тузан, төтен эчендә, төннәрен йокламыйча эшләп, аена 140—150 сум хезмәт хакы алабыз. Кибеттә исә уртакул костюм 100—120 сум тора. Димәк, син өстеңә костюм алып кисәң, ашарыңа калмый да диган сүз. Очын-очка гына ялгап барган бу тормыштан эшче халкы бер дә риза түгел, бик кимсенә, хурлана иде.

Ул елларда ачыктан-ачык ризасызлык белдерүләр, эш ташлау, забастовкалар булмады, дигән сүзләр бар. Юк сүз! Ниткән ул булмаган! Мин Магнитогорск шәһәрендә 1957—1965 елларда яшәдем. Шул чорда бу шәһәрдә генә дә ике забастовка булды. Чын-чынлап, ныклы таләпләр куеп эш ташлау. Зур коллективлар тарафыннан. Һәм мин аларның икесенә дә шаһит булдым.

Бер көнне иртән смена кабул итүгә безне вагоннар депосына эшкә билгеләделәр. Монда һәрвакыт эш муеннан, төзәтәсе вагоннарны депо эченә, махсус юлларга кертеп куясың, төзәтелгәннәрен алып янәшәдәге станциягә чыгарасың. Көнозын тәгәрмәч эчендәге тиен кебек әйләнәсең, кыскасы. Ярый, киләбез депога, капка ачык, әмма бернинди хәрәкәт юк. Беркем дә күренми дә. Туктадык, сигнал бирдек. Күренми каршыга чыгучы. Бу ни хәл бу! Әллә болар үлеп беткәнме? Берничә тапкыр гудок биргәч, депо ишеге ачылып, аннан безгә таныш слесарь Василь дәдәй чыкты.

— Бездә забастовка бүген, егетләр. Эш ташладык. Безнең таләпләрне үтәмәсәләр, эшләмибез бүген!—диде ул, бик тәвәккәл төстә һәм өстәп куйды:—Ә сез кире китә аласыз.

Үз колакларыма үзем ышанасым килмәде! Нәрсә диде бу дәдәй, забастовка, диде түгелме? Ничек... забастовка, нинди... забастовка? Безнең илдә, капиталистик илләрдәге кебек? Эшче сыйныф үз диктатурасына каршымы?.. Китче, булмас ла... Саша белән Иван Кутькога карап алдым. Аларның да йөзендә аптырау иде. Без барыбыз да үзебезне бу хәлгә куйган Василь дәдәйнең киң җилкәсенә карадык. Ә ул ышанычлы, тәвәккәл адымнары белән депо капкасына таба атлый иде инде.

— Әйдә, без дә барыйк әле!.. Нәрсә бар икән шунда?—дидем мин. Дөресен әйтим, үзем бик куркынып, эчтән калтыранып әйттем бу сүзне.

— Әйдә, ул-бу хәл булса, җәтрәк чыгып таярбыз...—диде Саша һәм без депога таба атладык. Паровоз будкасында Иван калды.

Кешеләр генә йөри торган тар ишектән керсәк, чыннан да! Бөтен депо халык белән тулган. Барысының да йөзләре сүрән, ачулы, күбесе тәмәке төтәтә. Шау-шу. Каршыдагы сәхнә кебек биек урында—начальниклар. Ул арада тресттан, горкомнан яхшы-яхшы киемле, спай гәүдәле, күркәм кешеләр килеп төштеләр. Сәхнә төрле рангтагы түрәләр белән тулды. Күрәбез: алар да бик дулкынлана, араларында кәгазь тоткан ниндидер кешеләр тыз-быз йөренә. Йөренерсең, агайнем, эшләр болайга киткәч...

Менә трестның партком секретаре Анкутдинов (татар кешесе, диләр иде аны) сәхнәнең алдына чыкты. Кулын күтәреп, тынычланырга чакырды.

— Җәмәгать, тынычланыйк. Бу инде политик чыгышка әйләнмәсен. Эш урыннарына таралышыйк.

— Юк, таралмыйбыз!

— Без әйткәннәр үтәлмәсә, беркем дә эш башламый!..

— Мондый шартларда эшләп булмый!

— Йә, берегез генә сөйләсен әле!—дип шарт куйды партком.

Шунда Андрей дәдәй алга чыгып басты. Инде олы яшьтәге, ап-ак зур башлы, олпат гәүдәле, нәкъ борынгы эшчеләр кебек киң күн алъяпкыч япкан тимерче Андрей дәдәйне бөтенесе дә яхшы белә, ихтирам итә иде. Аны Анкутдинов үзе дә белә булып чыкты.

— Рәхим итегез, Андрей дәдәй, сөйләгез! — диде ул, ихтирамлы итеп.

— Син, Анкутдинов, укымышлы кеше. Яхшы беләсең эшнең кая барганын. Борчак патша заманында да эшче болай яшәмәде. Син аның монысын да беләсең... Безнең нормировщик чыксын әле! — диде карт эшче.

Сәхнә алдына күзлек кигән, алга бөкрәйгән гәүдәле, ябык кына, олы яшьтәге кеше чыгып басты.

— Җә, әйт әле, Чувашин! — диде аңа Андрей дәдәй. — Безнең расценкаларны быел гына күпмегә кистең син? Мин — алтынчы разрядлы тимерче күпме алам хәзер? Айлык ике йөз сум акчага мин ничек көн итәргә тиеш? Шуны әйтеп бир син. Курыкмыйча, дөресен әйт! — дип боерды тимерче.

Нормировщик тагын да бөгелә төште. Бик куркынган, каушаган төстә әле эшчеләргә, әле начальникларга карап алды. Түрәләрнең берсе «сөйләргә мөмкин!» дигәндәй үзенә баш каккач кына, сүзгә кереште.

— Без... нәрсә? Без гаепле түгел. Расценкалар өстән төшә. Алтынчы разрядка ике йөз — аз инде ул. Соң, без нишли алабыз?.. — дип сөйләнде ул. Бу бәндә тәмам каушап, куркып калган иде.

— Ә сезнең таләпләр нинди, Андрей дәдәй? — диде партком секретаре.

— Без монда халык белән киңәштек. Булмастайны сорамыйбыз. Әмма үзебез куйганнан да бер карыш чигенмибез. Алтынчы разрядка — өч йөз илле, дүртенчегә — ике йөз илле. Безгә әлегә шул җитеп тора. Тамак туйса, шул җиткән. Без бернинди политик сүзгә кермибез! — диде Андрей дәдәй нык итеп. Халык гөрләтеп кул чапты.

Түрәләр җыелышып, сәхнә артына кереп киттеләр. Шактый киңәштеләр алар анда. Әмма эшче халык тәмәке тартып, сабыр гына көтеп торды. Бернинди тәртип бозу, сүгенүләр, кычкырулар булмады. Бераздан шул ук Анкутдинов чыкты.

— Сезнең шартлар тулысынча үтәлер, Андрей дәдәй... Җәмәгать, киләсе айда ук яңа расценкалар белән эш хакы алачаксыз! — диде партком секретаре тавышын күтәреп. — Ә хәзер, рәхим итеп, барыбыз да эшкә башлыйк. Бу инде эш ташлау булмасын, эш турында бер киңәшмә генә булып калсын. Шулай дип сүз куешыйк! — диде ул. Партком секретарьлары да ничек сөйләшәсен беләләр иде...

Ләкин әле тагын бер таләп ишетелде:

— Нормировщик Чувашинны бүгеннән үк эшеннән алыгыз. Ул күптән пенсиядә инде. Утырмасын анда сөлек булып!

— Монысы да үтәлер!

Һәм ни диярсез?! Деподагы эшче халык куйган барлык таләпләр тулысынча үтәлде. Ремонтчыларга үзләре билгеләгән эш хакын тулысынча түләделәр. Чувашин инде депода бүтән күренмәде. Әмма, партком секретаре сылап куйганча, эш турында киңәшмә генә түгел иде бу. Чын забастовка, эш ташлау иде. Әгәр эшчеләр куйган таләпләр үтәлмәсә, эшләр кая киткән булыр иде тагын.

Икенче забастовканы мин калибровка заводында күрдем. Бу заводта төрле әйберләр: ак калай, кадак, төрле юанлыктагы тимер арканнар һәм башка бик күпне ясыйлар. Продукциянең зур күпчелеге, аеруча ак калай, чит илләргә дә күп чыга. Без, төялгән вагоннарны алып чыгарга, бу завод цехларына еш керәбез. Иң яхшы калай бәйләмнәренә чит илләр: Һиндстан, Куба, Корея мөһерләре сугылган була. Кайбер калайлары бозык, кәкрәйгән-бөкрәйгән бәйләмнәр үзебезгә кала... Менә шушы зур завод өч көн буена эшләмәде. Хезмәт хакын күтәрүне таләп иттеләр. Әмма бирелә эшләр наять кенә төгәлләнмәде. Хезмәт хакын

күтәрделәр күтәрүен, тик унлап кешене шактый зур сроклар белән төрмәгә яптылар. Сөйләшүне бозып, заводка эшкә кермәкче булган кешеләрне, ягъни штрейкбрехрларны тотып кыйнаган өчен дигән булып. Усал ниятле хулиганлык ясаганнар, янәсе.

Ул елларда тормыштан, хезмәт хакыннан ризасызлык, түрәләрне, хакимиятне, коммунистларны тиргәү, алар тарафына бик тозлы сүзләрне юллау бар халык, шул исәптән тимер юлчылар арасында да бик киң таралган иде. Бездә машинист Евгений Назаров аеруча нык каргана, хакимиятне сүгә, үзебезнең башлыкларны бер дә яратмый иде. Ул богылдай гәүдәле, олпат кеше, кайчандыр үзе депо начальнигы булган, күп эчкәне өчен эшеннән алганнар. Тамак бик зур, Евгений Петровичка бер утырып ашаганда бөтене белән ипи, килосы белән колбаса кирәк. Һәм ул хезмәт хакын арттыру мәсьәләсен бик ансат кына хәл итеп куя.

— Нигә безгә акчаны болай бик аз түлиләр?! — дип кычкыра ул үзенең гөрелдәвекле тавышы белән.— Соң бит, әгәр дә инде акчалары җитми икән, бассыннар шул акча дигән нәрсәне ике тапкыр күп итеп. Безнең илдә кәгазь беткәнмени? Түләсеннәр безгә ике тапкыр артык. Шуңа да башлары җитми микәнни ул югарыда утырган дуңгызларның. Аналарын!..— дип, дәү йодрыгын күтәреп, каядыр югарыга яный.

Кайчак инде пенсиядәге машинистлар да эшкә килә. Машинистлар картлык ялына илле биштән чыгалар һәм аларның күбесе әле егетләр шикелле шыңгырдап торган, тап-таза кешеләр. Аларга елына ике ай эшләп алырга рөхсәт ителә, әлбәттә инде, күбесе бу форсатны кулдан ычкындырмый. Николай дәдәй Матюха — әнә шундый картларның берсе. Тәбәнәк кенә буйлы, кысык күзле, гел хәйләле елмаеп кына торган бу кеше белән мин «җылыту»да күп эшләдем. Аны бик бай, зур акчалы кеше дип сөйлиләр. Ул, чыннан да, акчага бик исәпле, эшкә килеп берничә сменалар үтми, үзенең ай азагында кулына күпме аласын чутлап йөри башлый. Мин үзем беркатлы, туп-турыдан яра торган кеше, бервакыт аннан сорадым:

— Николай дәдәй, синдә акча күп диләр. Дөресме шушы сүз?

Минем гаҗәпләнүемә каршы, сөйләшергә ярата торган бу карт берни дә яшереп тормады. Хәтта бу сорауга куанды да кебек.

— Дөрес сүз. Суммасын мин сиңа әйтеп тормыйм. Әмма акча күп миндә! — диде ул гади генә итеп, бераз мактана да төшеп.

— Сер булмаса, инде шунысын да әйтегез, ул тамаша акчаларны кайдан алдыгыз? — дидем мин.

— Ниткән сер ул! — дип кулын селтәде карт һәм хәйләле елмаюлы күзләре белән миңа карап алды.— Сугыш елларында халык бик ачыкты монда. Кешеләр дәүләт заемнарын базарга чыгарып саттылар. Бер дә юк бәяләргә генә. Ә минем шактый җыйнаган сәмәнем бар иде. Шунда башыма бер уй килде: тукта әле, нигә җыймаска миңа бу заемнарны. Киләчәктә кулга бернинди мәшәкатьсез үзеннән үзе килеп керәчәк акчалар бит бу! Һәм җыйдым мин ул заемнарны. Шактый күләмле ике чемодан... Менә хәзер инде шуның әҗерен күрәм. Тираж саен заемга отам. Зур суммалар чыгып куя кайчак...— дип сөйләде ул.

Менә бит, шайтан алгыры, ничек гади генә!

— Акча дигән нәрсә, егетем, көч ул! — диде Николай дәдәй һәм тагын сөйләп китте: — Кызым Наташа урта мәктәпне бетерде. Бик яхшы укыды, алтын медальгә. Киттем моны җитәкләп Мәскәү дәүләт университетына. Син шунда минем кызым үзенең белеме, алтын медале белән керде дип уйлыйсыңмы? — дип сорап куйды күзләрен кыскалап.— Керде пычагым белем белән! Бер кечкенә чемодан акча алып керде кызымны университетка. Бернинди киртәләрне белмичә... Беренче дәрестә укытучылары профессор аларны бастырып, кемнең әти-әниләре кем булуын сораган. Минем Наташамның бер гади машинист кызы икәнен белгәч, исе киткән карт профессорның. «Ничек килеп керә алдың син монда, кызыкаем?» — дип сораган. Кырык кешедән торган группада бер минем Наташам гади

эшче кызы икән. Калганы бар да зур түрәләр, акчалы кеше балалары... Менә шулай ул, егетем. Аларның бөтенесен сатып алырга була. Тик кесәңдә җитәрлек акчаң гына булсын. Акча белән — син үзең түрә! — диде Николай дәдәй, ышанычлы төстә.

Акчаны санарга, исәпләргә бик яратса да, ни гаҗәп, ул үзе бер дә саран кеше булып чыкмады. Аның карчыгы да комбинатта кайчандыр, пенсиягә чыкканчы, зур начальник булган. Шул карчыгы белән алар бер көтү ялгыз карт-карчыкларга ярдәм итеп яталар, балалар йортларына, ясleләргә акча бирәләр. Бервакыт Николай дәдәй, бәлки уены-чыны беләндер, миңа да тәкъдим ясады:

— Бер әйбәт костюмлык акча биримме соң үзеңә, Радик? Үзең баегач түләргә? — диде ул. Алмадым, билгеле.

Эшче Уралдан Татарстанга, үзебезнең авылдагы колхозчылар янына кайткан саен мин авыл халкының ул замандагы ил хакиме Хрущевны ничек ихтирам итүенә бик гаҗәпсенә идем. Авылда аны «Никита Сергеевич та Никита Сергеевич!» дип кенә сөйлиләр. Ә менә эшчеләр авызында исә илнең бу җитәкчесенә карата бер генә дә юньле сүз юк. Ә инде аның хакында сөйләнгән анекдотлар, мәзәкләр! Берчак Хрущев бер язучыга әйтә, имеш. «Вот у вас, у писателей, у многих есть псевдоним. Найдите, пожалуйста, и мне подходящий псевдоним». А у Вас псевдоним и так готов, Никита Сергеевич! Снимите со своей фамилии рыпящие и шипящие! Вот вам и псевдоним... — дигән, имеш, аңа теге язучы.

Хрущевны власть башыннан төшергәннең соңында икенче көнне үк металлургия комбинатында бер вакыйга булды. Ниндидер бер урындагы рәссам төне буе йокламаган, комбинатка иртәнге сменага кешеләр килешкә бер мартен миченең стенасына галәмәт зур итеп, завод коймасының аръягыннан күренеп торырлык итеп, Хрущевның сурәтен ясап куйган. Бу рәсемендә Никита Сергеевич соң дәрәҗәдә үпкәләгән, болай да калын иреннәре тәмам салынып төшкән иде. Эшче халкы белән уйнама син, бик ачы итеп көлә дә белә ул...

* * *

Без инде тәмам Магнитогорск кешеләре. Уң як шәһәрдәге яңа йорттан бирелгән фатирыбыз әйбәт, олы кызыбыз шушындагы мәктәпкә укырга керде. Дамира һаман да балалар бакчасында эшли. Мин дә үз эшемне яратам, яшь чагындагы тәртәгә тибүләр, эштә ялкауланулар бетте, мин хәзер — кадровой эшче, чын тимер юлчы. Аратирә булса да, хикәяләр дә язгалыйм. Аларны Казанда газета-журналлар баскалап та торалар. Бер заман Казаннан фәрман килеп төште: барча хикәяләрне җыйнап, Казанга килергә. Ул заманда юл йөрүләр арзан һәм җиңел иде. Шәһәр читенә терәлеп торган аэропортка төштем дә, ике сәгать эчендә Казанга кайтып та җиттем. Зур дулкынлану белән Бауман урамындагы Матбугат йортының биек баскычларыннан атлап кердем. Гомеремдә беренче мәртәбә. Мин — асылда майга буялып йөргән гади эшче. Әдәбиятта кыска хикәяләргә урын шактый түрдән икән. Ул замандагы нәшриятның баш редакторы Сафа ага Сабиров минем хикәяләрне ошатты. Аларны китап итеп чыгарырга дип мөһер сугылды. Шулай итеп, үзем Уралда яшәп торган җиремнән мин Казанда юка гына булса да, беренче китабымны чыгардым. Аны чыгарганда Сафа абый:

— Нигә дип, Радик туган, син «Бикташев» дигән псевдоним күтәреп йөрисең әле? Үз фамилияң дә ярыйсы гына ләбаса. Яңгырый да, — дип киңәш бирде. Китап үз фамилиям белән, ягъни «Радик Фәизов» имзасы белән чыкты.

Шулай итеп, без Дамира белән тормыштан канәгать, инде монда тәмам ияләнгән, картаеп үлгәнче Уралда яшәп калсак та риза идек. Менә җырларда, шигырьләрдә «кеше үзе туган җирендә, туган авылында гына

чын бәхетле була ала», дигән фикерләр еш яңгырый. Шагыйрәнә ялган бу. Әгәр кешеләр үз туган җирләрендә, туган авылларында гына яшәп калсалар, зур шәһәрләргә китеп, киң мәйданнарга чыкмасалар, күпме талантлар ачыла алмыйча йомылып калыр, күпме мөмкинлекләр кулдан ычкындырылыр иде. Адәм баласына ил-җирләр гизү, киң мәйдан, зур аудиторияләр кирәк. Үз авылында яшәп калса, кем генә танылган артист, язучы яисә зур галим, җитәкче, дәүләт эшлеклесе булып китә алыр иде икән?!

Әмма адәм баласы тәгъбирле, язмыш тәкъдирле дигән сүз бар бит әле. Кызганыч ки, бик тә дөрес сүз. Паровозда эшләп йөргәндә, инде эштән соң машинистлыкка укып кулга права алам дип фараз кылганда, язмыш минем яңакка берне китереп сукты. Саллы гына итеп. Уң як колакка әлләни булды. Сул яктан әйбәт ишетәм, әмма сөйләүче уң якта торса, аның тавышы шунда ук тоныклана. Шайтан алгыры, чукраклана барам түгелме мин?!

Баштарак мин моны беркемгә дә сиздермәскә тырыштым. Тик... Бер станциядә тукталып торабыз. Мин паровоздан төштем дә, чәйнеккә салкын су тутырып алырга дип, станция йорты ягына киттем. Аны-моны уйламыйча барам шулай тимер юл буйлап. Ярый әле аякларым, бөтен гәүдәм белән җирнең поезд якынлашып килгәндә була торган калтырануын тоеп алдым. Сискәнеп борылып карасам... маневр паровозы этеп килгән вагоннар минем өскә килә. Юлдан читкә сикерергә чак өлгердем. Тагын бер секундка соңарсам... Баш вагон мәйданчыгындагы таныш поездлар төзүче янымнан катлы-катлы итеп сүгенеп үтте. Ул сыбызгысын сызгырта, ул кычкыра икән. Ә мин берни ишетмәдем. Бу хәлдән аркаларым чымырдап китте.

Авыр поезд белән үр менеп киләбез. Паровоз бар җегәрен салып шаулый. Саша үз урыныннан миңа борылып нәрсәдер кычкырды. Тагын, тагын кычкырды. Аңлап кына булмый бит сүзләрен... Җитмәсә, машинист бит ул нәкъ минем уң якта. Инде станциягә килеп туктагач, Саша үзенең җете зәңгәр күзләре белән миңа бераз аптырап, текәлеп карап торды:

— Син нәрсә, Радик? Әллә ишетми башладың инде? — диде ул.

— Юк ла инде. Машина шавы бик көчле бит,— дигән булдым мин.

Ул арада ел саен була торган комиссия вакыты килеп җитте. Тимер юлчыларның сәламәтлеген, ишетү-күрү дәрәҗәләрен ел саен врачлар тикшерә һәм бик җентекләп тикшерә. Бу комиссиянең рәисе үзебезнең трест поликлиникасы врачы Иван Иванович. Инде бик симергән авыр гәүдәле, зур табак битле, гел кызмача йөри торган бу кешене пычагымны да белми дип сөйлиләр. Әмма ул кеше буларак киң күңелле, әйбәт иде. Менә мин комиссия үтәм.

— Уң як колагыңны яп!

Мин уң як колак тишегенә бармагымны тыктым.

— Сул ягын яп!

Менә монда инде хәйләгә керергә кирәк. Колак тишеген каплагандай гына иттем. Тик «берни белмәгән» Иван Иванович минем башыма китереп суккандай итте.

— Уң ягың белән ишетмисең син, Фәизов. Сине тимер юлдан, паровоздан алырга туры килә. Теләсәң, әнә слесарь булып депода йөрерсең,— диде ул, ваемсызлык белән генә һәм каләменә үрелде. Хәзер бер сүзе белән синең язмышыңны боза да ташлый, ике дә уйламый.

— Иван Иванович, зинһар өчен! — дидем мин ялынып.— Зинһар өчен әлегә берни язмый торыгыз. Мин... колагымны дәваләрмын... Ничек тә берәр җаен табармын әле. Сез инде әлегә язмый торыгыз.

— Ярый, мин язмый тора алам анысы,— диде ул киң күңеллелек белән.— Әмма ни бит... Озакка сузмый мәсьәләне үзең хәл ит син, Фәизов. Үзең беләсең, безнең поликлиникада борын-колак врачы юк. Без сиңа ярдәм итә алмыйбыз. Әнә шәһәрнекенә бар. Тик, ишетмәгән килеш тимер юлда эшләп йөрүнең нәрсә белән бетү ихтималын син үзең бик әйбәт беләсең! — диде ул.

Бардым шәһәр поликлиникасына, кердем колак врачы янына. Теге, сап-сары сипкелле, шүрәле төсле ябык вә озын буйлы, галәмәт усал тавышлы бер хатын колагымны актарды, борын тишекләренә әллә нәрсәләр тыгып бетерде. Инде тәмам азаплагач, процедурага җибәрде. Колакка уникe мәртәбә кайнар пычрак сыларга. Үттем бу хикмәтләрне дә. Ник бер файдасы тисен. Шунда инде теге врач үзенең озын, тимер кеби бармагы белән маңгаема китереп төртте.

— Булмый! Колак эченә синең тоз утырган. Каты һәм зур булып. Моңа инде операция кирәк! — дип хөкем чыгарды ул.

— Мин операциягә риза. Иртәгә үк килеп җитәм! — дидем мин шатланып. Әмма теге шатлыгымны тиз сүрелдерде.

— Кайда ул сиңа монда... операция?! Бик нечкә эш ул, аны Мәскәүдә генә ясыйлар әлегә. Ә анда аның чираты еллар буена алдан алына... Һе, операция, имеш! — сипкелле шүрәле һәм тагын маңгаема төртте. Бу юлы инде утын агачына төрткәндәй битарафлык белән.

Мин хәсрәт диңгезе уртасында калдым. Инде ни эшләргә, кая барырга? Паровозны ташлап беркая да китәсе килми бит минем. Инде үзебезнең депода слесарь булып та йөрисем килми... Менә һаман да шулай минем язмыш. «Җиттем!» — дигәндә генә җимереләм дә төшәм.

Без кайчандыр Әтнәнең саклык кассасында үзем белән бергә эшләгән Әхәт Фазылҗанов белән хат алышып тора идек. Районнар берләшкәч, Әхәт Арчага күченеп килде, район газетасы редакциясендә эшли. Мин ул газетага әледән-әле хикәяләр җибәрәм һәм алар чыгып та торалар. Әхәт — минем дус, өстәвенә тормышны миннән яхшырак белә торган, бик дөньяви, тәҗрибәле кеше. Барлык моң-зарларымны әйтеп, аңа хат язып салдым. Тиз арада җавап та килеп төште.

«Бәс хәлләрең андый булгач, каңгырап йөрмә анда. Тот та монда кайт. Без сиңа редакциядә эш бирәбез. Син бит — әзер журналист, сине өйрәтеп тә торасы юк. Арчада хәзер гомуми йортлар да салына, фатиры да булыр. Сиңа, татар язучысы булырга өметләнеп йөргән кешегә, татар арасында, татар дөньясында яшәве дә бик кирәк бит әле аның. Анда урыс арасында яшәп, күпме татар сүзе ишетәсең. Синең бит ни урыс, ни татар булып калуың бар...» — дип язган иде Әхәт дус хатында.

Язмыш дигән убырлы карчык менә шулай ул. Сине үзе ничек тели, шулай бутап тик йөртә. Шулай итеп, безгә дә үзебез инде тугыз елга якын яшәгән, иң әйбәт, матур яшьлек елларыбызны үткәргән, инде тәмам ияләнеп беткән шәһәребездән, нинди әйбәт фатирыбыздан кубарылып, кайтып китәргә туры килде. Ярый әле, Дамираның әти-әнисе Арчаныкы, безнең кайтып егылыр урын бар иде.

Менә туган ил, туган җир сагындыра, онытылмый, дибез. Бу шулай, әлбәттә. Тик, никадәрле еракта булмасын, үзең барып шундый еллар буе, кеше буларак ныклап аякка баскан җиргә дә бик ияләшәсең икән аны. Без Дамира белән, Урал суы буенда җәелеп утырган, комбинаты көне-төне кара төтеннәр төтәтеп утырган, инде бездән бик еракта калган Магнитогорск шәһәрен әле дә булса сагынабыз. Аның кояшлы киң урамнарын, чуеннан бизәкләп коелган рәшәткәләрен, иркен кибетләрен, хәтта трамвайларын да төшләребездә күрәбез. Җае чыккан саен анда яшәп калган бертуган абыем янына кунакка бара идек. Менә соңгы елларда ул бәхеттән дә колак кактык. Юл бәясе — коточкыч.

* * *

**1965** елның язында без Арчага кайтып төштек.

Арча — ул заманда әле үр өстендә утырган бер-ике катлы йортлардан торган, әлләни зур булмаган бер поселок иде. Урамнарында коры булса — тузан, яңгыр явып китте исә пычрагы да мулдан. Дамираның әти-

әнисе шактый иркен агач йортта тора, инде бала-чагаларын үстереп, кайсын-кая озатканнар, үзләре генә иде. Әби, йомшак телле, һәр нәрсәнең җаен таба белә торган, бик зиһенле, җыйнак гәүдәле бер карчык. Бабай — киресе. Таза, олпат гәүдә, киң йөзгә шадра төшкән, калын кашлар астындагы яшькелт күзләр синә текәлеп, нindидер яшертен бер киная белән көлемсерәп карыйлар.

— Әйдүк, әйдүк! Күпме кирәк, шулкадәр торыгыз! — дип каршылады ул безне.

Менә мин эшкә барам. Өстемә чиста ак күлмәк, кара костюм киеп, муеныма галстук бәйләп. Газета редакциясенә! Арчаның үзәк урамы иртәнге кояш нурларына коенган, каршыга очраган кешеләр дә елмая кебек. Минем күңелдә нindидер һавалану, куаныч. Соң, шулай булмыйча! Әле кичә генә мин өстемә мазутка буялган киемнәр киеп йөргән гади бер эшче идем бит. Ә менә хәзер интеллигентлар, зыялылар арасына кереп барам... Шулай да күңелне тагын бер корт кимерә әле. Яле, егетем, әгәр дә син ул редакциягә пычагым да майтара алмасаң. Синең бит гомереңдә бер мәкалә язып караганың юк. Хикәя язу гына — нәрсә әле ул... Паровозда инде барысы да шалкан кеби гади иде, винтельне бордың — топкага мазут килә, регуляторны ачып җибәрдең, машинаң бара. Монда синең алдыңа әллә ниткән кыенлыклар, үзең әлефен таяк дип тә белмәгән эшләр килеп басса? Аларга тешең-тырнагың үтмичә, хурлыклы рәвештә ишекнең кайсы якка ачылганын күрсәтсәләр?! Шундый тәшвишле уйлар белән мин кибетләр арасындагы аулак бер урында посып кына, мескен булып кына утырган бер катлы редакция йортына килеп җиттем. Алланың үзенә тапшырып, пыялалы ишекне ачып җибәрдем һәм... инде гомеремнең калган өлешенә сузылачак журналист маҗаралары дөньясына кереп киттем.

Бик тар гына, караңгы коридорда Әхәт Фазылҗанов кына йөренә, башка кешеләр әле килмәгән иде. Тар коридор димәктән, бу редакция йорты тышыннан да тәбәнәк, эченнән дә бик кысан, шыксыз, караңгы бер хәрабә булып чыкты. Әбәү, моның бүлмәләре безнең паровоз будкасыннан да таррак түгелме соң? Бүлмә саен бер тәрәзә, ә ике кеше кара каршы очрашсаң, ян белән генә борылып үтәрлек дәрәҗәдә тар коридорда тәрәзә гомумән юк, ул дөм караңгы дияргә була. Дөресен әйтим, мин ничектер күңелем кайтып, аптырап калдым. Әхәт тә минем хәлне аңлап алды, ахры.

— Беләсеңме, нинди йортта эшләү бәхете тиде сиңа? — диде ул көлеп. — Белеп торыгыз, хөрмәтле язучы вә журналист Радик Фәизов, тарихи йорт булыр бу. Элекке бер Арча баеның күпсанлы тарантасларын кертеп куя торган сарае бу! Карета сарае, ягъни. Сез галиҗанәбләре менә шушы карета сараенда илһамлы иҗат дәртенә биреләчәксез инде! Уңышлар телибез сезләргә!

— Ничек инде редакция — карета сарае булсын?! — дидем мин, Әхәтнең бу сүзләрен шаяртуга алып. Әхәт, гомумән, шулай киная салып сөйләргә ярата торган кеше инде ул.

— Ә ни эшләп булмасын? Әнә тәрәзәләргә җентекләп кара әле. Үзең дә төшенеп алырсың,— диде Әхәт.

Чыннан да, тәрәзәләргә әйбәтләп карасаң, аларның элеккеге киң, түгәрәк өсле капка урыны икәне ачык беленеп тора икән. Капкаларны кирпеч өеп тарайтканнар да, тәрәзә ясап куйганнар. Карета сараеннан башта «Яңа тормыш», ә аннары инде «Коммунизмга» ук дип аталган газета редакциясе әмәлләп куйганнар... Алга китеп әйтим, Арча районының хәзерге «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе әле дә булса шушы каттә йортта көн итеп ята. Бары тик бер үзгәреш бар. Мөхәррир булып инде күптән мәрхүм Ринат Таҗиев эшләгәндә янкорма өйдереп, аның коридорын гына бераз киңәйтте. Яңа бинаның якын киләчәктә генә салынасына да бернинди өмет күренми әле. Шушы бинада җан чыгармый көн итеп булса, бик әйбәт инде...

Ярый, әлегә минем эшкә беренче килгән көн генә бит. Тиз арада барлык хезмәткәрләр дә җыелды. Бераз көттереп мөхәррир Шакир ага Гафаров та килде. Шакир ага тәбәнәк буйлы, йөзенә тимгелләр төшкән, киң борынлы, инде олы яшьтәге кеше. Салмак кына итеп сөйләшә икән.

— Мин КПСС райкомында булдым,— диде ул үзенең тоткарлануын аңлатып, ахры. «КПСС» сүзен ничектер яратып, тәмләп, йомшак итеп «кә-пә-ис-ис» дип әйтте.

Барысы да редактор бүлмәсенә җыйналдылар. Бу бүлмәнең бүтәннәрдән аермасы шунда: ул аз гына иркен, стена буйларында утыра-утыра каешланып беткән урындыклар, ямьшәеп беткән бер диван тора. Газетаның чираттагы санын планлаштыра башладылар. Әхәт минем янга утырды, кайбер аңлатмалар биреп барды.

— Бу санга нинди шапка куябыз,— диде Шакир абый һәм өстәлдә яткан ак, кабарынкы кулларының симез бармакларын уйнатып алды.

— Шапка — беренче биттә иң өстәге зур хәрефләр белән җыелган баш, чакыру, лозунг була инде,— дип пышылдады миңа Әхәт.

— Язгы көн — ел туйдыра!

— Нәрсә, әйбәт шапка бу. Моңа, шәт, кәпәисис райкомында да каршы килмәсләр,— диде Шакир абый һәм аның бармаклары канәгатьләнү белән уйнап алдылар.— Ә баш мәкаләгә нинди тема алабыз?

— Балаларның җәйге ялы!

— Туктагыз әле, җәйге ялга иртәрәк бит әле. Менә «Искра» колхозы терлекчеләренең кышлату йомгакларын яктыртырга кирәк. Шуңа бәйләп җәйге чорга алда торган бурычларны куярга да була,— диде мөхәррир.

— Һаман да шул «Искра» да «Искра». Газета укучылардан оят бит инде...— дигән ризасызлык ишетелде. Шакир ага аскы иренен алга чыгарды.

— Алдынгыларны ничә күрсәтсәң дә, артык булмый, аппагым! Моны бит кәпәисис райкомында да хуплаячаклар,— диде ул.— Димәк, баш мәкалә — терлекчеләрнең җәйге чорга бурычлары.

— Баш мәкалә — беренче биттәге ике баганы алган редакция нотыгы, акыл сату, сүз уйнату була инде,— диде миңа һәр нәрсәне тешләп кенә сөйләшергә ярата торган Әхәт.

— Гата Хәлиуллинның мәктәпләр турындагы зур мәкаләсен кая куябыз?

— Аның урыны шул инде — икенче биттәге подвал.

— Подвал — газета битенең аскы өлешен алып торган зур мәкалә була,— дип аңлатты Әхәт.

— Ә Сәмигуллин Гыйниятнең теге язмасын?

— Авыл хуҗалыгы бит ул. Өченче биткә, чердакка.

— Чердак — газета битенең өске өлешен алып торган язма,— диде Әхәт.

Менә планлаштыру тәмам булды. Мин инде үземә нинди эш кушарлар, кая куярлар икән дип, пошынып утырам. Берни белмим бит әле!.. Бүтәннәр белән бүлмәдән чыгып барганда Шакир абый ишарәләп мине туктатты. Өстәле тартмасыннан клеенка тышлы калын бер дәфтәр чыгарды.

Менә бу, аппагым, бер өлкән хәбәрченең язмасы. Бик буталчык, авыр язылган, әмма эчтәлеге бар. Аны эшкәртергә Әхәт ирене, башкаларның исә тешләре үтми. Әллә син алынып карыйсыңмы шушы эшкә? Безнең өлкән, бик ихтирамлы хәбәрчебез инде бу, сугыш юлларын да үткән кеше,— диде Шакир абый. Боерык бирү тоны белән түгел, бер үтенеч сымак итеп әйтте.

Башта ук шунысын әйтеп куйыйм, редакциядә эшли башлавымның беренче көнендә үк минем күңелгә шундый уй кереп утырды: ни генә кушсалар да, ихлас салып, тырышып, әйбәт итеп башкарырга. Күпме урыннарга күчтем, күпме мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдым инде мин, тәмам туйдым инде андый хәлләрдән. Менә шушында ябышып

эшләргә кирәк хәзер! Һәм мин барлык хәбәрчеләрнең хатларын игътибар белән карап, җентекләп укып, кирәк икән, яңадан язып эшкәрттем.

Ә теге өлкән хәбәрченең калын дәфтәрдәге язмасы «Сандыктагы генерал» дип атала иде. Эчтәлеге, дөрестән дә, шактый кызыклы. Сугыш вакытында безнең хәбәрче үз отделениесе белән бер немец шәһәренә килеп керә. Шунда, зур маҗаралар үтеп, сандыкка кереп качкан бер немец генералын эзләп таба болар. Эчтәлеге бар, әмма язуы... Бер генә җөмләнең дә иясе, хәбәре үз урынында түгел, иясә бөтенләй дә юк.

Мин бу язманы бер дә ашыкмый гына яңабаштан язып чыктым. Кайбер нәрсәләрне бераз үземнән дә өстәдем. Аны Шакир абый алып укыды да, миңа карап, бармакларын бик канәгать төстә уйнатып торды.

— Бик әйбәт булган бит бу, аппагым! Әллә кайчан безгә кайтасың калган икән аны... Әзер журналист икәнсең бит син! — дип, мине мактап та алды. Сүз уңаенда әйтим, кешенең эшен күрә белә торган, бераүгә дә каты бәрелми торган, әйбәт кеше иде Шакир ага.

Өлкән хәбәрченең бу язмасы газетада зур һәм кызыклы булып басылып та чыкты. Әй, буа ерылып та китте инде шуннан! Калын-калын дәфтәрләрне берсе артыннан икенчесен җибәреп кенә тора теге карт. Байтагын яңадан яздым, денгә керттем мин аларны. Күп язмалары чыкты газетада. Укучылардан хатлар килде хәтта. Берзаман шушы хәбәрче, инде, гафу итегез, кабер якасына килеп җиткән, тәмам җөдәп беткән бер карт, редакциягә үзе килеп керде. Миңа рәхмәтен әйтерме дигән идем. Әмма башкачарак килеп чыкты.

— Энем, син шуны әйт әле миңа. Минем шушы язмаларымны бергә җыйнап Казанда китап итеп чыгарып булмас микән? Һәмдә ки син моны үз өстеңә алмыйсыңмы? — дип шыгырдады ул.

Шушы уңайдан мин бездәге журналистикага зур зыян салган, сәләтле журналистлар арасына чын халтурщиклар килеп керүгә юл ачкан бер хәлне әйтеп үтим. Нәкъ менә шушы хәбәрчеләрнең хатларын редакцияләргә яңадан язып эшкәртү нәтиҗәсендә журналистлар сафына очраклы, язу эшен белмәгән, бөтенләй дә сәләте булмаган кешеләр килеп эләгә. Җибәрә шундый бер кулайсыз егет редакциягә хат язып. Булмый бу язманың ни иясе, ни хәбәре, ул бернинди яңалык та алып килми. Ә редакция папкасы буш, хәбәрчеләр сирәк яза. Ә «кәпәисис» райкомы хәбәрчеләр хатларын сирәк урнаштырасыз, дип кисәтеп кенә тора. Ә урыннардан хәбәрчеләр эзләү, аларны вербовать итү, аларга ялыну, ни генә язып җибәрсәләр дә, газетада чыгаруны вәгъдә итү бара. Язу эшендә әлепне таяк дип белмәгән кешеләрдән урыннарда хәбәрчеләр постлары төзү. Редакциядә җыелыш саен: «Хәбәрчеләр белән эшләмисең!» — дип, хатлар бүлеге мөдирен бастырып куеп сүгүләр... Менә шуннан соң тотына инде редакция хезмәткәре теге егет язып җибәргән «шедевр»га ике куллап. Яңадан яза, телефоннан шул урынга шалтыратып, әллә никадәр яңа фактлар, саннар, хәтта фамилияләр өсти. Шулай тырыша торгач, ярыйсы гына хәбәр, зарисовка килеп чыга тагын. Һәм озакка сузмыйча гына газетада басылып та чыга. Әлбәттә инде, теге «автор» имзасы белән. Ә ул, беләсегез килсә, төшеп калганнардан түгел, ул уңган егет. Теге язманы газетадан кисеп ала да, кулларын угалап, әйбәтләп кенә бер калын дәфтәр битенә ябыштырып та куя. Аннары и... ни эшли? Аннары инде бик эшлекле, горур кыяфәттә кулына тагын каләм ала... Инде вакытлар үтеп, теге калын дәфтәр битләре ябыштырылган язмалар белән тулгач, ошбу дәфтәрне калкан итеп күтәрә дә, Казан дәүләт университетының журналистика факультетына килә. Ә тегендә бу абитуриентның дәфтәрен алып укып карыйлар да сокланалар. Менә бит! Өлгереп житкән журналист килгән... Кабул итәргә моны, һичнинди кир-тә-миртәләрсез!

Минемчә, булачак журналистларны ябыштырылган дәфтәрләргә карап түгел, ә урыннарга, район газеталары редакцияләренә, килеп, яшь хәбәрчеләрнең үз куллары белән язган хатларын укып сайлап алырга

кирәк. Моның бернинди артык мәшәкате юк, чөнки хәбәрчеләр язган хатлар редакцияләрдә еллар буе саклана. Ә яшь хәбәрчеләр арасында чын сәләт, талант ияләре да бар бит. Бу хакта киләчәктә сүз булыр әле.

Мин — редакциянең хатлар бүлеге хезмәткәре, әлбәттә инде, өстәл артында хәбәрче хатларын төзәтеп кенә утыра алмадым. Тиз арада Шакир абый мине урыннарга, колхозларга командировакага да йөртә башлады. Беренче сәфәрем аеруча хәтергә сеңеп калган.

— «Тукай — Кырлай» колхозына барасың. Урып-җыюга әзерлекнең торышын яктыртасың,— диде миңа Шакир абый. Мин аны аңлап җиткермәдем:

— Туктагыз әле, Шакир абый. Ничек инде ул — урып-җыюга әзерлек? Әле бит язгы эшләр дә бетеп җитмәгән...

— Һәһ-һә! — дип көлде мөхәррир.— Әгәр редакциядә эшлисең икән, син андый оппортун фикерләреңне башыңнан чыгарып ташла инде, аппагым. Бер урак беткән көннән аның икенчесенә әзерлек, җәй башыннан терлекләрне кышлатуга хәстәрлек башлана ул авыл җирендә. Колхозчы моңа өлгерә аламы, ул нәрсә уйлый — монысы синең эш түгел. Синең эш — фактларны кәгазьгә теркәү дә монда кайткач, аларны тулы итеп кәгазьгә төшерү. Кәпәисис райкомы шулай куша... Колхоз рәисе Сәлах Садриевичның үзен күр. Ул әйбәт кеше, барысын да яшерми сөйләп бирер. Син аннан менә ниләрне сора...— диде мөхәррир һәм мин колхоз рәисенә бирәсе сорауларны тезеп китте. Ә мин аларны блокнотыма терки бардым.— Бар, командировочный яздырып акча ал да, юлыңда бул!

Ул заман әле редакциянең җиңел машинасы әллә юк, әллә ватык иде шунда. Мин Арчаның төньяк читенә чыгып, юл буена бастым. Күрәм, Яңа Кырлай ягына өсте ябулы ике машина килә. Алдагысы туктап, мине кабинага утыртты. Шоферы Әнвәр исемле, минем яшьләрдәге кеше. Юл буе тегесен-монысын сөйләшеп бардык. Мин үзем кешегә ачык күңелле, хәзер аралашып, сөйләшеп китәм.

— Кич белән дә сезгә утырып кайтып булмас микән? — дидем мин Әнвәргә, инде Кырлайга җиткәч.

— Нишләп булмасын? Без Кенәр зонасы сельполарына азык-төлек, аракы илтәбез. Кичке дүртләрдә кире әйләнәбез. Мин сине сәгать бишкә кадәр шушында көтеп тә тора алам. Тыныч бул, калдырып китмәм! — диде Әнвәр.

«Тукай — Кырлай» колхозының идарәсе кайчандыр бөек шагыйребез Г. Тукайны сыендырган Сәгъди абзыйлар йортының янәшәсендә генә, манарасы киселгән элекке мәчет йортында икән. Мин анда курка-курка гына кердем. Колхоз рәисе нинди кеше бит әле, ул мине ничек каршы алыр? Материалны ничекләр итеп туплармын? Әмма мәчет йортының аскы катындагы шактый иркен бер бүлмәгә килеп кергәч, шөбһәләрем бердән тарала төште. Түрдәге киң өстәл артында миннән күп булса бер-ике яшькә генә олы, әмма инде шактый талчыккан кыяфәтле, өстенә таушалган сырма кигән, гади колхозчыдан берние белән дә аерылмаган бер кеше утыра иде. Нииндидер бер әчке сырхавы да бар, ахры, сулышы тоткарлана. Мин урыннарга баргач, төрле юк-барны, мәзәк сөйләшеп вакыт үткәрмәүне беренче көннәрдән үк үземә кагыйдә итеп куйдым. Хәл-әхвәл сорашып, танышып алуга, блокнотымны чыгарып өстәлгә салдым.

— Әзерлек бар инде ул анысы, булмыйча кала алмый инде ул. Тик мактанырлык кына эшләр юк әле... Менә комбайннар әзерлек сызыгында исәпләнә инде исәпләнүен. Әмма, әле тегесе тишек, монысы ертык дигәндәй, кайсысына аккумулятор кирәк, кайсысына — каеш. Аның өчен әйбер табып булмый бит, иптәш корреспондент...— дип сөйләде Сәлах Садриевич. Аның ихластан сөйләгәнен сизеп була иде. Ул үзен минем алда ничектер уңайсыз, хәтта гаепле төстә тотып, үтенүле итеп өстәп куйды: — Сез анда... бик каты язмассыз инде. Бүтәннәр алдында безне хур итеп ташламассыз...

Һәм мин урыннарда редакциядән килгән кешегә ихтирам, хәтта аннан курку кебек нәрсәнең дә бар икәнен тоеп алдым. Яшерми әйтим, бу миндә ниндидер канәгатьләнү тудырды, үз алдымда үземнең дәрәҗәм күтәрелде сыман.

Сәлах үзе рульдә икән, мине машинасына утыртып алып китте, машиналар утарында рәткә тезелеп куелган комбайннарны, ургычларны карадык.

— Боларның күбесе төзек. Кирәк икән, иртәгә басуга чыгып китә ала! — дип сөйләде Сәлах. Ул арада аны колхозның завхозы каядыр чакырып алды. Рәиснең китүе булды, шундагы механизаторлар, күбесе инде олы кешеләр, мине уратып алдылар. Зарланулар китте.

— Эшләрнең рәте- башы юк бездә, энем!

— Бу комбайннарны яңабаштан карап чыгасы бар әле...

— Запчасть юк, бер гайка таба алмый интегәбез...

— Түрәләр, Сәлах үзе дә бик сирәк килә безнең янга...

— Ремонттагыларга түләү юк...— дип сөйләделәр механизаторлар бер-берсен бүлеп һәм... кисәк авызларына су капкандай тынып калдылар. Карасам, колхоз рәисе безгә якынлашып килә икән...

Эш турында без күп булса ике сәгать сөйләштек. Аннары Сәлах мине машинасына утыртып, инде уҗымнар күтәрелеп килгән басуларга алып чыгып китте. Тукайның Шүрәле урманына алып менде. Төш вакытында колхоз ашханәсенең арткы аулак бүлмәсендә бик тәмле борчак ашы белән сыйлады.

— Син, Радик, гафу ит, монысы гына булмады инде,— диде ул бармагы белән ияк астына чиртеп.— Үземнең дә кәефсезләнеп йөргән вакыт...

— Кирәкми, ниткән ул! — дидем мин, уңайсызланып. Сәлахның дөнья тарафыннан яхшы ук кыйналган, әйбәт кеше икәне күренеп тора иде. Ул хәтта мине кичен үз машинасы белән Арчага кайтарып куярга да әйткән иде. Мин хәзер үземне күкнең җиденче катында, шактый һавалы хис итсәм дә, монысына ук бармадым. Артык булыр ул алай ук дип санадым. Кичке дүртләр тирәсендә юл читенә чыгып бастым.

Ул арада болытлап яңгырга җыена башлады. Күрәм, теге ике машина кайтып килә. Ничектер тоткарланып, шактый акрын кайталар болар. Әнвәр бу юлы арттан кайта икән. Ул кабина ишеген ачып миңа әйтте:

— Син алгы машинага утырып кайт әле, Радик. Аның шоферы... Без бүген аракы тараткан идек, үзең беләсең инде... Син шуның янына утырып, кабыргасына төрткәләп кайт әле. Находу йокыга китмәсен. Андый гадәтләре бар аның.

Алдагы машинаның кабинасына керүгә, аның шоферы, йөзе дә, күзләре дә бик нык көчәнгән кешенекедәй кып-кызыл булган, таза гына егет, тупас итеп иңбашыма шапылдатып алды.

— Һа, корреспондент! Кайтабызмы?

— Без кайтабыз. Әмма син, шофер, рулеңне туры тот! — дидем мин.

— Һа! Корреспондент кушкач, туры тотарга! — диде исерек егет һәм шатырдатып газга басты.

Ул арада җәйге яңгыр коя башлады. Чиләкләп. Болай гына күтәрелгән, бернинди асфальт җәелмәгән юл әлләни арада гына тәмам камыр булды. Машинабыз мут хатыннар кебек артын як-якка боргалый башлады. Хәзер җиргә төшереп бастырсаң, мөгаен генә, аягына да басып тора алмаслык шоферның башы да анда-монда бәргәләнә. Шул уңайга машина да пычрак юлның әле бер ягына, әле икенче ягына авыша.

— Син... ныклап тот! Юл читенә барып төшә күрмә! — дип кычкырдым мин, котым ботыма китеп.

Әйтеп кенә бетердем... Машинабыз биек дамбадан юл читенә төште дә китте. Ничек ул дөбердәп капланмады, шунысын әлегә кадәр аңлый алмыйм. Юкса бер як тәгәрмәчләре юл читендәге җирдән күтәрелеп тә беткән иде бит инде. Алла үзе саклады, күрәсең.

— Ни булды бу хәзер...— дидем мин, сулышымны көчкә алып.
— Нәрсә булды?! Бер нәрсә дә булмады... Син, корреспондент, мин барында курыкма! — диде үзе дә бераз айный төшкән шофер, искитмәле ваемсызлык белән.— Әллә син мине шушыннан юлга чыгып баса алмас дип беләсеңме? — Һәм машина яман үкереп, юл читендәге басуны ярып бара башлады. Бераз баргач, бер уңайлы урын туры китереп, чыннан да, шофер машинаны юл өстенә чыгарып та куйды.— Менә күрдеңме син! Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк! — диде ул, миңа мактанулы төстә карап.
Инде Арчага дүрт-биш километр калгач, Пәшкәү урманы дигән агачлык бар. Шул турыга җиткәч, Әнвәр машинасы кинәт безне үтеп китте дә, юл читенә чыгып туктады. Аның артына кереп, без дә туктадык.
Яңгыр инде үтеп киткән. Еракларга җәелгән, яңгыр әле генә юып алган ямь-яшел басулар, урман полосалары, еракталы зәңгәр урманнар шулкадәр матур, һава шулкадәр саф. Миңа, әле күптәнме авыр һавалы шәһәрдә торган кешегә, оҗмах тоелды бу.
— Бу килештән Арчага кереп булмый әле. Бераз шушында хәл алыйк,— диде Әнвәр һәм без юл читендәге үләнгә утырдык.
Шунда безнең машиналар артына бер җиңел машина килеп тортелде. Аннан өч кеше төшеп, безнең янга килде. Барысы да чиста киемнән, галстуктан. Мин әлегә район җитәкчеләрен танымыйм, әмма боларның төрле рангтагы түрәләр икәне әллә каян күренеп тора. Һәм алар үзләрен чын түрәләрчә тоттылар.
— Сез... аракы тараттыгызмы? — диде аларның берсе, ялтыр күзле, йөзенә кызыл борчекләр төшкән, тәбәнәк буйлысы. Монысы иң зур түрә иде, ахры, кискен, янаулы итеп әйтте.
— Без бүген аракы да тараттык,— диде Әнвәр.
— Китер хәзер үк бер яртыңны! — диде борчекле йөз һәм Әнвәргә акча сузды.
— Юк шул ярты. Таратып бетердек...
— А ну ач әле машинаңны! Үзебез табып алсак, кара аны, миңа үпкәләмә...— дип, бик хәтәр янады теге түрә Әнвәргә һәм алар өчәүләп арткы ишектән өсте ябулы машина эченә кереп киттеләр. Анда әрҗәләр, тагын әллә нәрсәләр кузгатып, дөбер-шатыр йөренделәр. Ике машинаны да шулай тикшереп чыктылар. Аракы таба алмагач, йөкчеләрдән дә болай яман сүгенделәр. Күренеп тора, алар кайдадыр яхшы гына төшереп алганнар. Ә бер авыз тигәч, мәгълүм инде, аппетит котыра, тагын сорый.
— Карагыз аны, телегезне авыз эчендә тотыгыз! — дип, тагын янады теге борчекле йөз, кузгалып киткәндә.
Алар китеп күздән югалуга, Әнвәр урыныннан торып, кабина ишеген ачты да, утыргычы артыннан... бер яртыны тартып та алды.
— Менә... фәләнем ул бушбугазларга! Бирермен мин аларга... Янаган була бит тагын. Бу яртыны инде саклап калырмын дигән идем. Насыйпка түгел икән, егетләр. Әйдәгез, хәзер үк шушында бөклибез аны! — диде ул һәм без шунда чирәмдә утырып, өчебезгә бер яртыны җөпләп тә куйдык.

* * *

— Йә, ничек, булдымы? Бераз материал туплый алдыңмы? — дип каршылады мине Шакир абый икенче көнне иртән.
— Булды, бардым, сөйләштем.
— Булса, урып-җыюга әзерлектә кырлайлылар тәҗрибәсен яктырта торган материал яз. Үрнәк итеп кую кыйбласындарак булсын инде ул.
— Нинди үрнәк әле ул анда! Комбайннарның каешы җитми... Механизаторлар зарлана...— дип башладым мин.
— Һе, каеш, имеш! — дип бүлде мине мөхәррир.— Син монда андый фикерләр күтәреп йөрмә әле, аппагым. Каешның җитмәгәнен,

аккумулятор булмаганын монда без дә беләбез аны. Бу турыда газетада кабатлап торуның кирәге дә юк. Менә үрнәк күрсәтә алырлык мәкалә яз син. Халыкны хезмәткә тупларлык. Менә бит нәрсәне аңлый белергә кирәк безнең эштә! — Һәм мөхәррир симез бармагын югары күтәрде.

Һәм мин яздым. Иркен басуларда баш калкытып килгән игеннәр, хедерларының үткер тешләрен кояшта ялтыратып хәзердән үк алга, басуларга омтылып торган комбайннар, ургычлар, кулларына гайка ачкычлары тоткан көләч йөзле механизаторлар турында яздым. Шакир абый укып чыкты, аның кара тимгелле йөзе бердән яктырып китте.

— Менә бит, аппагым. Бик әйбәт булган бу! Безнең бу санга нәкъ менә шушындый мәкалә тәкъдим ителә дә иде. Анысы тәнкыйть тә кирәк, анысын да язарга өлгерерсең әле. Әле үткән санда гына «Заря» колхозыннан урып-җыюга әзерлекне тәнкыйтьләп, зур материал биргән идек без. Халыкның гел күңелен төшереп кенә булмый бит. Бу санга үрнәк кирәк иде... Журналист ул мәсьәләнең әнә шул якларын да исәпкә алып эш итәргә тиеш. Аңладыңмы инде, аппагым? Менә шулай ул...— дип аңлатма ясады миңа мөхәррир.

Район газетасының мөхәррире, КПСС райкомы бюросы әгъзасы шулай сөйләп күрсәткәч, мин инде аңладым. Димәк, шулай кирәктер. Башкача язсаң, ул бит синең материалны газетага үткәрмәячәк һәм... вәссәлам! Мин аңладым. Тик күңел түрендә зур кара тап булып үзүзеңнән канәгатьсезлек, оялу, нәрсәгәдер үртәлү юшкыны утырып калды. Кичә кич беренче мәкаләмне ничек язу турында уйланып ятканда минем күз алдында бөтенләй башка күренешләр, күңелдә башка планнар иде бит. Колхоз рәисе Сәлахның юаш кына, сырхау чырайлы йөзе, әле кубесе басуга алып чыгарга әзер булмаган комбайннар, ачулы, сүрән йөз белән җитмәүчелекне, җитәкчеләрнең ваемсызлыгын тиргәгән, хәтта газета хәбәрчесе күз алдында да колхоз рәисе белән әйткәләшеп алган механизаторлар иде. Хезмәткә түләүнең азлыгыннан зарланулар, ачулы төстә төкеренүләр... Менә нәрсәләрне язарга җыенган һәм язарга да тиеш идем мин. Ләкин мөхәррир, райком, ә аннан инде бөтен сәясәт барышы бөтенләй икенче нәрсәне таләп итә икән. Син нәрсә кушсалар, шуны язарга тиеш, син ныклы бер кыса эчендә утырасың икән! Беренче көннән үк миңа шуны аңлаттылар.

Күңелне нык кысып торткан бу кыса, бу авыр юшкын мине һәм, ихтимал, бүтән күпчелек журналистларны да, еллар, күп еллар буена озата килде. Әйтмим анысы, ул елларда тормышны булганынча яктырткан, бөтен караңгы якларын әйләндереп чыгарган мәкаләләр һәм публицистик язмаларны да күп яздык. Әмма шулар белән беррәттән, «үрнәк күрсәтү, туплау тонындагы»ларын да җитәрлек язарга туры килде шул. Газетада беренче бастырган мәкаләм үк, үзегез күрәсез, әнә шундыйрак булды.

* * *

Редакцияләр алар, кем әйткәндәй, проходной двор кебек. Безнең редакциядә дә төрле елларда бик күп кешеләр эшләп чыкты. Аларның бөтенесен дә хәтерләп бетерүе мөмкин эш түгел. Араларында язу эшенең әлифен таяк дип белмәүчеләр дә җитәрлек булды. Әмма мин араларына килеп кергәндә монда коллектив иҗади яктан шактый көчле иде.

Журналистларның иң үткер каләмлесе, оста һәм колачлысы, һичшиксез, Әхәт Фазылҗанов. Озын буй, бераз каратутлы юка йөз, кискен хәрәкәтле, һәрвакыт үткер, тапкыр сүзле. Зур-зур мәкаләләр, очерклар, тетеп ташлый торган тәнкыйть мәкаләләре, фельетоннар, репликалар яза. Зур практик, әле редакциягә килгәнче үк күп еллар бухгалтер булып

эшләгән, урыннардагы эшнең торышын тиз төшенеп ала. Әхәт Фазылҗанов каләменнән котылу юк! Тиз һәм җиңел яза. Авыллардан кайта, коридорда башын як-якка салып бераз сызгырынып йөри дә бүлмәсенә кереп тына. Күпме генә вакыт үтә, Шакир абый өстәленә зур гына әзер материалны китереп тә сала. Әхәттә юмор да бик көчле.

Бервакыт Шакир абый әле генә «кәпәисис» райкомыннан хәбәр алып чыккан. Күңелсез хәбәр.

— Һе, менә син, ә! Әле әйбәт кенә эшләп ятканда. Усман Шагиевичның үзен бездән алалар бит әле, егетләр. Казанга министр булып китә икән ул... Менә инде син, ә... Нинди яхшы эшләп йөргәндә...— дип уфтана Шакир абый.

Усман Шагиевич — райкомның беренче секретаре. Татарча дөресләп әйтсәң, Госман Шаһи улы була инде ул. Әйтергә кирәк, Усман Шагиевич бик яхшы секретарь, зур практик, бик булган, игътибарлы, көчле кеше, чын җитәкче иде. Безнең район халкы аны бик яратты һәм әле үзе киткәч тә сагынып сөйләде.

Шакир абыйның уфтануларына Әхәт чик салды.

— Бүтән кайгыларың булмаса, Усман Шагиевич киткәнгә башың авырмасын, Шакир абый. Иртәгә үк икенчесе килә бит аның. Изге урын буш торамы? — диде ул көлеп.

Мин фараз иткәнчә, редакциядә Шакир абый түгел, ә нәкъ менә Әхәт мөхәррирлек итәргә тиеш иде. Чөнки ул, кайсы яктан гына алсаң да, аннан күпкә көчлерәк. Әмма Шакир абый КПСС райкомы китереп куйган кеше иде шул.

Кызганыч ки, мин редакциягә килгәч, Әхәт Фазылҗанов бездә озак эшләмәде. Башта аны республика газетасы «Социалистик Татарстан»га махсус хәбәрче итеп алдылар. Аннан инде Балтач районында чыга торган газетага мөхәррир итеп җибәрделәр.

Авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире — Рамазан Яруллин иде. Уртача гына буй, чем кара чәч, борыны өстендә — бик зур, калын кысалы, калын пыялалы күзлек. Рамазанның эше һәрвакыт тыгыз, ул авылларга чыгып керә дә, яза да яза. Корректорлар Сания апа белән Һәдия апа җае чыккан саен аны мактыйлар:

— Менә Рамазан кебек язгыгыз сез. Аның җөмләләрен төзәтеп тә торасы юк.

Яруллин язган материалларны мин үзем дә укыйм һәм шул нәрсәгә: теленең шомалыгына һәм йөгереклегенә игътибар итә идем. Һәм тиз арада мин бу хәлнең серен төшенеп тә алдым. Авыл хуҗалыгы мөдире һаман да шул бер төрле эшләр, кимчелекләр, бер төрле уңышлар хакында, бер кыса эченнән торып яза икән. Бер үк төрле җөмләләр, хәтта сүзләр белән. Шуңа күрә, гадәттә, аның фикере дә, җөмләләре дә күптән әзер. Монда хәтта тырышлык куйсаң да, бернинди мөгез чыгара алмыйсың. Менә мондый материалны укуы да, төзәтүе дә бик җиңел. Корректорларның да бит үз мәнфәгате... Алар да җиңел генә эшләү ягын каера... Әхәт киткәч, Рамазанны мөхәррир урынбасары итеп куйдылар.

Газетаның җаваплы секретаре — Илсур Хөсәенов. Мөхәррирдән кала, бары тик аның гына аерым бүлмә. Илсур — тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле, зур зәңгәр күзле, бик чибәр, ыспай кеше. Аның янына кайчан гына кермә, эше һәрвакыт муеннан. Ул материалларны укый, төзәтә, макетлар сала, газета битләренә рәсемнәр, клишеләр сайлый да шуларны күтәреп, типографиягә йөгерә. Шушы мең төрле мәшәкате өстенә ул... тагын берсенә өлгерә. Үзе бик әһәмиятле санаганына. Төштән соң, кичкә таба, Илсурның түм-түгәрәк йөзенә бик нәфис алсулык йөгергән, күзләре майланып ялтырыйлар. Аның инде теле гаҗәеп йомшакланган, ул һәркемгә:

— Әй җаныкаем, бәгырькәем...— дип кенә эндәшә.

Их, муллык еллары бит! Редакция каршысындагы тәрәзәдән күренеп торган, ачуым килмәгәе, кулны сузсаң да җитәрлектәге генә кибеттә шәрабның, аракының ниндие кирәк, шул тулып ята. Чагыштырмача

арзанлы гына. Таныш-белешләргә астан гына, стаканлап та салып бирәләр инде. Илсурыбыз елт итеп кенә шул кибеткә әледән-әле чыгып керә... Кайбер көннәрне кичкә таба инде ул тәмам «булып», аяк өстендә басып тора алмаслык хәлгә килә. Ул тәкъдирдә инде без аны яшерен генә өенә озатып куябыз. Ярый әле, фатиры якында гына. Шакир абыйга шунда ук секретарь кирәк була, ул бүлмәләрне ачып, Илсурны эзләп йөри башлый.

— Кая гына китте соң әле бу Хөсәенов. Әле генә шушында иде бит...

— Хәзер килә ул, Шакир абый. Ашыгыч бер йомышы төшеп кенә китте,— дип тынычландырабыз без аны. Эшне сизгәндер инде Шакир абый да. Сизеп тә әйтмәгәндер, бәлки.

Әйтергә кирәк, Илсур бик яхшы күңелле, хәлеңә керергә, ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер бер кеше. Бервакыт шулай аның янына кереп, эшләп алган акчаның бик азлыгыннан, һич тә җитмәвеннән зарланып торам.

— Ә ни эшләп син миңа әйтмисең аны?! — дип гаҗәпләнде Илсур күзләрен миңа текәп.— Мин бит гонорар язам. Сиңа артыгын да тамыза алам. Синең бит материалларың әйбәт була. Их, син...— диде ул мине шелтәләп. Һәм, дөрестән дә, шуннан соң ул минем материалларга гонарарны мулрак яза башлады. Бу өстәмә әлләни күп түгел, җитмәүчелекне һич кенә дә каплый алмый иде үзе. Әмма бит адәм баласының күңеле булсын өчен дә күп кирәкми.

Сәер генә гадәтләре дә бар иде Илсурның. Берчак турнирга дип шахмат уйнап утырабыз. Монда эш бик хәтәр инде, киеренкелек белән, һәркем ничек кенә булса да отып чыгасы килеп уйный. Турнир бит, ярыш... Шунда кемдер миңа эндәште дә, мин ялт итеп кенә читкә борылып алдым. Аннан карыйм, минем бер тура юкка чыккан! Бөтенләй булмаган да кебек. Югыйсә, әле уенның да башы гына, тура алдындагы фигура да кузгатылмаган, ул берничек тә урыныннан чыгып китә, гаип була алмый.

— Ә минем бер тура кайда әле?! — дидем мин, бу хәлгә бик тә гаҗәпләнеп.

— Әй, җаныкаем, оттырдың инде син ул тураңны...— ди Илсур зәңгәр күзләрен бәрәңгеләндереп.

— Соң бит, әле аның алды да ачылмаган!

— Оттырдың инде син аны. Бәхәсләшмә! Бу партияне уйнап та торма. Оттырдың инде син! — диде Илсур, ялынган сыман.

Шулай итеп, бу партиядә ул мине ансат кына отып алды. Ни хәл итәсең, бик тә отасы килгәндер инде...

Илсур бичара, ни кызганыч, бу дөньяда бик аз гына яшәп калды. Беркөнне ул мине үз бүлмәсенә дәшеп алды.

— Радик, җаныем, синең да ашказаның авырта бугай, иеме? Аңа каршы нәрсәләр генә эчәсең соң син? — ди бу. Үзенең төсе киткән, түгәрәк йөзе суырылып калган.

— Мин «Викалин» эчәм. Башлыча шул ярдәм итә миңа,— дидем мин.

— Җаныем, миңа да биреп кара әле шуны. Эчеп карыйм әле. Әлләнигә ашказаным гел борчый башлады. Гел тырмап тора, укшыйсымны китерә. Файдасы тимәс микән?..— ди Илсур.

Мин кесәмдә һәрвакыт «Викалин» төймәләре йөртәм. Чыгарып бирдем тегеңә.

Берничә көннән минем янга Илсур үзе керде.

— Ул син биргән даруның миңа бернинди дә файдасы юк бит әле, малай. Бик нык авыртам бит мин...— диде ул. Күрәм, чибәр йөзе тәмам сүрәнләнгән, бөтенләй кәефе киткән монын.

Шуннан инде Илсур эшли алмады. Аны шифаханәгә салдылар. Яман шеш табып, операция дә ясап карадылар. Булмады! Бер генә нәрсәнең дә файдасы тимәде. Нинди таза, корсак үстереп җибәргән ыспай, яхшы күңелле Илсурыбыз вафат булды. Кырык яше дә тулмастан. Язмыш, ни хәл итәсең.

Илсурдан соң редакциянең җаваплы секретаре итеп Рафис Әминовны куйдылар. Рус язучылары еш кына рус кешеләренең матурлыгына сокланып язалар. Мин дә үзебезнең татар кешеләре белән бераз горурланып алыйм әле. Урта буйлы, күпереп торган калын чәчле, туры, бик килешле борынлы, күркәм кеше Рафис Зарипович. Һәрвакыт үзенә генә хас зәвык белән киенеп, пөхтә йөри. Журналистларның «кешеләргә һәм үзенә таләпчән» дигән тәгъбирен кайберәүләр буш сүзгә санаса да, мин, шәхсән, бик тормышчан дип саныйм. Һәм ул тәгъбир Рафис Зариповичка бик туры килә. Әле тәрҗемәче булып эшләгән вакытта ук ул «алла үзе биргән» тәрҗемәче иде. Материалыңны тәрҗемә итә башлаганчы ул сине үзе янына чакырып ала. Үзең барында укып, материалга байтак өстәмәләр, төгәллекләр кертә. Аннан соң гына, өстәленә әллә ничә төрле сүзлекләр алып, тәрҗемәгә утыра. Бер дә ашыкмыйча, җай белән, ихлас белән эшли. Аннан соң инде редакция журналистлары йөриләр:

— Карале, мин язганнан да яхшы килеп чыккан бит бу!

— Мондый сүз куллану минем башка да килмәгән иде бит...

Секретарьлык эшенә дә Рафис Әминов әнә шулай ихласын салып кереште. Типографиядә мәкалә башларын җыя торган барлык төр хәрефләрне, ягъни шрифтларны барлады. Аерым бер брошюрага аларның күчермәсен алдырды. Хәтта бер газета юлына нинди хәреф ничә керә икәнен дә исәпләп, шуны янына язып куйды. Газета битләре өчен бик уңайлы макет өлгеләре ясады һәм ул өлгеләр әле дә булса бернинди үзгәрешсез кулланышта йөри. Машинкада басылган материалның газета битендә ничә юл алачагын билгели торган, махсус билгеләр төшерелгән линейкага кадәр ясады. Ул эшли башлауга, безнең газетаның йөзе яхшы якка сизелерлек үзгәрде.

Газетаның партия тормышы бүлеген Ринат Таҗиев алып бара. Элекке диңгезче, чем кара бөдрә чәч, киң маңгай, нык карашлы соры күзләр. Кара костюм, ак күлмәк, галстук. Эшкә нәкъ вакытында килә, нәкъ вакытында кайтып та китә. Эш өстәлендә ныклы тәртип, һәр китап, белешмә, күрсәтмә материаллар, партия матбугаты материаллары үз урынында. Үзе авылларга барып кайтса да, язганны нәкъ тиешле вакытка мөхәррир өстәленә китереп сала. Шулар өстенә, Ринат тормышта да бик тотнаклы, тыйнак кеше. Гаилә башлыгы үрнәге. Акча алган вакытларда без, редакциянең ир-атлары, эштән соң калабыз, бер-ике яртыны алып кереп, акча алганны билгелибез. Ә Ринат — Алла сакласын! Ул мондый «күмәкләшүләрдән» ерак тора, ул андый хәлләрдән өстен. Мондый вакытта Әхәт бер дә яратмыйча борынын җыера:

— Таҗиев педант инде ул.

Менә шундый кеше берзаман чын эчкечегә әйләнер, шәхес буларак бозылыр дип кем уйлаган?! Хәер, бу хакта сүз ары таба булыр.

Башта тәрҗемәче, аннан корреспондент — Фидаил Җәләлиев. Урта буйлы, нәфис түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле Фидаилнең елмаюында ниндидер хәйләкәрлек бар. Фидаил авырлык белән яза. Колхозларга барып матерал җыйнап кайта да, кулына чиста кәгазь бите ала, аның югары бер читенә «ике нөсхәдә» дип язып куя һәм... үзе урыныннан торып, бүлмәдән чыгып китә. Коридорда йөренә, кешеләр белән тегесен-монысын сөйләшә, тагын кереп өстәл артына утырып карый. Юк, булмый, яза гына алмый бит. Фидаил урамга ук чыгып китә, кибетләр тирәләрен әйләнә. Шулай байтак тулгак тоткач, иҗат газабы кичергәч кенә, кереп утыра. Әмма фактларны гына туплап, кыска, эшлекле итеп яза. Фидаил Бәдриевич тәмәке тартмады, аракыны да бик чамасын белеп кенә эчте. Әмма ул коллектив эчендә зур оештыручы, төрле «күмәкләшүләрне» башлап йөрүче иде. Берәр яңа әйбер алдың исә, янына хәзер Фидаил килеп җитә. Аның күзләре бик хәйләле көлемсери инде.

— Әһә, күлмәк алдың?.. Бик әйбәт, кара, нинди матур икән. Юарга кирәк моны, һичшиксез, юарга!

— Акча юк бит әле, Бәдрич! Менә шушы күлмәкне алып бетте.

— Акчасын үзем биреп торам. Әмма юмыйча кала алмыйсың инде. Коллектив сорый моны!..

Коллектив сорагач, үзеңнең дә тамак төбең кытыкланып торгач, кая барасың инде. Фидаилдән акча алып торасың да, кибеткә чыгып китәсең.

Ул ара да булмый, Фидаил яңа идея күтәреп чыга:

— Шахмат ярышы! Редакциядә шахмат ярышы оештырабыз!

Һәм оештыра да. Кем белән кем уйныйсын — графигын төзеп куя, отучыларга бүләкләрен таба. Ул эшләгән заманда без редакциягә ел саен диярлек яңа спорт кирәк-яраклары да ала идек. Җәй көннәрендә урман буйларына сәйранга чыга идек. Әмма Фидаил редакциядә озак эшләмәде. Аның Арчада җитәкчеләр, аеруча сәүдә хезмәткәрләре арасында дуслары буа буарлык иде. Бездән аны нефть базасына директор итеп алдылар. Анда бераз эшләгәч инде, ул гаиләсен алып, Казанга ук китеп барды.

Әйтәм бит, редакциядә бик күп кешеләр эшләде, алар еш алмашынып тордылар. Кайбер урыннардагы сәләтле хәбәрчеләрне дә эшкә чакырып алалар, алар берничә ел бездә эшләп китәләр иде. Шундыйларның берсе, Камил Якуб исемендәге колхозның Ташкичү авылыннан Рәҗәп Хәнәфиев аеруча хәтердә калган. Бу тракторчы егет безгә кыска хәбәрләр язып тора иде. Йөзен басу җилләре, кояш нурлары кара-кучкылт төскә керткән, озын буйлы, киң иңсәле, таза — чын тракторчы егет редакциягә килгәч, Шакир абый аннан сорау алды:

— Белемең күпме, Рәҗәп?

— Җиде класс, Шакир абый.

— Алай икән...— дип сузды мөхәррир һәм аның бармаклары өстәлдә канәгатьсезлек белән уйнап алдылар.— Ярый, син безгә хәбәрләр яздың ди инде. Тагын нәрсәләр яза беләсең соң син, аппагым?

Рәҗәпнең күзләрендә шаян чаткылар уйнап алды.

— Ә нәрсәләр кирәк соң сезгә, Шакир абый? Кыска хәбәрдән алып очеркка кадәр язабыз без аны! — диде ул, авыл кешеләречә гади итеп.— Нигә язмаска ди әле? Каләм кулда була торып.

— Алай икән... Карап карарбыз киләчәктә...— диде Шакир абый сузып кына.

Әмма гаҗәеп уен-көлкеле, үзен теләсә кем, теләсә кайсы түрә белән бик иркен тота торган бу тракторчы егетнең сүзләре һич кенә дә мактану яисә коры куык булып чыкмады. Безгә менә дигән мәкаләләр, зарисовкалар, зур-зур очерклар, хәтта шигырьләр язып күрсәтте Рәҗәп. Ул җибәргән материалларга республика газеталары да урынны бик теләп бирәләр иде.

Чираттагы санны планлаштырабыз. Миңа эчүчелек аркасында авыр хәлдә калып таркала башлаган бер гаилә турында язарга. Рәҗәпне бер колхозга яфрак азык әзерләүнең барышы турында язарга җибәрәләр. Коридорга чыгуга Рәҗәп бөтен дөньяны яңгыратып кычкыра:

— Радик абый, сиңа — на тему әхлака, ә миңа — на тему яфрака!

Рәҗәп колхоздан кайта һәм икенче көнне иртән үк Шакир абый өстәленә газета битенең яртысын алырлык мәкаләне китереп тә сала. Ул мәкаләдә барысы да яфрак азык әзерләү, аны әзерлибез дип яшь агачларны ботарлаудан ачыну, бригаданың таркаулыгы, җыелган яфрак азыкның киләчәктә әрәм булып кына бетәсенә дәлилләр белән раслаган ишарә, бу эшнең нәтиҗәсе турында уйланулар, шунда ук тагын урман табигатенең яме, кошлар сайравы, күбәләкләр очуы, тагын әлләниләр була. Рәҗәп исә үткер тәнкыйть мәкаләләрен, кыска фельетоннарны, сыер савучылар турында очеркларны мөхәррир өстәленә яудырып кына тора. Шакир абыйга бармакларын бик канәгать төстә уйнатып, башын чайкап утырырга гына кала.

Минем кайбер кешеләрнең үзләренә табигать тарафыннан бирелгән сәләткә гаять игътибарсыз, һич тә бәяләмичә, җиңел, хәтта ваемсыз карауларына исем китә. Мин авылларда йөргәндә, кешеләр белән арала-

шканда шигырь, хикәя яза алган, гомумән әдәбиятка-сәнгатькә сәләтле булган кешеләрне байтак очраттым. Тик алар бу сәләтләренә бернинди әһәмият бирмиләр, аны үстермиләр, халык алдына, газета-журналлар битләренә күтәреп чыгарга уйламыйлар да. Рәҗәп Хәнәфиев тә әнә шундый кешеләрнең берсе булып чыкты. Ул журналистикага ничек өермә кебек тиз һәм киң колач белән, җиңел генә килеп керсә, аннан шулай ук кисәк һәм ансат кына тукталып та калды. Чыгып китте, дисәң дә була. Ташкичү Арчага шактый ерак, көн саен кайтып-килеп йөрүләре бик читен. Рәҗәп Арчадан үзенә бер фатир бирүләрен сорады. Бездә соң сәләтле кешене күрә белү, аңа тиешле ярдәмне күрсәтү, шартлар тудыру бармы? Бер сорады Рәҗәп, ике сорады. Берничә айлар көтеп йөреп тә карады. Алай да булмагач, Шакир абый өстәленә эштән азат итүне сорап, гариза китереп салды. Шакир абый бик үгетләп, хәтта ялынып та караган иде. Ходай биргән мондый журналистны бер дә кулыннан ычкындырасы килми иде. Тик Рәҗәп риза булмады.

— Авылга кайтам мин! Әле трактор онытылмаган. Нәкъ журналистлар язганча була: йөрим корыч атымны иярләп, киң колхоз басуларын иңләп! — диде ул.

Авылга кайтып китте дә Рәҗәп, кабат берни дә язмады. Үзендәге менә дигән сәләтне, талантны үзе сөргән буразналар арасына күмде.

* * *

Ул арада минем эшләр алга барды. Без әби белән бабай йортыннан киттек, миңа яңа салынган йорттан ике бүлмәле фатир бирделәр. Үземне эштә күтәрделәр: хатлар бүлеге мөдире итеп куйдылар.

Редакциядә яңа эшли башлаган вакытларда мин үземдәге начар бер гадәттән иза чиктем. Шулай бервакыт коридорда дубляж буенча редактор урынбасары Антонина Ивановна белән сөйләшеп торабыз. Нигәдер бәхәсләшә идек. Дубляж дигәнем газетаның рус теленә тәрҗемә ителеп чыга торганы. Арчада торучы руслар өчен, тиражы мең данәдән артмаса да, андый газета да чыга. Шулай әлләни кызмый гына бәхәсләшкәндә, Антонина Ивановнаның болай да зур күзләре кисәк шар булды.

— Абау, Радик... Нигә бу кадәр әшәке итеп сүгенәсең әле син?! — диде ул.

— Ничек инде... сүгенәм?

— Соң, әле генә нинди оятсыз сүз ычкындырдың бит.

Инде олы яшьтәге, ап-ак чәчле бу хатын алдында оялудан битләрем кызышты. Шайтан! Күпме еллар производствода, тимер юлда эшчеләр, руслар арасында эшләүнең бер тискәре ягы да бар әле аның. Анда гади халык теленә тәмам күнегәсең. Ягъни, һәр ике җөмлә саен бер-ике бик тозлы, борычлы сүз кыстырырга. Бернинди ачу фәләннән түгел, ә бары тик шулай гадәтләнгәннән генә. Менә шушы гадәттән котылуы гаять авыр бер эш булып чыкты. Берзаман хатын-кызлар бу мәсьәләне редакциянең гомуми җыелышына куйдылар хәтта:

— Фәизов коридорда әшәке сүзләр белән сүгенеп йөри. Уйлап карагыз — редакциядә!

Үз-үземне җиңә барып, көчкә котылдым бу начар гадәттән.

Редакциядә эшләү, күп кешеләр белән очрашу, төрле маҗараларга тару акрынлап бу дөньяны танып-белергә дә өйрәтте. «Ярыш» колхозыннан хат килеп төште. Сыер савучыдан. Аны, терлекчелектә ничә еллар бик яхшы эшләп килгән, медаль белән бүләкләнгән алдынгыны колхоз рәисе фермадан куып җибәргән. Бу хәлне тикшереп, материал язарга мине җибәрделәр. Минем күңелдә бу кадәр гаделсезлеккә карата гайрәтле ачу. Әле юлда барышлый ук гади колхозчыга шундый игътибарсыз, вөҗдансыз мөнәсәбәттә торган колхоз җитәкчесен сурәтләргә берсеннән икенчесе үткенрәк эпитетлар эзлим. Тегенең тетмәсен тетеп,

бюрократлыкны фаш иткән фельетон язачакмын! Хезмәт кешесенә хөрмәт дип авыз суыбызны корыткан бер вакытта...

Бардым колхозга, таптым теге хатынның йортын. Урта яшьләрдәге, түгәрәк кенә, ыспай гына бер апа. Ул колхоз рәисе Габделнурның туры сүзне бер дә яратмавы, үзен бөтен ферма халкы алдында нинди әшәке сүзләр әйтеп хур итүе турында миңа бәйнә-бәйнә, ике сәгать буена сөйләде. Минем блокнот фактлар белән тулды. Бу зур эштән икебез дә шактый талчыккан, утырып чәй эчтек. Мин инде кайту юлына да чыкмакчы идем. Шунда келт итеп күңелемә килде: тукта әле, бу апа эшләп чыккан фермага да менәргә кирәк. Яңа, тагын да көчлерәк фактлар табып булмасмы?

— Булды бу, апа, рәхмәт сезгә. Хәзер инде мин фермага менеп сөйләшәм дә, кайтып та китәрмен,— дидем мин.

Шунда гаҗәп хәл булды. «Фермага менәм» сүзен ишетүгә, апаемның йөзе бердән үзгәреп китте. Андагы елмаюы, илһам нуры сүнде. Ул хәтта куркып калды кебек.

— Анда ни эшкә дип менәсең инде син, энем? Мин сиңа барысын да әйтеп бирдем бит инде,— диде ул.

— Соң, сезнең бергә эшләгән апалар белән дә сөйләшергә кирәктер бит инде. Алар да үз сүзләрен өстәрләр,— дидем мин.

— Йөри күрмә, энем, фермага барып. Андагыларның... гайбәтен җыеп. Ышан минем сүземә, мин бит хак сүзләр генә сөйләдем сиңа,— дип, апаем миңа ялына ук башлады.

Әмма минем күңелгә дә ниндидер шик кергән иде инде. Үз сүземдә нык тордым.

— Барыгыз алайса, менегез! Җыегыз гайбәтче хатыннар сүзләрен!..— диде теге апа. Аның инде зәһәре йөзенә бәреп чыккан иде.

Фермага менсәм, ике яшь кенә хатын чиләк-көянтә белән су күтәреп киләләр. Мине күрүгә, барган җирләреннән тукталып, көтеп алдылар.

— Бу чибәр егет ни эшләп йөри әле монда?

— Менә сезнең хәлне белергә килдем әле.

— Безнең хәлләр ал да гөл, менә үзең күреп торасың! - диделәр алар, иңнәрендәге тулы чиләкләрне чайкалдырып.— Калганын инде, егеткәй, үзең бел...

— Бик ал да гөл түгел икән шул. Кайберләрегезнең хәтерен дә бик калдыралар икән...— дидем мин.

Хатыннар ялт итеп кенә бер-берсенә карашып алдылар.

— Беләбез без ул хәтере калганны. Бик яхшы беләбез, ниткән ул... Әллә син инде шуның сүзен яклап килдең монда?! — һәм хатыннар үткер карашларын миңа текәделәр.

— Яклап килдем шул. Хаксызга рәнҗетелгәнне яклау — безнең эш. Мин бит — редакциядән! — дидем.

Хатыннар чиләк-көянтәләрен иңнәреннән алып, җиргә куйдылар. Шалтыратып куйдылар, сулары чайпалып түгелде.

— Әгәренки син аны яклап йөрисең икән... Әнә сиңа көянтә, әнә чиләк. Менә бу суларны үзең күтәреп ташы, чибәр егет! Без кайтабыз да китәбез! — диделәр алар.

Сүз зурга китте. Ферма өенә барлык терлекчеләр җыелды. Колхоз рәисе, озын буйлы, караңгы гына чырайлы, урта яшьләрендәге кеше — Габделнур үзе дә килде. Терлекчеләрнең таләбе белән рәис машинасына утыртып, тиз генә теге хатынның үзен дә алып менделәр. Җилтерәтеп уртага чыгарып бастырдылар. Аны чын мәгънәсендә допрослау башланды:

— Йә, әйт әле, теләсә кемгә бәйләнеп кем тавыш чыгара монда? Кем әләк күтәреп йөри?

— Ничә тапкыр сыерларны саумыйча да калдырдың? Бичара малкайларны... Шуны әйт син!

— Сандугач бичараның күзенә кем ак төшерде? Чыбык белән сугып.

Өлкән яшьтәге бер апа тегенең каршысына ук чыгып басты.

— Габделнур өстеннән гәҗиткә язып йөрисең икән тагын... Оятсыз син, җирбит! — диде ул нәфрәт белән.

Терлекчеләрнең үпкә һәм нәфрәт сүзләре теге ханымга тәки барып җитте бит. Ул кисәк йөзен куллары белән каплады да елап ук җибәрде. Терлекче хатыннар аптырап, каушап калдылар. Тик алай да аларның карары бердәм булды: моннан ары ул ханымны фермага якын да китермәскә. Чөнки ул малларны җәлләми!

Менә шулай ул тормышта. Әгәр син нинди дә булса низагны тикшерергә алынасың икән, ике якны да нәкъ бердәй күреп тыңларга тиешсең. Дәгъвачыны яклап фельетон язу бик җиңел булса да һәм кызыксындырып торса да. Бер якны гына тыңлап эш итсәң, тишек чабатага утырып калуың бик ихтимал...

Хәзер инде минем очерклар, фельетоннар, публицистик мәкаләләр үзебездә дә, республика газета-журналларында да еш чыга. Мин инде районда шактый танылдым. Җитәкчеләр дә әйбәт белә үземне. Мөхәрриребез Шакир абый, инде өлкән яшьтәге авырайган кеше, төрле җыелышларга, райбашкарма комитеты утырышларына үзе йөрергә бик иренә. Ул редакция вәкиле итеп, ягъни үзе урынына... еш кына мине җибәрә. Мин исә колакка катырак, мондый җыелышларда күп нәрсәне ишетеп тә бетермим. Киңрәк җилкәле бер җитәкче артына кереп посам да, йокымсырап тик утырам. Безнең райбашкарма рәисе Тимерхан Борһанович Борһанов, урта буйлы, тулы түгәрәк гәүдәле, калын кара кашлы күркәм, тапкыр сүзле кеше, минем бу хәйләне тиз арада төшенеп алды. Ул җай гына сөйләгән җиреннән кисәк тавышын күтәрә. Сүз кыстыра:

— Иптәш Фәизов! Менә монысы редакция өчен әһәмиятле. Боларын блокнотка теркәп алыгыз! — Һәм сүзен инде мин дә ишетерлек итеп дәвам итә.

Көзгә таба бу, уракка төшкән вакыт. Тимерхан Борһанович мине үз бүлмәсенә чакыртып алды.

— Социаль заказ бар бит әле сиңа, Фәизов! — диде ул, гадәтенчә җай гына итеп. — Үзең беләсең, уракка әле кичә генә төштек. Беренче көннәрдә бер дә генә җай бармый бит ул. Йә дымлы салам тыгыла, йә каешлары өзелә, дигәндәй... Ну монысын үзең дә беләсең. Республика газетасыннан корреспондент килеп төште бит әле, малай. Колхозларда булам ди... — Тимерхан Борһанович миңа карап алды, киңәш тонына күчте. — Ни эшлибез инде без аның белән? Сизеп торам: тәнкыйть мәкаләсе язарга аның исәбе. Ул үзенең шул мәкаләсе белән бөтен район халкының күңелен сүрәчәк бит аннары. Эш башланып кына киткәндә! Моңа бит юл куярга һич тә ярамый, — дип кабатлады Тимерхан Борһанович һәм кызыклы гына нәтиҗә ясап куйды. — Ә синең бурыч... иптәш Фәизов, аңа дөрес юнәлеш бирү, уңай тәҗрибәне күрсәтү... Вәт менә сиңа социаль заказ бу!

Мин кыюсыз гына каршы төштем:

— Тимерхан Борһанович, ничек инде?.. Язам дигән кешенең кулына сугып булмый бит аның.

— Ә менә анысы инде аның синең тәҗрибә, синең осталык, иптәш Фәизов. Син бит яхшы журналист та, үзебезнең район патриоты да... Хәзер сез болай эшләгез. Мин сезгә үземнең шоферны, машинамны бирәм. Сез шуңа утырып, бергәләп чыгып китегез. Барсын, йөрсен, барысын да күрсен... Тик безне хурлап кына язмасын... Тырышып кара инде... — диде райбашкарма рәисе.

Ул арада бүлмәгә республика газетасы кешесе килеп керде. Олы яшьтәге, тәбәнәк кенә, ябык кына бер кеше. Кояш вә җилләр ашаган йөзе бик юка, карашы үткер, бик вакчыл кешедер бу... Миңа ни эшләргә кала хәзер?

Ни хәл итәсең, чыгып утырдык райбашкарманың чия төсендәге «Волга»сына. Киттек Әтнә ягыннан юл өстендә беренче «Октябрь» колхозына. Арыш галәмәт уңган, басуда кая карама — комбайн. Тик унлап машинаның нибары ике-өче генә эшли ала. Чыннан да, кайсысының каешы чыдамаган, кичә генә яңгыр явып үткән иде, комбайн иңкү урынга кереп баткан... Хикмәт, кыскасы. Ә теге агай исә бу хикмәтне күреп, тәмам илһамланды. Блокнотын әзер тотып, әле үзләре дә аптырап калган комбайнчылар янына килә, әле колхоз рәисе Мирзаян Шәрипович каршысына. Тегеләрнең күзләренә керердәй булып сораулар яудыра:

— Бу комбайн ник туктап тора? Нәрсә ул, яхшылап ремонтланмаганмы? Аның нәрсәсе әзер түгел?

Ул арада кесәсеннән шырпы тартмасы чыгара да, киселгән камылның озынлыгын үлчәп ала.

— Камылны бик биектән алдырасыз. Ник алай? — дип бәйләнә.

Колхоз рәисе Мирзаян Шәрипович Вахитов, басынкы холыклы, сабыр кеше, күзләрен гаепле төстә челт-челт йомгалап, тыйнак кына елмая.

— Соң, беренче көннәрдә һаман да шулай була инде ул, ни... Әхмәт абый. Әле техникасы да, кешеләре дә җайлашып бетмәгән, ашлыгы да өлгереп җитмәгән дигәндә... Менә бит, ни бит... Ашыгып керешелә бит. Ни хәл итик, райком ашыктыра, көнен, сәгатен куя. Мин үзем, мәсәлән, бер-ике көн сабыр да итәр идем әле,— ди ул уфтанып.

Теге агайның анда-монда эше юк.

— Райком ашыктыра... райком белеп ашыктыра! Беренче көннәр! Беренче теземнәр, тәүге башаклар... Беренче хезмәт дәрте. Эш бит һәркайда гөрләп барырга тиеш! — ди ул, үз сүзләреннән үзе илһамланып һәм блокнотын әзер тотып, бер туктап торган комбайн яныннан икенчесенә йөгерә.— Ә сезнең... нәрсә әле монда?! Бер нәрсәнең рәте-чираты юк бит! — дип шелтәли. Ни хәл итәсең, аңа вәкаләт бирелгән, ул синең кыенлыкларың, хәлнең реаль торышы белән кызыксынмый, ул моңа керешми. Аңа гөрләп торган эш кирәк һәм ул эш булырга тиеш!

Без Мирзаян Шәрипович белән бер-беребезгә карашып, өлкә корреспонденты артыннан йөрибез. Ничек чыгарга бу хәлдән?

— Мирзаян Шәрипович, ни эшләргә соң? Бетерә бит бу карт безне бу килештән,— дидем мин.

— Әллә болындагы җәйләүгә алып төшик микән? — диде Мирзаян Шәрипович та, аптырап кына.— Анда кызлар төшкә чәй куялар. Мәен дә табарга була...

Чынлап та, алып төшәргә бу картны җәйләүгә. Табарга аның белән уртак тел. Юкса, нәрсә килеп чыга бит?! Колхоз — районда иң алдынгы. Уракка да иң беренче булып, тулы әзерлектә төште. Нинди фактлар туплап китә хәзер бу бәндә ошбу колхоз турында үзенең блокнотына, нәрсәләр язып чыкмас ул бөтен республикага? Дөреслек түгел бит инде бу! Һәм мин сак кына кармак салый карадым:

— Әхмәт абый, инде җитеп тормасмы? Инде төш вакыты да җитә. Җәйләүдә безгә чәй дә әзерләгәннәр анда...— мин әйтәм.

Әхмәт аганың күзләрендә бер фикер кабынды да шунда ук сүнде дә.

— Җитеп тормас! Бер хуҗалыктагы хәлдән чыгып мин бит район турында фикер туплый алмыйм... Алып барыгыз мине тагын бер колхозга! — дип хәл итте ул, кискен төстә.

Мирзаян Шәриповичны нәүмизлектә һәм борчуда калдырып киттек без «Чулпан» колхозына. Монда рәис — минем авылдаш, сабакташ һәм дус Наил Сабиров. Ул инде күп еллар эшләгән зур тәҗрибә иясе, салмак сүзле, тыныч холыклы олпат кеше. Колхозга килеп төшүгә, мин аны бер читкә чакырып алдым да хәлне аңлатып бирдем. Наил Закирович артыгын пошыну күрсәтмәде.

— Һи, җаен табабыз аның... Ул менә азрак «тегесен» тота микән? Син шунысын гына белеп ал. Калган ягын мин үзем рәтлим аның...— диде ул.

Киттек чыгып басуларга. Гөнаһ шомлыгына, монда да нәкъ шундый ук хәл. Кайсы комбайн тыгылган, кайсы ватылган, күбесе тукталып тора. Әхмәт ага тагын теге гөнаһ дәфтәрен — блокнотын тартып чыгарды. Тагын илһамланып тегендә чаба, монда йөгерә. Фактлар туплый. Инде озын җәйге көн дә кичкә авышты. Мин бер җаен туры китереп, сүз арасында әйтә куйдым:

— Инде күп йөрелде, ардык та, бугай, Әхмәт абый. Капкалап аласы булыр... Сез, гафу итегез... азрак «тегене» тотасызмы соң? — һәм ияк астына чиртеп алдым.

— Болай... күп булмаганда, әлләни зыянлы да түгел инде ул югыйсә... — диде теге, сузып кына.

Минем эчкә җылы керде. Әһә, күп булмаганда!.. Беләбез без моның нәрсә икәнен. Һәм бу шатлыклы хәбәрне җәт кенә Наил Закировичка житкердем. Ул безнең машинага күчеп утырды да, шоферын авылга кайтарып җибәрде.

Инде көн кичкә авышкач, кайттык без Бәхтияр авылына. Кереп утырдык авыл уртасындагы алма бакчасына. Җәйдек яшел чирәм өстенә киң ашъяулык. Таратып салдык анда Наил Закировичның шоферы колхоз ашханәсеннән алып менгән нигъмәтләрне. Утырттык уртага ике акбашлыны чыгарып. Кырлы стаканнарга яртылаш итеп салып бер-икене күтәреп куюга, моңарчы бик житди, төксе булып кына йөргән Әхмәт абый бераз үзгәрә төште. Аның ябык йөзе түгәрәкләнеп, коймакланып киткәндәй булды. Тагын берәрне күтәргәч, теле дә ачылды.

— Менә мин бервакыт Апас районына баргач, андагы бер колхозда... — дип, үз башыннан үткәннәрне сөйли башламасынмы бу!

Ә безнең исә үз кайгыбыз кайгы. Теге «социаль заказ»ны ничек үтәргә? Кайсы ягыннан якын килеп карарга бу картка? Инде икенче шешәнең төбендә генә калгач, өчебез дә шактый кәефләнеп, Әхмәт агайның күзләрендәге үҗәтлек чаткылары сүнгәч, мин тәмам батырланып, юлны турыдан ярырга булым.

— Әхмәт абый! — дип башладым мин хис белән. — Менә без Наил Закирович белән... үз районыбызның патриотлары. Бу бит инде шулай булырга тиеш тә! Һәркемнең үз районы, үз колхозы өчен җаны авырта. Шулай булгач, Сез, Әхмәт абый... нитегез инде. Сез безнең район турында тәнкыйть мәкаләсе язып чыкмагыз инде. Без моны Сездән үтенеп сорыйбыз! — дидем мин.

Минем бу ялкынлы сүзләрдән шактый кыза төшкән Әхмәт ага бердән айнып китте.

— Алай икән әле бу... Менә кайда икән ул чикләвек?.. — дип сузды ул, кысык күзләре белән бер миңа, бер Наилгә карап һәм бераз нидер уйланып утыргач, үзалдына көлемсерәп куйды. Эченнән нидер хәл иткәндәй, кискен итеп кулын селтәде. — Соң, ни эшләргә инде сезнең белән? Әйбәт егетләр күренәсез бит сез болай... — диде Әхмәт ага елмаеп.

Безнең эчләргә җан керде. Аңлады бит безне бу карт, керде бит бу безнең хәлгә! Ә Наил Закирович ул арада картның шактый күләмле сумкасына бер чиләк кызарып пешкән алма китереп салды. Алма уртасына тагын бер акбашлыны утыртып куйды. Бу хәрәкәтләрне Әхмәт ага искәреп торды, билгеле. Әле тагын байтак шулай утырып кич якынлашкач, ул безгә болай диде:

— Ну егетләр... әйбәт егетләр икәнсез сез. Сезнең хәлне, сезнең борычларны да аңлыйм инде мин... Кабат Арчага барып тормыйм. Мине сез Әтнә кунакханәсенә озатып куегыз. Иртәгә мин шуннан үз хутым белән Казанга кайтып китәрмен. Сезне борчуга калырлык итмәм!

Һәм молодец карт булып чыкты ул! Республика газеталарында Арча районында уракның барышын кискен тәнкыйтьләгән мәкалә күренмәде.

* * *

**А**й ул командировкалар! Ниләр генә күрмәдем, нинди генә хәлләргә тарымадым мин авылларда йөргәндә. Кышның салкын бер көне. Инде төштән соң Шакир абый мине чакырып алды.

— «Северный» совхозына барасың, аппагым. Менә хәзер чык та, юл уңае машинага утырып китәрсең. Анда зоотехник Фәгаль Гайфуллинны тап. Яшь, эшлекле зоотехник. Очерк язарга сиңа.

«Северный» совхозы — районның иң ерактагы хуҗалыгы. Кышкы юлда алтмыш чакрымга җыела бугай... Урам чатына чыгып бастым. Көн салкын, буранлап та тора. Минем аякта — ботинка. Көтәм. Күренми машиналар. Менә аякларым туңа башлады, менә бөтен гәүдәм. Инде боз кисәгенә әйләнәм бугай дигәндә генә, шул якка баручы машиналар күренде. Әрҗәләренә биек итеп нидер төягәннәр, брезент япканнар. Аллага шөкер, алдан килгәне тукталып, мине алды. Кабинага кереп утыруыма шофер, олы яшьтәге караңгы чырайлы кеше, миңа карап, башын чайкап куйды. Утыргычы артында казынып, аннан киез итекләр тартып чыгарды да минем алга ташлады.

— Сал бу штиблетларыңны. Ки хәзер үк менә боларны! — дип боерды ул.— Салкын тидерәсең бит хәзер.

Без Арчадан чыкканда караңгы төшеп килә иде инде. Күпме генә барганбыздыр, үкереп торган буран купты. Машиналар урман эченә килеп керделәр. Монда да кар салган икән, бер-бер артлы көрткә кереп баткан саен бер-берсен тарта, этә башладылар. Китте кычкырулар, сүгенүләр... Галәмәт авырлык белән алга барабыз. Менә бер иңкүлек урын. Безнең алдан барган машина иңкүлектән чыгып китте, ә менә без нәкъ урталыкта тукталып калдык бит. Шунда ук машина мин утырган якка янтая башлады.

— Монда күпер бар. Бер як тәгәрмәч күпер читеннән ычкынды, ахры, каһәре! — диде шофер. Ни гаҗәп, ул моны гаять тыныч тавыш белән әйтте. Гүя ки, безгә бернинди куркыныч та янамый иде.

Ул арада машина янтая да янтая. Мин курка башладым, ишекне ачарга талпындым.

— Ачма ишекне! Машина астында каласың киләмени...— дип кычкырды шофер.

— Ә без... аусак?

— Аусак, эш харап инде анысы. Безнең бит әрҗәләрдә аракы, Казаннан аракы алып кайтышыбыз,— диде ул һаман да тып-тыныч калып һәм өстәп куйды.— Машина ауса да, сиңа ни пычагым да булмый кабина эчендә. Утыра бир шушында! — Һәм үзе кабинадан чыгып та китте.

Алланың рәхмәте, никадәр янтайды машина, әмма аумады. Күпер читендәге калын кар катламы тотып калды аны. Корыч трос белән алдан эләктерделәр, икенче машина буферы белән сак кына арттан этте. Азапландылар шоферлар, карга батып, юешләнеп беттеләр, әмма машинаны йолкып алып, юлга бастырып куйдылар. Шофер кабинага кереп утырды да, бүреген салып куеп, эчен бушатканчы бер сүгенде... Шофер тирләгән маңгаен сөртеп алды, кызарып беткән куллары белән рульгә тотынды. Ул арада юл әйбәтләнә төште, яхшы гына киттеләр. Урманнан чыгуга юл уңае авылларда тукталып, кибеттә аракы калдыра башладылар. Беренче кибеттә үк эшләрен бетергәч, шофер кабинага бер ярты аракы күтәреп керде. Үзенә салды, минем алга да бер стакан аракы куйды.

— Эч, энем, бушка килгән аракы ул. Мең шешә ватылмыйча кайтса, берсен аның безгә бушлай бирәләр... Эч, энем! Бөтен халык эчкәндә син генә фәрештә булып кала алмассың. Салкын да алмас үзеңне...— диде ул.

Без совхоз үзәге Шушмабаш авылына барып җиткәнче берничә кибеткә кердек... Шофер халкы инде шактый кәефләнгән иде. Инде кичке сәгать унбер тулган. Шофер агай әйбәт кеше икән, әйтеп куйды:

— Бу кара төндә... идарәдә кеше юк инде. Кая барасың, безгә генә кайтып йокларсың.

Тик машина утары йортында кизүлек итүче бер апа бар булып чыкты.

— Син редакциядән килдеңме, энем? Алай булгач, киттек безнең кунак йортына. Берүзеңә бер йорт, үзе якты, үзе май кебек җылы. Рәхәтләнеп йокла. Йокың да бик килгән бугай...— дип көлде ул апа миңа карап.— Тик шуны онытма, төнлә белән синең яныңа тагын шундый йокысы килгән бер кеше кайтыр. Аны ишек ачып кертерсең, ярыймы? — диде ул һәм мине шунда якындагы гына кунак йортына озатып, аның ачкычын бирде.

Дөрестән дә, иркен фин йортында беркем дә юк, дистәгә якын буш карават тора, яп-якты һәм бик җылы иде. Мин рәхәтләнеп өсләремне чишенеп куйдым һәм... шунда ук үтереп ашыйсым килә башлады. Аракы эчелде, ә кабарга нәрсә иде? Ипи дә суган... Менә шушында әйтеп куйыйм әле, һәрвакыт, нинди генә компаниягә эләксәм дә, нинди генә мөмкинлекләр булса да, мин үземнең газета хәбәрчесе, матбугат вәкиле икәнемне беркайчан да онытмадым. Чаманы, тыйнаклыкны югалтмадым. Кешеләр арасында бер вакытта да исергәнче, үземне кысадан чыгарганчы эчмәдем. Ул елларда күп, бик күп хәбәрчеләргә, матбугат вәкилләренә нәкъ менә шушы нәрсәләр җитмәде. Бу бит аракының бик арзан, күп кулланылган, елга булып аккан еллары иде.

Ярый, мин кунак йортында, карын бүренеке кебек ач. Ни эшләргә? Бу вакытта кая барып нәрсә таба аласың? Киттем мин бүлмә буйлап, караватт янындагы тумбочкалардан нинди дә булса ризык эзләп. Булды бит! Бер тумбочкадан ярты бөтен ипи, ярты банка шикәр табып алдым. Ишек катындагы бакта су да бар. Бераз гына тамак ялгап алсам, зыян булмас бит? Утырдым һәм... теге ипи белән шикәрне ялмап куйганымны сизми дә калганмын.

Берзаман ишек шакыдылар. Чыгып ачсам, ишек янында майга буялган киемле бер кеше тора. Үзен җилләр чайкый, аягында чак басып тора. Керде бу өйгә, өстен чишенде һәм... туп-туры мин әле генә «ревизия ясаган» тумбочкага таба юнәлде. Буш банканы алды, аны югары күтәреп карады да, гаҗәпләнүеннәндер инде, озын итеп сызгырып җибәрде.

— Сез гафу итегез инде, зинһар. Мин алып ашаган идем ул ипи белән шикәрне,— дидем мин.

— Ә шулаймы? Бик әйбәт булган. Без... күрәсез, яхшы гына сыйланган идек. Василий Федорович булам! — диде теге һәм миңа кулын сузды.

Василий Федорович монда Казаннан килгән инженер икән. Фермаларга су һәм җылыту торбалары үткәрү өчен совхоз аларны махсус чакыртып алган. Алар көнозын салкында эшләп бик туңалар да, кичләрен, билгеле инде, җылынып алырга да кирәк бит. Василий белән без байтак сөйләшеп утырдык, шахмат та уйнап алдык әле.

Иртәгесен мин Фәгаль Гайфуллин белән күрештем. Фәгаль ябык кына, тәбәнәк кенә буйлы, зур күзлекле, әле яңа укып кайткан белгеч, миңа бик күп яңалыклар һәм кызыклы нәрсәләр сөйләде. Ул барлык терлекләр өчен, фәнни нигезләнүләрдән чыгып, тәүлеклек ашату рационнары төзегән. Савым сыерларны бозаулату, дуңгызларны балалату графиклары, азыклардагы аксым, үзләштерелүчән протеин, каротин микъдарлары... Продуктлыгы кимегән терлекләрне яшьләре белән алмаштыру, җәйге чорда продукт алуны арттыру юллары... Азыкны тиешле срокларда әзерләү һәм аны эшкәртеп бирү... Фәгаль өстәлгә төрле графиклар, диаграммалар, сызымнар китереп салды. Бик бирелеп, кулларын кискен селтәп, үз-үзенә ышанып сөйләде ул. Күренеп тора, совхоз терлекчелеген күтәрүдә ихлас салып, җиң сызганып керешкән иде.

Мин яшь белгеч Фәгаль Гайфуллинның башлангычлары, планнары турында зур итеп очерк яздым, ул үзебездә генә түгел, республика газетасында да басылып чыкты. Алга китеп әйтим, Фәгаль күп еллар буена бик әйбәт эшләде, совхозда терлекчелекне, чыннан да зур табышлы тармак итүдә үзеннән өлеш кертте.

Беләсезме, газетаның үз хәбәрчесе булу бик четерекле, үзенчәлекле эш ул. Иң башлап аңа дөреслекне, хәлләрнең нәкъ тормыштагыча торышын, ягъни чынбарлыкны бик сирәк очракларда гына сөйлиләр. Аннан килеп, ул бу чынбарлыкны үзе дә тикшереп белә алмый. Әйтик мин, газета хәбәрчесе, зоотехник Фәгаль төзеп куйган ул графиклар, рационнарның ничек үтәлешен фермаларга кереп тикшереп йөри ала идемме? Аларның тәгәл үтәлешен хәтта зоотехник үзе дә тикшереп бетерә алмый бит. Хәбәрчегә күпчелек очракта әле теләктәгене, кәгазьдә, планда булганнарны гына чынбарлыктагы кебек итеп сөйлиләр. Һич тә усал ният белән түгел. Чөнки сөйләүчеләр үзләре дә шул планнарны, теләктәгене тормышка ашырырга омтылып эшли һәм яши бит. Шунлыктан хәбәрче тарафыннан хуплау, мактау тонында язылган әйбернең күпчелеге чынбарлык түгел, шуңа омтылышны гына күрсәтә алар. Бу кайчак зур ялгышларга, күз буяуга, хәтта көлкеле хәлләргә дә китерә. Үз тәҗрибәмнән мин моның бик ачы мисалларын китерә алам.

Бардым колхозга, язгы кыр эшләренә әзерлекнең торышын тикшереп язарга.

— Ә бездә әзерлек полный, иптәш корреспондент! — диде колхоз рәисе һәм мине үзенең машинасына утыртып, машиналар утарына алып китте. Анда барсак, чыннан да, зур тәртип, чәчкечләр, сабаннар, культиваторлар рәт-рәт итеп тезеп куелган. Якында гына тракторлар. Утарда, берничә механизаторны исәпкә алмаганда, инде ремонтчылар да күренми.

Кайттым мин редакциягә. Галәмәт яхшы әзерлекне күрсәтеп, сүзләрне кызганмыйча репортаж язып бирдем. Шакир абый мин язганны хуплап, симез бармагын күтәрде һәм репортаж ялт итеп кенә басылып та чыкты. Ике көн үтте микән, Шакир абый мине тагын чакырып алды.

— Авыл хуҗалыгы идарәсеннән колхозларга инженерлар бара. Әзерлекне тикшерергә. Кайсы колхозга икәнен тәгәл белмәдем. Ияреп бар син шуларга. Бер тәнкыйть мәкаләсе булыр. Анысы да кирәк бит аның,— диде мөхәррир.

Кердем идарәгә. Аннан Леонид Мезин белән Гомәр Ситдыйков баралар икән. Икесе дә инженерлар, берни белән дә хисаплашмый торган галәмәт таләпчән белгечләр. Киттем мин шулар машинасына утырып. Барабыз Яңа Кенәр юлыннан. Һәм болар бара торгач, һич уйламаганда, әле генә мин мактап язган колхоз юлына борылмасыннармы! Колхоз идарәсенә дә барып тормады болар, килешли үк машина утарына туктадылар. Әлләни арада гына колхоз рәисе дә килеп җитте. Без җәлт итеп кенә бер-беребезгә карашып алдык. Колхоз рәисенең карашында курку, аптырап калу бар иде...

Киттеләр ике белгеч рәткә тезеп куелган чәчкечләрне икәүләп тикшереп. Якты йөзем! Ишетелеп кенә тора:

— Ни эшләп бу чәчкеч нормага көйләнмәгән?

— Моның төп валы ник кәкере?

— Монда тиешле чарыклар кайда?

Чәчүгә тулысынча әзер булган ник бер чәчкеч табылсын!... Һәркайсының нәрсәседер җитешми, һәркайсын әле төзәтәсе, көйлисе бар. Инде тикшерүчеләр культиваторлар арасына килеп кергәннәр иде, тагын шул ук хәл... Йөрибез без колхоз рәисе белән тегеләр артыннан ияреп, бер-беребезгә күтәрелеп карарга да кыймыйча. Мине тагын бер корт кимерә. Менә Шакир абый күзенә ничек күренәсе булыр әле?!Ниләр язасы булыр? Миннән бит тәнкыйть мәкаләсе көтәләр. Кичә мактап язылган хуҗалыктан бүген... Җанны уч төбендә генә тотып кайттым редакциягә.

— Җә, аппагым, буламы тәнкыйть? Гел мактау гына ярамый безнең эштә. Кимчелекләрне тар-мар иткән мәкалә дә бик кирәк. Киләсе санга ук! — дип каршылады мине Шакир абый.

— Була! — мин әйтәм.— Бик зур тәнкыйть мәкаләсе булырга тора әле, Шакир абый...

— Кайсы колхозда? — диде ул, бармакларын уйнатып.
— «Ракета»дан! — мин әйтәм.— Әле кичә без мактаулы репортаж биргән колхоздан.
— Ә?! — Шакир абый берни аңламыйча миңа текәлде.— Син шаяртасың булыр?
— Нинди шаярту әле! — мин әйтәм һәм Шакир абыйга барысын да сөйләп бирдем. Хәзер тиргәр, акыл сата башлар дип көткән идем. Әмма алай булмады.
— Шайтан икән... Кара инде син аны. Ни хәл итәсең, безнең эштә мондый терсәкләр дә килеп чыккалый шул, аппагым. Ярый инде, бу юлы бернәрсә дә язмассың. Инженерлар тапкан хәлләр тикшерү протоколында гына кала ул, матбугатка чыкмый. Менә шулай, өйрәнә тор, аппагым...— диде дә Шакир абый, шуның белән бетерде. Ни әйтсәң дә әйбәт, хәлгә керә торган кеше иде ул. Аннары ул мондый хәлләргә таргалаган да булгандыр инде.
Совхозга бардым. Сыер савучы Таибә Баһавиева турында зур очерк язарга. Таибә — безнең районда гына түгел, бөтен республикага билгеле терлекче. Әйтерең генә бармы: Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Ленин ордены белән бүләкләнгән, әллә никадәр медальләре бар. СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең алтын медале белән бүләкләнеп, аны Мәскәүгә үзен чакырып тапшырганнар. Мин инде бу савымчы янына үземне бик югары рухта тотып, аңа бирәсе сорауларымны алдан ук әзерләп бардым. Хезмәт кешесен югары күтәреп күрсәтергә! — Менә безнең, журналистларның девизы.
Таибә эш урынында, фермада иде. Сәнәк белән биниһая зур итеп салам күтәреп кергән бер хатынны күрсәттеләр миңа. Ул хатын күтәргән саламын ачу белән ферма коридорына атып бәрде дә сораулы карашы белән миңа текәлде. Нык бәдәнле, озынча саргылт йөзле бер хатын, башындагы яулыгы астыннан җирән чәчләре чыгып тора. Сырма өстеннән иске генә халат кигән, аякларындагы резина итекләре ямаулы... Күзләрендә сынаулы көлемсерәү, киная бар.
— Сез югары нәтиҗәләргә ничек итеп ирешәсез? Үзегезнең алдынгы эш алымнарыгыз турында сөйләсәгез иде,— дип башладым мин.
Савымчының күзләрендә хәтәр чаткылар кабынды.
— Нәрсәләр сайрыйсың соң син, энем?! Нинди тәҗрибә, нинди эш алымы кирәк сиңа? — диде ул нәфрәт белән.— Менә минем кулымдагы сәнәк, менә салам. Шуларны бер генә күтәреп кара әле син!.. Егерме биш сыерга башак болгатып кара... Әнә сенаж ташып кара, апара ташы! Менә шуннан нәтиҗәне үзең дә бик әйбәт чыгарырсың. Миннән сорап торасың да булмас! — диде Таибә ачынып һәм дәвам итте: — Минем өстәге халатны, аякларымдагы итекләрне күрәсеңме син? Мин шушы тишек итек белән ничек итеп көне буе пычрак ярып йөрергә тиеш булам. Тәҗрибә эзләмә син, аны язма. Ник менә җитәкчеләр фермага килмиләр, ник безгә яңа резина итекләр, әйбәт эш киеме бирмиләр... Менә шуларны яз син! Менә алдынгыларның алдынгысы Таибә Баһавиеваның төннәр буе йоклый алмыйча биле сызлап чыга. Бүгенгесе көндә Таибә кулындагы сәнәген, чиләген ташлап, фермадан китәргә уйлап тора. Менә шуларны яз син, матур егетем! — дип сөйләп китте Таибә.
Аның бу ачулы, әрнүле сүзләреннән мин артым белән салкын суга килеп утыргандай булдым. Нindидер сөремнән, йокымсыраудан айнып киткәндәй. Мөшкел хәлдә калуымны күреп, Таибә мине жәлләде, күрәсең.
— Ярый, бу пычракта син фермада миңа тагылып йөрмә инде, корреспондент егет. Кирәкмәскә ботинкаларыңны эт итеп. Монда син күрмәгән берни дә юк... Әнә безнең өйгә төш тә утыр. Әнкәй сиңа чәй куеп эчертсен. Кич белән өйгә кайткач, үзем сорауларыңа җавап бирермен. Ул гәҗитәңә материалсыз калмассың, курыкма! — диде ул һәм үз эше белән китте.

Фермадан эштән кайткач, Таибә апа җәт кенә мунчага кереп, юынып, өстенә килешле генә күлмәк киеп чыкты һәм... яшь кенә, чибәр генә бер ханымга әйләнде. Нәкъ минем яшьләрдә икән ләбаса. Чәй янында без аның белән бик озак сөйләшеп утырдык.

Һәм мин балачагы авыр сугыш елларына туры килгән, колхозга чәчүлек орлык күтәреп кайтканда язгы суга төшеп батып үлә язган, гомере буена фермада терлекләр арасында эшләгән, шул эше белән бәйләнешле сәбәптән иреннән аерылган ялгыз хатынның авыр, михнәтле тормышы турында зур итеп очерк яздым. Шакир абый бу очеркны укып чыкты, озак кына бармакларын уйнатып утырды.

— Бу очерк әйбәт язылган анысы. Әдәби яктан да, тормышчан булуы белән дә... Тик, менә, аппагым, алдынгы тәҗрибә күренми бит. Үрнәк көче, туплау көче кайда? Моны укып кәпәисис райкомында ни диярләр?

— Анда бу очеркны укып та тормыйлар бит, Шакир абый.

— Үзләре укымасалар, аларга укып, җиткерүчеләре җитәрлек аның...— диде Шакир абый пошынып.— Белмим инде... Әллә мин әйткәннәрдән чыгып, яңадан язып карыйсыңмы? Алдынгы тәҗрибә...

— Тәҗрибәләр, нәтиҗәләр... мәкалә темасы алар. Очеркта, минемчә, иң алдан кеше үзе күренеп торырга тиеш анда. Мин очеркны үзгәртмим, Шакир абый!—дидем мин, нык итеп.

— Мәйлең...— диде мөхәррир бераз үпкәли төшеп һәм бу турыда сүзне озайтмады. Ул елларда безнең җәмгыять тормышында икейөзлелекнең, купайту, турыдан-туры ялганлау, сүздә — бер, ә эштә бөтенләй икенче булуларның тулып ятуын гади хезмәт кешеләре дә, матбугат әһелләре, хәтта җитәкчеләр үзләре дә, һәркем бик әйбәт белә иде инде. Миңа, кайчандыр әдәбиятка, журналистикага да ялкынлы, югары хисләр белән, җиң сызганып килеп кергән кешегә дә, тора-бара бик күп нәрсәләр бөтенләй икенче ягы белән ачылдылар. Бернинди хезмәт ялкыны, үрнәк күрсәтергә омтылу, туплану дигән нәрсәләр юк. Бу төшенчәләр барысы да уйлап чыгарылган, һавадан алып сөйләнелә һәм языла торган, ясалма, асылда дөньяда булмый торган нәрсәләр. Кем белән — кайчандыр, революциядән соңгы елларда алар булгандыр, җәмгыятьнең үсешенә күпмедер этәргеч тә биргәндер. Әмма хәзер кешеләрнең дөньяга карашы бик нык үзгәргән инде. Хәзер барысы да бик гади: кешеләр тамак туйдыру һәм тормыш алып бару бәрабәренә эшлиләр. Берәүләр эшен яратып, чын күңеленнән илһамланып башкара, аннан тәм-ямь таба. Ансыз гомумән яши алмый. Икенчеләр зур табышка, зур эш хакына омтыла. Шуңа күрә дә тырыша. Болары инде безнең мактый ала торган кешеләребез. Нәкъ менә шулардан без «тәҗрибә», «үрнәк» эзлибез. Кайберәүләр көн үтсенгә йөриләр. Ачыктан-ачык. Менә болары инде безнең тәнкыйть дөньясы... Менә шулай бара да бара инде ул.

Ә тормыш миңа, язучыга һәм журналистка, үзенең яңа якларын күрсәтә.

Урак өсте. Районның төньяктагы иң ерак читендә Ключище дигән рус авылы һәм анда безнең якларның Маресьевы бар икән. Николай Гаврилов дигән берәү бер аягы төптән булмаган килеш комбайнда эшләп йөри икән. Киттем мин шуның янына.

Гаҗәеп ямьле урыннар. Урман куенына кереп утырган кечкенә генә авыл, бер якта тигез, игеннәр бик уңган басулар. Гавриловлар комбайны авылдан ерак та түгел эшләп йөри. Алар комбайнда өчәүләп: үзе, малае, хатыны Наташа түтәй эшлиләр икән. Мине күргәч, Николай комбайнны туктатты, башта өске мәйданчыктан култык таякларын җиргә ташлады. Аннары бик авырлык белән баскычтан үзе төште. Бик таза, имәннең төп буедай нык гәүдәле, чәчләре күпереп торган, туры борынлы, йөз чалымнары эре, килешле, үзе күркәм, чибәр кеше. Куллары шундый зур, матур. Ә менә бер аяк төптән юк... Аның урынына юан агач бәйләп куелган. Шулай да күзләрендә күңел төшенкелеге, мескенлек күренми. Күзләре сабырлык, җылы көлемсерәү белән карыйлар.

— Эшләр җай барамы? — дидем мин.

— Эшләр бу басуда акрын бара,— диде Гаврилов. «Акрын» сүзенә басым ясап әйтте.

— Ничек болай... үзегезгә авырмы? — дип сорадым мин сак кына һәм һич көтелмәгән җавапны ишеттем:

— Бу басуда кош оялары күп. Урман бик якын бит. Арыш арасы тулы кош балалары. Әнә егетебез алдан бара...— диде Гаврилов, комбайннан бераз алдарак кулына озын таяк тотып торган улына күрсәтеп.— Без исә Наташа белән аның артыннан, җай гына барабыз. Аз гына карамасаң, кош балаларының пычакка эләгүе дә ихтимал... Менә шулай эшләп торабыз әлегә,— диде комбайнчы.

Ул текә тимер баскычтан сыңар аягы белән сикерә-сикерә мәйданчыкка менде. Шундый авыр гәүдәсе белән кискен хәрәкәтләр ясап менгәндә комбайнның тимерләре зыңлап торды. Кызыл яулыгын рус хатыннарынча артка бәйләгән, ире кебек үк тулы, эре гәүдәле, калын кашлары сызылып киткән, түгәрәк йөзле, бик чибәр Наташа түтәй ян мәйданга басты. Гаврилов аяк белән баса торган бар педальләрне озайтып, аларны кулга көйләгән. Куллары белән кискен, ашыгыч хәрәкәтләр ясап тау хәтле машинаны кузгатып җибәрде. Авырдыр инде бер аяксыз комбайн йөртү, авырдыр... Алар шулай киттеләр: иң алдан озын таягын арышлар өстендә салмак кына селтәп уллары бара, аның артыннан — үкереп, һавага тузан туздырып комбайн... Мин салам өеме өстенә утырып, бу күренешне карап калдым. Бу дөньяда нинди хәлләр булмый да, нинди генә кешеләр булмый бит.

Инде озын җәйге көн үтеп кич җиткәч, соң гына аларның өенә кайттык. Алданрак кайтып киткән Наташа түтәй инде идәннәрне юып чыгарган, алты почмаклы йорт гаҗәеп чиста, кунакчыл, бик тәмле аш исләре чыккан иде. Николай ишек бусагасына утырып, иңбашына салынган киң каешны чишеп җибәрде, авыр агач аяк дөбердәп идәнгә килеп төште. Аннары Николай нәни бала төсле идәннән артына шуышып килде дә, өстәл янындагы урындыкка менеп утырды. Өстәлгә Наташа түтәй урман гөмбәләре, тагын әллә нинди үләннәр салып, итләп пешергән искитмәле тәмле аш чыгарды, уртага бер ярты да куелган иде. Аштан соң Николай идән уртасына җәелеп утырды. Миңа үз кыйссасын сөйләде.

Сугыш башланганда Гавриловлар Донбасста булалар. Николай шахтада эшли. Аны армиягә алуга, немецлар шунда ук килеп тә җитәләр. Николайга үзе торган поселокны саклап сугышка керергә туры килә. Шул ук бәрелештә, поселок читендә Николай яраланып егыла. Немецлар яралыларны машинага төйиләр, һушларына килеп хәл җыеп алгач, качмасыннар дип, өсләренә төрле тимер-томыр ташлыйлар, муйнына автомат аскан берничә солдат та машина әрҗәсенә менеп утыра. Николай дөбердәп барган машина әрҗәсендә, тимер-томыр астында аңына килә. Янәшәсендә иптәшләре ыңгырашалар, әрҗә кырыенда немецлар утыра. Туп-туры, каршыдагы немец ябык кына, мундиры якасыннан нечкә муены күренеп тора... Яшь, гайрәтле ирнең бөтен барлыгы ирекkә, бу вәхшиләр кулыннан качып китәргә омтыла. Ул җаен туры китереп сикереп тора, каршысындагы немецны бер селтәнүдә бәреп очыра һәм машина барган көйгә үзе юлга сикерә. Тузан эчендә ауналып калган Николайга немецлар ядрә яңгыры яудыралар. Әмма инде машинаны туктатып тормыйлар. Әсирне инде тишелеп беткәнгә санап, юлларын дәвам итәләр. Бәхеткә, алар аткан пуляларның берсе генә дә Николайга тими. Тик аның өстендәге шинеле генә теткәләнеп беткән була.

Николай Гаврилов аннан соң партизаннарга барып кушылган, тагын армиягә эләккән, озын фронт юлларын үткән. Аягы сугышта яраланмаган икән. Иң үкенечлесе дә шул: инде нинди дәһшәттән исән калгач, тыныч елларда, МТСта эшләгәндә булган ул фаҗига. Икеләтә фаҗига: Николайның аягын өздерүгә — аның бертуган энесе сәбәпче була. Кыш-

ның салкын бер көнендә Николай нидер төзәтергә дип чылбырлы трактор астына керә. Бу вакытта аның энесе кабинада утыра, ә кабина тәрәзәләре бозланып каткан. Абыйсының аска кергәнен абайламый калган энесе тракторны урыныннан кузгата... Әгәр дә вакытында тиешле ярдәм күрсәтелсә, чылбыр астында калып изелгән аяк пычрактан тиз генә чистартылса, яралыны больницага вакытында җиткерсәләр, аякны кисмичә саклап калу ихтималы да булган әле. Әмма бездә мондый эшләр үзвакытында эшләнәме соң? МТСның каядыр киткән шәфкать туташын табып китергәнче, машинаны кабызганчы, Арча больницасына килгән яралыны врачлар караганчы... Кисәргә туры килә аякны!

— Пенсия дә бик җитә анысы. Капка төбендә кояшта кызынып утырсам да, беркем дә бер сүз әйтмәячәк. Тик менә йөрәк дигән нәрсә дә бар бит әле адәм баласында... Башкалар басуларда игеннәрне җыйганда мин ни йөрәгем белән кул кушырып утыра алам?! Тимер даганы китереп бөгәрлек бит минем ул кулларым! — дип сөйләде миңа сыңар аяклы комбайнчы үзенең киң учлы, дәү кулларын күрсәтеп.

Андый кешеләрне дә байтак күрдем мин. Аяк табанының яртысы булмаган килеш тракторда, күкрәген дошман снаряды ярчыгы чәнчеп торган килеш чәчү машинасы басмасында эшләп йөргән кешеләрне күрдем. «Фидакарьлек», «социализм эшенә бирелгәнлек, фәлән-төгән» дип, бик ихтимал, без бу кешеләрнең хәтерен калдырганбыздыр, хәтта аларны түбәнәйткәнбездер. Чөнки алар өчен хезмәт ул — җан азыгы, рух таләбе. Төрле атамалардан югары торган изге төшенчә...

Тормыш тагын кайбер якларын күрсәтте әле миңа.

Безнең районга Казахстанның кино әһелләре килде. Бөтен илгә билгеле булган, без кинофильмнарда ничәмә тапкыр күргән, яраткан актерлар! Кино сәнгатенә кагылышлы журналлар мөхәррирләре, рәссамнар, төшерүче-режиссерлар. Кыскасы, бер зур автобус халык. Аларны Арчадан Олы Әтнәгә, Социалистик Хезмәт Герое Нургали ага Бариев рәислек иткән Киров исемендәге колхозга алып бардылар. Олы Әтнә мәдәният йорты бөтен республикага данлы. Анда, кем әйткәндәй, алма төшмәслек булып халык җыелган иде. Халык театры режиссеры Гомәр Мәрдәнов кунакларны ялкынлы сүзләре, Олы Әтнә үешчәннәренең җырбиюләре белән каршылады. Кунаклар үзләре дә русча, татарча һәм казахчалап та сөйләделәр. Аяктан бәреп егарлык бик матур очрашу булды бу. Соңыннан кунаклар һәм аларга ияреп килгән район җитәкчеләре дә ашханәгә юнәлделәр. Иркен ашханәдә йөзгә һич тә кызыллык китермәслек итеп табын әзерләнгән иде. Кунаклар анысы тыйнак булдылар, чамасын белеп кенә ашадылар, чамасын белеп эчтеләр. Әмма бу мәҗлеснең чыны тыйнак кунакларны гаҗәеп якты йөз белән автобусларына утыртып Казанга озатып җибәргәч башланды әле. Кунаклар күздән гаип булуга, кубарылып озатуга чыккан бар халык кире ашханәгә керде, үз урыннарына утырды. Менә шунда башланды инде мәҗлеснең кәттәсе. Китте тост күтәрүләр, бер-береңне мактау, урыннан торып кочаклашу-үбешүләр. Ә аракы, шампан шәрабе су урынына ага. Кунаклар — тирә-як колхоз рәисләре, белгечләр һәм җаен табып бирегә эләккән башка төр урта кул түрәләр, үгез кеби таза кавемнәр. Берсе артыннан икенчесен күтәреп кенә җибәрәләр. Районнан килгән җитәкче-түрәләр дә алардан әлләни калышмый. Ә бит урамда уттай җәй көне, эш вакыты.

Бу пирәш әле моның белән генә бетте дип уйлыйсызмы? Район җитәкчеләре Арчага кайтышлый җыйнаулашып юл уңаендагы тагын бер колхозга керделәр әле. Монда исә Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл ачканнар икән. Бу тантанага районның хәрби комиссары Иван Федорович Христофоров үзе дә килгән. Һәйкәл ачу тантанасын бетереп яталар иде инде. Җыелган авыл халкы һәйкәл янында калды. Ә җитәкчеләр исә машиналарга төялеп, колхоз басуының ерак почмагындагы урман полосасына юнәлделәр. Монда!.. Яшел чирәмгә галәмәт киң брезент җәелгән. Анда кантары-кантары белән пешкән ит, чиләге белән

аш, бәрәңге, җиләк-җимеш. «Столичный» һәм шампан шәрабе әрҗәсе-әрҗәсе белән тора. Һәм китте шуннан хәлләр! Бактың исә, җитәкче-түрәләрнең һәркайсы шампан шәрабен үлеп тә ярата икән. Гәүдәләр олпат, күләмле, чәркәләр дә шулай күләмле... Галәмәт күңелле итеп утырдылар. Монда инде әйтелгән тостларның, кочаклашу-үбешүнең гомумән исәп-хисабы югалды. Китте берсеннән берсе үткен мәзәкләр вә анекдотлар. Араларында җитди сәясиләре, шул вакыт өчен аяктан бәреп ега, тиешле урынга барып ирешсә, башыңны кәтер җибәрә торганнары да бар иде. Менә шундый «үзара өчен» дип кенә сөйләнгән бер мәзәк.

Берзаман Социализм, Коммунизм һәм Капитализм юлга чыгалар. Ниндидер ашыгыч юлга. Менә бервакыт Коммунизм белән Капитализм күрәләр: Социализм каядыр шунда артта, еракта калган бит. Берни эшләр хәл юк, тукталып көтә башлыйлар тегене. Көтәләр, җан атып көтәләр. Инде көн үтеп, кояш баеганда гына күренә теге. Сөйрәлеп кенә килә бу.

— Кайда булдың син?—дип ташланалар тегеңә.

— Мин чират тордым!—ди Социализм.

— Нәрсәгә?

— Иткә.

— Ә нәрсә соң ул чират?—ди Капитализм аптырап.

— Мин чиратның нәрсә икәнен бик яхшы беләм инде анысы. Ә менә ит дигәне нәрсә икән аның? Мин шунысын белмим...—ди Коммунизм.

Менә шундый мәзәкләр сөйләшеп, «ха-ха-ха!»лап утыра торгач, бугазларны киереп җырлый, үкерә, кикерә торгач, җәйге көн тәмам кичкә авышты. Караңгы төшеп, күктә йолдызлар кабынды. Кайберәүләр инде өйгә кайтырга да вакыт икәнне исләренә төшерделәр. Тик икенче кайберәүләре инде чирәмгә түнеп, «мәрткә киткән», ә кайсылары якындагы арыш басуына таралып, гаип үк булган иде. Шофер халкы ашыгыч рәвештә егылган түрәләрне нәкъ капчык кеби күтәреп машинага сала, гаип булганнарны эзли башлады. Кычкырулар, ямьсез итеп сүгенүләр, артык мәлҗегәннәргә берәрне тамызып алулар китте. Инде төн җиткәч, бер-берсен көчкә генә табып, таралыша алдылар... Менә бу—безнең җәмгыять тормышының үзенә генә хас тагын бер ягы инде. Кем белә, безнең җәмгыятькә генә хас афәт микән әле бу?

...«Мир» колхозына бардым. Монда Венета, Михайловка, Платоновка—рус авыллары. Бу авыллар безнең, әйтик, Олы Мәңгәр, Күшәр, Түбән Шашы, Дусым кебек авыллардан кискен аерылып торалар. Йортларының күбесе иске, тәбәнәк, авыл буенча капка-койма юк диярлек, теләсә кем атлап кына керә алырлык тәбәнәк, җимерек читәннәр. Күпләренең, гафу итәсез, кереп утырырга бәдрәфләре дә юк. Йомышларын өй баскычы янәшәсендә генә, әвеслек астында үтиләр. Менә шундый авыллар... Колхозы да нәкъ шундый, районда иң артта калган хуҗалык. Татар кешесе—Сәлах абый Мөхетдинов рәислек итә. Сәлах абый үзе бу авыллардан түгел, Кәченеке, килеп, эшләп йөри. Инде олы яшьтәге, зур түгәрәк йөзен шадра тешләп алган, бик күпне күргән, җайлы, сабыр холыклы кеше. Ул Кәчегә атнасына бер генә кайта икән. Биредә, җимерелеп беткән чиркәү каршысындагы иске бер йортта үзе генә көн итә. Мин килгән көнне аңарда кундым. Күрәм, инде йоклар алдыннан гына Сәлах абый өстәлгә бик күп берлекләр чыгарып салды. Шуларны санап утыра. Гаҗәп тоелды бу миңа. Колхоз рәисе берлек акчалар җыеп, санап утыра...

— Ни эшләмәк буласың инде син ул берлекләрең белән, Сәлах абый?—дидем мин көлеп.

— Бер дә көлмә син ул берлекләрдән, иптәш корреспондент!—диде Сәлах абый җитди тостә.— Бик хикмәтле берлек болар. Шулар ярдәмендә минем бу авыллардагы урыс кешеләрен эшләтеп яткан көнем әле...

— Ничек инде... шулкадәр аз акча беләнме?—дидем мин аптырап.

— Ә механизмы бик гади аның, иптәш корреспондент,— диде Сәлах абый, хәзер инде үзе көлеп.— Монда иртән идарәгә синең янына кергән кеше исәнлек-саулык сорашмый. «Бер сум бир, председатель... Баш төзәтергә! — дип үтенә. Һәм син шул бер сумны бирми кара. Ул тәкъдирдә җавап кыска: «Әнә сиңа трактор алайса, үзең утыр да эшлә! Эшләр менә шулайрак бит монда, иптәш Фәизов. Үзең дә сизәсең булыр...— дип сөйләде Сәлах абый.

Әйе, халыкның нинди икәнен сизәргә була иде. Әле кичә кич Венета кибетенә арзанлы кызыл аракы китерделәр. Кешеләр бу аракыны кесәгә яисә куенга кыстырып түгел, ә шешәләрне кочакка кысып, кочагы-кочагы белән алып чыктылар кибеттән. Кесәләре дә як-якка бүлтәеп тора иде әле. Минем аракыны кибеттән мондый ысул белән ташыганны моңарчы күргәнем дә юк иде.

Нәрсә генә булды безнең социалистик җәмгыятькә? Нигә ул әнә шулай башыннан, уртасыннан, нигезеннән череде? Ә бит кешеләр эшли иде, алга бара идек шикелле. Акрынлап булса да гел алга, үргә менә бардык. Мин инде дөньяда беренче булып галәмгә очуларны, нинди куәтле атом бозваткычлары, куәтле тракторлар, машиналар турында әйтмим дә. Болары инде аның промышленность, фән, техника үсеше. Ә бит безгә якын, без белгән авыл хуҗалыгы, колхоз һәм совхозлар да алга, үсешкә бардылар. Купайтып әйтүгә саналмасын, ныклы адымнар белән. Һәм мин моны һич кире кагып булмаслык дәлилләр белән раслый алам. Мин район газетасы редакциясендә 1965 елда эшли башладым. Шуннан алып 1980 елларга кадәр, ягъни нибары унбиш ел эчендә җирләрдән уңыш алу ике, ике ярым тапкырга, ә сыерлардан сөт савып алу өч-дүрт тапкырга артты. Бервакыт без редакциядәге архивны — район газетасы төпләмәләрен карап утырдык. Утызынчы елларда, әйтик, «8 март колхозында бер сыердан елга уртача 800 килограмм сөт сауганнар, бер гектар җирдән 10—12 центнер уңыш җыйганнар. Инде сиксәненче елларда шушы хуҗалыкта бу саннар 3000—4000 килограммга, 25—30 центнерга җитте бит. Ә колхозга кадәрге аерым хуҗалык вакытта крәстиян үзе тубалдан кул белән сибеп орлык чәчкән җирләрдән күпме уңыш алгандыр дип уйлыйсыз? Бик уңган елларда 8—10 центнер! Менә шулай ул. Элек тә әйбәт булган, муллык, җиңеллек булган, ай ул заманалар, дип, «аһ» орулар, бик матур әкият кенә ул. Колхоз, күмәк хуҗалык крәстиянне бөтенләй икенче юлга чыгарды. Аның кулына куәтле техника, ашламалар, югары эшкәртү технологиясе бирде. Крәстиян җирне гөлбакча итеп эшкәртергә, аннан моңарчы күрелмәгән уңыш алуга, терлекләр өчен бик файдалы азык культуралары үстерергә өйрәнде. Күпме кимчелекләре булмасын, күпме тиргәмәсеннәр, күмәк хуҗалыкның өстенлекләре барыбер күбрәк. Моны берничек тә инкарь итеп булмый.

Ә нинди иркенлек, туклык, муллык килгән иде бит! Кешеләр социалистик стройның үзгәрүен теләмиләр, бу хакта башларына да китермиләр иде. Алар бары тик илдәге төрле тәртипсезлекләр, әрәм-шәрәм итүләрдән, җитәкчеләрнең башбаштаклыгыннан, үз персоналлары һәм кесәләре турында гына кайгыртуларыннан риза түгелләр иде.

Әйе, нәкъ шулай булды! Коммунистлар партиясе әһелләре һәм алар теләсә кайсы урынга китереп куйган түрәләр тәртипсез, башбаштак, вөҗдансыз булдылар. Бер елны безнең Арчада хәбәр таралды. Шомлы хәбәр:

— Элеваторда ашлык яна икән!..

— Тау-тау арыш кыза, эшкәртеп бетерә алмыйлар.

— Райком кушуы буенча китереп тутырганнар. Райком икмәк сату планының үтәлеше турында рапорт бирергә ашыга. Республика каршысында... күренергә!

Һәм бу нәфрәтле сүзләр хакыйкать иде. Кайбер түрәләр үзләренең персоналларын республика түрәләре каршысында «күрсәтү» өчен генә дә менә шундый вөҗдансызлыкларга, крестьянның ел буе маңгай тирс түгеп

үстергән уңышны яндыруга, ягъни турыдан-туры зур җинаять ясауга кадәр барып җиттеләр. Ә бит аларның берсе дә бу җинаятьләре өчен җавап бирмәде, киресенчә, тагын да өстен торган түрәләр тарафыннан макталды гына. Менә шундый сәясәт нәтиҗәсендә инде коммунист-түрәләр тәмам оятларын җуйдылар. Ахырында алар бөтенхалык эшенә, социализм эшенә хыянәт иттеләр! Илдә яшәп килгән, халык яклаган стройны тибеп җимерделәр. Тарих аларны беркайчан да гафу итмәячәк әле. Көтмәсеннәр!..

Сиксәненче елларда халык күңелендә, шул исәптән журналистлар күңелендә дә тирәнтен үзгәрешләр башланды. Халык илдәге җитәкче даирәләрнең, властька гомерлеккә килеп, үлгәнче утыра торган генераль секретарьларның, коммунист-түрәләр өерләренең илне тупикка алып килүләрен ачык сизенә башлады. Бу турыда инде кешеләр ачыктан-ачык, һәркайда сөйләделәр. Мондый күңел төшенкелеге, күңел кайту матбуатка да үтеп керде.

Мин дә инде, шәхсән, газета өчен купайтылган, теләктәгене чынбарлык итеп күрсәткән мәкаләләр язудан суына төштем. Башлыча, кимчелекләрне ачып салуга, җәмгыятьнең кая баруы турында уйланулар, җитәкчеләр тарафына кактырулар-суктыруларга күчтем. Бу инде публицистика була. Тәртипсезлекләрдән, башбаштаклыклардан ачыну хәтта кыска хикәяләргә дә үтеп керде. Республика газета-журналларында күпсанлы хикәяләрем, публицистик мәкаләләрем басылды. Мин инде язучы, журналист булып киттем. Мине СССР Язучылар берлегенә кабул иттеләр.

* * *

Мөхәррир Шакир ага Гафаровны олылап пенсиягә озаттык. Яңа мөхәррир итеп кайчандыр үзебездә партия тормышы бүлеген алып барган, ә аннары КПСС райкомының агитация һәм пропаганда бүлеген җитәкләп, чыныгу алган Ринат Әсгатович Таҗиевны билгеләделәр.

Иртәгесен эшкә килсәк, без үзебезнең кысан, гадәттә, шактый шапшак редакциябезне танымый тордык. Болай да тар коридорда үтеп йөрергә комачау итеп торган шкафлар икенче урынга күчереп куелган. Бүлмәләрдә моңарчы күрелмәгән тәртип, чисталык. Хәтта һәркемнең эш өстәленә кадәр ревизия ясалган. Өстәл тартмаларында һәрвакыт тулып ята торган артык-портык кирәкмәгән кәгазьләр, язмаган ручкалар, сынык карандашларга кадәр чыгарып ташланган. Иртән Ринат безнең барчабызны мөхәррир бүлмәсенә җыйнап алды.

— Моннан ары ныклы эчке тәртип кагыйдәләре буенча эшлибез, иптәшләр! — дип башлады Ринат үзеннән моңарчы һич ишетелмәгәнчә кискен һәм таләпчән итеп. — Кагыйдәләр әнә, һәр бүлмәгә язып эленгән. Эшкә нәкъ вакытында киләбез һәм вакытында кайтып китәбез. Соңга калып килүчеләргә, эштән иртә китүчеләргә, эш вакытында кибет-мазарга чыгып йөрүләргә мин чик куячакмын! Эш вакытында кая да булса чыгарга кирәк икән, рәхим итеп, миннән сорагыз! Эш вакытында гәп сугып утырулар, шахмат уйнаулар да туктатыла! — дип сөйләде Ринат Әсгатович һәм без барыбыз да күңелдән елмаеп куйдык. Ул, үзе болай яхшы күңелле, гади мөнәсәбәтле кеше, хәзер исә бөтен көчен куеп, үзен бик җитди, таләпчән тотарга тырыша, түгәрәк йөзе тәмам алсуланган, сүзләрен теш арасыннан чыгарып, сәер сөйләшә, читтән карап торганда болар барысы да аңа бер дә килешми, гайре табигый, хәтта көлкс чыга иде. Тик, алдан ук әйтеп куйыйм, Ринатның мондый фуфырлыгы күп булса ике-өч көнгә генә барды. Тиз арада ул тагын гади мөнәсәбәтле, кирәк чагында синең хәлеңә керә торган, кирәк икән

сиңа кычкырып, ярыйсы гына сүгенә ала торган гади бер кешегә әйләнде. Әмма эшкә намуслы карауны, тиешле тәртип саклауны һәрвакыт таләп итте.

Ринат Таҗиев мөхәррир булырга алдан ук ниятләнеп, әзерләнеп, тегесен — тегеләй, монысын болай итәр идем, дип, хыялланып йөргән иде, күрәсең. Мөхәррир вазифаларын үтәүгә ул ике куллап, җиң сызганып кереште. Иң әүвәле шул җәйдә үк безнең кайчандыр тарантас абзары булган кысан бинабыз янына янкорма төсендә иркен коридор ясатты. Шактый иркенәеп киттек. Төзүчеләр стеналарны обойладылар, идәннәргә матур линолеум җәйделәр, һәр бүлмәне ялт иттерделәр. Яңа урындыклар, өстәлләр сатып алынды. Элек тә без, ир-атлар, хатын-кызларның зарлануына нуль әһәмият биреп, эш урыннарыбызда теләсә никадәр тәмәке тарта идек. Редакция бүлмәләре зәп-зәңгәр төтен булыр иде. Ринат — үзе тартмаган, тәмәкене җене дә сөймәгән кеше — безнең бу кәефне кыскартты: редакциядә кемнең дә булса тәмәке тартуын катгый рәвештә тыйды.

Ул килү белән газетаның эчтәлеге дә шактый яхшырды, баеды. Ринат Әсгатович үзе яза торган мөхәррир иде, зур-зур мәкаләләр, публицистик әйберләр, хәтта фельетоннар язды. Аның әйберләренә республика газета-журналлары да урын бирделәр.

Ул арада безнең җаваплы секретарь Рафис Зарипович Әминов башка эшкә күчте. Ринат мине үзе янына чакырып алды.

— Мин сине, Радик Хәбибрахманович, газетаның җаваплы секретаре итеп куярга торам әле,— диде ул.

Аптырап калдым. Беренчедән, мин ул эшне бөтенләй дә белмим. Бер тапкыр макет та төзеп караганым юк. Икенчедән, җаваплы секретарь ул — мөхәррирдән кала, икенче югары урын булса да, сине эш өстәленә бәйләп куя. Нәкъ бәйдәге эт кебек итеп. Син инде редакциядән беркая да чыгып китә алмыйсың, димәк, иҗади мөмкинлекләрең дә тарая дигән сүз.

— Булмас миннән бу эш, Ринат Әсгатович. Өйрәнә дә алмам, аннары, үзең беләсең, мин бит иҗат кешесе,— дидем мин.

— Булыр! Бер дә курыкма син, авылларга чыгасың килгәндә һич тоткарлыксыз чыгарсың. Андый чакта макетларны мин үзем салырмын! — диде Ринат нык итеп. Күрәсең, ул үзе өчен бу мәсьәләне чишеп куйган иде инде. Аннары, әйтергә кирәк, ул бернинди эштән дә тартынмый, секретарьлык эшен дә яхшы гына белә иде.— Гомереңбуена хатлар бүлегендә утырмассың бит инде. Бераз үсәргә дә вакыттыр, инде олыгаеп киләсең, пеләш баш! — диде ул дусларча һәм мин, йомшак кеше, риза булдым. Һәм алдан әйтеп куйыйм, моның өчен бер тамчы үкенмим.

Ай-һай, кыен булды миңа башта! Газета битләренең макетларын төзи генә алмыйм бит! Көндезен көннәр буе җәфаланам да, кич кайтып урынга яттым исә, күз алдына чиста газета бите килә. Сала башлыйм макет, тегеләй итәм, болай итәм, сыймый материаллар, яисә артып кала. Саташып бетәм, үзалдыма мыгырданып ятам. Берничә айлар үтте шулай. Тора-бара өйрәндем тагын, хәтта остарып киттем. Алга китеп әйтим, мин редакциядә картлык ялына чыкканчы, егерме елга якын җаваплы секретарь булып эшләдем. Һәм, мактануга алмагыз, әйбәт секретарь булдым. Типографиядә газета битләрен эшләүче, ягъни верстать итүче хатын-кызлар хәтта:

— Радик абый, син булганда без дә эшлибез әле. Пенсиягә дә чыкмыйбыз. Синең белән эшләве җиңел! — дип йөрделәр. Әйе, газета битләрен салучы Мәксүдә, Дания, Гандәлиф, Сәвия белән мин озак еллар буена зур татулык саклап, уен-көлке белән, кем әйткәндәй, җырлап эшләдем. Алар да үз эшләренең чын осталары, кирәк чакта без, Гандәлиф белән, әйтик, бер газета битен ярты сәгатьтә ясап та бетерә идек. Линотипистка лар, ягъни газета юлларын металлга коючы Әлфия һәм Миңсара белән дә татулык, килешеп эшләү зур булды. Мин иренмим,

кайсы биткә материалларны алдан җыйныйсы икәнен күрсәтеп, тәртипкә салып куям, бу линотиписткалар эшенә зур җиңеллек ясый.

Ринат һәр атна саен летучка үткәрүне, ягъни, үзебез чыгарган газетага үзебез аның теле, бизәлеше, материалларның эчтәлеге ягыннан тикшерү ясауны гамәлгә кертте. Мондый күзәтүләрне, журналист һәм язучы да буларак, еш кына мин ясый идем. Кызык нәрсәләр ачыкланды. Менә «Кибет» дип исемләнгән кыска гына, унбиш юллык кына мәкалә. Шушы унбиш юлда аны язган автор «кибет» сүзен унҗиде мәртәбә кабатлаган! Исәпкә алыгыз, хәбәрче түгел, редакция хезмәткәре... Һәм, кызганыч ки, газета битләрендә мондый бер дә кирәкмәгән, телне бик бозган, ярлыландырган кабатлаулар һәрвакыт тулып ята. Журналистлар мәкаләләрендә дә хәбәрчеләр җибәргән хатларда да «эш» сүзе аеруча еш яратып кабатлана. Кайбер җөмләләрдә хәтта «эшне кызу тотып эшлиләр» кебек көлкеләр килеп чыга. Ачуым килмәгәе, «эшне эшләп эшлиләр» кебек. Бу кабатлауларны материаллардан мөхәррир һәм җаваплы секретарь да, аннары инде корректорлар да чүпләп бетерә алмыйлар. Барыбер үтеп керә алар газета битләренә! Сыер савучы яисә механизатор кебек хезмәт алдынгыларыннан бер үк кешенең рәсеме газетада еш кабатланып урнаштырыла. Кайчак бер ел эчендә, әйтик, газета укучылар бер үк сыер савучының рәсемен дүрт-биш тапкыр күрәләр. Алар турында материаллар да кабат-кабат языла. Моның сәбәбе: әйтик, газетаның фотохәбәрчесе колхозга барып төшә. Үзенә алдынгы сыер савучыны күрсәтүләрен сорый. Аңа ничә барса, шул бер алдынгы Сәвияне күрсәтәләр инде. Материаллар белән дә шундый ук хәл. Хәер, ул заманда бу уңайдан төрле кешедә караш төрлечә иде. Безнең летучкага КПСС райкомыннан килеп утырган бер ханым әлеге мәсьәләне болай хәл итте:

— Кабатлана бирсен! Хезмәт алдынгыларының рәсемен, алар турында материалларны күпме телисез, шулкадәр урнаштырыгыз. Шуның өчен дә алар хезмәт алдынгылары! Алар үрнәген халык һәрдаим белеп торсын! — диде.

Ринат Әсгатович берничә еллар ихлас күңел салып, югары принцип тотып, бик әйбәт эшләде. Ул үзенең табигате белән үк гаҗәеп эш сөючән, бернинди ваклыклардан курыкмый, иренми торган, үзен ныклы тәртипкә буйсындырган кеше иде. Корректорлар авырып китсә, газета битләрен үзе укый, мин авылларга чыксам, макетларны сала, хәтта рәсем асларына текст язуны да мөхәррир кеше өчен вак эшкә санамый, язып бирә. Мин Ринатның иртән иртәрәк килеп үз бүлмәсендә өстәлләрдән, тәрәзәләрдән тузан сөртеп, тәртип салып йөргәнен күп тапкырлар күрдем. Ул җыештыручы апа куйган тәртиптән дә риза түгел, үзенекен куя иде. Иң әйбәте: кешеләргә мөнәсәбәте яхшы, хаксызга бер вакытта да, беркемгә дә тавышын күтәрми, хәлгә керә белә. Мин үзем — гомер буена балыкчы кеше. Җәйнең матур көннәрендә, инде төштән соң, газетаны рөхсәт биреп басарга тапшыргач, секретарь өчен кичектергесез эшләр беткәч, коридорда сөйләнеп йөри башлыйм:

— Их, бер дә дөреслек юк бу дөньяда...

Ринат моны ишетеп, бүлмәсеннән чыга, сорап куя:

— Нәрсәгә шыңшыйсың? Нигә... дөреслек юк?

— Менә бит нинди ямьле көн. Ә мин — балыкчы, шушындый көндә кичкә кадәр редакциядә утырырга тиеш... — дим мин.

Ринат көлеп куя, тавышын түбәнәйтә:

— Шыпырт кына җыен да, әкрен генә шыл. Мондагы эшләрне үзем карармын.

Әйбәт мөхәррир, әйбәт кеше!

Ринат Әсгатовичның гаилә тормышы да бик тәртипле. Алар безнең йортка каршы гына, шундый ук ике катлы йортта, ике бүлмәле кысан гына фатирда торалар. Хатыны Роза Арча педагогия училищесында рус теле һәм әдәбиятын укыта. Үзенең белеме, таләпчәнлеге белән районда данлыклы педагог. Роза өйдә дә бик чиста, тәртипле хуҗабикә. Шул

кадәр пар килгәннәр, тату һәм бердәм яшиләр. Гаиләдә ике бала, бер кыз һәм бер малай үсеп килә. Аларга кергән саен мин фатирларындагы тәртипкә, чисталыкка сокланып чыгам. Һәр нәрсә үз урынында, һәркайда пөхтәлек. Инде башкасын әйтмим, Ринатның аяк киемен чистарта торган щеткасы да махсус урында, кадакта эленеп тора. Ул үзе эшкә иртән һәрвакыт ялт итеп килә. Өс-баш кетер-кетер, үтүкләнгән, ак күлмәк өстеннән галстук һәрвакыт үз урынында.

Җитмешенче-сиксәненче еллар. Кода-кодагыйлыкның чәчәк атуы, дөньясы баскан ялган, үзара коточкыч битарафлык, әйбер муллыгы, аракының арзанлыгы, җитәкчеләрнең аерым бер каста булып яшәве, башбаштаклыгы, җыелып эчүләр! Җәмгыять менә шулай сырхауга әйләнде. Бу гамәлләр барчасы бергә җыйналышып, йөзләгән, меңләгән кешеләрне шәхес буларак бозды, таркатты, ахырда фаҗигага китереп, бу дөньядан ук алып китте. Менә дигән, булдыклы, эшлекле кешеләрне. Һәм ни кызганыч! Безнең Ринат Әсгатович та әнә шул гамәлләрнең, җәмгыять сазга кереп барган җитмешенче елларның корбаны булды. Алай гына да түгел, бу гамәлләр, җәмгыятьнең сырхавы аның язмышында бигрәк тә ачык күренә.

Ринатның фаҗигасе, минемчә, редакциянең җиңел машинасыннан башланды. Әйе, никадәр гаҗәп тоелмасын, бу — шулай. Без сизә башладык: мөхәррирнең машинаны корреспондентлар карамагына бирәсе килми, ул аңа үзе генә утырып йөрүне кулайрак күрә. Бервакыт эштән бергәләп кайтканда ул миңа турыдан-туры әйтте:

— Моннан ары редакция машинасын мин сезнең берегезгә дә бирмәячәкмен...

— Ничек инде — бирмисең? Ә егетләр авылларга нәрсәгә утырып йөрерләр соң?

— Әнә юл уңае машиналарга утырып йөрерләр. Шуның өчен мин аларга командировочный түлим.

— Соң бит редакция машинасы нәкъ менә корреспондентлар өчен диелгән. Мөхәррир үзе аңа атнасына берничә сәгать кенә утырып йөри ала! — дидем мин, законнарны яхшы белүемне сиздереп.

— Син миңа закон өйрәтмә! — дип тупас кына бүлде мине Таҗиев.— Законнар алар — үтәмәс өчен чыгарылган. Моннан ары машинадан мин үзем генә файдаланам! — дип өстәде ул. Бу инде Ринат Әсгатович авызыннан чыккан яңа сүз, яңа фикер иде. Шунысын да онытмыйк, ул елларда «законнар — үтәмәс өчен чыгарылган!» дигән гыйбарә эрелеваклы түрәләр арасында киң таралган һәм тормышка да киң ашырыла иде.

Таҗиев сүзендә торды. Шофер итеп ул каяндыр шунда инде төрмәләрдә утырып чыккан, үз хатынын җәберләп торуы, аның өстеннән башка хатыннар белән йөрүе, эчкечелеге, нахаллыгы белән бөтен Арчага танылган Мәсхүт исемле бер бәндәне эзләп тапты. Шуннан инде — китте хәлләр. Безнең редакция егетләре авылларга барасы булса, чат башына чыгалар, автобус яисә юл уңае машина көтәләр. «Әй, тукта әле! Әй, утырт әле!» Шул ук вакытта редакциянең кызыл төстәге «Москвич»ы гаражда тик тора. Дөресе, шофер Мәсхүт, үзе янына кергән бүтән шоферлар белән ләчтит сатып, мөхәррирнең әмерен көтеп утыра. Әйтерең бармы, моңарчы барча мөхәррирләр поездга утырып йөргән Казанга Таҗиев машина белән генә элдертә. Туган авылы Курсага, башка вак-төяк йомышларга... Редакция хезмәткәрләренә машина бирмәүне Таҗиев үзенә ныклы бер кагыйдә итеп куйды.

Монысы гына ярар иде әле. Шушы машина эчүчеләргә зур нәфрәт белән караган, һәрвакыт аек Ринат Әсгатовичны... аракы эчәргә өйрәтте! Әйе, әйе, чын мәгънәсендә, туры мәгънәсендә. Беләләр бит редакция машинасының гаражда күпвакыт тик торганын. Килә кайсы да булса урта кул бер түрә Ринат Әсгатович янына. Машинаны сорап торырга килә. Әлбәттә инде, бер яртыны кыстыра да килә, гадәте шулай бит аның

хәзер. Һәм ни кызганыч, Ринат менә шундый яртылардан авыз иткәли башлады. Тиз арада бу шөгыль аңа бик ошап киттс күрәсең, әчми әчкән кеше аракыга бик тиз бирешә дигән сүз бар. Дөрес икән. Күп булса бер-ике ел эчендә безнең Ринат Әсгатовичны хәмер тулысы белән үзенә буйсындырды.

Бервакыт мин кыш көне, инде эштән соң, нигәдер ашыгыч рәвештә кибеткә төштем. Редакция яныннан үтеп барам, мөхәррир бүлмәсендә ут яна. Тәрәзә пәрдәләре ныклап ябылган. Ә редакция ишеге эчтән бикле. Аптырый төшеп тәрәзә янына киләм. Эчтән стаканнар чыңлаган тавышлар, исерек сөйләнүләр, хихылдаулар ишетелә. Пирәш бара... Һәм болар тиз арада гадәти күренешкә әйләнде.

Шуңа карамастан Ринат Әсгатович үзенең эшкә сәләтен, редакциядәге үзе куйган ныклы тәртипне, хезмәткәрләр арасында һәм район җитәкчеләре алдында да үзенең абруен саклап кала алды. Ни әйтсәң дә анда ниндидер эчке бер ныклык, тәртип бар иде. Кичтән карыйсың, ул — хәйран булган, сүзен дә җуньләп сөйләшә алмый. Ә иртән күрәсең, шул кеше инде ап-аек, чиста һәм пөхтә итеп киенгән, эшкә омтылып тора. Хәтере менә дигән, кичә сөйләгәнне, кәефле вакытта биргән вәгъдәсен дә беркайчан да онытмый. Кешеләргә тупас түгел, хәлгә керә белә. Гаҗәеп тә бер кеше, асылда әйбәт күңелле, кешелекле иде Ринат Әсгатович.

Әмма юк шул! Бу дөньяда хәмер белән дус булып та һаман да тәртипле тормыш алып барып булмый икән. Безнең Ринат Әсгатович белән дә шулайрак булды. Акрынлап ул үзенең һәлакәтенә атлады. Редакциядә сәер хәлләр башланды. Бер көн күрәм: минем бүлмәдә яшь кенә бер егет пәйда булды. Кечкенә генә буйлы, өс-баш та бик әлләни зәвыклы түгел, бер аякка яхшы ук аксый да бу.

— Мин — сезнең яңа хезмәткәр. Хатлар бүлеге корреспонденты! — дип белдерде бу. Мин авызымны зур ачып, беравык кирс яба алмый тордым. Бераз исемә килгәч, сорыйм тегеннән:

— Соң, син азрак газеталарга яздыңмы соң? Мәкаләләрең чыкканы булдымы?

— Моңарчы юк иде әле. Хәзер язарбыз менә...— диде егетем, гамьсез генә төстә.

— Энем, җаным, кем алды сине монда эшкә? — дидем мин, тәмам гаҗиз калып.

— Ә нәрсә? Ринат абый белән сөйләшенгән...— диде ул.

Китте авылларга чыгып егетем. Бернинди мәгълүмат туплап кайта алмады, бернинди мәкалә язмады... Берничә айлар йөрде егет редакция арбасында артык йөк булып. Берничә айлар бөтен коллективны җәфалады... Ул гына да түгел, кулларына моңарчы журналист каләмен тотып та карамаган, иҗади хезмәтнең әлефен таяк дип тә белмәгән балта осталары, слесарьлар бездә шулай байтак кеше эшләп чыкты редакциядә. Берничә ай гына булса да. Нинди максатларда, нәрсәгә исәп тотып алды аларны Ринат Әсгатович редакциягә? Монысын мин әлегә кадәр төшенә алмыйм. Кода-кодагыйлык, дуслар сүзен тыңлау, тулы стаканнарны күтәрү булды бугай моңа сәбәп.

Ай аллам! Инде фаҗига үзе дә, кара кайгы да ерак йөрмәгән икән шул.

Кышның салкын, буранлы бер көне иде. Иртән редакциягә төшүгә, Ринат мине үз янына чакырып алды.

— Мин хәзер Мәсхүт белән Казанга чыгып китәм. Санаторийдан кызым кайта, шуны каршы алырга барабыз. Син монда эшләрне үзең алып бар инде,— диде ул.

Гонаһ шомлыгына күрә, шофер Мәсхүт кичә кичке пирәштән айнып җитмәгән була. Җитмәсә, «Сез исерек башларга ышанычым юк!» — дип, машинага Ринатның хатыны Роза ханым да чыгып утыра. Ринат Әсгатович: «Көн салкын, син барып йөрмә, төшеп кал машинадан, Роза!» — дип, кат-кат үтенә. «Юк, кызымны үзем каршы алам!» — ди Роза ханым. Әмма аңа кызын күрү инде насыйп булмаган икән шул...

Казан юлында, Биектау авылын чыгу белән, Мәсхүт юл йөрүнең барлык кагыйдәләрен бозып, икеләтә куып үтү ясый. Каршыга ажгырып килгән «Волга» машинасын күрүгә, ул үз машинасын текә итеп читкә бора, юл читендәге канауга төшү бәрабәренә булса да бәрелешүдән котылып калырга исәпли. Тик соң була шул инде. Зур тизлектә килгән, шоферы берни абайламаган авыр «Волга» яны белән торган редакция «Москвич»ының ишекләрен җимереп, сытып-яньчеп, аның эченә керә. Арткы урында берүзе утырган Роза ханым хәтта кычкырырга да өлгерми кала...

Без кубарылып, Биектауга бардык. Без килеп җиткәндә Ринат белән Мәсхүт шифаханә палаталарында авыр хәлдә яталар, ә Роза ханымның гәүдәсе салынган носилка коридорда тора, аның өстенә ак җәймә ябылган иде инде...

Монда инде нәрсә әйтәсең? Моңа инде кемне гаеплисең? Язмыштыр инде бу. Адәм баласының артыннан ул туганнан алып гүргә кергәнче озата йөргән кара язмыштыр...

Шифаханәдә Мәсхүткә дә, Ринат Әсгатовичның үзенә дә катлаулы операцияләр ясадылар. Икесе дә савыгып чыктылар тагын. Ринат Әсгатович яңадан редакциягә эшкә килде. Дөрес, хәзер инде шофер булып Мәсхүт эшләмәде. Аны кулга алдылар, хөкем иттеләр. Арчадан бик ерак та булмаган Пановка колониясенә байтак елларга эшкә җибәрделәр. Ул аннан да әле ял көннәрендә кайткалап, гаиләсенә җәбер салып йөрде. Аннары, шундый бер кайтуында, үз-үзенә кул салды...

Ринат Әсгатович яңадан әйбәт кенә эшли башлады. Аның эшкә сәләте дә, дәрте дә сүнмәгән иде. Әмма... Инде дә, инде дә сабак алынырга тиеш иде кебек... Ни хәл итәсең, хәзер бит инде Роза ханымның шулкадәр үкенечле төстә һәлак булу кайгысы да өстәлде...

Редакциягә шофер булып Данис Хәсәнов килде. Чибәр генә, яшь кенә кеше. Килде һәм Ринат абыйсыннан шактый җәфалар күрде. Чөнки инде Ринат Әсгатович, халык әйткәнчә, баш ташлап эчә башлады...

Ошбу дөньяда кешеләрнең бер-берсенә карата булган игътибарсызлыгы, битарафлыгы гаҗәп бер хәл. Ринат Әсгатовичның — район газетасы редакциясе мөхәррире булган, сәләтле, булдыклы, эш башкара алган бер кешенең — әнә шулай түбәнгә, сазга, чын мәгънәсендә һәлакәтенә тәгәри баруын барысы да күреп тордылар. Ап-ачык күрделәр. Үзебезнең редакция коллективы, район җәмәгатьчелеге, җитәкчеләр, КПСС райкомындагы барлык вәкаләтле кешеләр күрде. Аны үгетләргә, аны кисәтергә, хәтта куркытырга бик була иде бит! Акылга утырту өчен вакытлыча эшеннән алып торырга мөмкин иде. КПСС райкомында утырган кашка тәкәсе түрәләрнең бер ныклы сүзе җитә иде кешене акылга утыртырга. Юк! Ник берсе бер авыз сүз әйтсен. Ник берсе инде сазга батып барган кеше хакында аз гына борчылу, кайгырту күрсәтсен. Коточкыч, кеше үтерә торган җинаятьчел битарафлык ул елларда да безнең җәмгыятьнең җәфасы, фаҗигасе булды һәм, кызганыч ки, ул әле дә шулайрак кала булса кирәк.

Мин, шәхсән, Ринатны берничә тапкыр кисәтергә омтылып карадым, әмма нәтиҗәсе булмады.

1980 елның көзе. Пычрак, галәмәт шыксыз, юеш карлы көн. Иртәгә район партия конференциясе буласы. Мин иртән редакциягә төштем. Материаллар инде тупланган, әмма газета санын конкрет планлаштырасы бар. Махсус сан бит. Ринат Әсгатович редакциядә бөтенләй дә күренми. Ни генә булмасын, мондый көндә ул иртән үк эштә булырга тиеш иде бит инде. Сәгать тугызынчыга да китте, юк Ринат. Коридорда карганып йөри идем, каршыма шофер Данис очрады.

— Син ни эшләп үзең генә йөрисең әле? Ринат абыең кайда? — мин әйтәм.

Теге үзе дә аптырап калды.

— Мин аны бүген бөтенләй дә күрмәдем әле...— ди.

Шунда келт итеп исемә төште. Без торган йортлар кара-каршы гына, иртән мин туалетка чыкканда, инде көн якты булуга карамастан, Ринатның кухнәсендә ут яна иде. Иртән эшкә төшеп киткәндә тагын минем күңелгә кагылып үтте бу хәл. Менә хәзер эчләрем «жу» итеп китте. Тукта әле, соңгы вакытта өендә берьялгызы гына бит бу. Нигә алай янып калган аның уты?! Шундый төгәл, тәртипле кешенең...

Йә, аллам! Адәм балаларына нинди үлемнәр җибәрәсең, аларны нинди әҗәлләр белән үз яныңа аласың син... Ринат Әсгатовичның кичтән өенә авыру кеше сыман кайтып килүен күрүче кешеләр булган... Монда фаҗигале үлем турында озаклап сөйлисе юк. Ринатның вафатын йөрәк өянәгеннән күрделәр. Шунысы гаҗәп, Ринат Әсгатович хәтта шул хәлендә дә үзенең пөхтәлегенә, чисталыгына турылыклы булып калган иде. Ул вакыттагы районның баш врачы Владимир Иванович Кубин соңыннан болай дип сөйләде:

— Таҗиевның квартирасына кергәч, минем бер нәрсәгә исем китте. Андагы тәртип, андагы чисталыкны, зәвыкны моңарчы беркайда күргәнем юк иде...

Ринат Әсгатовичны үзенең туган авылы Курсага алып кайтып, бик зурлап җирләдек. Халык күп иде. Күмүдә якташ язучыбыз, Ринатның күптәнге танышы Мөхәммәт Мәһдиев тә катнашты.

Ринатның җеназасында аның турында бик күп җылы сүзләр әйтелде. Аны авылдашлары да, арчалылар да яраталар, ихтирам итәләр иде. Мөхәммәт әйткән сүзләр аеруча хәтердә калган.

— Гаҗәеп киң күңелле, әйбәт кеше иде Ринат. Менә минем кулымдагы бу күн перчаткалар — аныкы. Әле бер көнне генә, минем ялан кул икәнемне күргәч, ул аны үз кулларыннан салып бирде. «Миндә тагын бар. Ки рәхәтләнеп!» — дип, авызымны да ачырмады,— дип сөйләде ул.

Дөрестән дә, Ринат Әсгатович һәрвакыт кешеләргә ихлас күңелennән ярдәм итәргә, яхшылык эшләргә әзер торды. Кабатлап әйтәм, эшкә бик сәләтле, булдыклы, дөнья бәясе кеше иде ул. Вафатында аңа нибары кырык сигез яшь иде әле. Тагын кабатлыйм, ул шул еллардагы гомуми битарафлык, җавапсызлык, вөҗдансызлык корбаны булды. Югары җитәкчеләрнең аз гына игътибары, кискен бер чарасы аны һәлакәтеннән йолып кала ала иде. Ринат Таҗиев — кешегә эш аты итеп кенә караган, аны винтикка санаган коммунистик режим, торгынлык еллары корбаны булды.

Кайчандыр Ринат Әсгатович янында сырпаланып йөргән, аның шешәдәше, «дусты» булган кайберәүләрнең бу юлларны укыгач, борыны җыерылыр, мөгаен. Дөреслекне, чынбарлыкны язганны яратмаслар. Җыерылмагыз, господа! Монда әле чынбарлыкның дүрттән бер өлеше дә ачылмады. Өстәвенә, Ринатның һәләкатендә сезнең дә өлешегез бар. Аның фаҗигасе — сезнең дә вөҗданыгызда!

* * *

Сиксәненче елларда инде мин, әйткәнемчә, язучы булып киттем. Хәзер инде мин бөтен эшне ташлап, язучылык, иҗат эшенә дә бирелә ала идем. Мактанып әйтү түгел, моңа җитәрлек дәрманым да, сәләтем дә бар иде. Әмма мин журналистлык, газетачы эшен дә бердәй яраттым. Ияләнгән коллективны, яраткан эшемне ташлап китәсем килмәде.

Шунысын да әйтим, Арча районында чыга торган элекке «Коммунизмга», хәзерге «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе коллективы мөхәррирләрдән асылда уңды. Минем егерме җиде ел эшләү дәверемдә бездә дүрт мөхәррир булды. Шакир ага Гафаров, Ринат Таҗиев, Тәлгать Мостафин һәм Тәлгать Гомәров. Болар барысы да асылда әйбәт күңелле, хезмәткәрләргә артык җәбер салмый торган, бик вакланмый торган

кешеләр. Мөхәррире белән килешә алмыйча этле-мәчеле яшәгән коллективлар бихисап. Бер-берсе белән килешмичә, нервларын ашап, бер-берсенең канына тоз салып көн иткән коллективлар. Аллам сакласын!.. Аннан килеп безнең хезмәт коллективы үзе дә, асылда, һәрвакыт диярлек тату, бердәм булды.

Ринат Таҗиевның фаҗигале үлеменнән соң, безгә мөхәррир итеп күп еллар буена КПСС райкомының агитация һәм пропаганда бүлеген җитәкләгән Тәлгать Мостафинны китерделәр. Урта буй, җыерчыклы киң маңгай, калын кысалы күзлек аша кыюсыз гына караган зәңгәр күзләр, мөлаем генә елмаю.

— Ну, Радикҗан, хәзер син материалларга байыйсың инде,— диде миңа үзем белән бер бүлмәдә утырып эшләгән, партия тормышы бүлеге мөдире, мөхәррир урынбасары Равил Сабирович. Бик юморлы, үткер акыллы, тапкыр сүзле кеше сүз уңаенда.— Син күрәсең, райком секретарьлары трибуналардан бүксә киереп дилбегә буе докладлар, нотыклар сөйлиләр. Депутатлар, активистлар, колхоз рәисләре, төрле җитәкче-митәкчеләр барчасы ябырылып чыгыш-мыгышлар ясый. Син шунысын да белеп тор, алар сөйләгән сүзләрнең берсе генә дә үз сүзләре түгел. Хәтта инде фикерләре дә үзләренеке түгел. Болар бар да — Тәлгать Нурзадовичның иҗат җимешләре. Бөтен райкомны алып барган кеше ул Мостафин...

Һәм чыннан да. Килде безгә Тәлгать Нурзадович. Иртән керәм мөхәррир бүлмәсенә, көндезен, кичен керәм. Ничә генә керсәм дә, безнең яңа мөхәррир җиң сызганып эштә. Баш күтәрми кыштыр-кыштыр нидер яза.

— Нәрсәләр язабыз, Нурзадович?

— Бу — кичәге сессиядән отчет бу.

— Бу — поселокта санитария торышы буенча бик әһәмиятле мәкалә.

— Бу — укучыларның кышкы каникуллары...

Гаҗәеп эшчән кеше. Язган әйберләренең күпчелеген Тәлгать Нурзадович миңа укытып алды. Мине зур тәҗрибә иясе танып. Ару гына яза, фикерле белә. Тик кабатлаулар да юк түгел. Ни хикмәт, Нурзадович «эш» сүзен бик ярата. Җөмлә башында бу сүзне бер куллана икән, җөмлә азагына кадәр ул инде аны берничә тапкыр кабатлый. Әмма бу хакта күрсәткәнгә, төзәткәннәргә хәтере калмый. Асылда әйбәт кенә яза. Күп яза. Алай гынамы әле! Безнең редакциягә килгәч тә райком иңнәреннән төшмәде әле, элеккечә утыруында дәвам итте. Күрәм, Нурзадовичның бүген бөтенләй вакыты юк. Сорыйм:

— Тагын нинди ашыгыч мәкалә, Нурзадович?

— Әй, мәкалә түгел әле. Беренчегә конференция доклады...— ди ул ашыгып һәм тагын эшенә чума. Ә аның алдында өстәлдә! Төрле сводкалар, мәгълүматлар, аңлатмалар — кәгазь боткасы. Райкомның барлык секретарьлары, район башкарма комитеты, рәисе, хәтта бүлек мөдирләре, җыен ыбыр-чыбыры Тәлгать Нурзадовичның муен тамырында утыралар... Ә ул түзә, ул карусыз...

Гаҗәеп тыйнак кеше. Күрәм, Казанга дип җыена бу. Нигәдер чакырганнар.

— Машина белән барасыңмы, Нурзадович!

— Юу-у-у-к! — дип суза ул.— Ниткән... Машина белән егетләр «Искра» колхозына китә бүген. Язгы әзерлекне тикшерәсе бар... Миңа — әнә электричка йөреп тора.

Гаҗәеп кенә түгел, тыйнакның да тыйнагы Тәлгать Нурзадович. Сез Арча поселогы буйлап үтегез. Электә райкомда аз гына эшләп, артын гына җылытып чыккан кешеләр дә хәзер — аерым йортта. Болын кебек иркен йортларда, хәтта кайберләре ике катлыларында. Ә Нурзадович башта райкомда, аннан редакциядә гомере буена эшләде. Аның кулындагы мөмкинлекләр — диңгез иде. Берсеннән дә файдаланмады. Гомуми йортта, кысан гына фатирында яшәп калды.

Берчак редакциядә егетләр арасында бәхәс чыкты: коммунизмны, гомумән, төзеп буламы? Шунда мин мондый фикер әйттем: була, ник булмасын! Әмма моның өчен барлык кешеләрне безнең Тәлгать Нурзадович кебек итеп тәрбиялисе бар.

Сиксәненче еллар ахырында редакциядә эшкә сәләтле, бердәм коллектив тупланды. Мөхәррир урынбасары, партия бүлеге мөдире Равил Вәлиев хакында аеруча әйтәсем килә. Без аның белән бер бүлмәдә утырып, ун елга якын эшләдек. Озын буй, киң иңсәле нык гәүдә, туры борынлы, кара кучкыллы, киң маңгайлы күркәм йөз, коңгырт күзләренең карашы бик игътибарлы. Ул безгә халык контроле район комитеты рәисе булып эшләгән җиреннән, сәламәтлеге какшап килде. «Тагын бер чиновник!» — дип, мин борынымны җыерган идем. Әмма бу уемнан тиз арада кире кайттым. Бик тирән белемле, авыл хуҗалыгы, икътисад, сәүдә эше, Советлар тормышыннан, кайсы гына өлкәне алма, шуннан гаять киң мәгълүматлы, бик дөньяви, өстәвенә бик эшчән дә бер кеше булып чыкты Равил Сабирович. Сүзгә оста, тапкыр, юморга бай.

Равил Сабировичның һәр өлкәдә киң мәгълүматлы, өстәвенә хәтере дә бик әйбәт булуы миңа зур бер уңайлык, әйтергә мөмкин, табыш булды. Нинди дә булса публицистик мәкалә язарга җыенсам, мин үзем уйлаганнардан тыш, башта аннан да мәгълүматлар алам. Моның өчен юри сүз башлап җибәрәм:

— Менә Равил Сабирович, техника күбәйде анысы. Әмма колхоз-совхозларда атларга рәт бетеп бара бит...

— Ат ул, Радикҗан, гаҗәеп бер хайван. Аннан әле дә, техника заманында да зур табышлар алырга була! — дип күтәреп ала бу теманы Равил Сабирович һәм кулларын җәя-җәя, бик бирелеп, лекция укыган профессор сыман җитди төстә сөйләп китә.— Тик, ни кызганыч, моны безнең җитәкчеләр аңламыйлар. Араларында аңлаганнары да бар, әмма алары мәшәкатеннән курка. Ә бит, уйлап карасаң, ат — асрау өчен иң арзанлы хайван, җәй көне аны гомумән дә тәрбияләргә кирәкми. Көтүлектә йөреп тә туклана ул. Хәтта инде шунда симерә дә. Димәк, безнең район хуҗалыкларында гына да ат итен күпләп җитештерү чыганаклары бар. Шуннан ки..., бит әле дә булса хуҗалыкларда ат белән башкарып булган эшләр күпме?! — ди Равил Сабирович илһамлану белән. Аның хәтере — искиткеч. Ул элекке еллардагы районда атаклы ат караучыларны хәтерли, бу уңайдан хәзер кайсы хуҗалыкта эшнең ничек торганын белә.— Тукта әле, төгәллек кертәбез хәзер! — һәм авыл хуҗалыгы идарәсенә шалтыратып, андагы белгечләрдән хуҗалыклардагы хәзерге атлар саны турындагы мәгълүматларны җыйнап ала. Аның өстәле кырыена зур кадак кагылган, аңа дәү счет элеп куелган. Равил Сабирович шул счетны ала да, аның төймәләрен шалт та шолт салып, хуҗалыкларда атлар санының ничек үзгәрә баруын исәпләп чыгара.

— Менә сиңа, Радикҗан, кызыклы саннар! — ди ул кулларын киң җәеп һәм миңа ул исәпләп чыгарганнарны, аның фикерләрен блокнотыма теркисе генә кала. Аннан соң инде үз уйларым белән баетып язгач, әйбәт кенә мәкалә килеп чыга. Яшерми әйтәм, аның фикерләренә, ул биргән мәгълүматларга, ул китергән саннар һәм чагыштыруларга таянып, мин байтак публицистик мәкаләләр яздым. Минемчә, моның бернинди гаебе юк. Мондый фикер һәм мәгълүмат чыганагыннан файдаланмый калу үзе бер гөнаһ булыр иде.

Мин, җаваплы секретарь буларак, гомумән, Равил Сабировичтан уңдым. Эш вакытында шулай бит: ашыгыч рәвештә рәсем астына текст язасы, яисә сводка, газета битендә буш калган урынга кыска гына хәбәр кирәк була. Мин моны Равил Сабировичка гына әйтәм. Ул беркайчан да «бу урынбасар эше түгел, минем өчен ваклану» дип тормады. Блокнотын тотып идарәгә ашыкты, сводкасын да ясады, хәбәрен дә табып бирде. Гаҗәеп эшчән, төгәл кеше.

Равил Сабирович рәсми яктан алганда зур белемле түгел, ул урта мәктәпне дә тәмамламаган, җиденче класста туктальш калган. Ә шулай да без, редакциянең университетларда укыган кешеләре, күп сораулар белән аңа мөрәҗәгать итәбез:

— Равил Сабирович, авыл хуҗалыгын күтәрү буенча соңгы елларда нинди карарлар булды әле?

— Пайчылар җәмгыятенең нинди хокуклары бар?

— Сайлау участоклары нинди принциплардан чыгып төзелә? Равил Сабирович коңгырт күзләрен әңгәмәдәшенә текәп һәм теләсә нинди сорауга, теләсә нинди темага тулы җавап бирә.

— Ә сез, дипломлы кешеләр, политэкономияне юньләп укымагансыз бит! — ди ул ахырдан.

Без редакциядә аның белән нинди генә темаларга сөйләшмәдек тә, нинди темаларга бәхәсләшмәдек! Ул партия эшенә чын күңеленнән бирелгән, инанган коммунист, атеист. Партия мәктәбендә Мәскәүдә укыган, үзлегеннән укып зур белемгә ия булган, тормыш юлы үтеп, тәҗрибә тупланган, зур практик кеше. Әмма мин дә бит, әлләни практик булмасам да, дөнья әдәбиятыннан һәм фәлсәфәдән шактый мәгълүматлы.

— Анысы бездә демократия дигән нәрсә юк инде. «Д» хәрефе дә юк аның! — дип башлыйм мин.

— Бездә демократия — иксез-чиксез! — дип кире кага Равил Сабирович минем беренче бу селтәнүемне.

— Ну ярый. Ә ни өчен алайса, әйтик, теләгән кеше безнең илдән читкә чыгып китә алмый?

— Кеше үзе туган иленә, Ватанына гына хезмәт итәргә тиеш! — ди Равил Сабирович инанган төстә.

— Юк сүз! — дип каршы төшәм мин кыза башлап.— Кеше ул — тумыштан ирекле булып туа. Ул үзе кайда теләсә, шунда яшәргә, нинди идеалларга хезмәт итәргә теләсә, шуңа хезмәт итәргә хокуклы!

— Трухлявый интеллегентлар сүзе бу! Демогогия бу! — дип тәкърарлый теге.

— Бу фикерне демогогия дип атау — үзе демогогия! — дип китереп куям мин.

Шуннан инде китә бәхәс. Борынгы Греция, Рим демократияләреннән башлап, хәзерге Франция, Америкага килеп җитәбез. Маркс, Энгельс, Ленин сүзләре дәлил итеп китерелә. Шунда инде минем бу яктан белем шактый гына сай икәне ачыла. Шулай да минем үз сүземне аста калдырасым килми: «Кеше тумыштан ирекле. Ул тормышта да ирекле булырга тиеш»! Без инде бер-беребезне белемсезлектә, наданлыкта гаепләп, яхшы ук тērттерә башлыйбыз. Тик алай да икебез дә бер-беребезне шәхси кимсетүгә барып җитмәскә омтылабыз. Ахырда Равил Сабирович үзенең «трухлявый интеллигент!» сүзен әйтеп, кул селти дә, бүгенгә шул җитеп торыр, янәсе. Икенче көнне эшкә төшкәч, ул берни булмагандай миңа кулын бирә:

— Исәнме, Радикҗан!

Мин бер нәрсәгә, шушындый белемле кешенең интеллигентларга нәфрәт белдереп, «трухлявый» дип борын җыеруына бик аптырый идем. Баксаң, бу аның үз сүзләре булмаган икән. Инанган коммунист буларак, Равил Сабирович Ленин фикерен шулай кабатларга яраткан икән. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин зыялыларны «трухлявый интеллигент» дип атауга, аларның башына нәҗес тутырылган дип әйтүгә барып җиткән бит. Монысын мин, гафу итегез, һич кенә дә аңлый алмыйм.

Без Равил Сабирович белән көндез тату гына эшлибез. Ә кичкә таба исә яңа темага: коммунист-җитәкчеләрнең әхлак нормаларын бозуы турында бәхәс куба. Равил Сабирович коммунист-түрәләрне аяк терәп яклый, социализм төзү эше бәрабәренә аларның теләсә нинди кыйланышлары акланырга тиеш дип саный. Алар — эш кешеләре, аларга да бушану, ял кирәк, янәсе. Мин исә тегеләргә каршы берсеннән икенчесе

хәтәр фактлар китерәм. Тагын китә кычкырыш. Бәхәсләшкәндә, никадәр саклансаң да, кискен сүзләр дә ычкына инде ул. Булмый бит тыелып. Алай да без бер-беребезгә ачу саклауга барып җитмәдек.

Равил Сабирович эшне бик ярата иде, редакциядә әле пенсиягә чыккач та, бер-ике ел эшләп йөрде. Әмма, ни кызганыч, аның да язмышы фаҗигале булды. Хәйран гына йөргән җиреннән хатыны Фәһимә кисәк кенә дөнья куйды. Бик авыр кичерде моны Равил Сабирович. Алар гомерләре буена тату яшәделәр, ике егет үстерделәр, гаиләләре тәртипле иде. Фәһимәнең вафатыннан соң, Равил Сабирович инде эшли алмады, бик хәтәр төшенкелеккә бирелде, кара кайгыга батты. Редакциягә керсә дә, телендә гел хатыны булды. Сүзен дә әйтә алмый, пышык-пышык елап та җибәрә. Яман авыру хәсрәттән, күңел төшенкелегеннән башлана, диләр. Дөрестер, ахры. Бу авыру кисәк кенә Равил Сабировичны да тотып алды. Һәм тиз арада, алтмыш дүрт яше тулар-тулмас гүргә алып керде...

...Редакциядә эшләр хәзер шактый үзгәрде. Илдә барган вакыйгалар бөтен авырлыклары белән матбугат басмаларына да килеп кагылдылар. Кәгазь бәяләрен хәзер әйтергә дә куркыныч, типография, почта хезмәтләре өчен түләү көннән-көн арта.. Алай да пенсиягә киткән Тәлгать Мостафин урынына килгән яңа мөхәррир Тәлгать Гомәров хуҗалык итә белүче, уңган егет булып чыкты әле. Ул ничектер җаен тапты, белдерүләр һәм реклама бүлеге оештырып, аңа бу эшкә шактый гына сәләтле Рамил Сафиуллинны мөдир итеп куйды. Төрле белдерүләр, тәбрикләүләр урнаштырудан хәзер газета шактый гына файда күрә. «Коммунизмга» дигән исемне хәзер «Арча хәбәрләре» дип үзгәрттеләр. Барып җитеп булмады бит коммунизмга!

Алдагысын белеп булмый, әлбәттә. Бигрәк тә хәзерге болгавыр заманда. Әмма газета базар экономикалы тормышка яраклаша барыр, киләчәктә дә яшәр дигән өмет бар.

Ә мин инде пенсиядә. Мин инде, дөресен генә әйткәндә, картайдым. Алай да еш кына редакциягә керәм, каләмдәшләремнең хәлләрен сорашам-белешәм, үзем дә материаллар китерәм. Кайчандыр үзем көннәр буе чабып йөргән, идәнгә җәелгән линолеумның һәр җыерчыгы таныш булган коридор буйлап акрын гына йөренәм, кайчак үзем эшләгән өстәл артына кереп утырам. Үткән гомеремне, монда эшләп киткән иптәшләремне, дусларымны, инде мәрхүм булганнарны хәтерлим. Күңелне сагыну-сагыш кыса. Дөнья фани, гомер үтә...

Яраткан эш мәңге онытылмый инде ул. Күзләрең соңгы тапкыр йомылганчы сине озата бара...

*1993—1994.*
*Арча.*

# ШИГЪРИЯТ



## Зөлфәт

## ТӨНБОЕК КҮЗ ЙОМГАН МӘЛЛӘРДӘ

### Тезлән дә бер...

Бу борынгы күктә
Бик борынгы
Ак болытлар йөзә югары...
Тезләнеп, бар белгәнеңне укы
Туфрагында Бөек Болгарның!

...Кара сөрем япкан
Бу күкләрне,
Яулар килеп утлар гүләткән —
Кара кисәү, ятим хәрабәләр
Торып калган бөек дәүләттән.

Яуда ятып калган яугирләрне
Төнлә чишендергән бур сыман
Килгән бу төбәккә мародерлар,
Кабер ташын казып ташыган.

Ташыган да,
                капка төпләренә
Аяк кырыр өчен түшәгән,
Юкса,
        шушы җирдә, изге яуда
Ярсып яу атлары кешнәгән!

Җиңелдеңме —
                шакшы аяк белән
Йөрәгеңә басып үтәрләр...

Юк, язмасын гына җиңелергә —
Тарихыңны чүпрәк итәрләр!

Көл-корымнар кабат дәүләт булмас,
Тик
Кайта бит Тарих каргышы,
Һәр төбәктән: «Вон!» — шул мародерга...
Яшәвенә күрә — язмышы.

Угрының шул озын кулы корый...
Боргалана мәет талаучы.
...Синең үчең кайта бугай инде
Кайта, Бөек Болгар каласы!

Шуны теләп,
                белгәнемне укыйм,
Аһы калка Бөек Болгарның!
Һәм килер көн...
Син аңларсың, татар,
Болгар аша юлың узганын!

Бик борынгы авыр көннәрдә дә.
Кичә, иртәгә дә, бүген дә
Авыр уйлар төяп болыт йөзә,
Уйлар йөзә Болгар күгендә...

## Күрешә калсак...

Томанлы таңда наз иңә җиргә,
Әйтерсең, сыер бозавын ялый...
Ходайның изге сәгате инде —
Уҗымнар шыта, Мөхәммәт абый...

Газаплы ләззәт, ләззәтле газап
Җылы туфрактан гарешкә аша.
Ходаем, берүк ярдәм ит җиргә —
Җир уҗымлаган мәлләр ләбаса...

Яшәүнең сере ачылган мәлләр...
Тик крестьян гына сизенә моны —
Сискәнә җирдә уҗымнар түгел —
Фани дөньяның мәңгелек моңы.

Безнең бетүләр шушы микәнни
Дигән шикелле күңел ут йота —
Тынычлан, адәм баласы, диеп,
Мөхәммәт абый, уҗымнар шыта...

Йөргән җиреңдә, хәтта гүреңдә
Уҗымнарга күз саласы килә.
Игенен чәчкән бер крестьян булып
Басу түрендә каласы килә.

Шул басу түре — бар дөньяң синең,
Бар дөньяң — шушы уҗым бит инде.

Тургайлар, никтер, оча эзләнеп,
Кайда соң үзе, диләр шикелле.

Исә дә исә уҗымнар җиле...
Вакыт алдында без һаман сабый.
Күрешсәк анда — сөйләрмен таңда
Уҗым шытканын, Мөхәммәт абый!..

* * *

Җанда гүя йолдыз кабыздың...
«Мәңге бергә!..» — диден бугай ла
Тик икебез белгән тугайда...
Язмыш юлын безнең кем сызды? —
Җанда гүя йолдыз кабыздың...

«Мәңге бергә!..» — диден бугай ла,
Зәңгәр төндә шәмгә ут элдең,
Төнге толымнарың сүтелде...
Дертләп куйды йөрәк шулай да —
«Мәңге бергә!..» — диден бугай ла...

Тик икебез белгән тугайда
Эзләр калды чыкта җемелдәп,
Бетмәс сагыш калды күңелдә...
Икебезгә уртак моң кайда? —
Тик икебез белгән тугайда!

Язмыш юлын безнең кем сызды? —
Аңлый алмыйм шуны һич кенә...
Язмыш нурлы булсын өченгә
Син бит сөю шәмен кабыздың! —
Язмыш юлын безнең кем сызды?

Җанда гүя йолдыз кабыздың...
Ул йолдызың тере... Ул яна! —
Сизеп мәллә синсез дөньяда
Каласымны шулай ялгызым,
Җанда минем йолдыз кабыздың?..

## Соңгы томан

Бу тетрәнү инде китмәстер җаннан —
Афәтле хистән тетрәнә дөньям...
Каплый гомерне дәһшәтле томан.
Йолдызлар күктә каралып тынган
Мәңгегә бүтән кабынмас сыман...

Авыр, буш томан кайларга ага?
Китмәскә килгән кебек дөньяга...
Уйлар тулгана, күңел шомлана,
Кара болыттан авыр шом тама...
Җан сорап томан кайларга ага?

И томан, бездә булды ни үчен?
Яндык дөньялар җылынсын өчен,
Сөюдән булды бар яшәр көчем...
Ярым иде ул — иң газиз кешем —
Төннәрдә күргән иң газиз төшем...

...Бу томан сиңа барып сарылды —
Эзләгән икән синең җаныңны...
Уятып синең бар моңнарыңны —
Гүяки яшен болытларыңны,
Җанымны телеп яшен ярылды...

## Юк

Канәферләр чәчәк аткан бер төн...
Ай балкыды — моңлы ул төндә.
Авылың да хәтта Җирдә юк бит! —
Учак яктык... менде тетеннәр!..

Тик икебез генә килгән сыман
Идек ләбаса бу дөньяга!..
Уйлауга ук канәферле төнне
Җан сызлатып шул ук моң ява...

...Син юк инде... Ләкин бу хәтерем
Хәтерләтеп һич тә туймады
Канәфернең таңда былбыл кунган,
Икебезне белгән куагын.

Хәзер исә
Шул ук төнгә карап
Сыкранам мин... калдым берьялгыз.
Кайда соң сез, серле канәферләр?
Кайда
Ай нурына чумган кыз?..

## Моңсу җилләр

Кала адәм баласыннан
Моңсу искән җилләр генә...
Кил болынның төрләреннән
Көлә-көлә, Гөлнәзирә!

Кил әле, кил! Яз гөленнән
Тәкыялар үрә-үрә!
Кил әле, кил! Китмә генә
Китмә генә, Гөлнәзирә! —

Диеп кенә әйтер идем
Кычкырып бу фани җирдән! —
Тәңре безне тыңламады...
Нишлим инде, Гөлнәзирәм?!

Ничек кенә кайтырга соң
Синле ямьле көннәремә?
...Күрәсең, без бу дөньяда
Моңсу искән җилләр генә...
Гөлнәзирә!

* * *

Кереп бастык икәү талбасмага
Төнбоек күз йомган мәлләрдә...
Ниләр генә юрап йоклый алар
Без күрәсе килер көннәргә?

Ак яулыгың шуды иңнәреңнән,
Мин, күрәсең, саксыз кагылгач,
Син сөйләдең микән, әллә инде
Сайрадымы ярсу сандугач?

Икәү генә белгән якты айлы
Төннәр генә йөрткән җилләрдә
Талбасмага дәштең, Гөлнәзирәм,
Төнбоек күз йомган мәлләрдә...

Йолдызлы күк тына, моңлана да
Нидер тоеп, карый, тыңлана...
Әнә алар, икәү — талбасмада!
Нишләп алар моңсу, уйлана?..

Йолдызлар ни диеп эндәшәдер
Икәү ялгыз калган төннәрдә?
Уйный дулкын... Һәм без — талбасмада,
Төнбоек күз йомган мәлләрдә...

* * *

Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен!
Язмышыма килә эндәшәсем...
Күпме еллар яшәп үттем дә мин,
Томырылдым тирән үткелгә мин —
Синең белән килде сөйләшәсем...
Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен!

Язмышыма килә эндәшәсем...
Түгелсен лә кайнар, ярсу яшем!
Тала, язмыш, кыйна бу җанымны,
Суксын яшен барлык булганымны!
Керфегемдә инде кипмәс яшем —
Язмышыма килә эндәшәсем...

Күпме еллар яшәп үттем дә мин,
Сер йомгагын сүттем-сүттем дә мин,
Гомерлеккә сыкрап калды бәгырь...
Ничек инде? Син һәм... салкын кабер?!

Синдә булган икән дөнья гамем,
Күпме еллар яшәп үтсәм дә мин...

Томырылдым тирән үткелгә мин,
Тик... дөньяның чиксез читендә син...
Юк, кабынмас кабат яшьлек таңы,
Үтте дә бит китте гомер янып,
Күрдем дә мин бәхет сүтелгәнен —
Томырылдым тирән үткелгә мин!..

Синең белән килде сөйләшәсем,
«Таң ата... Күр!..» — диеп эндәшәсем,
Сыйпап кайнар, калын толымыңны...
Кемнәр тояр тагын мондый моңны?
Әйтерсең кош кошка эндәшәсе —
Синең белән килде сөйләшәсем...

Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен,
Күкрәсен күк, уйнакласын яшен!
Очар йолдызлар күк галәм ярып,
Кушкан килде җиргә, китеп барды...
Изге икән Җирдә тик күз яше...
Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен!





**Локман Закир**

# БҮРЕЛӘР

хикәя

Ат караучы Сәлмән абзыйның элегрәк йокысызлыктан болай интеккәне юк иде. Бүген исә төн урталары узуга карамастан, күзенә йокы кермәде. Элек аның тыныч йокысын кандалалар да, үз янында ирләр сыман хырылдап ятучы калын гәүдәле хатыны да бүлдерә алмый иде. Ә бүген ул пошынып, әледән-әле әйләнеп ятты. Аның бу хәленә зарлангандай, бабасыннан мирас булып калган агач карават туктаусыз шыгырдап торды.

Ниһаять, болай азапланып яту туйдырды Сәлмән абзыйны, ул җылы урыныннан торды, өйдәгеләрне уятмас өчен идәнгә сак кына басып, бусагага килеп чүмәште, тәмәке төреп кабызды.

Сыек кына ай яктысы төшкән идәндә иске тун, ямаулы фуфайка ише нәрсәләр ябынган балалар чайрап йокы симертә. Алар янәшәсендә саламга күмелеп, берничә сарык бәтие белән йонлач себер мәчесе бөгәрләнеп ятткан.

Сәлмән абзый тәмәкесен соң кат чытырдатып суырды да кулын пешерә башлаган төпчеген куесу чиләгенә ташлады һәм янә караватына барып ауды, күзләрен йомып, бераз булса да онытылырга теләде, чөнки аның иртә таңнан сәфәр чыгып китәсе бар иде.

Инде авыл әтәчләре икенче кат дәррәү кычкырып, кышкы тынлыкны яңгыраттылар, ә Сәлмән абзый һаман уяу иде әле. Юк, аны иртә таңнан суык юлга чыгып китәсе булу борчымый, ул моңа яшьли күнеккән. Колхоз рәисенең үзенә беренче кат җылы карашын тою, кичә кылган яхшылыгы дулкынландырган иде аны. Соң, шулай булмыйча, шәһәргә бәрәңге сатарга бару өчен ат сорарга баргач, ике дә уйлап тормыйча, рөхсәт итте ләбаса. «Үзең теләгән атны җик, Сәлмән абзый, синең өчен берни җәл түгел»,— дип, аркасыннан да сыйпап куйды әле. Әлегәчә рәиснең аңа болай бер дә якты йөз күрсәткәне булмады бит. «Менә ул орден алуның хикмәте, ниһаять, Чатан абзалары белән да санлаша башладылар түгелме?! Үз иясен бик соңлап килеп тапса да, ярап куйды әле

ул. Һы, санлашмый ни, кан түгеп алынган бүләк ләбаса. Тиккә бирмиләр орден кадәр орденны!» — дип фәһемләде Сәлмән абзый.

Әлеге бүләккә ия булуына әле һаман ышанып җитә алмыйча, шул турыда язылган гәзитне тагын бер кат укып карыйсы килде. Әмма ут кабызасы итмәде, кулы белән мендәр астындагы гәзитне капшап карау белән чикләнде. Кыштырдый, җанашым! «Уен эшмени! — дип, уй йомгагын сүтүне дәвам итте Сәлмән абзый.— Рейстагны алган вакытта күрсәткән батырлыгы өчен иптәш Атнагулов Сәлмән Габделмән улы Беренче дәрәҗәдәге Дан ордены белән бүләкләнгән иде... Шуны иясенә тапшырырга!..— диелгән бит...»

Моңа кадәр аның исем-фамилиясен дә онытканнар иде бугай инде. Кыска гына итеп, Чатан дип кенә йөртәләр аны. Бу кушамат аңа фронттан аягы яраланып кайткан көннән үк тагылды. Чатан дигән шул бер сүз аның бөтен тәрҗемәи хәлен үзенә сыйдырган: ат караучы Сәлмән Габделмән улы Атнагулов — Бөек Ватан сугышы инвалиды, Пүчинкә авылында туган, Мәүлиха исемле хатыны, өч баласы бар...

Колхоз идарәсендә саклана торган исемлектә дә Сәлмән абзый фамилиясе турысына өстәп, «Чатан» дип язып куелган. Ошбу кушамат кыска булуы белән авыл түрәләрен күп сүз әрәм итүдән коткара. Әйтергә дә җайлы, башкалар белән буташтыру куркынычы да юк. Хәтта ки, Чатан кушаматы урам исемнәре, йорт номерлары булмаган авыл җирендә ориентир-тамга өчен дә бик җайлы. Әйтик колхоз рәисе бригадирга нәрәт бирә: «Чатаннар турында телеграф баганасы ауган, нимидленне яңасын утыртыгыз!» Монда инде бригадирга барысы да көн кебек ачык, тәгаенләп-шәрехләп торасы да юк. Чатаннар турында ауган багана и һәм — вәссәлам!

Сәлмән абзый әлеге кушаматына үзе дә күптән күнекте инде. Дөрес, баштарак җене котыра иде Чатан дигәнгә. Ул үзенең гариплеген исенә төшереп торучы кушаматтан ничек кенә котылырга теләмәде. Күпме тавыш-гауга чыкты шуның өчен. Хәтта бервакыт ярсып китеп, күршесе Кара Зәкине чүт кенә балта белән бәреп үтерми калды. Шуның өчен таш капчыкка эләгеп, берничә ел Лаеш шулпасы чөмерергә дә туры килде Сәлмән абзыйга. Хәер, Кара Зәки белән низагның башка җитди сәбәпләре дә булмады түгел. Бәрәңге бакчасы сукмагы буенда үсеп утырган карт каенны кисеп аударган бит кара шайтан. Имештер, аның бакчасын күләгәли, имештер, күләгәдә бәрәңге начар үсә, уңышы бөтенләй дә чыкмый, янәсе. Заманында бабасы утырткан шул каен өчен йөрәге әрнеде Сәлмән абзыйның. Шул турыда әйткәч: «Юк белән баш катырма әле, Чатан тәре!» — дип теш ыржайта бит әле җитмәсә, мөртәт! Әле тагын нәрсә ди бит, имештер, Сәлмән сугышка алынгач, фронтка ук җибәрмәсеннәр өчен аяк сеңерен юри кискән, шуннан гарип булып калган, имеш. Сугыш батырын куркак дип мыскыллау ләбаса бу!..— Шушы хәлләр исенә төшкәч, Сәлмән абзый ачудан үз алдына сүгенеп куйды. Бу вакытта ул юньсез күршесен янә дә тотып тукмарга әзер иде.

Кара Зәки белән Сәлмән абзыйның җеннәре ярашмау сугыштан соң ук башланды. Хатының юньсез булса, аерып котылырсың, күршең юньсез булса, ничек котылырсың, дип, халык белми әйтми шул. Сәлмән абзый шаукымлы бу нигезне ташлап, җир читенә олагырга да риза булыр иде дә, ишле гаиләсе, гомер буе бөртекләп төзегән хуҗалыгы бар. Хуҗадан башка нишләр алар? Беткә ачу итеп, тунны утка ягу да егетлек түгел. Уф! Күрәсе дә килми шул кара еланны. Битендәге теге вакытта балта белән ясалган тирән яра эзе Сәлмән абзыйга төрмәдә үткәргән мәхбүслек елларын хәтерләтә җитмәсә...

Ә бит үз аягын үзе бозган дип, Сәлмән абзыйга бөһтан яла яккан өчен Кара Зәки үзе Лаеш шулпасын эчәргә бик тә лаек бәндә. Ялганның аягы озын була, дигәндәй, әлеге, үз аягын үзе бозган, дигән ялган авылда бик тиз таралды. Адәм баласы бит ул дөреслеккә шикләнеп караса да, ялганга тиз ышанучан. Фронтта алган медальләрен тагып

чыкса, күрерләр иде күрүен Чатанның кем икәнен. Ләкин ул, Кара Зәки кебек, чылтыравык тәтиләр таккан түшен киереп йөрергә яратмый шул. Ямаулы кәчтүнгә медальләр тагып йөрү килешәмени? Инде әнә гәзиттә язып чыктылар аның орден алуы турында. Чатанның кемлеген аңлаганнардыр, ниһаять. Медальләр янына орден да өстәлде. «Тукта әле, медальләремне кая куйган идем соң әле?—дип сөйләнде Сәлмән абзый.—Нуҗәли балалар уйнарга алып, югалтып бетерделәр икән? Бәлкем, Кара Зәкинең түшендә минем медальләр чылтырашадыр? Наград кәгазьләре саклана-саклануын, ә менә сандыкта медальләр азайган шикелле? Ярый, базардан кайткач, эзләп карармын әле. Бәлкем ярыктан идән астына төшкәннәрдер. Күрсәтермен әле шул кара шайтанга бөтен наградларымны бергә тагып чыгып. Күрсен кемне куркак дип мыскыл иткәнлеген, ыштыр бит! Чатан, имеш, куркак, имеш! Һы! Бу бит сугыш инвалидын хакарәт итү. Сукырга сукыр дип әйтү белән бер ләбаса бу. Сукырны, син—сукыр, дип күпме ирештерсәң дә, күрә башламас. Тумыштан куркак булган куянны да батыр итеп булмый. Һәркемнең, һәр җан иясенең батыр буласы килә, шул исәптән, куянның да. Куян ничек бүредән көнләшсә, куркак бәндә дә батыр кешегә шулай көнләшеп карый. Әмма Кара Зәки куян гына түгел, бүре ул. Ерткычларның да куркаклары буладыр, күрәсең...»

— Нәрсә мыгырдыйсың син? Төшләнәсеңме соң?—дип, ирен иңнәреннән тотып селкетте Мәүлиха.

— Юк ла, йокламыйм мин,—диде Сәлмән абзый.—Син белмисеңме минем медальләр кая таралды икән?

— Каян килеп төште әле башыңа медаль кайгысы? Шунда, сандыктадыр. Кая китсеннәр. Йокла, тиздән таң атар. Сиңа иртә торасы бит. Йокла!

Берничә минуттан хатыны янә хырылдый башлады. Шуны тыңлап ята-ята, Сәлмән абзый үзе дә оеды, уйлары төш белән алмашынды. Имеш, ул хөкем залында, агач бүлемтек эчендә утыра. Ике ягына ике сакчы—милиционер баскан. Судья гаепләү сүзен укыганнан соң, эшнең асылын тәфтишли башлый.

— Зыян күрүче Зәки Зарипов, әйтегез әле, Сәлмән Атнагулов сезгә нинди хәл-әхвәлдә балта белән сукты?

Кара Зәки алдагы рәттә утырган урыныннан торып баса, яңа кәчтүм изүендәге медальләрен чылтыратып, судья өстәле янына килә. Залда тынлык. Кара Зәки башта сынаулы карашын Чатан Сәлмәнгә юнәлтә, аннары өстәл артында утыручы судьяга борыла.

— Ул көнне миндә кунаклар бар иде,—дип башлый ул сүзен.—Улы белән баҗай килгән иде. Сүз ара сүз китеп, мин межа янындагы күрше каенының бакчамны кояштан күләгәләвеннән, шуңа күрә бәрәңгем уңмаудан зарланып алдым. Кунакларым киңәше белән, әлеге каенны кисеп аударырга дип, балта алып, бакчага чыктык. Эшне бетергән генә идек, әллә кайдан Чатан, то-есть, Сәлмән Атнагулов килеп чыкты. Без каен өстенә утырып, ял итә идек. Аны-моны әйтми-нитми, минем изүгә килеп ябышты. Медальләремне йолкып алып, җиргә салып таптый башлады... Табигый ки, мин аның кулына ябыштым. Ул шулвакыт бер читтә яткан балтамны алды да миңа кизәнде. Чүт кенә янга тайпылып калдым, юкса харап итә иде. Болай да, менә балта йөзе битемне сызып узды. Шуннан калганын хәтерләмим—аңымны җуеп егылганмын...

Шаһитлардан җаваплар алганнан соң, судья яңгыравык тавышы белән Сәлмән абзыйга сорау бирде:

— Хөкем ителүче Атнагулов! Сезнең балта белән ни өчен кизәнүегез аңлашыла. Ә менә медальләрне—хөкүмәт бүләкләрен ни өчен җиргә салып таптадыгыз—монысы акылга сыймый. Аңлатып бирегез әле шуны?

Үзенә кадәр сөйләүчеләрне игътибар белән тыңлаганга, Сәлмән абзыйның җавабы күптән әзер иде инде.

— Мин бу кара шайтанның... тьфү, аты корыгыры! Зәкинең изүеннән борып алып, үзе кисеп аударган каен янына салмакчы идем. Ә ул каршылык күрсәтте, тартылды. Шул вакытта түшендәге мактанчык тәтиләре, әй лә, медальләре шалтырап җиргә коелды. Мин аларны таптамадым... Юк-юк! Алла сакласын, рәзе бу мөмкин эш? Мин алай итмәдем. Билгеле, әвәрә килгәндә ялгыш, аяк астында калуы ихтимал. Дөресен әйткәндә, мин бу кара шайтанны... әй лә, Кара Зәкине күптән акылга утыртырга теш кайрап йөри идем. Шул кабахәт бит инде, биләмче хатыннар кебек, минем турыда гайбәт таратучы...

— Нинди гайбәт? Төгәлрәк әйтегез,— диде судья.

— Нинди булсын? Һы! Янәсе, мин фронтка, ягъни алгы сызыкка эләкмәс өчен аяк сеңеремне кискәнмен дә, яраландым дип алдаганмын икән. Үзегез уйлап-фәһемләп карагыз, рәзе мөмкин эш бу? Сугышта бит моның өчен трибунал иде...

Судья үткен карашын Кара Зәкигә төбәде:

— Гражданин Зарипов! Сез Атнагулов фронтка бармас өчен үз аягын үзе яралаган, дип, сөйләп йөрдегезме?

Кара Зәкинең табак бите бурлат кебек кызарып чыкты. Ул үзен кем дә булса бүлдерүдән курыккандай, ашыгып җавап бирде:

— Шыттыра ул, иптәш судья, оятсыз рәвештә алдалый! Ул моны берничек тә дәлилли алмый. Шаһитлары кайда? Әйтсеннәр...

Сүзгә яклаучы-адвокат кушылды:

— Хөкем ителүче Атнагулов! Сез гайбәт турындагы сүзегезнең дөреслеген дәлилли аласызмы?

— Ник дәлилләмәскә! Әнә Зәки Зариповның бәләкәй улы Пәрхидән сорагыз. Ул минем аяк турындагы әтисе әкиятен мәктәпләрендә сөйләгән. Бөтен класс алдында минем малайны куркак куян дип үртәгән. Шуның өчен канга батып сугышканнар. Шуннан соң минем малай укуын бөтенләй ташлады. Ышанмасагыз, мәктәп директорыннан сорагыз. Ул малайны мәктәпкә килергә үгетләп йөрде...— Сәлмән абзый судьяга үпкәле караш ташлап, өстәде: — Һы, үзегез турында шундый яман сүз таратсалар, нишләр идегез икән, ә?..

Ул үзен аклап тагын нидер әйтмәкче иде дә, судьяның кул ишарәсен күреп, тынды.

— Тынычланыгыз, хөкем ителүче Атнагулов! Бала-чага сөйләгән сүзләр җитди дәлил була алмый,— дип бүлдерде аны судья, үртәлгән тавыш белән.— Үзегезне мыскыл иткән кешене сез судка бирергә тиеш идегез. Бездә бәхәсле мәсьәләләрне балта белән хәл итмиләр. Аның өчен гадел совет законнары бар, гадел хөкем бар. Ну-с, гражданин Атнагулов, сез үзегезнең гаепле булуыгызны таныйсызмы?

— Әх, бу кара еланның башын ук кисеп ташлыйсым калган! — дип кычкырып җибәрде Сәлмән абзый ярсып һәм үзен утырткан агач читлектән чыгарга талпынып куйды...

Нәкъ шул вакыт уянып китте ул. Салкын тир бәреп чыккан маңгаен тозланган күлмәк җиңе белән сөртеп, чалкан әйләнеп ятты һәм әле генә күргәннәренең үз башыннан күптән узган булып, хәзер төш кенә икәненә сөенде. Аннары мендәр астына кулын тыгып, аннан теге гәзитне алды, сукыр кеше кебек, учын гәзит битендәге юллар өстеннән шудырды, гүяки, ул үз батырлыгы турында язылганнарны бармаклары белән дә тоя иде. «Хәзер мине яңадан элеккеге эшемә — амбар мөдире итеп куярга мөмкиннәр,— дип хыялланды ул, күзләрен йомган хәлдә.— Анда эше дә дәрәҗәле, хезмәт көне дә күбрәк булыр. һәрхәлдә, уңыш күпме чыкса да, ач калмыйсың инде анда. Әй, балалар сөенер! Ни дисәң дә, аталары тирес эчендә казынучы түгел, яхшымы-яманмы, амбар мөдире булачак бит. Хатынның шатлыгы да эченә сыймас! Аңа быел яңа күлмәк белән сырма алası булыр. Югыйсә, өсте-башы карарлык түгел, кырык корама, мең ямау дигәндәй... Авылдашлар да, мөдир Сәлмән абзаларын санга

сугарлар иде, нибучь. Ә районнан килгән түрәләр аңа иптәш Атнагулов дип зурлап эндәшерләр иде. Ул чакта Кара Зәки дә минем белән санлашмый булдыра алмаячак. Һы, кем соң ул? Мазутка буялып йөрүче тракторчы гына лабаса. Эшләгәненнән тик торган көннәре күбрәк. Андый ялкаулар буа буарлык колхозда. Ә амбар мөдире — бераү генә ул. Аның идарәдә аерым өстәле бар хәтта, шкафындагы кенәгәләреннән дә икмәк исе килеп тора аның. Әйе-е, хаклык барыбер өскә чыга ул, сабыр булырга гына кирәк. Тик моңа бөтен кешенең нервысы чыдамый шул. Хаклык өчен көрәшкәндә күпләр тормыш мәгънәсен югалтып, авыруга сабыша, дөреслекне табалмый. Ә мин хаклык-дөреслекнең өскә чыкканын көтеп алалдым, шөкер!.. Бөтен кешедә андый сабырлык була алмый шул. Әнә бит, күптән түгел мәктәп завхозының асрамага алып үстергән кызы асылынып үлде. Уналты яшендә генә иде, бичара. Ни генә лыгырдамадылар яман телләр. Укытучылардан, хәтта чүт кенә җаны чыкмыйча йөри торган чахотка авырулы директордан да шикләнделәр! Кыз бала үзенә үзе кул салганнан соң гына, хәл ачыкланды. Район гинекологы, имеш! Юкныбарны лыгырдый белә, ә гыйффәтле кызны хатыннан аера алмаган... Ә минем кушаматка килгәндә, анысы пүчтәк. Бу яктан да уңдым әле мин. Чатан кушаматы миңа сугышта яралануым өчен бирелде. Әнә шадра Зәкәрияне битендәге түгәрәк мөһергә охшаган кызыл табы өчен Клэймә дип атадылар. Ә сукыр Кәримгә борыны ямьшек булганга — Мөгезборын кушаматын тактылар. Итекче Хәнифулланы Тиле Хәниф, диләр. Ни өчен шулай атаганнарын беркем белми. Әнә Бригадир Курамшаны ни өчендер Чибәр дип атыйлар, гәрчә чибәр булмаса да...»

Өченче әтәчләр кычкырганнан соң, Сәлмән абзый вакытны чамалап, урыныннан кузгалды. Зур мич авызына ярты гәүдәсе белән тыгылып, кичтән кибәргә куйган киез итекләрен тартып чыгарды. Биш капчык бәрәңгене ул кичтән үк сайлап тутырып, әзерләп куйган иде инде. Шушы капчыкларга таянып, көлгә буялган җылы киез итекләрен киде, аннары тәмәке кабызды. Зәңгәр төтенгә уралып, ишек алдына чыкты. Тирә-юньдә — тынлык, тик авылның аргы очында гына эт өргәне ишетелә. Шыңшый-шыңшый өрә, бүре йөри микәнни? Әле яктырырга өлгермәгән күк гөмбәзендә йолдызлар салкыннан калтырана. Ай да күшегеп, кечерәеп калган шикелле. «Көн аяз булачак!» — дип сөйләнде Сәлмән абзый, учын-учка уыштырып.— Шулай торса, ике сәгатьтән базарда булачакмын, Алла боерса. Һава хәлләре генә бозылып куймасын, Ходаем!» Ул җылытылган абзар ишеген ачып керде. Куначадагы тавыклар, ишек шыгырдавына үзләренчә «ка-ка-ка!» дип, аваз биреп, борчылып алдылар. Ләкин Сәлмән абзыйда тавыклар кайгысы юк, сыерының хәлен белешергә иде исәбе. «Шушы көннәрдә бозауларга тиеш бу малкай»,— дип уйлады ул, кабарынкы корсагын салам өстенә салып яткан һәм авыр-авыр тын алган сыерга карап.— Шуңарчы шәһәргә барып кайтуым әйбәт булачак әле. Югыйсә, акчасыз калуыбыз бар...»

Аннары Сәлмән абзый, абзарны тыштан бикләп, колхозның атлар сараена юнәлде. Үзен Чатан кушаматына лаек иткән сул аягы тездән бөгелмәгәнлектән, аның гәүдәсе сәгать маятнигы кебек як-якка чайкалып бара иде.

Ул Йонлач кушаматлы, арада әйбәт саналган байталны үрәчәле чанага җикте. Дирбияләрен капшап-каккалап тикшерде. Чанасына мул итеп салам түшәде. Шәһәргә барып җиткәнче бәрәңге өшемәслек булсын. Аннары атлар өчен су җылыта торган куышта дөньясын онытып йоклап яткан бердәнбер ярдәмчесен — тумыштан чукрак һәм телсез Әптине төрткәләп уятты. Егет үзен башкача уята алмауларын белгәнгә, ишек келәсен элмичә генә йоклый иде. Ул өлкән ат караучының сәфәр чыгасын, бөтен җаваплылыкның үзенә каласын аңлап, нәчәлнигенең күрсәтмәкиңәшләрен игътибар белән «тыңлады».

Сәлмән абзый ат җигеп кайткан вакытка хатыны мич ягып, өйне җылыткан, кичтән калган бәрәңге шулпасын кайнарлатып куйган иде инде. Юлга исә мичкә тәгәрәткән кабыклы бәрәңгене чуптарлы сөлгегә кат-кат төреп, юл биштәренә салып куйды. «Тагын нәрсәне булса да онытмадыммы икән?—дип, зиһенен җыяр өчен, җылы мичкә сөялеп торды ул. Шулвакыт тәҗел кирәккә дип саклап торган өч тәңкә акчасы барлыгын исенә төшерде. Шуны яшергән урыныннан табып, иренә сузды. «Ал, ал! Юлда кирәге чыгуы бар»,—диде ул, акчаны ирексезләп диярлек иренең кесәсенә салды. Сәлман абзый риза булып алса да, юлга чыгып китәр алдыннан акчаны кесәсеннән чыгарып, сиздерми генә, эскәтер астына кыстырып куйды.

Әле таң атып җитмәгән, тышта караңгы булуга карамастан, өйдәгеләр барысы да уянган иделәр. Җиңелчә генә киенгән олы улы урыс капканы ачып, әтисе чыгып киткәнне көтеп тора иде. Ул салкыннан котылу өчен бер урында биегәндәй таптана, бөтен уе—тизрәк җылы урынына—иске тун астына кереп чуму. Әниләре ризык салынган төенчекне чана алдына—саламга күмеп куйды. Гаиләнең калган әгъзалары—елтыр борынлы балалар туңган тәрәзәне тыннары белән эретеп, әтиләренең китүен карап торалар. Аларның аяк тирәсендә уралган сарык бәрәннәре, без дә хуҗабызны озатыйк әле, дигәндәй, нечкә муеннарын тәрәзәгә таба сузалар иде. Ә карт себер мәчесенең үз кайгысы: ул, буталыштан файдаланып, салам өстеннән торды да малайларның бушап калган җылы урынына барып ятты. Һәм, күрдегезме минем кем икәнне!—дигәндәй, яшькелт күзләрен кыскалап, бөдрә башлы аңгыра бәтиләргә карады. Ләкин аңа бу урында озак ятарга туры килмәде. Әтиләрен озатканнан соң, балалар яңадан йокларга яттылар. Песине куып җибәрделәр. Песи, моңа үпкәләгән сыман моңсу мияулап, мич башына үрмәләде.

Мәүлиха түти ирен юлга озаткач та әле өенә керергә ашыкмады. Ул иртәнге тынлыкта һаман саен ераклаша барган чана табаннары шыгырдавына, ара-тирә ат пошкыруына колак салып, капка төбендә басып торды. Тәмәке төтене исе сеңеп калган салкынча һава аңа кырык икенче елның кышкы иртәсен хәтерләтте. Ирен сугышка озатып калган иртәне. «Гомере булса, бер кайтыр әле, сугышта да бөтенесе һәлак булмый бит...»—дип уйлаганы хәтерендә.

Өстеннән күп йөрүдән тыгызланган юлдан чына табаннары рельстан барган шикелле шома шуа. Төнлә әйбәт ял иткән байтал шәп элдертә, гүяки, ул һава хәле әйбәт торганда тизрәк каладан әйләнеп кайту өчен ашыга иде. Менә инде алар ярты юлны диярлек уздылар да шикелле, әнә Покровка авылының иске, ярым җимерек чиркәве күренде. Аның инде исеме генә чиркәү, ә гамәлдә ул егерменче еллардан бирле колхозга амбар хезмәтен үти...

Сәлмән абзый атлар хәлен яхшы аңлый, аларны ригая кыла, шуңа ул Йонлачны да үз җаена куйды, артыгын кумады, үр менгәндә чанадан төшеп, җәяү барды, текәрәк урыннарда атка булышкалады. Түбән таба исә бәрәңге өстенә ябылган брезентка ятып, ял итте. Мондый чакта аның башына төрле уйлар килде. Ул бүген бәрәңге сатудан кулга керәчәк акчаны исәпләп-санап карады. «Чиләген икешәр сумнан җибәрә алсам, алтмыш сум була, бер ярымнан гына алсалар, табыш азрак тиячәк...»

Шундый уйлар белән әвәрә килеп барганда кинәттән байтал туктап, хәвефле итеп кешнәп җибәрде. «Шайтан алгыры, нүҗәли ыңгырчак бавы ычкынды икән?—дип сөйләнде Сәлмән абзый, чанасыннан төшә-төшә. Әмма сәбәпнең күпкә җитди булуын күреп, сүгенеп куйды:—Иблис токымы! Тапканнар кайда ял итәргә!» Кырык-илле метр арырак, юлга аркылы ике бүре яткан иде. Алар ялкау гына башларын боргалап, атлы кеше якынлашканны көтәләр иде.

Бу ерткычлар өстенә күрәләтә барсаң, хәтәр, кире авылга кайтып китсәң, ояты ни тора. Сәлмән абзый бүреләрнең торып китәренә өмет баглады. Алай-болай була калса дип, саклык чарасын күрде: толыбын өстеннән салып, чанага ташлады, киез итек балтырыннан озын пычагын тартып чыгарды...

Ат караучы булып озак еллар эшләү дәверендә хәтәр хәлләргә аз тарырга туры килмәде аңарга. Чатан булуына карамастан, ул күзенә ак-кара күренмичә дулап чапкан айгырларның йөгәненнән эләктереп туктатырга, кеше талый торганнарын да акылга утыртырга өйрәнде. Шулай бервакыт бөтен кешенең котын алып тора торган сөзгәк үгез белән дә алышырга туры килгән иде аңарга. нәсел үгезе булганга сугымга җибәрми тоталар иде үзен. Шул мөртәт бәй чылбырын өзеп, иреккә чыккан бит. Шактый саллы чылбыр өзеген өстерәп, авыл урамын гизә бу. Башта ул тыныч тотты үзен. Аннары сәнәкләр, көрәкләр белән коралланган кешеләрне күргәч, күзләрен кан басты. Үзен ауларга җыелган халыкны пыр туздырып, куа башлады. Килә, күз алдында кылый Миңнулланы таптап узды, ике мужикны мөгезенә элеп атты. Аягы яралангач, тагын да котыра төште. Котлары калмаган кешеләр өйләренә кереп качтылар, ә теге ерткыч, киң урамнарны тар итеп, үкереп йөри бирде. Кичкә таба ул Сәлмәннең өе каршындагы тупыл агачына сыртын терәп ятты. Сәлмән үзенең ызба башына менеп, шуннан торып, үгезне күзәтте, уңайлы мизгелне көтеп алып, мөртәтнең муенына аркан ыргытты һәм үз тормышын куркыныч астына куеп, тупылга урады тегене. Аннан соң ай буе үгезне «акылга утыртты». Башта аны, ата-анасы белән сүгә-сүгә, камчы белән ярды, шулай итеп, үгездән җәбер-җәфа күрүчеләрнең үчен алды. Ашатмады, эчермәде. Үгез хәлсезләнә башлагач кына, янына килеп, маңгаен, муен астын кашып, иркәләгән булды. Су бирде, ашарга бирде. Билгеле, ул боларны колхоз рәисенең рөхсәте белән эшләде инде. Шуннан соң, Ходайның хикмәте, нәсел үгезе Сәлмән абзыйны үз итте. Ә калганнарны барыбер таныырга теләмәде, барысы да аннан уттан курыккандай куркалар иде. Үгез картаеп, гамәлгә ярамый башлагач, аны ит комбинатына Сәлмән абзый үзе илтеп тапшырды...

Сөзгәк үгез белән булган вакыйга Сәлмән абзыйның абруен кинәт күтәреп җибәрде. Ул авылның горурлыгына әверелде. Сугышлы уйнаучы малайларга хәтле: «Мин Сатан кебек көчле, батыр!» — дип мактанышалар. Ә мәктәп директоры, укучыларга кыюлык, батырлык турында сөйләгәндә, мисалга Сәлмән абзый исемен дә атый башлады. Авылдашлары: «Чатан ифрат гайрәтле мужик!» — дигән нәтиҗәгә килделәр. Аларның берсе дә Чатан кушаматын үзенә алырга каршы булмас иде шикелле...

Инде менә шушы Сәлмән абзый кулына сугым пычагы тоткан килеш, бүреләргә каршы барырга шүрләбрәк тора. «Хет юлдан читтәрәк булсалар, узып кына китәр идем, — дип акларга тырышты ул үзен. — Әгәренки минем шушы ерткычлардан шүрләп калуымны авылдашлар белсә, хурлыгы ни тора!» Ул гарьлегеннән һәм ачудан каеш камчысы белән бәрәңге капчыкларын каплаган брезентка сукты. Туңган брезент өстендә шартлаган камчы тавышыннан бүреләр сискәнеп куйдылар шикелле, аптырап, бер-берсенә карашып алдылар. Нишлибез, янәсе. «Әһә, котыгыз ботыгызга төштеме!» — дип кычкырды Сәлмән абзый һәм тагынтагын камчысы белән брезентка орды. Берочтан, урысчалатып, катлыкатлы итеп сүгенде. Ниһаять, бүреләр әкрен генә кузгалып, үзләренең камчылы кешедән һич тә курыкмаганлыкларын сиздерергә теләгәндәй, ашыкмый гына бер-беренең эзенә баса-баса, каршыдагы куаклыкка таба китеп бардылар.

Тынычлана төшкән байтал, хуҗасының чөңгерүен дә көтмәстән, зыкы ябыштырган чана табаннарын як-якка кузгаткалап, юлын дәвам итте. Ул әле генә үзенең шомланып торуыннан уңайсызлангандай, гаепле сыман кат-кат пошкырынып куйды. «Үзе эттән әлләни зур булмаса да, бик

хәтәр ерткыч шул бүре дигәнең!» — Йонлач байтал гүя, шулай диярга тели иде. Ул туктап заяга уздырган вакытны куып җитәргә теләгәндәй, адымнарын тизләткәннән-тизләтә барды, шулай итеп, хуҗасының ышанычын акларга, үзенең яхшы исемен саклап калырга тели иде шикелле. Ә хуҗа кеше, чанага кырын ятып барган шәпкә, үзенчә фәлсәфә корды: «Бүре — гайрәтле, ә куян — куркак... Кызык, Ходай ерткыч җанварны көчле гайрәтле итеп яраткан, ә куянны куркак иткән. Нигә алай икән ул? Ерткычларны көчле һәм куркусыз, гайрәтле һәм әрсез итеп ярату нигә кирәкте икән? Юлбарысны, крокодилны яки еланны ал. Барысы да шундый... Примир әйтик, Ходай куянны да куркусыз итеп яратса, ул да ерткычка әйләнер иде микән?..»

Сәлмән абзый кала урамына әнә шундый уйларга уралып килеп керде. Ул катлы-катлы тартма-йортларга карап: «Ничек аумыйча тора икән болар?» — дип гаҗәпләнү кичерде. Бу йортлар җил иркендә әкрен генә чайкалышып торалар шикелле иде. Шәһәр эченә кергән саен юллар күбәя, тармаклана барды. Сәлмән абзый базарга бару юлын сорар өчен дилбегәсен тартып, атын туктатты. Толыбын салып куйды, тәмәке кабызды. Шулвакыт әллә кайдан дәштеләр:

— Агайне, товарың күпме тора?

Тавышның иясе үзе күренмәсә дә, Сәлмән абзый җавап бирәсе итте:

— Чиләге — ике тәңкә, даром-шаром...

Шул арада кайсы чиләк, кайсы хуҗалык сумкасы, кайсы сетка тоткан кешеләр җыелып өлгерде.

Сәлмән абзый брезентны кайтарып куеп, бер капчыкның бавын чиште. Үзе алып килгән чиләккә тутыра да башлады.

— Мужикның бәхете бар икән, — диде сетка тоткан хатын, шул арада төзелеп өлгергән чиратка ишарәләп. — Базарга барып торасы да юк.

— Безнең өчен дә шәп булды әле бу. Бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына. Кибеттән черек-мерек бәрәңге алганчы... — диде чиләк тоткан карт.

Ярты сәгать вакыт узмагандыр, инде ике капчык бушап та калды. «Эшләр болай тәгәрәсә, төшке ашка өйгә кайтып җитәм, Алла боерса, — дип уйлады Сәлмән абзый. Улын үзе белән алмавына үкенеп куйды. — Янымда булышчым булса, чиләкне тизрәк тутырыр иде...»

Җылы фатирыннан җиңелчә киенеп чыккан сатып алучылар чиратта күшегә, акрын кыймылдыйсың, дип, авыл мужигын ашыктыра башлады.

— Ул әле йокыдан уянып җитмәгән, — дип шаяртты мыеклы ир кеше, халат кесәсеннән папирос чыгарып.

— Ул бүген иртәнге физзарядканы ясарга онытандыр, — дип тәрттерде бәрәңге капчыгыдай зур корсаклы ир.

— Безобразие! — дип ризасызлык белдерде өченчесе. — Сдачага вак акчасы да юк. Көтеп тор инде хәзер туңып, аның бер сумы булганны!

Шәһәр саранчаларының мондый сүзләре Сәлмән абзыйның ачуын китерсә дә, ул дәшмәде, түзде, күшеккән кулларын капчык белән чиләк арасында тизрәк хәрәкәтләндерергә тырышты. «Әле кибеткә сугылырга да өлгерермен, — дип исәп итте ул. — Үземә бүрек карармын, малайга мәктәпкә йөрергә кәчтүм-чалбар, хатынга күлмәклек ситсы аласы булыр. Хуҗалык кибетендә кадак булмасмы..»

Ул арада чират арта барды, бәрәңге дә бетеп, капчыклар да бушап килә иде инде. Ул соңгы капчыкның авызын чиште.

Шулвакыт башына каракүл бүрек кигән кылыч борынлы хатын чәрелдәп җибәрде:

— Боже мой! Чиләгенә икешәр сум каера! Һәр килосы егерме тиен дигән сүз бит бу. Каһәр суккыры спекулянтлар, бернидән дә курыкмый талыйлар шәһәр халкын!

Сәлмән абзый дәшми-тынмый чиләгенә бәрәңге тутыруында булды.

— Ә бит магазинда килосы унике тиен генә! — дип дәвам итте кылыч борын, чираттагыларның үз сүзен куәтләүләрен өмет итеп.

— Магазинда бәрәңге түгел, чүп-чар ул, минеке сайлап тутырылган, отборный бәрәңге, бик беләсең килсә,— диде Сәлмән абзый, чыдамы төкәнеп, аннары өстәде: — Ошамый икән, магазиннан барып ал! Ирексезләп сатмыйм.

Хатын кызып ук китте:

— Ишеттегезме, иптәшләр? Ул совет сәүдәсен хурлый! Әле үзе магазиннан алып килеп сатадыр, мөгаен! — диде ул, арттан кайсыныңдыр үзенә теләктәшлек белдерүен сизеп, әтәчләнде.

Сәлмән абзый мондый ук һөҗүмне көтмәгән иде булса кирәк, каушады, ни дип тә әйтергә белмәде. Ул әлеге тилчә телле хатынны яхшырак күрү өчен билен турайтты. Шул вакытта, гөнаһ шомлыгына, каткан туң җиңе теге фетнәнең озын борынына эләкте, борыннан шырлап кан китте.

— Ах, боже! Ул хулиган! — дип шау күтәрде хатын һәм борынын кысып тоткан килеш, каядыр китеп югалды.

Явыз хатын салып киткән дошманлык уты чираттагыларга күчеп, дөрли башлаган иде инде. Фикерләр икегә аерылды. Берәүләре авыл мужигын ачкүзлелектә, спекулянтлыкта, хулиганлыкта гаепләделәр, икенче берәүләр аны яхшы бәрәңге алып килгән өчен мактадылар, якладылар.

— Сугыш инвалиды булса да, өйдә мич башында гына утырмый кеше, файдалы эш белән шөгыльләнә, маладис! — диде күзлекле кыз.

— Ниткән сугыш инвалиды булсын ул, эштә имгәткәндер әле аягын,— диде әле генә зур чиләген тотып, чиратка баскан ханым. Сәлмән абзый кичәге гәзиттә язылганнарны әйтеп, әлеге ханымның авызын томаларга уйлаган иде дә, арада үзен яклаучылар табылуга күңеле булып, дәшми калды.

— Хезмәт инвалиды сугыш инвалидыннан түбәнрәк дәрәҗәдәмени? — диде күзлекле кызый.— Ул менә дигән бәрәңге китергән, ә сез һаман канәгать түгел. Рәзе бу бәрәңгеләрне кибетнеке белән чагыштырып була, әллә каян аерылып тора!

Мондый мактау сүзләре җанына сары май булып ятты Сәлмән абзыйның, хәтта күңеле йомшарды. Ул бәрәңге чиләгенә иелгән хәлдә, шомарып беткән тун җиңе белән сиздерми генә күз яшен сыпырып алды һәм ашыгып тәмәке кабызды.

Килеп туган бәхәстә катнашмаучылар күбрәк иде, алар башта дәшми тордылар, аннары авыл гыйбатын яманлаучыларның тавышы көррәк чыгуын чамалап, шулар ягына аудылар.

Борынын тоткан хатынның җиңнәренә кызыл чүпрәк бәйләгән берничә яшүсмер ияртеп килеп чыгуы мәсьәләне көтелмәгәнчә хәл итте.

— Документыгыз? — диде кырыс тавыш белән дружиначыларның озын буйлысы. Ул башкаларның башлыгы иде булса кирәк.

— Нинди дакуминт? Юк ул минем. Калхузда пачпырт бирмиләр безгә,— дип җаваплашты Сәлмән абзый, тыныч булырга тырышып.

— Нишләп тиешсез җирдә сатасыз? Ник базарда түгел? Совет сәүдәсе кагыйдәләрен бозып, пнимаешь!

— Мин базарга бара идем. Тик менә биредә туктаттылар...— Сәлмән абзый үзенең сүзенә хуплау көтеп, як-ягына каранды.

— Кайсыгыз туктатты аны? — Кызыл җиңле егет карчыганыкыдай карашы белән чираттагыларны капшап алды.— Йә, кайсыгыз?

Дәшүче булмады. Сәлмән абзыйга янә сорау арты сорау яуды. Ул арада чираттагылар, бәласеннән башаяк, дигәндәй, шыпан-шыпан таралышып та беттеләр.

— Өстәвенә, кулыгызга ирек биргәнсез! — диде дружиначы башлыгы, җиңендәге кызыл бантны төзәткәләп.

— Билемне турайтканда ялгыш җиңем тиеп китте, ялгыш...— дип акланырга тырышты Сәлмән абзый. Каракүл бүрекле хатынның катгый таләбе белән, дружиначылар Сәлмән абзыйны милиция бүлегенә алып

киттеләр. Үз чанасына утырттылар, аның тирәсенә кызыл җиңле егетләр һәм кызыл борынлы хатын урнашты. Дилбегәне дружиначылар башлыгы үзе тотты. Башта алар уңга киттеләр, аннары сулга борылдылар, күпер астыннан чыктылар, тагын сулга, тагын уңга...

Сәлмән абзыйга барыбер иде инде. Ул адашты, хәзер җибәрсәләр дә, ничек кайтасын белмәс кебек тоелды аңа. Шулай да, күңелсез бу хәлдән ничек тә котылырга кирәк иде. Ул каракүл бүрекле хатын белән килешү эзләп карарга булды. Колагына иелеп, акрын гына дәште:

— Телисеңме, мин сиңа менә бу калган ярты капчык бәрәңгене бирәм? Бушлай, ә?

Хатынның себер мәчесенеке төсле яшькелт күзләрендә нәфрәт чаткылары биеште:

— Ишеттегезме, иптәшләр? — дип кабынып китте ул, дружиначыларга.— Бу авыл гыйбаты миңа ришвәт төртмәкче! Ишеттегезме?

Егетләр җавап бирмәде. Хатынның кемлеген чамалый башлаган иделәр булса кирәк.

Милиция бүлегендәге дежурныйның вакыты тыгыз чакка туры килделәр. Ул бик җитди кыяфәттә, кем беләндер телефоннан сөйләшә иде. Аннары тагын ниндидер эш кырган булып, тыз-быз чабып йөрде. Сәлмән абзыйга чират төштән соң гына җитте. Әңгәмә вакытында һәр сорау кәкрегә чалыш килеп торды, ул берничек тә үзен акларлык дәлилләр китерә алмады. Тентү вакытында киез итек балтырыннан ялтырап торган пычак та килеп чыккач, эшләр бөтенләй хөртиләнде.

— Нәрсә бу? Нишләп килеп керүгә тапшырмадыгыз? — дип сорады дежур милиционер, кырыс итеп.

Сәлмән абзый нидер әйтмәкче булып, авызын ача башлауга, бүлдерде:

— Сез беләсезме салкын корал йөртергә ярамаганны, гражданин?

— Юлда бүреләр очрап торганга алган идем,— дип акланды Сәлмән абзый.

— Беләбез без, мондый пычакны нинди бүреләр өчен йөреткәнегезне! — диде милиционер.— Әнә, кичәгенәк бу тирәдә берәүне суйдылар! Әлеге җинаятьтә шушы пычакның дәһеле юктыр дип кем әйтә ала? Ә? Бүреләр, имеш. Ә сез беләсезме, бүреләргә кагылу безнең илдә закон белән тыела?!

Каракүл бүрекле хатын авыл мужигының киез итек балтырыннан беләк буе финка килеп чыккач, шүрләп калган иде. Аның күңелен икеләнү тойгысы биләп алды. Мондый рецидивист белән бәйләнгәненә үкенә башлады ул. Сорау алу беркетмәсенә фамилиясе теркәлмәс борын, биредән шылу ягын чамалады. Әмма дежур милиционер аның юлына аркылы төште һәм аңардан җавап алырга кереште. Пычакның тәэсире көчле булдымы, әллә инде күңеленә Ходай мәрхәмәт хисе иңдердеме, хатын авыл мужигының спекулянтлыгы, совет сәүдәсен хакарәт итүе, хулиганлыгы турында ник бер сүз әйтсен.

Беркетмәгә кул куйганда Сәлмән абзый каракүл бүрекле хатынга борылып, аңа шыпырт кына рәхмәт әйтте. Тегесе дә аңа дустанә елмайгандай итте. Үзенең йөзе гасабилы агарынган иде, чыгып киткәндә, каушавыннан чак кына абынып егылмый калды.

Сәлмән абзыйга акчаларын кире кайтарып бирделәр. Пычагын, махсус журналга язып куйганнан соң, сейфка бикләп куйдылар.

Көн кичкә авышты, тышта буранлый башлады, әмма авыл агаен һаман җибәрмиләр иде әле. Дежур милиционер телефон аша аның кемлеген тикшерергә тели иде. Ләкин ул Пучинкә авылын бик озак алалмый интекте. Ниһаять, аңа авылдан, бездә андый кеше яшәми, дип җавап бирделәр. Шуннан соң, Сәлмән абзыйны кабат тентеделәр дә, ялгызын бер камерага ябып куйдылар.

— Сез, гражданин, безне буташтырмакчы буласыз,— диде дежур милиционер коры гына итеп, камера ишеген япканда.

— Минем кушаматым бар! Чатан мин, Чатан! Ат караучы Чатанны сорагыз сез, мине авылда шулай дип йөртәләр,— дип кычкырды Сәлмән абзый ишекне дөбердәтеп.

Милиционер тәти тапкан бала сыман шатланды:

— Әһ-һә! Ниһаять, ачыкланды. Җинаятьче кушаматсыз буламыни! Кичә «Кылый» дигән асыл кошны каптырган идек, бүген «Чатан» үзе килеп эләкте!

Сәлмән абзый, камерада басып торган килеш, иминлек сакчысын игътибар белән тыңлады, ләкин аның сөйләгәннәрен әйткәннәрен шаяру гынадыр дип, дәшмәде. Дежурный исә өстәл тартмасын ачып, беркетмәне алды да, зур эш башкаргандай, иң өскә эре хәрефләр белән ЧАТАН дип язып куйды.

Шулай да ул бераздан Сәлмән абзыйның авылына тагын шалтыратып белеште, Чатанның ат караучы Атнагулов Сәлмән Габделмән улы икәнен ачыклады һәм аны чыгарып җибәрде.

Инде алдан ниятләгәненчә, кибетләрдә йөрү өчен вакыты калмаган иде. Шул тирәдәге азык-төлек кибетеннән тиз генә кереп бер ярты алды да юлны сораша-сораша, авылына таба элдертте. Әле караңгы төшәргә өлгермәгән, әмма көннең бозыласын хәбәр бирә торган җәяүле буран күңелгә борчу сала иде.

Ниһаять, мең бәла белән шәһәрне чыгып, Пүчинкә юлына төшкәч, тынычланды. Инде хәзер тамак ялгап алсаң да була, дип уйлады ул, эчендә «урта авыл этләре»нең өрүен тоеп. Аты барган шәпкә, чана башындагы төенчектән чикмәнле бәрәңгеләрне алды. Куенындагы шешәне алып, чана башына эләктереп, бөкесен ачты һәм бер-ике йотым аракы уртлап куйды, аннары бәрәңгегә ябырылды. Ач карынга эчкән «утлы су» бик тиз башка йөгерде, аякларын җылытып җибәрде. Әле генә булып узган күңелсез хәлләр онытылды, җанга рәхәтлек иңде. Ул толып изүен ачып җибәрде дә чанага кырын ятты. Җилнең һаман көчәя баруы да, юлда көрт өемнәре хасил була башлау да аны әллә ни борчымый иде шикелле. Кар диңгезе эчендә тирбәлеп кайта-кайта, күз кабаклары авырайганнан авырайды...

Салкын һава аны тиздән аңына китерде. Ул атының гыжылдап тын алуын ишетте. Йонлач байтал чананы ничектер гадәти булмаганча, йолкып-йолкып өстери, вакыт-вакыт туктап ял итеп тора, аннары хуҗасының куганын көтмичә, тагын кузгала. Ул кайту юнәлешен әледән-әле үзгәртеп тора сыман.

Чатан кыенлык белән генә урыныннан кузгалды. Ул юлдан язганлыгын төшенә һәм хәзер дөрес юнәлешне чамаларга тели иде. Әмма ком шикелле каты кар бөртекләре белән аралашкан куәтле җил аны аяктан екты. Байтал, корсак астына кадәр карга баткан килеш, еш-еш сулый һәм ярдәм көтеп, хуҗасына борылып-борылып карый иде. Сәлмән абзый, тәртәгә тотына-тотына, байталның баш ягына чыкты, бәсләнгән танавын учы белән сыпыргалап, аны тынычландырырга, дәртләндерергә тырышты. Ат үз янында кеше булуын сизгәч, өмет белән пошкыргалап куйды, бозланган керфекләре аша мөлдерәп, хуҗасына карады. Гүя ул: «Син миңа юлны күрсәт тә дилбегәне кулыңа ал, ә мин сине ничек тә өеңә кадәр алып кайтырмын!» — дияргә тели иде. Сәлмән абзый атын бик яхшы аңлый, әмма нишләсен, үзе дә чарасыз, үзе дә башкалар ярдәменә мохтаҗ иде шул. Ул чанадан брезентны алды. Йонлачның өстенә ябып куярга теләде, ләкин котырынган җил брезентны шундый көч белән йолыккаларга тотынды ки, байталны чүт кенә аяктан екмады. Озак туктап торырга ярамый иде, тирләгән атның йоннары салкыннан укмашып ката башлады. Сәлмән абзый брезентын җилдән аралап, кире чанага ташлады, үзе Толыбына төренеп, утырды да дүрт аяклы юлдашын алга, билгесезлеккә әйдәде. «Язмыштан узмыш юк! Ходай ни язган — шуны күрербез...» — дигән уйдан тынычлангандай булды, бераздан ул йокыга талды.

Сәлмән абзый кинәт каядыр, түбәнгә таба мәтәлүен сизеп, уянып китте. Ләкин соң иде инде, тәгәрәп төшкәндә ниндидер каты нәрсәгә башы белән бәрелүдән аңын җуйды.

Һушына килгәч, ул үзенең чокыр-ермак төбендә ятуын күрде. Башында бүреге юк, бияләйләре дә каядыр төшеп калган. Үзеннән ерак түгел карга буталган толыбын күреп, Сәлмән абзый җиңел сулап куйды. Толыбының бер җиңен умырып алып, башына киде, югарыга күз төбәп, байталын эзләде. «Ул анда мине көтеп торадыр»,— дип уйлады ул, чокырдан чыгу өчен кар ерып, өскә үрмәли башлады. Әмма үрмәләгән саен кире шуып аска төшә иде. Бу мәлдә ул адәм баласының табигать кодрәте каршында никадәр көчсез икәнен җаны белән тоеп, шомланды. Чокыр өстенә менеп кенә җиттем дигәндә, кырыйдагы каты кар, кубып, үзенең корбанын янә аска бәреп төшерде.

Сәлмән абзый капкынга эләккән җанвар сыман, котылу җаен эзләде. Әле генә ясаган хатасын кабатламас өчен, чокырның икенче башыннан күтәрелеп карарга булды. Кар ерып барганда үзенең бүрегенә килеп төртелде, әмма аны алып тормады, ник дигәндә, толып җиңе иске бүреккә караганда шәбрәк җылыта иде. «Бәлки янәшәдә генә берәр авыл бардыр, ә мин монда тилмерәм»,— ул тагын югарыга үрмәләде. Чокыр-ермак шактый иркен, ләкин аның төбеннән бик иркенләп йөрергә куркыныч иде. Чөнки Сәлмән абзый белә: мондый ерганакларда, калын кар каплаганлыктан, кышын да туңмый торган коелар була. Еш кына алар төрле ерткыч җанварларга капкын булалар иде.

Бу капкыннан котылырга азапланып караулары һичбер нәтиҗә бирмәгәч, Сәлмән абзый чокыр кырына утырып, бераз хәл алырга, салкын кан белән тагын нинди хәрәкәтләр ясарга икәнен уйлап карарга булды. «Һәр адәм баласы кайчан да булса бер үләргә хөкем ителгән. Әмма ләкин үлем белән үлем арасында аерма да бар. Динсез бәндәләр өчен үлем — бетү, юкка чыгу, ә Аллага ышана торган динле кешеләр өчен үлем юкка чыгу түгел, ә бәлки фани дөньядан бакый дөньяга күчү генә ул. Шуңа күрә динле адәмгә яшәү җиңелрәк, ул үлемнән курыкмый... Ә шулай да, табигать биргән гомерне тәмам яшәп бетерми торып үлү — аяныч нәрсә, фаҗига. Бу бәладән ничек тә котылырга кирәк...» — Сәлмән абзый әнә шулай уйланды. Шул вакыт аның күзе чокыр өстендә, җил иркендә утыручы тәбәнәк кенә куакка төште. Бу куак аңа коткаручы фәрештә булып күренде. Ул кулын сузып шуңа таба үрмәләде. «Барыбер чыгам!» — дип пышылдады, өшегән иреннәрен чак-чак кыймылдатып. Әмма сузылып ябышуга, әлеге куак тамыры-ние белән йолкынып, чокыр мәхбүсе белән бергә аска шуышты...

Сулу алган арада ул түш кесәсен капшап карады, акчалары урынында иде. Аның күңелендә тагын өмет чаткысы кабынды. Ул сукыр лампаны сүндермичә үзен көтеп утырган хатынын, балаларын күз алдына китерде, бүген-иртәгә бозаулыйсы сыеры турында уйлап алды. Тәненә көч кереп, кәефе күтәрелеп китте сыман. Шушы көч аны янә урыныннан кузгатты. Моннан алдагы уңышсызлыкларын исәпкә алып, ул хәзер сакланыбрак хәрәкәт итте. «Бу юлы мине алдый алмассың!» — дип сөйләнде ул, кем беләндер бәхәсләшкән кебек. Ул чокырның сөзәгрәк почмагына таба тырмашты. Җилнең арттан булуы да уңайлы иде. Ниһаять, ул чокырдан башын сузып карый алды. «Котылам бит болай булгач!» — дигән уй күңелен җылытып узды. Өстә чак-чак кына эләгеп торган хәлдә, ул карашы белән тирә-юньне айкап алды, комсызланып ирек һавасын сулады, гүя монда һава башка төрле булып, аннан яшәү тәме килә иде. Ярдан ерак түгел үсеп утырган ялгыз имәнгә карап, Сәлмән абзый моның кайсы урын икәнен чамалады. Шайтан чокырына килеп капкан икән ләбаса! Моннан авылга сигез чакрым тирәсе булырга тиеш.

Аны әсир иткән Шайтан чокыры, чыннан да, бик тирән булып, элек-электән төрле куркыныч вакыйгаларга, риваятьләргә бай иде. Имеш, бер төндә шушы чокыр төбеннән ут баганасы чыгып, болытларга

чаклы күтәрелгән. Ә икенче бервакыт давыл чыгып, чокыр янында үскән карт имәнне төбе-тамыры белән йолкып алган да, басу-кырлар өстендә очырып йөрткән. Аннары янә шушында китереп ташлаган, имеш. Бу тирәне кеше адаштыра торган җенле урын, дип сөйлиләр иде картлар.

Сәлмән абзый кар астыннан очлаеп чыгып торган зур гына ташка үрелеп ябышты. Шуңа тартылып, исән аягын чокыр кырыена күтәреп куймакчы булды. Аһ, шулвакыт таш урыныннан кубып, Сәлмән абзыйны янә чокыр эченә бәреп төшерде. Каты бәрелүдән Сәлмән абзый аңын җуйды. Бераздан ушын җыя алды. Аның башы әйләнә, косасы килә иде. Аякланырга теләде — булдыра алмады. Хәле утырып торырлык кына. Ул чокыр төбенә җайлабрак урнашты, өстән явып торган мамык кар, аны салкыннан сакларга теләгәндәй, ап-ак юрган сыра башлады.

Йокылы-уяулы халәттә, аның күз алдыннан кинокадрлар сыман тормыш юлы узды: фронт, окоптан чыгып, һөҗүмгә ташланулар, яраланып, госпитальдә аунау, шатлыклы җиңү көннәре... Аннары тагын күңелсез күренешләр: каланың өскә авам-авам дип торган бертөсле соры-шыксыз йортлары, кулларын күшектереп, бәрәңге сатып торуы, каракүл бүрекле явыз хатын, милиция бүлегендә тинтерәтүләре... Инде әнә ул чанага кырын яткан килеш, авылына кайтып килә. «На-а, малкай!..» — дип әйдәде ул атын һәм түш кесәсендәге бәрәңге сатып алган акчаларын учы белән капшап караганнан соң, аларның күңелле кыштырдавын ишетеп, тынычланды, бераздан инде ул тирән йокыга талды...

Ә күктән кар ишелде дә ишелде, чокыр төбендә толыбына төренеп, йокыга талган Чатан ат караучыны ак юрганына төрә барды. Гүяки табигать үзенең сөекле баласын кар юрганы белән шулай томалап, аны суыктан да, бүреләрдән дә, дөнья мәшәкатьләреннән дә араларга тели иде...

...Иртәнге якта табигать тынычланды, җил басылды, кар явудан тукталды, болытлар үз эшләрен башкарып, каядыр китеп югалдылар. Тирә-юнь күз камаштырырлык аклыкка буялган, һәртөрле эзләр, юллар томаланган, әйтерсең, буран бөтенесен үзенчә тигезләп киткән иде. Пүчинкә авылы кешеләре көрт күмеп киткән өйләреннән мең бәла белән чыгып, ишек алларын көрәргә, мәшәкатьле дөньяга сукмаклар салырга керештеләр. Чатанның кичә шәһәрдән әйләнеп кайтмавы турындагы хәбәр авылда тиз таралды. Идарәдә өч кешедән эзләү төркеме оештырдылар. Өчесе дә тәҗрибәле аучылар, киң табанлы чаңгыларын киеп, көрт салган юлдан калага таба чыгып киттеләр. Шайтан чокырына җиткәч, туктап, тәмәке тарттылар да, тагын кузгалдылар. Ә аларның чаңгы эзләре астында, тирән көрткә күмелеп, инде тәннәре суынып барган Чатан Сәлмән үлем йокысы белән йоклый иде. Очы-кырые булмаган буталчык төшләр кочагында иде ул. Гүяки ул болытлардан да югарырак күтәрелеп, таулар-урманнар, шәһәр, авыллар өстеннән очып бара. Менә ул туган авылы күгендә әйләнә башлады. Тып-тыныч җәйге кояшлы көн икән. Әнә колхоз идарәсе янына халык җыелган. Кызыл бәрхет белән ябылган президиум өстәле артында колхоз рәисе һәм районнан килгән вәкил утыра. Алар ат караучы Чатан Сәлмән белән очрашырга килгәннәр. Сәлмән абзый үзе турында сөйләгәннәрен тыңлый. Барысы да аны күкләргә чөеп мактыйлар, аңа сугышта күрсәткән батырлыклары, колхоздагы тырыш хезмәте өчен рәхмәтләр укыйлар, аны зурлап, Сәлмән иптәш Атнагулов дип атыйлар. Аеруча мәктәп директоры тырыша: өлкән ат караучының ничек итеп нәсел үгезен акылга утыртуын, кырыкмыш тайларны өйрәтүен, тагын әллә ниләрне искә ала. Авылдашлары Сәлмәннең кулын кысалар, тәбрик итәләр. Ә район хәрби комиссариаты вәкиле аның күкрәгенә сугышта тапшырылмый калган орденын таккannan соң, ике битеннән үбеп ала. Сәлмән абзыйның күңелен җылы рәхмәт тойгылары били, ул сөенеченнән туктаусыз елмая...

*1970 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рафаэль Сибат

### ТӘН-ЖАННЫҢ БЕРЛЕГЕ — ИҢ БӨЕК МИЗГЕЛЕҢ

* * *

Тән нәрсә ул?
Җанның әле очасы бар:
Ул — Галәмне,
Галәм аны кочасы бар.

Тән нәрсә ул?
Чиксез булган чиксезлектә...
Бары Җанны
Өйрәтмәгез ипсезлеккә —

Аның әле
Тәнен ташлап очасы бар.
Һәм дөньяны
Өр-яңадан ачасы бар...

### Бисмилла

Куанычлар белән узсын көнем,
Таңнан торып әйтәм: «Бисмилла...»
Бабаларым исме белән җанда
Ходаемның бөек исме лә.

Сәфәрләрем булсын уңышлыдан,
Юлга чыксам, әйтәм: «Бисмилла...»
Әткәм-әнкәм исме белән рәттән
Ходаемның бөек исме лә.

Максатларым чынга ашсын дим дә
Эш башласам, әйтәм: «Бисмилла...»
Сөйгәнемнең исме кебек хисле
Ходаемның бөек исме лә.

Саулыклар һәм озын гомер бирсен,
Кич ятканда әйтәм: «Бисмилла...»
Балаларым исме кебек якын
Ходаемның бөек исме лә.

* * *

Төшкә керә әти, гел дә керә...
Хаста килеш түгел, сау-таза:
Мин тәртипле — разый булып йөри,
Тирән базда ятсам — бау суза...

Төшкә керә әткәй, һаман керә...
Керер инде үзем үлгәнче.
И Ходаем! Төшләрендә — бәхил,
Тегендә дә көлеп килсәче...

* * *

*Әтинең кабер ташына*

«Иң соңгы капканы үтеп,
Керсәң кара туфракка,
Ул дөньяның ишекләре
Ачыла тик бер якка...

Беркемгә дә мәңгелек юк —
Сүнәчәк шәмнәр яна...
Мин кайталмам инде кире,
Килерсез минем янга...»

* * *

Күрсенмә син:
Тегенең дип,
Гомерләре балда үтә.
Балның агу булуы бар —
Бар да үтә, бар да үтә...

Көнләшмә син:
Бу адәм дип,
Инде күпме «ярлар» үпкән.
Һәркем өчен соңгы яр бар —
Бар да үтә, бар да үтә...

Таң калма син:
Бу патшаның

Таҗ-тәхете нурдан икән!
Кара ләхет көтә аны —
Бар да үтә, бар да үтә...

## Милләттәшкә

Аршын-аршын атлап Алып бара,
Юл-тузанда эзе калып бара.
Алып дигәннәре — Халык бара,
Җир-Китапка сүзен салып бара.
Йә, бер сүзен тартып алып кара!
Йә ул сүздән читтә калып кара —
«Син», «мин»нәрдән торган Халык бара:
Сине миннән йолкып алып кара,
Мине синнән тартып алып кара —
Тик бергәлек киләчәккә алып бара!
Бара Халык ара-ара,
Халык бара!
Шул халыктан
Бер адымга калып кара —
Милләтсезлек... арбасына салып бара...
Ышанмасаң —
Маңкортларны алып кара...

* * *

Сакалыннан сыйпап җилнең
Мин бу кырларга килдем.
Башаклары тук дәүләтнең
Халкы тукмы? — дип йөрдем...

Бу кырларда шигырь ята,
Аны бозган чор ята.
Икмәксез заман елата,
Ипи булса — җырлата.

Берәү ашый, берәү ялый...
Теге җырлый, бу елый.
Күрсенеп лә миләр уйлый,
Күрсенеп лә илләр уйлый:
— Күрсидәге ниләр уйлый?
— Күрсидәге ниләр уйлый...

* * *

Атлар төшкән үләнгә...
Чәчәк белән гәпләшәме,
Гүя кергән биләмгә.

Атлар төшкән үләнгә...
Кояшы да баеп бара,
Озынайды күләгә...

Атлар төшкән үләнгә...
Караңгылык күмә көнне,—
Бу көн бүген үлгәнгә...

Атлар киткән үләннән...
Моңсу миңа, бик ямансу —
Чү, йөрәгем, сөйләнмә...

* * *

Күбәләк җил...
Гашыйклардай
Йомшак тисә битемә —
Рәхәтлекне көт кенә:
Сөйгән сыман итенә.

Күбәләк җил —
Әбекәем
Рухы булган Изге Нур.
Яшәүләре, һай, хозур!
Нәни мизгел нинди зур!!

Күбәләк җил!
Тагы да кил...

## Боекканда

Көне буе боек йөрим,
Җаным тулы моңсулык.
Ятып күңел мендәренә
Рух елый сулык-сулык.

Көне буе боек йөрим...
И, бу боегуларны!
Киләм-эчәм, киләм-эчәм —
Җитми кое сулары.

Гүя җанымны сукалап
Узадыр тракторлар.
Чыгармыйм сагышны читкә,
Саргаер кара кырлар.

И, мине бу дөньяларга
Китергән ай-үктәбер.
Шатлыкка манып моңнарны
Ялгыз башым үп лә бер.

Нигә алай? Кем тәкъдире?
Көне буе сагышта...
Сары сагышларда янып
Үлмәм микән бу кышта...

Ниләр насыйп? Язмышыммы??
Тәңрем миңа ни кылган?
Ятып Җаным мендәренә
Рухым елый сулкылдап...

* * *

Нә шатлыгым, сөенечләрем?..
Җанга тулган көенеч-әрем...

Чәчәк диеп тотсам — тигәнәк,
Чәнчә ул Рухка тигәләп.

Ни мәхәббәт, Сөю-Сөелү? —
Авыруга бер чир өелү...

Күңелләрдә зарлы шом-шөбһә,
Чагып торадыр гел шик-шөпшә.

Кемгә зарлан? Беркем аңламас...
Сүзең ишетсә дә — тыңламас...

Сизеп гомер җилдәй узганын,
Һәркем Җирдә уйлый үз гамен.

Бәхет өләшкәндә Хак-Ходай
Кайда йөрдең, Сибат, син болай?!...

* * *

Кереп барам кара төннәремә...
Көннәр миңа никтер иш түгел.
Дәртем сүнде, дәрман-куәт сынды,
Йөргәнгәме бушка көч түгеп?

Кереп барам кара төннәремә...
Вакыт уза... Авыр — өй черек.
Эчеп-эчеп элек исермәдем,
Эчмичә дә хәзер исерек.

Кереп барам кара төннәремә...
Кем соң болгый кара яулыгын?
Яшәп булмый җирдә теләгәнчә,
Яшәү — житкән кадәр саулыгың...

Кереп барам кара төннәремә...
Ник яктыра микән җаннарым?
Үлем дигән Бөек Сер Утында
Дөрләп тәнем яна — аңладым...

Кереп барам кара төннәремә...
Чыгып булмас инде аңардан.
Җан ташлаган бу тән һич терелмәс,
Тәнен ташлап Җанмы яңарган?..

## И Бөек Сер...

Дөньялар бик күпкә катлаулы...
Сукырлык юлында атлаумы?..

Бездән күп акыллы бу агач —
Кислород бүлә ул сулагач.

Амеба бәлки чын галимдер,
Аларда иң бөек фал-диндер...

Куркакмы? Куяннар батырдыр...
Шыксызмы? Еланнар матурдыр...

Үләннәр сөйләшә беләләр,
Чәчәкләр елмаеп көләләр.

Белмибез, калганбыз аңгыра —
Каеннар җырлыйлар яңгырга...

Аллаһы Җаны бар һәркемдә,
Тоемлыйк аны без һәр көндә...

Уй-фикер, Акыл бар һәр җанда —
Идарә итә Рух Җиһанда...

Бөек Сер! Өсле дә аслы син...
...Шул серне, йә аңлат, расла, син?

* * *

Уйламыйм —
Бу дөнья кайгысын
Кискәндер Мәңгелек Кайчысы...

Уйда мин —
Ник килми атлыгып,
Ходайдан Мәңгелек Шатлыгы...

И Кешем!
Өметтә тотсаң да
Мәңгелек Диңгезен,
Тән-Җанның Берлеге —
Иң бөек мизгелең...



**Шагыйрь Мөхәммәт Мирза (ИЛФАК МИРЗА-МӨХӘММӘТ улы ИБРАҺИМОВ) Актаныш районының Чалманарат авылында 1952 елның 3 декабрендә туган. Атаклы Мөхтәр Мутин, Гамил Афзалларны тәрбияләгән Такталачык авылы урта мәктәбендә укыган. Казан мәдәният һәм сәнгать институтының театр режиссерлары әзерләү бүлеген тәмамлаган. 1994 елда «Кәккүк тавышын санадым» исемле шигырьләр җыентыгын Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарды. Актаныштa яши. 1995 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.**

**Соңгы вакытларда язган кыска шигырьләренең бер өлеше белән «Казан утлары» укучыларын таныштырырга телибез.**

**— Теләгеңә ачык юл, Мөхәммәт Мирза! — дибез.**

**Рөстәм МИНГАЛИМ**

# Мөхәммәт Мирза

## НУР ОЧЫНА КУНЫП...

* * *

Керфегем төште кәгазьгә,
киселде язар сүзем:
сулкылдап елап җибәрдем,
яшьләнде — төннең күзе.

* * *

Ага да, ага вакыт —
гүя дәрья-су кебек...
Кеше гомере —
дәрья суда — бер күбек...

* * *

*...О войне?..*
*окопная правда еще не написана...*
*Г. Бакланов.*

Окоп дөреслеген язар өчен
окопларда яту кирәк шул.

Окопларда ятып,
исән калганнар бик сирәк шул...

* * *

Бар да — үтә,
Бар да — китә.
Кала — хәтер.
Кала — кабер.

## Димәк

Күрәчәк йөртә кешене,
җыяр ризыгы йөртә:
качаклар кайта көньяктан,
җылы һәм ризык беткән...

## Әнкәй

Карашыңны тоям һәр тарафта:
агып барган ап-ак болыттан да,
ак күбеккә баткан шомырттан да,
бармак имеп яткан оныктан да...

## Томанда

Талы да юк, яры да юк,
Агыйдел дә юк сыман:
бар җиһанда салкын тынлык,
бар җиһанда ак томан.

* * *

Тулган Ай серле елмая.
«Таныйсыңмы әллә?» — дим:
Төнозын бер керфек какмый
айга баккан бәндә мин.

* * *

Без кабызган утлар янып тора,
без төзегән йортлар балкып тора,

без омтылган оҗмах-тормыш кына
офык артларына качып тора...

* * *

Кайнар хисләремне
салкын карашыңа
манам да алам, манам да алам...
Барыбер — янам...

* * *

Нур очына кунып,
урап кайтсам әгәр
киләчәктән,
сөенерме күңел?
Әллә көенерме —
күрәчәктән?!

* * *

Җир
галәм каршында
имтихан тота —
өлгергәнлеккә.

* * *

Ерак калмады шул инде язга,
изүләре ачык кышкы көннең.
...Һәм, мөлдерәп, очына тамчы төште
күңелемдә тулган боз сөңгенең.

* * *

Күкләр куйса киртә,
күкрәп булмый һич тә.
Кояш байый гына,—
Кояш чыкмый кичтән.

* * *

Һәркемнең
тәнен — Җир,
җанын — Ай
көтәдер...

* * *

Ник баса бу моң мине,
авыраеп баса моң!?

Килә чыгып чабасым,
ярып төннең карасын.

* * *

Белмим
алда тагын ниләр күрәсемне;
беләм —
барсы өчен кыйммәт түләсемне...

* * *

Инемдәге
фәрештәнең
берсе — нәфис,
берсе... нәфес.

* * *

Карама очында ярты Ай,
үләндә таң чыгы ялтырый...
Изелгән җиләкләр өстендә
онытылган кульяулык зар елый...

* * *

Язылaverасы җырлар язылмаган,
табынасы ярлар табылмаган.
Үткәннәрдән гыйбрәт алынмаган,
киләчәккә күпер салынмаган.

* * *

Уң кабагым тарта,
сул кабагым тарта:
әллә шатлык арта,
әллә кайгым — артта?



# УЛ ҺӘР ҖАН ИЯСЕНӘ ГАШЫЙК

Язучы, журналист, тел галиме...

Мондый төрле яктан зыялы шәхесләр безнең татарда бик борынгы заманнардан ук була килгән. Каюм Насыйри шикелле мәгърифәтчеләр заманыннан ук. Каләмдәшебез Илдар Низамов — әнә шушы күркәм шәҗәрәбезне дәвам иттерүчеләрнең берсе. Аны укучылар шигъри телле, хискә бай парчалар, нәсерләр, хикәятләр авторы буларак та, Идел-дәрьяны аркылыга-буйга кичкән талантлы журналист буларак та, сөйләмият дигән яңа фән буенча студентларга гыйлем бирүче галим буларак та яхшы беләләр. Әле шулар өстенә, Илдар Низамов табигатькә, Җиргә үзенчә гашыйк. Бу сыйфаты да аңарга борынгы бабаларыбыздан күчкән булса кирәк. Җиргә, табигатькә булган мәхәббәте аны ял көннәрендә язучыларның Васильеводагы «Яз» дип аталган бакчачылар ширкәтендәге бәләкәй генә, гади генә дачасына әйди. Биредә һәр кадак аның үзе тарафыннан кагылган, һәр карыш җир үзе тарафыннан эшкәртелгән, хәтта сыерчыкояларын да ул үзенчә матурлап ясап куя белә...

Кыскасы, талантны да, тырышлык-уңганлыкны да мул биргән аңа авыл табигате.

Илдар Мәлик улы Низамов Әтнә районының Олы Бәрәзә авылында 1936 елның 3 сентябрендә укытучы гаиләсендә туган. Ә балачак һәм мәктәп еллары шушы районның Ключи-Сап авылында уза. Ул 1951—55 елларда Казан елга техникумында укый, аны тәмамлаганнан соң, Агыйдел елга пароходчылыгында штурман булып эшли. Аннары Илдар дигән егет, Ерак Көнчыгышта солдат хезмәтеннән соң, яңадан шул ук яраткан эшенә кайта. 1960 елларда, әдәби талантын күреп алып, Илдар Низамовны Уфада чыга торган татар гәзите — «Кызыл таң» редакциясенә эшкә чакырып алалар. Шунда эшләү елларында ул Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый.

1968 елда Илдар Низамов Казанга күчеп килә. Биредә аның хезмәте журналистика белән тыгыз бәйләнгән. Ул башта «Социалистик Татарстан» (хәзерге — «Ватаным Татарстан»), аннары Татарстан китап нәшриятында җиң сызганып эшли, иҗат эше белән дә шөгыльләнә, фәнни гыйлемен арттыра.

Илдар Низамов — Татарстан Язучылар һәм Журналистлар берлеге әгъзасы, Казан дәүләт университеты доценты, филология фәннәре докторы ике дистәгә якын әдәби-публицистик һәм фәнни китаплар авторы. Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты.

Сентябрь башында Илдар Мәлик улы Низамовның түгәрәк юбилее. Без аны шушы күркәм бәйрәме белән котлыйбыз, аның киләчәктә дә шулай янып-ялкынланып, иҗади тормыш белән яшәвен телибез һәм укучыларыбызга юбилярның бер шәлкем әдәби парчаларын тәкъдим итәбез.

# Илдар Низамов

# ПАРЧАЛАР

## Башлам: Үзгәрмәс сурәт

Февральнең якты, салкынча иртәсе. Куак һәм агачлар йөнтәс бәстә. Менә якын гына бер агачта үзе күренмәгән кошның быел беренче мәртәбә ачык кына, дәртле генә сызгырып куюы күңелне капыл сискәндереп, уятып, очындырып җибәрде. Кышларның тиздән очланасына, язларның килеп җитәчәгенә беренче хәбәр түгелме соң бу!

Нәкъ шулай! Беләбез! Ел саен кабатлана бу көтелгән вакыйга, ел саен сискәндереп, дулкынландырып ала.

Беренче мәртәбә ишетеп хисләнгән мизгел әле дә хәтердә. Заманында шул хисне парча итеп тә язган идем. Хәзер менә шул парчам хәтердә сүзгә-сүз яңарды.

Уйга да бирелергә сәбәп булды: «яз хәбәре» ел да бер төрле кабатланмый, дулкынлану мизгелләре төрлечә була, димәк, теге парчаны да, яңа хис төсмерләрен өстәп, гомумиләштереп, фаразый хистойгыларны да кушып, зуррак бер әсәр итеп язып булыр иде. Хәсән Сарьян минем беренче парчалар китапчыгымны укыгач, боларның һәркайсы үзе бер хикәя, повесть булмаса да, дигән иде, «әрәм иткәнсең», дигән кебегрәк мәгънә белән «ых-хык» дип, борын тавышы да чыгарып куйган Яде.

Чү, кая таба сукалыйсың?! Син бит парчаңа кул күтәрәсең түгелме! Балаңны үзгәртеп буламыни?!

Минем парча ул мәгълүм бер кешенең яисә бүтән бер җан иясенең мәгълүм бер яшәеш мизгелендә минем аңым, хисемдә чагылып китүе. Үзенә күрә мин генә төшергән фотосурәт ул. Шул ук вакытта очраклы чагылу да түгел, ул — күңел тибрәнүе, башкаларны да дулкынландырыр, аларга да рәхәт йә авыр мизгел булыр дип ышанганга төшерелгән сурәт. Кире кайтарып яисә үзгәртеп кенә рәхәтлекне йә сызлауны арттырып яки киметеп була торган сурәт түгел.

Яратсагыз иде парчаларымны!

## Бураннарың белән кил син...

Шәһәрдә дә авылдагы кебек чын буран кубар икән! Җилнең шомлы сулышы көчәйгән саен, әлерәк кенә өстән аска ишелеп яуган, кара томанны хәтерләткән кар чаршавы болганганнан-болгана бара, аның инде кая таба хәрәкәт итүен дә чамалавы кыен: астан да бөркелә, ян-яктан да сарыла — күзне йомып, битне каплап, башны иеп, көч-хәл белән буранны сөзеп кенә атларга кала. Җитмәсә, юлым да үргә — Болак астыннан университет тавына..;

Ул да булмады, буранның тоташ гүләвеннән озын, ачы сызгыруга охшаган сәер шау аерылып, болай таба якынайганнан-якыная иде. Йөзгә, гәүдәгә көчле дә, үткен дә дулкын бәрелә бара. Тауның теге ягындагы урамнардан бу якка гайрәтле, зәһәр өермә ябырылып килә икән. Ул алыптан качып чапкан яралы аждаһа кебек кая керер тишек тапмыйча

боргалана, бөгәрләнә, әле мәйдан, чатларны иңли, әле ишек алларына бәреп керә, тыкрыкларда адашып сукрана, түбә калайларын дөңгердәтә, агач-куакларны сындыра. Аның бөтен гәүдәсе урамнарны тутырып калтырана, диварларга каты бәрелеп ухылдый, зыңгылдый, колак тондыргыч башка тавышлар чыгара.

Менә өермә тугыз баллы давыл дулкыны кебек безнең турны да каплап, томалап куйды: машиналар җанлы киртәгә төртелгәндәй калтырады, туктап та калдылар, ә адәм балалары ирексездән җиргә чүгәләде, артка чиктеләр, егылып та киткәләделәр. Мин юан юкәгә терәлеп калдым.

Күзем ачканда, өермә дуамалланып-йөгәнсезләнеп сызгыра-сызгыра безнең өстән үтеп тә бара, урам буйлап алга элдертә иде. Ниһаять, һушка килеп, җиңел тын алдык. Тоташ буран өстебездә ыжгыра бирсә дә, «аждаһа»ның зәһәр сулышы безнең яннан ерагая бара иде. Аяк астында җиребез упмаганга, койма, стеналар өстебезгә аумаганга куанып, шул ук вакытта гайрәтле, дәһшәтле бу күренешкә мөкиббән булып, хәтта ихтыярсыз сокланып та әле аның артыннан карап шаккатып торабыз.

Өермә исә шәһәр өстендә һаман гарасат булып «кылана» бирә: әле өскә ташланып, чыбыкларны ачы сызгырта, һаваны кар белән болгата, әле аска ыргылып, йортлар, коймалар арасындагы тыкрыкларга, бушлыкларга кысылып чиный, ыңгыраша, ухылдый.

Миндә дә аннан өркү хисе, аны аңлау, аны хуплау хисенә алышына бара. Ул бит шушы таш капчыктан чыгу юлын эзли! Ошамый аңа биредә, ник килеп кергәненә үкенә, шуңа котырына, шуңа зәхмәтләнә.

Әй яралы өермә, йөрмә син монда көчеңне әрәм итеп, тынчу почмакларда адашып, туры гына элдерт шушы урам буйлап. Алда вокзал мәйданнары, аннары Идел өсләре. Дула, дула да чыгып ычкын дәрья киңлекләренә, басу, кырларыңа. Тот үз кыйблаңны, чык тизрәк иреккә. Хәерле юу-у-ул сиңа-а-а!

## Гыйнвар тамчысы

Кояш бүген башка көннәрдәгедән бер генә минутка артыграк җылыттымы, әллә булачак тамчы үзе язны зарыгып, түземсезләнеп көтә идеме, менә ул суга әверелеп, түбә буйлап тәгәрәп тә китте. Аның артыннан тагын берничәсе иярде.

Тик алар әле кыюсыз-басынкы, хәлсез иде, түбә озын, җитмәсә, салкын җиле дә каршы иде. Шулай итеп, беренче тамчылар түбә читеннән очып та китә алмадылар, бер-берсенә ябышып, шунда кечкенә сөңге булып катып калдылар.

Шундук сөңгегә: «Бу ниткән мәгънәсезлек!» дип сукранып, ачы җил бәрелде; сукрануы сәер сызгыру булып яңгырады, ләкин сөңге бирешмәде, түбәгә ныграк ябышты гына сыман.

Бүтәннәрнең дә аны: «И-и-и мәнсез, кая болай кабаландың, гыйнварда тамчы тамамыни, менә тор инде кыш буе бер мәгънәсезгә асылынып», дип әрләүләре бар.

Ә мин алай хөкем йөртмим. Әйе, анысы, гомере озын, кыен булыр бу тынгысыз тамчыларның — язга чаклы бик озак-ерак бит әле. Шулай да ул мәгънәсез, файдасыз гомер булмас. Күпме җан иясе аны күреп, язны, аның аерылгысыз билгесен — кояшта җемелдәп шыбырдашкан тамчыларны хәтергә төшерерләр, сүрелгән өметләрен яңартып, үстереп җибәрерләр.

Әнә бит гыйнварның иң кыска көнендә, кояшның иң санаулы кадерле минутларында да ул, саф бәллүр хәтирә булып, өметле җемелди...

## Җанда типкән чишмә

Переделкино. Килеп, ике көн дә үтмәде, тик кенә торганда, күңелнең төбендә үк капыл гына бер чишмә тибеп чыга башлады — җанда, тәндә моңарчы үзләрен сиздермәгән-белдермәгән моң күзәнәкләре хәрәкәткә килде: «Хафизаләм иркәм...»

Ни сәбәптән, кайдан бу моң? Нигә нәкъ менә «Хафизаләм иркәм...» нигә бүтән көй түгел?

Бу сорауга җавапны бары бер генә җирдән алып була иде, күрәсең, уйларым шундук туган якларга, өйгә очты. Әйе, әйе, җыр ул — туган иленнең, туган ягыңның, шунда калган бөтен кадерле һәм кадерсез, яхшы һәм яман, күңелле һәм күңелсез нәрсәләрнең бер төене, күзәнәгедер. Иле булган кеше күңелендә моң, җыр йөртми калмас. Тумыштан ил-йортсыз зимагор, гидайларның, кала җилбәзәкләренең генә үз күңелендә ярала торган моң, җырлары булмыйдыр. Илең бар — җырың бар, кайларга гына китеп, кайларда гына төпләнсәң дә, дөньяның кайсы гына почмагында, күпме яшәсәң дә күңелеңдә шул моң, туфракка төшеп үз шартын көтеп яткан орлык кебек, өметле бер күзәнәк булып күңел төпкелендә ята бирә, һәм сихри бер сулыш өрелүгә, ул менә әлегедәй тыелгысыз бер чишмә булып тибеп тә чыга. «Хафизаләм лә иркәм...»

Рәхәт, бик рәхәт күңелеңдә менә шундый ышанычлы күзәнәкмоңыңның барлыгын тоеп яшәве. Ул сиңа киңәшче дә, юатучы, юлдаш та...

## Дога белән үтләтү

«Әнкәмнең догалары» беренче ишеткәндә хәйран игътибарны җәлеп иткән иде. Башкаларга да ошаган, күрәсең, шуннан аны көн аралаш диярлек җырлатырга керештеләр.

Һәм... бздерделәр. Ишетәсе дә килми башлады. Үтләттереп тә җырны «үтереп» була икән.

Бу юлы да радио, телевидение, «халык сорый бит», дигән сылтауга ябышты.

Чыннан да халыкмы сорый?

Авылдан шәһәргә күчеп яисә читкә китеп, татар мохитеннән, җырыннан аерылып яшәп яткан берәүгә бер заман әти, әнисенең яки берәр туганының юбилее җиткәнен исенә төшерәләр дә ул, башкалардан күреп, элек чыккан берәр игълан-котлауны күчереп алып, газетка котлау җибәрә яисә җыр тапшыруларын үтенеп, радиога заявка бирә. Нинди җыр? — дигәндә аңа берәр якыны: «Әнә бит башкалар, «Әнкәмнең догаларын» («Балан», «Миләш», «Минем кадерлеләрем» һ. б.) сорый, дип, колагына аеруча еш чалынган җырны әйтә. Ә тегенең үзенең татар радиосын да тыңлаганы юк, җырга да исе китми, әнисенең нинди җыр яратканын да белми ул, «иске» җыр сорап, адәм хурлыгына калудан куркып, башкалардан калышмаска хәл кыла...

Ә көн саен радио тыңлаучыларның «догалардан» инде гарык булып, үтләп бетүендә аның да, радионың да ни эше бар...

## «Җыртык» ямаучыларга

Вакыт-вакыт «акыллы башлар» җырларның сүзләренә бәйләнеп ала; «мәгънәсезлек», «мантыйксызлык» табалар, янәсе. «Сандугачлар капкада сайрый ди мени, нишләп капкада канатлары булсын ди... Сандугачка кайчан инде пыяла оя тәтесен ди...» янәсе.

Менә нинди хәлгә китереп җиткерде безне үзебезнең мантыйк, психология фәннәре булмау, телебезнең нечкәлекләрен белмәү. Җыр бит ул — газет хәбәре түгел, газетта да гел генә төгәл, туры факт, саннар белән эш ителми, анда да кыек әйтеп туры тидерүләр, төрттерү, көлдерүләр, күчерелмә мәгънәле, образлы гыйбарәләр була.

Ә җыр ул — хис нурларыннан үрелә, ә хис ул акылның турыдан-туры чагылышы түгел, анда хыял зәңгәр күкләрдә очып йөри, диңгез төпләренә төшеп йөзеп китә, сандугач булып, пыяла ояларга кереп кешечә «сайрый» ала, эч серләрен синең белән, минем белән уртаклаша ала. Хискә бернинди чик, киртә юк аңа.

Җырда сандугач ул — туган як үзе, туган йорт, анда калган сөекле яр, чишмә челтерәве, агач шаулавы, чык бөртекләренең җемелдәве. Шуңа күрә дә ул, йортына әйләнеп кайткач, тәрәзә йөзлекләренә, капка такталарына сандугачның үзен, талпынып кагынган канатларын сурәт итеп ясап куя...

Ярар, җитәр, болай да көн кебек ачык хакыйкатьне тәкърарлап, вакыт исраф иткәнче, барыбер бәйләнәчәк «акыллы башларга» тагын берничә «җыртык» күрсәтик тә туктыйк:

Сандугач кунган капкага,
Башын салган тактага...

Сандугачлар басуда,
Басуда — су ташуда...

Сандугачлар килеп кунды
Күлмәгем путасына...

Сөенегез, «акыллы башлар»! Чыннан да, җырның да «җыртыгы» бар икән бит, ямагыз әле шуларны, югыйсә, эшегез беткән бит!

## Бар шундый бер җыр

Көндәлек хәрәкәтне мин иртүк торып урамда йөреп керүдән башлыйм. Кәеф нинди булуга, урамда көннең нинди булуына карамастан чыгам. Киресенчә, күп вакыт кәеф көннең иртән миңа нинди булып күренүенә карап, йә көр, йә сүлпән, йә битараф, йә тагын бүтәнчә башланып китә.

Бүген менә һич көтмәгәндә-уйламаганда миңа яз башлануын сиздергән сәер бер хәбәр килеп җиткәндәй тоелды. Юк, күзгә күренгән, колакка бәрелгән яки тән-гәүдә тоемлаган берәр табигать үзгәрүе рәвешендә дә түгел иде ул хәбәр. Нечкә генә бер сиземләү язның якынаюы, алдагы көннәрдә, боерган булса, кәеф тә, сәламәтлек тә яхшы якка гына үзгәрер дигән өмет хисе рәвешендә булып, шул илһамландырып, канатландырып җибәрде.

Шундый кәеф белән өйгә кереп, вакытны әрәм итмичә, эшкә дә утырдым. Хәтта, бирелеп китеп, көн саен шушы вакытта тыңларга күнеккән радионы кабызырга оныта язганмын. Кабызып җибәрсәм, җыр...

«Сине миңа язлар алып килде»...

Ни бу? Ничек болай? Кем минем күңел тибрәнүен тоеп, нәкъ шуңа тәңгәл килгән җыр-моң табып юллаган? Бу нинди могҗиза! Алай дисәң, нәкъ тә мин тойган мизгелне нәкъ минем кебек тойган тагын бүтән булу мөмкинме?! Аннары, бу бит җыр-моң, мөгаен, бүген түгел, ә алданрак әзерләнгәндер. Гомумән, монда мине уйлау, мине күз алдында тоту ихтималы булмагандыр.

Димәк ки, бардыр бу дөньяда шундый җырлар, кайсыдыр ки алар мине беләләр, мине күрәләр, хәтерлиләр, аларның дулкыннары минем

күңел дулкыннарына туры килә, һәм алар нәкъ миңа кирәкле мизгелне тоеп килеп тә җитәләр.

Бар андый җырлар. Берәү генә дә түгелдер әле.

## Шаярта

Хатыным өйгә кереп: «Алма бакчасында бытбылдык тавышы ишетелде; кайдан килеп чыккан ул?» — диде. Чыннан да, бытбылдыкның авыл эченә үк килеп чыгуы сәер иде. Шулай да мин бөтенләй үк шаккатып калмадым. Дөнья булгач,ниләр булмас! Иртәнге якта үзем дә сәер бер күренешкә юлыккан идем ләбаса. Өй түбәсе өстендә генә ап-ачык тургай тавышын ишетеп, лапастан атылып чыксам, өй өстендә берниндә тургай да, тавышы да юк иде.

Аптырап, нәүмизләнеп торганда, бакча рәшәткәсе буеннан «йөзепйөзеп» очып киткән ике тургайны күреп калдым. Кайтып барышларыдыр. Андый чакта, күрәсең, алар рәшәткәгә басып та сайрый беләләрдер.

Әле менә бытбылдык турында да шулай уйлап куйдым.

Уйлам куйдым куюын, тик шөбһә китмәде: тургай кайтса да бытбылдык әле бу вакытта кайтмый бугай. Нинди аптыраш соң бу?!

Икенче көнне иртән лапаста маташканда, бытбылдык тавышын нәкъ түбә өстендә ишетеп, янә ишек алдына атылып чыктым.

Ни күрәм, юкәдә очынып-очынып, кагынып-кагынып сайраган сыерчык тач та менә бытбылдык тавышы чыгара икән! Шунда гына сыерчыкның төрле кошлар төсле сайрый белүе искә төшеп, үземә дә кызык, көлке булып китте.

Ай да шук, ай да шаян «артист» икәнсең бит син, сыерчык!

## Без — җан ияләре

Кояш җылытып ук җибәрде. Түбәдән тамчы тама. Изрәтә. Гамьсезлек баскан. Йокымсырап урамнан атлыйсың да атлыйсың...

Бер маэмайга килеп терәлә язгач кына, күзне ачып җибәрдем. Ә ул ике йорт арасында тротуарның нәкъ уртасына килеп баскан да кымшанмый да. Юк, аптырап яисә теләнеп тормый, ә «өстемә бассагыз да китмим», дип махсус үҗәтләнеп тора. Карашы да катгый, нидер таләп итә.

Бу тиранә беләм кебек. Этләрен дә. Бар үткенчеләре, бар теләнчеләре дигәндәй. Бу — андыйлардан түгел. Моның үзенә бер нияте — нидер сорый, юк, таләп итә. Нәрсә кирәк соң аңа?

Чү, төшенә башладым түгелме: ул бит тротуарга шлагбаум кебек аркылы баскан, ул бит шушы төштән үтмәскә куша!

Ярар, синенчә булсын; ырылдарга да күп сорамыйсың, ахры, дип, мин тротуардан төшеп, юлымны читтәнрәк дәвам иттердем. Этем, минем арттан килүчеләрне дә көтеп, тыныч кына басып калды.

Йа дөнья! Янә җай гына атлап, изри башлап, урам почмагына гына житүем булды, артта кинәт авыр дөңгердәп гөрселдәгән тавышка борылып карасам, хәйраннарга шаккаттым: агач ботакларын, түбә челтәрләрен җимереп-сындырып, түбәдән бозлы-сөңгеле кар тавы ишелеп төшеп, бөтен тирә-юньне басып куйган иде...

Йөгереп баруга, эчкә шундук җылы да керде — коткаручым ишек алды буйлап элдертә иде...

Икеме-өчме көн үткәч, газетта бер кешенең башка бер урамда башына түбәдән боз сөңге төшеп, һәлак булуын яздылар...

## Горурлык

Кышкы салкыннар иде, подвал баскычы астында ят бер кыргый мәче балалады. Баласы терчә иде: баскыч астыннан өскә йөгерә дә чыга, йөгерә дә чыга. Аны саклап, әнкәсе дә кеше күзенә күренергә мәҗбүр. Өстәвенә, баласы үскән саен, аңарга үз сөте генә җитмәсен дә, квартир хуҗаларының үткән-сүткәндә ишек төбенә куйган тәм-томыннан баш тартуның мәгънәсезлек икәнен дә төшенде, күрәсең. Кыскасы, ике-өч ай эчендә мәчебез тәмам элекке — «өй мәчесе» хәленә кайта язган иде инде.

Тик, тәмам матураеп җиткәч кенә, баласы суга төшкәндәй юк та булды: әллә хуҗа табылдымы, әллә кыргый мәчеләрдә баланы вакыты җиткәч «үз мохитенә» кайтару гадәте бар идеме...

Әнкә мәче үзе дә кинәт үзгәрде: подъездда күренмәс булды. Чүп савыты тирәсендә чагылып киткәндә дә элек үзен, баласын ашатканнарга да исе китми, койрык болгап, ялагайланып аларга якын килми, сырпаланмый, ара саклый иде. Кыяфәт, караш та горурдан. Ул гүя: «Бала хакына гына сезнең алда сырпаланырга, мияуларга мәҗбүр идем, анысы өчен рәхмәт, ә болай без андыйлардан түгел...» дия кебек иде.

## Станса чыпчыклары

Станса, вокзалларда тормыш икенче. Кыяфәтләр, холык-фигыльләр үзгәрә. Кешеләрнеке генә түгел, кош-кортныкы да...

Ни тыйнак песнәкләр дә, кеше арасында чуалып, азык теләнеп, әрсезләнеп беткән. Көнбагыш бөртеген кулдан ук алмасалар да платформа култыкчасыннан, эскәмиядән янында ук килеп чукып алып китәләр. Хәрәкәтләре әрсез, нәзакәтсез. Урмандагы, бакчадагы кебек бик чиста да түгел үзләре.

Болары әле түзәрлек икән, ә менә чыпчыклар... Әнә бер көтүе өермәдәй пыр тузып килеп төште дә песнәккә дип сибелгән җимгә ташланды, чыр-чу килеп, йон-каурыйларына кадәр йолкып-тузгытып, сугышаталаша бөртекләрне хап-хап китерделәр дә, тузан күтәреп, кубып та киттеләр. Тычкан төсе кебек гайрәт чигергеч төс, тырпайган, пычрак йон, илтифатсыз, комсыз караш, сугыш чукмарына хас кыяфәт — менә станца чыпчыгының сурәте. Сагынырсың авыл чыпчыгын! Нишләтми сезне, и-и җан ияләре, шәһәр, станцалар...

Ә бит бирешмәгәннәрне алар да буйсындыра алмый — әнә песнәкләр җимгә комкүзләнеп ябырылмый, берәмләп кенә очып килеп, бөртекләп кенә алып китәләр дә читтә ботакка кунып кына ашап алалар; иптәшләрен дә дәшәләр, үз нәүбәте җиткәч кенә кабат киләләр. Җимне ярып, тамак ялгап алгач, ботакка сөртеп, томшыкны чистартып куялар...

Бөгелмәгәннәрне станса да бөгә алмый...

## «Әрсез»

Бервакыт әни сөйләгән иде. Бик каты чирләп, түшәктә үк ята икән; күз ачып баш күтәрерлек тә хәле юк. Әмма үзе борчылып уйлап ята: каз бәпкәләренә су салынмаган, ә көн бик бөркү...

Шулай уйласа да, хәле — хәл, кузгала алмый. Менә бервакыт сәер тавышка айнып киткәндәй була. Тышкы яктан ишек төбендә үк каз бәпкәләренең берсе бик ачыргаланып, сузып-сузып пипелди бит. Нәрсә булган, шул чаклы шарран ярмаса — тәпие ярыкка кысылганмы, күсефәләп азапламыймы?..

Әни мондый дәшүгә чыдый алмый, ничек итсә итә, караватыннан төшеп, ишекне ача.

«Менә тамаша,—дип сөйләде ул,—бусагага ук менеп баскан бер бәпкә, мине күргәч сөенеченнән үк алпан-тилпән таптанып алды да менә болай итә башламасынмы (әни, муенын өскә сузып, каз су йотып җибәргән кебек итеп күрсәтте). Ничек итсә итте, суга йотыкканнарын тәки белдертте бит, бәгырькәем».

Әни кармаланып-мүкәләп булса да чыгып караса, савытлары копкоры, тәмам әлсерәп бетеп, томшыкларын ук ачканнар; карашлары томанлана башлаган, чак кына җан тәслим кылмаганнар...

Шулай итеп, теге «әрсез» коткарып калган бит туганнарын...

## Путевканы кемгә бирәләр?

Безнең подъездда да берәр мәче булмый торганы юк. Тик алар алмашынып тора. Быел гына менә өченчесе күренде. Моңарчы кышын икәү алышынган иде инде. Котмәгәндә пәйда булган кебек котмәгәндә юкка да чыкканнар иде.

Озак көттермәде, менә — яңасы. Монысы да шыксыз ябык, төссез. Күзләр кыргыйлана башлаган. Үзе куркуданмы, ачлыктанмы бөтен тәне белән калтырый. Шулай да чүплек мәчеләре кебек тәмам кыргыйланып та бетмәгән әле. Үзенә игътибарны, шәфкать-теләктәшлекне тоеп, карашында, таларга әзер тору белән бергә, үтенү-ялвару да калкып чыкты; сырпалану гадәтен дә бөтенләй онытып бетермәгән, ахрысы, карлыккан, әрсез тавышында да гозер кебек нәрсәкәй төсмерләнде.

Шуңа күрәдер инде күрше кызы түзмәде, баскыч читенә сөяк-санак чыгарып салды. Мәчебез, комсыз мырылдап, аңа ташланды...

Тегеләре дә башта тәмам бетешеп, калтырап кергәннәр иде бит, азыкка шулай комсызланып, ачкүзләнеп ташланалар, әләктереп алгач, як-якка ачулы карап, хәтәр мыраулыйлар иде. Җылыда яткач, үткәнсүткәннән капкаларга да әләккәләгәч, алар акрынлап «адәм» рәтенә кергәннәр иде бит...

Туктале, җылыда тернәкләнеп, хәл җыя башлагач, төс-кыяфәт кергәч кенә кая югалдылар икән алар, берсе югала да, аның урынына бетерешкән икенчесе килеп төшә. Менә яңасы...

Әллә «иректә», ягъни чүплектә көн күргән мәчеләрнең берәр оешмасы булып, аларның «профсоюзлары» бармы, шул аларның бик йончыганнарын, чирләгән яисә тәмам рәттән чыкканнарына шулай подъездларга кереп «ял итеп» алырга рөхсәт бирәме? Үзенә күрә бер профилактикага.

Ә бит аларда путевка бүлгәндә гаделлек бар кебек: нәкъ кирәгенә бирәләр. Чиртсәң кан чыгарлык, капкорсаклы мәчеләр күренми бит!

## Бармак һәм кармак

Суга ыргытыйм дигәндә, кармак ялгыш бармакка кадалды. Кылчыклы очы иткә кереп үк батты. Тартып карадым — коточкыч авырту; чәчрәп кан чыкты...

Ай-яй хәтәр хәл икән! Җиңел генә тартып чыгарырмын димә. Куркудан җанны хәвефле шом, аңны ничаралык томалый бара. Бер ялгызым. Кешеләргә ерак. Нишләргә?!

Мондый чакта ничек тә куркуның якасыннан алмыйча, берәр тәвәккәллеккә ябышмыйча булмый, күрәсең. Ярый пәкенең очы үткен иде, ярый иренне тешләп бармак тиресен ите-ние белән ярып җибәрдем дә күзне дә чытырдатып кысып, кармакны йолкып та алдым.

Бөтен елга буен аптыратып, үкереп-сүгенеп ташлаганмын — төкер! Күздән яшь атылып чыккан — төкер! Ике кул беләктән кып-кызыл кан —

төкер! Аның каруы кармак бармактан... әй лә, бармак кармактан азат! Аның каруы җаннан шом, аңнан ничаралык йолкып ташланган — рәхә-ә-әт!

Шулай да аңларсың балык хәлләрен...

Әй кеше, кармак, капкын, элмәк, тозак, алдавычлар ясама димим, без дә җан иясе, безгә дә яшәргә кирәк. Тик берүк үз алдавычларыңа да, бүтәннәр кармак, алдавычларына да эләгә күрмә. Алар мәрхәмәтсез, алар кансыз.

Үз тәнебездә, үз җаныбызда тойдык...

## Хәйләкәр билчән

Бакча җиләгенең кыл үзәгеннән билчән төртеп чыккан. Чәнечкеле өч-дүрт яфрагын ни арададыр җәеп җибәреп, җиләк яфракларын каплый да башлаган. Аһ явыз, аһ комсыз, менә мин сине хәзер!

Тик ыргылуым ташка күтәрелгән кылыч кебегрәк булып калды... Нишләтергә соң бу хәйләкәр явызны? Җиләкнең нәкъ уртасыннан тишеп чыккан бит, төбеннән умырып булмый, җиләк тә йолкыныр, тамырына чабып кара, җиләккә дә һәлакәт, яфракларын берәм-берәм умырып ташласаң гына инде. Юу-у-ук! Бер-ике көннән үк тагын да әрсезләнеп бермә-бер күбрәк, чәнечкелерәк яфрак бәреп чыгачак, җиләкнең җелеген суырып бетерәчәк. Нишләргә?

Кертә күрмә эчеңә, үзәгеңә чит-ят фикри орлык, үсентеләрне; якын җибәрә күрмә гаиләңә, нәсел, ыруыңа ят-дошмани иманлы затларны — үрчегәнен, үзәгеңне корытканын сизми дә каласың, сизгәндә инде соң була...

## Танырсыз әле

Таныш бер гаилә белән буйурманда гөмбә барлап йөрибез. Соргылт бер гөмбәгә тап булдык. Юан, итләч тәпиле, батынкы эшләпәле. Элек тә очрый иде. Озак саклана, корт басмый үзен. Әмма бездә аны җыймыйлар. Минем дә сынап караган юк.

Танышның хатыны аны диккать белән карады, чистартты, тәмләп кенә иснәде. Бу — белгеч. «Свинушканың бер төре бугай, исе саф, тәмле», диде. Ул да кистереп кенә әйтмәгәч, без аларга тимәскә булдык.

Моны ишеткәч, танышның алты яшьлек шук малае янә очраган бер гөмбәгә «у-у-у поганый!» дип, тибеп җибәрмәкче иде дә, әнисе тыеп калды: «Тимә, балакай, без белмәгәч тә, бәлки ул юньле гөмбәдер, кошларга, җәнлекләргә кирәктер».

И-и-и акыллы хатын, мәрхәмәтле ана! Чыннан да, танымау, ашарга яраклымы-юкмы икәнен белмәү әле аны тибәрергә, гайбәтен сатарга, начар сүз әйтергә димәгән.

Танымаганнар, танылмаганнар күпме әле бу дөньяда, барыбызга да тибә башласалар!

## Үзгәреш

Көзге елга. Ярына килеп басуга, беренче тәэсир шул ки: җәйгесеннән нык аерыла бит. Ярлар шул ук, суы шул ук, ә менә аерма барыбер сизелә. Хәтта моңа борчылып, уйланырга мәҗбүрсең: нидән гыйбарәт соң бу аерма!?

Ярлар шул — шулын, әмма шул да түгел: агачлары таныш, куаклар да шулар, ә менә аларны бәйләп-кушып торган, серле бер тынлык, күләгәлек биреп торган үлән, чәчәкләр юк; шулардан төшкән сурәт-

сурәт күләгәләр дә булмагач, су өсте дә шәрә, үтә ачык булып күренә. Суның үзендә дә камыштыр, коймак-коймак төнбоектыр, аларның калфак-калфак ак, сары чәчәкләредер — берсе дә юк.

Аның каруы, су өсте кипкән яфраклардан чоп-чуар иде. Чуарлык аларның сап-сары, коңгырт-сары, коңгырт-яшел, хәтта кап-кара төсләреннән генә түгел, ә тал, шомыртныкы, каен, миләшнеке рәвешендә булудан да иде; чуарлык янә аларның төрлечә хәрәкәтләнүеннән дә: бөтерелүләреннән, тегендә-монда ыргылып бәрешү-төртелүләреннән, шул ук вакытта барысының да бердәй кабалануларыннан иде.

Төп аерма нәкъ менә шушында да бугай: җәйге елга үзенең агышына игътибар итми кебек иде, җай гына, агарга тиеш булганга гына, балыкларны, суүсемнәрне, яр буеннан асылынган куакларны җанландырыр, җилләтер, хәрәкәтләндерер өчен генә агадыр сыман иде.

Ә бүген ул агуны үзенең төп эше дип саный сыман, бүген ул менә бу коры яфракларны монда туңып калмасыннар өчен тизрәк алып китәргә ашыга. Ә тегеләре тиздән кыш җитәсен, су өстенең туңып хәрәкәтсез каласын чамаламыйлар, кечкенә чоңгылларга кереп бөтереләләр, берберсенә бәрелеп, уйнаклашалар, агымга каршы ыргылып маташалар. Агым исә аларны куалый, ашыктыра, ашыктыра...

Ниһаять, көзге елганың җәйгесеннән аермасы безнең аңга да барып житте: көзге елга хушлашу, бушану билгесе икән. Ә без җәйге елганы гына күзәтеп, аның шул хозур, купшы мизгелләрендә генә тәм алып, елга гел шулай, күңелле халәттә рәхәт яши дип уйлыйбыз тагы...

Көзен дә елгага күз салып алу кирәк икән...

## Тыелырсың

Адәм баласының нәфесе ел әйләнәсенә тыелгысыз. Яздан башлап бөтен җәй буена басу, урманында, су буйларында күпме йөрелгән; җиләк-җимешеннән, үлән-тамырыннан, балык-гөмбәсеннән дисеңме, күпме авыз ителгән — табигать бичара күпме тапталган, таланган, җәберләнгән.

Инде менә кара көз җитеп, һавалар тәмам бозылып, юллар өзлегеп беткәч, табигатькә аз гына тынычланып, төнәреп алырга да бик вакыт кана, әмма кеше дигәнең, аеруча каланың тынчу һавасында изаланып, шуннан ничек кенә ычкынырга дип зар-интизар булып яткан бәндәләре моны уйламый шул, аның күзенә, бәйдән ычкынган маэмайныкы кебек ак-кара күренмидер...

Ноябрь башы. Мин дә киттем бит шулай су буена кармак тотып. Июнь башы диярсең.

Яр буйлары соры-төссез, күз салырлык берни юк; суы да кара чырайлы, сукранып-сыкранып кына ага сыман. Кояш иренеп, сүрән генә күтәрелә башлауга, салкын көчәеп китте, үлән-кыякларны ап-ак йөнтәс кырау басты. Өстәвенә, кискен үтәли җил тәнне калтырата. Үч иткән кебек кармакны көйләгәндә җебе уралып-буталып китте дә шуны сүтеп азапланганда, бармаклар башта кызарып, аннан зәңгәрләнеп бетте, бөтенләй тыңламас хәлгә килде. Бөршәеп каткан бармаклар суалчанны да килдекитте генә каптырды.

Шундый кулның кармак сабын тотып торырлык хәле буламы инде, ирексездән ярга куймакчы идем, туң ярдан шуып суга төшә башлады, аны эләктерәм дип үзем чак кына яр астына китми калдым. Йөрәкләр жу итеп китте...

Нәкъ менә шул мизгелдә күз ачылып киткәндәй булды: ычкын моннан тизрәк, теләми бит табигать болай йөрүеңне, синнән котылырга тели; үҗәтләнеп ятсаң, тагын да кырысланыр йә... Калкавыч та чиртү түгел, кымшанмады да, ризасыз чырайлы дулкыннар гына аны тибәрделәр, тибәрделәр. Аңлашыла-а-а! Җый җәһәтрәк кармагыңны...

Басырсың алай тиз генә комсызлыкны — кайтышлый урманга кереп чыгарга булдым: балык шулпасы тәтемәде, бәлки гөмбә ашыннан сыйланырга язгандыр. Баллы гөмбә чыгу ихтималы бар иде бит — башта суытты, аннан бер-ике көн җылы торды. Әнә-әнә ялганчы гөмбә кырадан җемелдәп утыра лабаса, нигә чыны да булмас икән?

Шулай каударланып кереп киттем урман эченә үк. Алны-артны карамый ачкүзләнеп чабам гына! Карашым һәр коры яфракны, ботакны бораулый гына: менә очрый, менә күренә, хет бер гөмбә сыңары булса да очрарга тиеш бит бу кадәр чабуга!

Шунда кинәт кенә нидер сизенеп, кылт туктап калдым — мин бит инде кайтыр юлга якынаерга тиеш идем. Ә каршыда да, ян-якта да ят бер урман. Күк йөзен тоныклык эңгер-меңгер баскан. Күз карашы әйләнәдә ник бер таныш нәрсә булсын.

Җанны салкын бер шом урый башлады. Аны куарга теләп, янә алга ыргылдым, бик ымсынып берәр таныш сукмак, агачларны табарга тырыштым. Юк, урманның ятлыгы көчәя генә төште. Бу урманны гомумән яхшы белгәнгә «адашу» дигән шик-шөбһәне моңарчы башка да китергән булмады. Әле дә, күңел инде шом белән тәмам тулса да, һич тә «адаштым» дип таныйсы килми иде.

Тик, телисеңме-теләмисеңме, мин чынлап торып адашкан идем: күзләр кая төртелергә белмичә, бөтенләй югалып, тегеләй-болай йөгереште, йөрәк чынлап торып куркып сулкылдады, тез буыннары салкын бер калтыраудан хәлсезләнгән. Нишләргә? Кай якка ташланып карарга? Гомер бакый таныш, өч агачлы урманда адаш инде, адәм көлкесе.

Юу-у-ук, адашу түгел, сихер бу, зәхмәт, ниндидер каргыш бу, беләсең килсә! Җәза бу! Табигать мине кисәтә, өркетә бит! Тагын да катырак җәзасын китереп салмас дип кем әйтер. Ник тарыдым мин бу бәлагә!

Чыннан да, бер генә акыллы җан иясе дә юк бит бу минутта урманда — бер җиләк, бер гөмбә, бер кош-корт, җәнлек-җанвар юк бит. Хәтта бүре-фәлән, хәтта браконьер-җанкыяр сыңары да юк бит. Барысы да мәнле — белә табигатькә ял-тынычлык кирәк икәнен, бер мин — аңгыра!

Кичер мине, табигатем, табам мин юлны, хәзер үк китәм мин синең яныңнан...

## Очлам

Парча ул әби төенчегендәге чикләвектер, янчыктагы көмеш тәңкәдер. Һәр чикләвек, һәр тәңкә ялгызы да тәмле, кадерле. Аның тәмен, ләззәтен тоясың. Шул ук вакытта ул дәвамлы ләззәт — икенчесен, өченчесен телисең, алары тагын да туграк, тәмлерәк булыр дип өмет итәсең...

Әби чикләвек төенчеген беркайчан да төбенә чаклы бушатып бетермәс иде, «тәмле әйбер күп булмый, аны бөртекләп җыялар», дип әз-әзләп кенә өләшер иде.

Парча «җыя» торган язучы да, акыллы хатын-кыз кебек, бөтен байлыгын, серен берьюлы төбенә чаклы селкеп бетермәс. Үзенә өмет баглаган укучысына ул барыбер ни дә булса саклар, эзләнүләрен дә туктатмас, туграк, тәмлерәк «чикләвекләрен» җыя торыр, чистартып, киптереп, берәм-берәм бирә торыр.

Укучы буларак миңа күп кенә әдибебез, булган «чикләвекләрен» биреп бетермичә, китеп барганнардыр кебек тоела. Иске китапларны, архив кәгазьләрен актарып укыганда, истәлекләр барлаганда, мин шуларга юлыгырмын дип ымсынам, өмет итәм. Мин аларны Тукайдан, Исхакыйдан көтәм, сугыштан кайта алмаган язучыларыбыздан көтәм, арабыздан иртә китеп барган Фаил Шәфигуллин, Хәсән Сарьян, Мөхәммәт Мәһдиевләрдән көтәм...

Җыям әле парчаларны, селкеп бетермәдем әле төенчегемне; исән булсак, очрашырбыз әле...

# ХАЛЫК ИҖАТЫ — ҮЛЕМСЕЗ

Укучыларга тәкъдим ителә торган «Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе» дигән әкият 1899 елда Казанда аерым китап булып чыккан. Басмага әзерләүченең исеме билгеле түгел, китапның титул битендә: «Басма улынмыштыр Казанда Чирков хатыны варисларының табгыханәсендә (*типографиясендә.*— Л. Җ.) 1899 елда»,— дигән мәгълүмат кына бар. Әмма аның шул чор мәгърифәтчеләренең тырышлыгы белән дөнья күрүенә шикләнмәскә мөмкин.

Эчтәлеге бик мавыктыргыч һәм күләмле без белгән мәшһүр «Ак бүре» әкияте белән бердәй булган бу тылсымлы әсәр XX гасыр башында һәм аннан соңгы дәверләрдә нәшер ителгән күпсанлы фольклор җыентыкларының берсендә дә күренми, ягъни ул бер мәртәбә басылып чыккан да онытылган.

Бу әкияттә халкыбызның башка әкиятләре буенча таныш сюжетлар янәшәлек итсәләр дә, кешенең гөмбәгә әверелеп максатка ирешүе белән тыгыз бәйләнгән үзәк сюжет моңарчы без белгән әкиятләрдә очрамый. Шуны истә тотып, без ошбу «Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе» дигән әкиятне укучыларның киң даирәсенә тәкъдим итәргә булдык. Текстны гарәп язуыннан хәзерге графикага Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенең фәнни хезмәткәре Әдибә Сабирова күчерде.

Әкиятне матбугатка әзерләгәндә, беренче мәртәбә китап рәвешендә басылып чыккан замандагы рухны саклау ниятеннән, аның телен һәм стилен мөмкин кадәр оригиналдагыча калдырырга тырыштык. Мәсәлән: берлән (белән), дәю (див), егълау (елау), илә (белән), кеби (кебек), максуд (максат) һ. б. сүзләр, әдәбиятыбыз классикларының әсәрләрендә дә еш очраганлыктан, һәркемгә җиңел аңлашыла. Шуңа күрә, әлеге сүзләрне иске язылышында калдырдык. Аңлавы авыррак булган гарәп-фарсы алынмалары да шул көенчә калды, әмма һәр урында җәя эчендә аларның мәгънәсе күрсәтелеп барылды. Димәк, әкиятнең лексикасына бер үзгәреш тә кертелмәде дигән сүз. Бары тик, еш очраганлыктан, текстны артык чуарламау максатыннан, берничә очракта гына фонетик үзгәртү ясалды. Әйтик, төшем килешенең иске варианты яңача бирелде: кызыны — кызын, нәрсәләренә — нәрсәләрне. Бу хәл тартым кушымчаларына да кагыла: баламыз — балабыз, балаңыз — балагыз, хәлемез — хәлебез, хәлеңез — хәлегез. Текстта янә шуңа охшаш төзәтү кертелгән тагын берничә сүз очрар: килеңез — килегез, һәркаюсы — һәркайсы һ. б.

Инде, әйдәгез, безнең өчен өр-яңа булган борынгы әкият белән танышыйк.

Ленар ҖАМАЛЕТДИН,[1]
филология фәннәре кандидаты.

---

[1] Ленар ҖАМАЛЕТДИН *(1935) — фольклорчы галим, татар халык әкиятләренең дистәгә якын җыентыгын төзеп бастыручы, халык авыз иҗатына багышланган күпсанлы мәкаләләр авторы. Ул — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

# БАҺАДИРШАҺ ВӘ ГӨМБӘ ХИКӘЯСЕ

Әүвәл заманда бер мәмләкәттә бер бик бай вә олуг падишаһ бар иде. Ул падишаһның Гөлбикә исемле бер генә кызы бар иде. Ир баласы һич юк иде.

Падишаһ үзеннән соң үз урынына падишаһ булырга угылы булмавына бик хафаланыр иде. Падишаһ бик күп нәзерләр әйтте, суфи вә дәрвишләргә бик күп догалар кыйлдырды. Үзе дә Ходай тәгаләдән, бик ихлас белән дога кыйлып, бер углан сорады. Ходай тәгалә падишаһның догасын кабул кыйлды: бер заман падишаһның хатыны дөньяга бер ир бала китерде. Падишаһ бик сөенде, Ходай тәгаләгә бик шөкерләр кыйлды, барча нәзерләрен әда кыйлды (үтәде.— Л. Җ.)[1], бик күп фәкыйрь-фокарага ингам ихсан кыйлды (яхшы нигъмәтләр бирде.) Падишаһ бик күп халык зыяфәт кыйлып (чакырып), мәҗлес ясады. Шаһзадәгә Баһадиршаһ дәю (дип) исем куйдылар.

Падишаһның сарайлары бик зур вә солтанәт иде. Сарайларының артында бер зур бакчасы бар иде. Бакча артында бер зур агым су да бар иде.

Бер заман җәйнең бик матур кояшлы көне иде. Падишаһның кызы Гөлбикә хезмәтче кызлар илә уйнашып-көлешеп йөргәндә:

— Һай, бик кәефем китте, эчем поша башлады,— диде.

Хезмәтче кызлар:

— Безнең дә әллә нишләп эчебез поша башлады, әллә нәрсәдән курыккан шикелле булабыз,— диделәр.

Падишаһ кызы, бераз кәефебез килмәс микән вә күңелебез ачылмас микән дип, хезмәтче кызларга бакчага аш әзерләргә кушты.

Бәс, хезмәтче кызлар су буенда бакчаның күшәгенә (аулак урынына, беседкасына) бик ләззәтле тәгамнәр әзерләделәр. Уенчы кызлар мөхкәмә (таза, нык) күшәк янына килеп төрле уеннар уйный башладылар. Падишаһның кызы мәҗлескә утырды.

Бер заман, кәеф берлә хозур кыйлап мәҗлес корып утырганда, бик каты җил вә давыл чыкты. Бакча буендагы су шулкадәр дулкынланды ки, тәмам бакчаны су баса язды.

Бу вакыйгадан соң мәҗлестәге кызлар һәркайсы һушсыз булып егылдылар. Шул арада давыл берлә бик зур тау кеби бер гыйфрит (ягъни диюләр падишаһы) очып төште дә падишаһ кызы Гөлбикәне күтәреп алып китте.

Бакчаның сакчылары тиз падишаһка барып вакыйганы бәян кыйлдылар, ягъни бер зур гыйфрит килеп, падишаһның кызын алып киткәнлеген хәбәр бирделәр. Падишаһ вә хатыны, бу хәбәрне ишетеп, хәйран калдылар. Ышаныр-ышанмас тиз егълый-егълый бакчага төштеләр. Күрделәр ки, күшәк эчендә хезмәтче кызлар һушсыз булып яталар. Падишаһның үз кызы юк. Падишаһ вә хатыны вакыйганың растлыгын белгәч, һәр икесе биһуш булып егылдылар.

Берничә сәгатьтән соң бу хәбәр Баһадиршаһка иреште. Тиз Баһадиршаһ бакчага йөгерде. Килсә, күрде ки, атасы-анасы егылышып яталар, тутасы Гөлбикә юк. Баһадиршаһ та кайгырып бик күп егълады.

Бу хәбәр бөтен шәһәргә җәелде. Бу төн шәһәр халкы кайгырышып матәм тоттылар. Падишаһ вә хатыны берничә көн авыру булып яттылар, һич кызлары исләреннән чыкмады. Сагына-сагына икесе дә тәмам саргайдылар.

Бу вакыйга булган заманда Баһадиршаһ унҗиде яшенә җитмеш иде. Исеменә муафыйк (тиң килгән) бик баһадир егет иде. Мөгаллимнәрнең тәртип вә назыйм (оешканлык) берлә укытулары сәясендә (нәтиҗәсендә) күпгыйлем тәхсил кыйлмыш иде (казанган иде, алган иде). Җеннәр вә

[1] Алга таба да — фольклорчы автор искәрмәләре.

диюләрнең зарарыннан саклый торган догаларны үгрәнмеш (өйрәнгән) иде.

Бәһадиршаһ туталарын бик сагыныр иде һәм ата-аналарын да бик кызганыр иде. Падишаһның шәһәреннән берничә йөз чакрым диңгез тарафында бер бик зур урман бар иде. Ул урманда җеннәр вә диюләр вә һәртөрле гаҗәеп хайваннар барлыгы арасында бик мәшһүр иде. Һәркем падишаһның кызын шул урмандагы диюләрнең берсе алгандыр диеп сөйләр иде. Бәһадиршаһ та тутасын шул урманда диер иде.

Бер заман Бәһадиршаһ шул урманга диюләр кулыннан тутасын алып кайтмак хәтеренә килде. Бәһадиршаһ, яшь булса да, җен вә диюдән һич курыкмас иде. Үзенең батырлыгына вә догасына бик ышаныр иде. Бәһадиршаһ ошбу фаразын ата-анасына әйтеп рөхсәт сорады.

Падишаһ вә хатыны һич рөхсәт бирмәделәр:

— Юк фаразларны кыйлма инде, Гөлбикә кеше алырлык җирдә генә түгелдер. Инде без сине дә ул урманга җибәреп бердәнбер балабыздан да аерылыр хәлебез юк,— диделәр.

Бәһадиршаһ бик ялынып-ялварып бакты. Ләкин ата-анасы һич разый булмадылар:

— Зинһар, газиз балабыз, мөмкин булмаган эшкә рөхсәт сорап безне борчыма, ходай сакласын, әгәр дә без синнән дә коры калсак, син урманда бер сәбәп берлә һәлак булсаң, без ничек дөньяда торырбыз,— диделәр.

Мондый сүзләр илә һәр икесе угылларын фаразыннан кире сөрергә бик тырышып бактылар. Ләкин Бәһадиршаһ һич сүзеннән кайтмады:

— Зинһар, мине күңелем төшкән эштән тыймагыз, әгәр дә мин чыкмый калсам да, бу җирдә рәхәт тора алмасмын, уйлана-уйлана авыруга сабышып бетәрмен,— диде.— Бәлки, сез рөхсәт бирмәсәгез дә, мин үзем бер вакыт табып чыгып китәрмен,— диде.

Бәһадиршаһ күп ялвара торгач, атасы да, анасы да риза булдылар. Бәһадиршаһ бик сөенеп юл кирәкләрен әзерләргә тотынды. Атасы күп акча вә бик кыйммәтле кораллар бирде вә янына Тимерҗан исемле бер куәтле вә батыр солдатны җибәрәчәк булды.

Бәс, берничә көннән соң, тәмам юл кирәкләрен әзерләп бетереп, Бәһадиршаһ вә солдат һәр икесе бөтен шәһәр халкы илә бәхилләшеп юлга чыктылар. Берничә чакрым җиргә кадәр падишаһ үзе вә барча вәзирләр һәм гаскәрләр вә шәһәр халкы боларны озата бардылар. Бәһадиршаһ ата вә анасыннан хәер-фатиха алып тәмам бәхилләшеп күрешеп аерылды. Падишаһ вә хатыны һәр икесе егълашып калдылар.

Берничә көн барганнан соң, әлеге дию пәриләре күплеге илә мәшһүр мәзкүр (әйтеп үтелгән) зурурманга барып җиттеләр. Ходага тапшырып, төрле догалар укып, урманга кереп киттеләр. Урман бик куркыныч иде, һич адәм заты керми торган бер урман иде. Юллары вә агачлары да бик куркынычлы иде. Төрле ерткыч җанварлар вә ерткыч кошлар тавышлары ишетелмәктә иде. Урман эчендә бик озак бардылар. Бер заман кич булды, урман кап-караңгы булды, бик каты җил чыкты, агачлар шауламага башлады. Әллә нindәен гаҗәеп тавышлар ишетелә башлады. Төрле тарафтан ялт-йолт утлар вә ялкыннар һәм итсез сөякле генә адәм гәүдәләре күренә башлады. Тимерҗан солдат бик курка башлады. Ләкин Бәһадиршаһ һич курыкмады. Чөнки һаман диюләрнең зарарыннан саклый торган доганы укыр иде. Җеннәр күзгә күренсәләр дә, зарарларын ирешмәслекне белер иде. Һаман кап-кара урман эчендә бик күп заман бардылар. Бара торгач, юлсыз җирләргә килеп чыктылар. Тимерҗан бик арыды. Туктап ашап-эчеп, бераз ял итмәкче булдылар. Үз яннарында тәгамнәре, бераз сулары бар иде. Ашадылар-эчтеләр, атларын һәм үләнгә җибәрделәр.

Тимерҗан бер агач төбенә ятып йокламакчы булды. Бәһадиршаһ бер юл табып булмас микән дип, җәяүләп тарафны тәфтиш кыйлмага (тикшерергә) чыгып китте. Төрле тарафка барып бакты,— һич яхшы юл таба

алмады. Йөри торгач, адашып, Тимерҗан калган җирне җуйды. Йөрде-йөрде, һич таба алмый гаҗиз булды. Ул арада таң да атмыш иде. Бу ике зур диюләр янына килеп чыкты. Диюләр бик иләмсез кыяфәтле иделәр, күзләре ут янып тора иде. Икәүләшеп зур агачларны тамырларыннан куптарып алып, бер-берсе берлә агачлар илә шау килеп сугыша иделәр. Баһадиршаһ боларны күргәч, бераз хәвефкә калды, ни кыйларга да белмәде. Шул арада диюләр Баһадиршаһны күрделәр дә сугышларыннан туктадылар: «Әйдә шул кешегә барып хәлебезне әйтик, шул кеше арабыздагы низагны киссен, ул ни диеп хөкем кыйлса, шул хөкемгә һәр икебез разый булыйк»,— диештеләр. Шуннан соң, тапкан нәрсәләрен кулларына алып, йөгерешеп Баһадиршаһ янына килделәр. Баһадиршаһ, куркып, ни кыйлырга белмичә тора иде, һаман үзенең догасын укый иде.

Диюләр Баһадиршаһның шикләнебрәк торганлыгын белделәр:

— И әфәнде, бездән һич курыкма, без сиңа зарар итәргә килмәдек, син безнең низагыбызга бер хөкем кыйлсана,— диделәр.

Баһадиршаһ боларга ни дип җавап бирергә дә белмәде, җавап бирмәсә дә хәвефләнде:

— Ни низагыгыз бар? — диде.

Диюләрнең берсе:

— Без икебез урманда сәер кыйлып (гизеп) йөргәндә ошбу нәрсәләрне таптык,— диеп, кулларындагы паласны, эскәтер вә бүрекне күрсәтте.— Ошбу нәрсәләрне мин үзем әүвәл күреп кулыма алдым. Ошбу иптәшем: «Мин әүвәл күрдем, ул нәрсә миңа тиеш»,— ди. Инде без бик күп сугыштык, аннан файда чыкмады, инде син һичберебезне якламыйча вә җәберләмичә гаделлек берлә хөкем кыйл,— диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Бу нәрсәләрдә ни хасият (үзенчәлек) бар? — диде.

Диюләр әйттеләр:

— Бу нәрсәләр бик хасиятле нәрсәләрдер,— диделәр,— кем дә кем ошбу паласны җәеп өстенә менеп утырса, кай тарафка баруны теләсә, шул тарафка очыртып алып китәдер; вә дәхи ошбу эскәтерне җәеп куйсаң, ниндәен тәгам теләсәң, шул тәгам хәзер буладыр; вә дәхи ошбу бүрекне кигән кеше һичбер кеше күзенә күренми йөри аладыр. Мондаен гаҗәеп хасиятле нәрсәләр диюләрнең дә күбесендә юктыр,— диде.

Баһадиршаһ ошбу нәрсәләрнең хасиятләренә бик кызыкты, бер хәйлә илә үзенә калдырмакчы булды. Диюләргә әйтте:

— Сез бу нәрсәләрне уртак тапкан икәнсез, минем хөкемем шул ки, йөгергәндә сезнең кайсыгыз узса, бу нәрсәләр шуңар булыр,— диде.

Диюләр һәр икесе бу хөкемне бик мәгъкуль күрделәр, йөгерешеп-узышып карамакчы булдылар.

Баһадиршаһ әйтте:

— Ун чакрым чамасы җирдән йөгерешеп килегез, мин ошбу агач төбендә сезне көтеп торыйм,— диде.

Диюләр лапыр-лопыр килеп йөгерешеп киттеләр.

Баһадиршаһ ошбу нәрсәләрне кулына алып калды. Инде ни кыйлырга белмәде. Паласка утырып очып китсә, Тимерҗан ялгыз кала, яки эзләп йөрсә, диюләрнең чабышып килеп җитү ихтималлары бар. Бераз уйлап торды да, Ходага тапшырып, паласка утырып, туталары янына китүне мәгъкуль тапты. «Шаять Тимерҗанны да Хода үзе саклар»,— диеп, бүрек илә эскәтерне кулына тотып, паласны җәеп, өстенә менеп утырды да:

— И палас, син мине тутам янына илтеп куй,— диде.

Шул сәгать палас югары күтәрелеп, Баһадиршаһны алып бер тарафка очып китте.

Диюләр, бик каты пыр-пыр килеп, дөньяны туздырып чабышып килеп җиттеләр, икесе дә бертигез килде. Кайсы элек килгәнлеге мәгълүм булырлык булмады. Килеп җиткәч тә: «Мин элек килдем» дә «мин элек килдем»,— дип янә сугыша башладылар. Баһадиршаһның юклыгын сизмичә бик күп сугыштылар да, арып туктагач, күрделәр ки: агач төбендә

Бaһадиршаһ юк һәм хасиятле нәрсәләр дә юк. Бөтен урманны туздырып шау-шу килеп, Баһадирны эзләп йөри башладылар. Әгәр тапсалар, бик каты кыйнап үтермәкче иделәр.

Бер заман, урман арасында йөргәндә, Тимерҗанны күрделәр. Тимерҗан бик гаҗиз булып, аптырап, Баһадиршаһны эзләп йөрер иде. Диюләр, Тимерҗанны күрү берлә, икәүләшеп килеп ябыштылар, һәр икесе аны, Баһадиршаһ диеп, таныр-танымас бик каты кыйный башладылар, чөнки таң вакытында Баһадиршаһны бик яхшы танып калмаган иделәр. Тимерҗан бик курыкты. Бик ялынып, аякларына егылып ялвара башлады:

— Зинһар кыйнамагыз, мине ни өчен бу кадәр кыйныйсыз, минем ни гаебем бар?—диде.

Диюләр:

— Безне алдап ник качтың, безнең нәрсәләребезне ник яшердең?—диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Ул нindәен нәрсәләр, мин һичбер нәрсә алганым юк, мин сезне әүвәл күрешем,—диде.

Шуннан соң диюләр, текәбрәк карагач, Баһадиршаһ түгел икәнлеген белделәр дә кыйнаудан туктадылар:

— Инде, зинһар, гафу ит, без сине үзебезне алдаган кеше диеп белдек,—диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Ул сезне алдаган кеше кем иде, ни кыяфәтле иде?—диде.

Диюләр әйттеләр:

— Фәлән кыяфәтле, фәлән киемле бер егет,—диделәр.

Тимерҗан боларга тугры килгән кешенең Баһадиршаһ икәнлеген белде.

Һәм диюләр дә Тимерҗанга:

— Син нинди кеше, кая барасың?—диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Мин бер мөсафирмын, ошбу урманны күргәч, бу нindәен урман икән, дәю тамаша кыйларга кергән идем: йөри торгач, адашып юлымны саташтым, урманнан чыгыйм-чыгыйм ди-ди никадәр йөрдем, һәнүз (һаман да) урман кырыена чыгып җиткәнем юк,—диде.

Диюләр Тимерҗанны бик кызгандылар, юлны да күрсәттеләр, янә бер хасиятле алма да бирделәр:

— Ни максудың булса да, ошбу алманы бераз кап,—ни теләсәң, шул сәгать максудың хасыйл булыр,—диделәр дә үз юлларына киттеләр.

Тимерҗан: «Инде бу алманы ни максуд берлә кабыйм икән»,—дип, байтак уйланып торды. Ахырында, Баһадиршаһка юлыкмак максудына ният кыйлап, бераз капты. Шул сәгать җир астыннан бер ишәк чыгып каршында торды. Тимерҗан белде ки, ошбу ишәк Баһадиршаһ янына алып барачак. Ходага тапшырып, ишәккә атланды. Атлануы берлә, ишәк чабып алып китте. Ишәк илә Тимерҗан бик күп барды, кая барам икән ди-ди хәвефләнә-хәвефләнә бара иде. Бер заман ишәк, урманның бер җиренә барып җиткәч, тын туктады. Тимерҗан атланып, килә-килә бик армы иде. Ишәк туктагач, җиргә төшеп бераз ял итмәкче булды. Җиргә төшүе берлә ишәк күздән гаип булды.

Тимерҗаш: «Баһадиршаһ ошбу җирдә микәнни?»—диеп уйланып як-ягына каранып торганда, алпан-тилпән эштеренә-эштеренә бер бик зур гөмбә килгәнен күрде. Тимерҗан карап тора иде, акрын-акрын гөмбә аның янына килеп җитте:

— И агай, син нинди зат, синнән адәм исе киләдер, бу җиргә һич адәм заты килгәне юк иде, син ничек монда килдең?—диде.

Тимерҗан:

— Синең ни эшең бар, үзем килдем!—диде.

Гөмбә әйтте:

— Минем ник эшем булмасын, мин ошбу сәйранлыкның каравылчысымын, син ник рөхсәтсез килдең? Мин сине падишаһыбызга барып әйтермен. Безнең падишаһыбыз бик куәтле падишаһтыр, ошбу урмандагы җеннәр, диюләр, париләр һәм һәртөрле хайваннар вә гөмбәләр аның кул астында торалар. Әгәр дә сине күрсә, һич ашамый калмас, ул адәм ите бик яратадыр,— диде.

Тимерҗанның бу гөмбәгә бик ачуы килде; кулы-аягы юклыгы мәгълүм булганлыгыннан, куәтсезлеген белеп, гөмбәне кыйнамакчы булды. Янына таба барып, башына йодрык берлә бер генә мәртәбә орган иде, гөмбәнең эшләпәсе өзелеп төште. Шул сәгать гөмбә, чыр-чыр килеп кычкырып, җан бирә башлады. Тимерҗан кызыксынып гөмбәнең эшләпәсен алып кигән иде, шул сәгать үзе дә тышкы яктан гөмбә кыяфәтле булды да китте. Бу хәлне күреп, Тимерҗан бик гаҗәпсенде, алманы кабып иске хәленә кайтмакчы да булды, ләкин капмады, чөнки уйлый торгач, гөмбә көенчә торуны мәгъкуль күрде: «Фаразан (уйлап карaганда) диюләрнең падишаһлары килә калса, тотар да ашар. Әгәр дә гөмбә кыяфәтле булса, бәлки адәм икәнлеген танымас, ихтимал, әүвәлге каравылчы дип белер».

Шул арада бик каты бер җил вә давыл чыкты, бераз соңра бик күп гөмбәләр килә башладылар, гөмбәләр артыннан диюләрнең патшасы гыйфритне күтәреп китерделәр. Янә гыйфрит янында Баһадиршаһның тутасы бара иде. Курку вә хафа сәбәпле, ул бик ябыккан вә саргайган иде. Бу халыклар падишаһны гөмбәләр шәһәренең сәйранлыгына тамаша кыйлдыру өчен кунак итеп алып килмешләр иде. Гөмбәләр дә һәркайсы урманның зур падишаһы гыйфрәткә табигъ (иярүче, буйсынучы) иделәр.

Сәйранлыкка килеп җиткәч тә, берничә гөмбә Тимерҗан янына килделәр:

— Нихәл, яхшы сакладыңмы, хәвеф-хәтәр юкмы?—диделәр.

Тимерҗан:

— Бик яхшы сакладым, һичбер хәвеф-хәтәр юк, һәрбер нәрсә сәламәт,—диде.

Тимерҗанның кеше икәнлеген һич танымадылар, әүвәлге каравылчы гөмбә диеп белделәр, чөнки Тимерҗан тышкы яктан бигайниһи (нәкъ) чын гөмбә кыяфәтле иде.

Гөмбәләр бик гаҗәеп ашлар пешереп, диюләрне бик сыйладылар, һәркайсы берничә сәгать кәеф-сафа кыйлдылар. Падишаһ кызы дию вә гөмбәләрнең кыйланышына күңелсез генә карап-карап торыр иде. Аңа да берәр төрле тәгам бирeп ашаттылар.

Тимерҗан падишаһ кызын күреп таныды, хәлне күреп бик кызганды һәм, шаять бер җай табып алып кайтып булмас микән диеп, эченнән бераз сөенде; кызга үзенең Тимерҗан икәнлеген белдермәде, чөнки аның берлә сөйләшеп торса, гөмбәләр кеше икәнлеген белдерүләре дә ихтималдыр.

Кичкә таба барча диюләр вә гөмбәләр Гөмбә шәһәренә кайтып киттеләр. Гөмбәләрнең башлыгы каравылчы Тимерҗанга, сәйранлыкны яхшы сакламага кушып, бераз чәйлек биреп калдырды.

Тимерҗан янә урман эчендә ялгыз калды. Тимерҗан гөмбә булуына бик кайгырыр иде, ләкин алмасын адәм кыяфәтенә кайту нияте берлә капса, диюләрдән куркыр иде; әүвәлге шәһәренә кайту нияте берлә капса, Баһадиршаһтан башка кайткач, падишаһ үлтерер дип куркыр иде. Баһадиршаһ илә күрешеп булмасмы, бәлки кызны да кулга төшереп булмасмы, диеп тә фикерләр иде.

Бер заман ялгыз уйланып йөргәндә күккә таба караган иде, ерактан бер зур карамчык (кара тап) очып килгәнне күрде. Бераздан соң карамчык якынлашты. Карап тора торгач күрде ки, бер палас өстендә Баһадиршаһ очып киләдер. Шул арада Баһадиршаһ җиргә килеп тә төште. Палас өстендә очып килә-килә бик армыш вә ялыкмыш иде. Килеп төшкәч, тарафына карады, күрде ки, төшкән җире һичбер кешесез бер урмандыр.

Як-ягына караныш торганда күрде ки, бер тарафтан бер зур гөмбә селкенә-селкенә үзенә таба киләдер. Гөмбәнең йөрүен күргәч, Баһадиршаһ бик гаҗәпкә калды. Янына килеп җитә башлагач, гөмбәне үтермәкче булып кылычны хәзерли башлаган иде, Тимерҗан кычкырып сәлам бирде. Баһадиршаһ Тимерҗан тавышын ишеткәч бик сөенде, ләкин Тимерҗан тавышы гөмбә эченнән ишетелүенә бик гаҗәпсенде. Сәламне алды да сораша башлады.

Баһадир:

— Син кем буласың?

Тимер:

— Мин синең юлдашың Тимерҗан әфәнде буламын.

Баһадир:

— Син ни сәбәп берлә бу кыяфәткә кердең?

Тимер:

— Бу урман гөмбәләр урманы икән. Каравылчы гөмбә берлә низаглашкан идек, ул мине диюләргә әйтеп үтертмәкче булды. Шуннан соң мин аны үтердем дә эшләпәсен алып башыма кидем. Аны кию берлә шул сәгать үзем дә гөмбә кыяфәтендә булдым.

Баһадир:

— Син монда ни эшләп торасың?

Тимер:

— Бу җир гөмбәләрнең сәйранлык җирләре икән. Мин ошбу җирне каравыллап торам.

Баһадир:

— Гөмбәләр синең кеше икәнлегеңне белмиләрме?

Тимер:

— Юк, алар һич сизмиләр, алар һаман мине әүвәлге каравылчылары диеп белеп йөриләр.

Тимерҗан Баһадиршаһ берлә кул биреп күрешмәк өчен һаман якын килер иде, ләкин Баһадиршаһ кылычы берлә үзенә бик якын китермәс иде, чөнки һаман гөмбәнең Тимерҗан икәнлегенә ышанып бетмәгән иде. Ихтимал, диюләрнең бер хәйләсе түгел микән, дәю һаман шөбһәләнер иде.

Шуннан соң Тимерҗан әйтте:

— Ник куркасың, әллә минем Тимерҗан икәнлегемә ышанмыйсыңмы?

Баһадир:

— Ышанамын, ышансам да бик якын килми торуның мәгъкуль,— диде.

Тимер:

— Син кая югалдың?

Баһадир:

— Мин юл эзләп йөри торгач, адаштым да сине таба алмадым, йөри торгач, бик гаҗәп ике диюгә очрадым, алардан ошбу палас илә ошбу бүрекне һәм дәстәрханны алдым да, паласка утырып, монда очып килдем.

Сөйләшә торгач, Баһадиршаһ гөмбәнең Тимерҗан икәнлегенә ышанды. Шуннан соң һәр икесе башларына килгән вакыйгаларын бер-берсенә бәян кыйлыштылар. Тимерҗан Баһадиршаһка тутасының бу җиргә килгәнлеген дә сөйләде. Аны ишетеп Баһадиршаһ бик шатланды. Ул көнне көн буенча һәм төн буенча сөйләшеп вә киңәшеп чыктылар.

Иртәгәсен, кояш чыгып бераз күтәрелгәч, янә гөмбәләр килә башладылар. Алар күренә башлагач, Тимерҗан Баһадиршаһка бер агач башына менеп качып торырга кушты.

Бер заман берничә дию пәриләре Баһадиршаһның тутасын тәхет берлә күтәреп китереп төшерделәр. Ул тәхеттә гыйфрит үзе юк иде, чөнки ул үзе һәр заман берәр сәгать соң килер иде.

Баһадиршаһ тутасын күргәч, янына барып күрешмичә чыдый алмады. Үзенең котына вә догаларына ышанып, Ходайга тәәккәл кыйлап, таянып, агачтан төште дә тутасы янына барды. Тутасы кардәшен күреп шаккатты, бик куанды, һәр икесе сөенешеп сөйләшә башладылар. Тутасы Баһадиршаһтан ни өчен вә ни рәвешчә килгәнлеген сөаль кыйлды. Баһадиршаһ һәрбер кыйссасын бәян кыйлды. Тутасы кардәше үзен дию кулыннан алу максуды берлә килүенә бик рәхмәт укыды:

— Ләкин мине ала алырсың микән, мине моннан алып китү бик мөшкел булыр,— диде.

Яхшы гына сөйләшеп торган заманда: «Гыйфрит килә»,— диделәр. Баһадиршаһ гыйфрит килеп җиткәнче хасиятле бүрекне киде дә күздән гаип булды.

Гыйфрит янә бер зур тәхет берлә очып килеп төште. Кыз янына барып утырды. Килеп утыргач та:

— Бу ни гаҗәп, бу җирдә бер адәм исе бар,— диде.

Кыз әйтте:

— Ник монда адәм исе булмасын, мин үзем адәм ич!

Гыйфрит әйтте:

— Юк инде, син асылда адәм нәселеннән булсаң да, хәзердә дию хатыны булдың; хәзер син дию хөкемендә, диде. Бу җирдә синнән башка бер адәм исе килә,— диде.

Шул арада Баһадиршаһ бүрекне салды да гыйфритнең каршысына килеп чыкты. Һич курыкмыйча:

— Хуш, ни кыйлмакчы буласың? Ул адәм мин буламын,— диде.

Баһадиршаһның бу рәвешчә батырлануын күргәч, тутасы егълый башлады, ачу берлә кардәшен гыйфрит һәлак кыйлыр диеп, бик курыкты. Баһадиршаһка күз кысып, юашлык берлә сөйләшергә кушты.

Гыйфрит әйтте:

— Ни кыйлмакчы булыйм? Сине пешертеп, майга кыздырып ашамакчы буламын,— диде.

Баһадиршаһ һич каушамыйча:

— Яхшы, кулыгыздан килсә, тәҗрибә кыйлып карагыз,— диде.

Баһадиршаһ бу сүзләрне әйткәндә тутасының тәмам төсе китте. Шул арада гыйфрит Баһадиршаһны тотып булмакчы булды. Ләкин тотарга һич кулы бармады, чөнки Баһадиршаһ һаман догасын укып тормакта иде. Падишаһ кызы, энесенә гыйфритнең көче җитмәгәнлеген күреп, бик сөенде. Гаскәрләре вә хезмәткәрләре алдында бер кешегә куәте җитмәвенә гыйфритнең бик кәефе китте вә бик гарьләнде. Шулай булса да, сиздермәскә тырышып, Баһадиршаһ илә йомшак кына сөйләшә башлады вә әйтте:

— Син кем буласың? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Мин фәлән мәмләкәт падишаһының угылы буламын,— диде.

Гыйфрит Баһадиршаһның бу сүзләрен ишеткәч, эшнең кая барачагын сизенде, ягъни Баһадиршаһның дога илә тутасын алыр өчен килгәнлеген белде вә әйтте:

— Син монда ни өчен килдең? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Мин газиз тутамны алмага килдем,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул тутаңны ник алып китәсең? Инде ул безнең җиргә бик ияләнде. Мин аны бик кадерләп тотамын,— диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Бик яхшы, рәхмәт. Моңарчы кадерләп тоткансыз икән. Ләкин мин атамның әмере илә килдем. Атам әйтте: «Ни кыйлсаң да кыйл — кызымны алып кайт»,— диде. Мин тәнемдә җаным бар кадәр атамның сүзен җиренә китерергә тырышамын,— диде.

Гыйфрит ни җавап бирергә белмәде; чөнки каты җавап бирсә, ихтимал, Баһадиршаһ бик тәэсирле догалар укып, гаскәрләре алдында хур итәр диеп курыкты. Шулай булса да, Баһадиршаһны гаҗиз кыйлыр өчен, әйтте:

— Мин сиңа тутаңны бирермен, ләкин бик зур бер шартым бар, диде. Әгәр дә шул шартны кыйла алсаң, тутаңны хәзер, бүген алып китәрсең,— диде.

Падишаһ кызы, бу сүзләрне ишеткәч, бер яктан бик куанды. Ләкин шарты ни икән дәю бик уйга калды.

Баһадиршаһ әйтте:

— Ни шартыгыз бар? — диде.

Гыйфрит әйтте:

— Мине ошбу җирдә фәлән төрле ашлар — нигъмәтләр берлән туйганчы сыйла, шуннан соң мин сиңа тутаңны бирермен,— диде.

Гыйфрәт теләгән ашлар бик гаҗәеп ашлар иде. Ул ашларны адәм баласы хәзерләмәк һич мөмкин түгел иде, вә дәхи гыйфрит бик күп ашар иде. Үзен Баһадиршаһ һич туйдыра алмас диеп гөман (уй, фикер) кыйлыр иде.

Баһадиршаһ бик сөенеп: «Ярый, бик яхшы, рәхим итегез»,— диеп, дәстәрханны падишаһ алдына китереп җәйде. Шул сәгать дәстәрхан өстендә падишаһ теләгән ашлар хәзер булды. Бу эшкә гыйфрит бик тәгаҗҗеб кыйлды (гаҗәпләнде). Һәм шул мәҗлестә булган башка кешеләр дә бик гаҗәпсенделәр. Гөлбикә дә бик сөенде. Гыйфрит, ашап бетерим дип, бик күп ашады, янындагы кешеләр дә ашадылар, һәркайсы туйдылар. Дәстәрханда аш һаман бетмәде. Гыйфрит туйгач та бераз ашап бакты, ләкин ашны һич бетерә алмады. Ахры гаҗиз булып, ашаудан туктады.

Гыйфрит туктагач, Баһадиршаһ әйтте:

— Тагы ниндәен тәгамнәр телисез? Сорагыз, без тиз хәзер кыйлырбыз,— диде.

Гыйфрит янә бик гаҗәеп, дөньяда һич булмый торган тәгамнәр өстәде. Шул сәгать дәстәрханда ул тәгамнәр дә хәзер булды. Ләкин аларны гыйфрит ашый алмады, чөнки карына бугазына кадәр тулган иде.

Гыйфрит дәстәрханның хасиятен аңлады һәм ул дәстәрханны үзенә алырга бик кызыкты, Баһадиршаһтан сорады:

— Син бу дәстәрханны кайдан алдың? — диде.

Баһадир әйтте:

— Бер урманда ике диюдән алдым,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул кулындагы палас илә бүрек нинди нәрсәләр? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Алар да дәстәрхан кеби хасиятле нәрсәләр,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ниндәен хасиятләре бар? — диде.

Баһадиршаһ паласның да, бүрекнең дә хасиятләрен бәян кыйлды. Гыйфрит бу нәрсәләргә дә бик кызыкты. Янә сорады:

— Син бу нәрсәләрне каян алдың? — дие.

Баһадиршаһ әйтте:

— Боларны да шул диюләрдән алдым,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул диюләр бу нәрсәләрне ничек сиңа бирделәр? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Дога укып, әүвәл аларның һушларын җибәрдем дә аннан соң алып качтым,— диде.

Гыйфрит, бу сүзләрне ишеткәч, үзе дә бик каушады, Баһадиршаһ илә тагы да йомшаграк сөйләшә башлады.

Гыйфрит әйтте:

— Инде мин сиңа тутаңны бирәмен, ләкин синнән үтенәмен: хасиятле өч нәрсәңне дә миңа бирсәнә,— диде.

Баһадиршаһ һичберсен бирәсе килмәде. Чөнки һәркайсы юлда үзенә кирәк булачак иде. Сөйләшеп торган арада гыйфрит тиз генә качып китте. Баһадиршаһ илә Гөлбикә инде: «Шаять котылдык бугай, гыйфрит догадан куркып качып китте бугай,— диештеләр.— Тиз генә паласка утырып очып китәек»,— диеп хәзерләнә башладылар.

Шул арада Тимерҗан да килеп җитте:

— Зинһар, мине дә алып кайтыгыз, монда ялгыз калдырмагыз,— диде.

Өчәүләшеп утырып китәрбез диеп торганда, күктән бер кош килде дә Баһадиршаһны биленнән күтәреп алып китте. Палас, дәстәрхан, бүрек — һәркайсы шул җирдә калдылар. Гөлбикә илә Тимерҗан куркышып, гаҗәпсенеп калдылар. Гөлбикә, кайгырып, бик еглады. Алар икесе паласка утырып китәргә киңәшкәнче, гыйфрит үзе дә килеп җитте. Гыйфрит шул сәгать хасиятле нәрсәләрне алды да, гаскәр вә хезмәткәрләренә әмер кыйлып, кызны вә үзен күтәреп йортларына алып кайтырга кушты. Һәркайсы киттеләр. Тимерҗан ялгыз аптырап калды.

Йортына кайткач та гыйфрит Гөлбикәне бик мәхкәм (нык) бер сарайга бикләп куйды.

Тимерҗан, ялгыз калгач, бик хафаланып кычкырып еглады. Баһадиршаһтан тәмам өметен кисте. Чөнки ул кош аны, әлбәттә, үлтермәк, һәлак кыйлмак өчен алып киткәнлеге мәгълүмдер. Тимерҗан акрынлап урманнан чыгып шәһәр тарафына кайтуны фарыз кыйлды.

Гөмбәләрнең сәйранлыгыннан бер читкәрәк китеп, алмасын кабып кеше кыяфәтенә кайтты, кулында алмасы бары бер генә кабарлык калды. «Инде ни рәвешчә шәһәргә кайтырмын икән?» — дәю уйлана-уйлана, урман эченнән бик озак барды. Бара торгач, бер су буена барып чыкты. Су буена утырып су эчеп, балык пешереп ашап, бераз ял итмәкче булып утырды. Бераз йокламакчы булып яткан иде, өстеннән бер зур кош очып барганын күрде. Яхшылабрак карагач күрде ки, ул кошның аягында бер кеше дә асылып барадыр. Тимерҗан: «Әлбәттә, бу кош Баһадиршаһны алып киткән кош булырга кирәк»,— диде. Инде ничек Баһадиршаһны ул кош кулыннан коткармак кирәк? Алманы капса, бәлки кош ташлар иде — алмасы бары бер генә кабарлык калган, шәһәргә кайтмак өчен үзенә кирәк иде. Әгәр дә алма бетсә, һәр икесе урманда аптырашып гаҗиз булып калмак кирәк. Әгәр дә алманы кызганып капмый калса, Баһадиршаһ һәлак булмак кирәк. Бераз вакыт уйлап торды-торды да, Ходайга тапшырып, кош кулындагы кешенең сәламәт килеп төшүен адарынып (теләп), калган алмасын кабып бетерде. Ул капканчы кош байтак җир узып китмеш иде.

Тимерҗан алманы капкач та, кош кире борылып килде дә Баһадиршаһны җиргә куеп, очып китте. Баһадиршаһның тәмам һушы киткән иде. Тагы берәр сәгать кош кулында йөрсә, җан бирер дәрәҗәгә килеп җиткән иде. Бер-ике сәгать җирдә һушсыз булып ятты. Айныгач, күзен ачып карагач, янында Тимерҗанны күреп бик сөенде. Икәүләшеп еглашып күрештеләр. Тимерҗан тиз Баһадиршаһка балык пешереп ашатты.

Ашап-эчеп бетергәнче кич булды, урман тәмам караңгыланды. Урман эчендә су буйларында ялт-йолт утлар күренә башлады. Су өстеннән зур хайваннарның башлары күренә башлады, төрлеерткыч хайваннарның тавышлары вә елан сызгырган тавышлар ишетелә башлады. Төн уртасы җиткәч, бик каты бер җил чыкты. Агачлар вә сулар дулкынланып шау иттеләр.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан урманның шаулавыннан вә ишетелгән тавышлардан бик куркыштылар. Урман эчендә бу кадәр куркынычлы хәл күргәннәре юк иде. Бу су буе бигрәк куркынычлы җир икәнлеген белделәр. Төн уртасы авышкач, җил вә давыл бераз басылды. Таң алдыннан Баһадиршаһ илә Тимерҗан йокыга киттеләр.

Кояш чыгып күтәрелгәч, һәр икесе йокыдан тордылар. Киңәшә-киңәшә су буе белән су агымына таба киттеләр. Икесенең дә кулларында һичбер хасиятле нәрсә юк иде. Чөнки Баһадиршаһның палас, бүрек, дәстәрханы гөмбәләр янында калмыш иде. Тимерҗанның алмасы да беткән иде. Шул сәбәптән Тимерҗан Баһадиршаһка кайтыйк дип киңәш бирер иде, ләкин Баһадиршаһның тутасын алмыйча шәһәргә кайтасы килмидер иде. Үзенең куәтенә вә догаларына ышанып, һаман һәрничек булса да тутамны алырмын, диеп фараз кыйлыр иде.

Көн буенча су буе берлә бардылар. Юлда гаҗәеп агачлар вә төрле-төрле җимешләр күрделәр. Урманның ул тирәсенә һич адәм заты кергәне юк иде. Бара торгач, кич булды. Үткән кичтәге кеби урман вә су куркыныч хәлгә керде. Төн уртасы җитте. Янә бик каты җил вә давыл чыкты. Төн уртасы авышканчы һаман акрын-акрын алга таба бардылар.

Төн уртасы авышып давыл басылгач, бер җиргә ял итмәкче булып утырдылар. Шул арада агач арасыннан су буенда бер тәрәзә яктысы күренде. Яхшылабрак карасалар, күрделәр ки: су буенда кечкенә генә бер йорт бар икән. Икесе дә куркырга да, курыкмаска да белмәделәр. Икәүләшеп акрын гына өйнең янына барып, тәрәзәсеннән эченә карадылар. Күрделәр ки: өй эчендә сачлары агарган, тешләре төшеп беткән, күзләре ут шикелле ялт-йолт итеп тора торган арык вә ямьсез бер карчык утырадыр. Сачларын туздырып, күзләрен челәйтеп, күккә таба карап, сихер укып утырадыр. Тәрәзәдән бик күп карап тордылар. Карчык һаман укый да укый. Укый торгач, бик ямьсез тавыш берлә кычкырып җибәрә. Бик күп укыгач, башын шап итеп җиргә бәреп, сәҗдәгә китте. Берничә мәртәбә сәҗдә кыйлды да, дога кыйлып, үзенең гамәлен тәмам итте. Ул арада таң да якынлашкан иде.

Гамәле тәмам булгач, карчык, бик каты кычкырып, кулына бер яулык тотып селкеде. Шул сәгать урман арасыннан берничә пәри килеп чыкты. Су эченнән янә бер-ике пәри чыкты. Һәркайсы йөгерешеп карчык янына керделәр. Карчык аларга берничә төрле эшләр боерды: кайсына он вә ярма китерергә кушты, кайсына ит вә май китерергә кушты. Су пәриләренә су вә балык китерергә кушты. Шуннан соң пәриләр, пырылдашып карчык өеннән чабышып чыгып, төрлесе төрле тарафка йөгерешеп киттеләр.

Пәриләр өйгә кергәч, йорт янында ике кеше торганлыгын карчыкка сөйләгәннәр булырга кирәк; чөнки пәриләр чыккач та, карчык, ишеген ачып:

— Әйдәгез, кунаклар, хуш килдегез, йортыбызга рәхим итегез,— диде.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан куркыр-курыкмас, Ходайга тапшырып, догаларын укып, карчыкның өенә керделәр. Өй эчендә бер карават, бер-ике озын эскәмия вә бер өстәл бар иде. Мич эчендә ут та янып торадыр иде. Карчыкны тәгъзыйм кылып (олылап) кулын үбеп күрештеләр.

Карчык:

— Утырыгыз,— диде.

Һәр икесе эскәмиягә барып утырдылар. Карчык сораштыра башлады. Баһадиршаһ үзләренең кем икәнлекләрен вә һәрбер башларыннан кичкән вакыйгаларны берәм-берәм бәян кылды.

Карчык әйтте:

— Мин үз пәриләремнән: «Гыйфрит бер адәм падишаһының бер кызын урлап килгән, имеш»,— дәю ишеткән идем һәм, ул кызны вә ата-анасын кызганып, бик хафаланган идем. Ләкин ул кызның үзен һич күргәнем юк. Чөнки ул гыйфрит бездән бик ерак булмаса да, дуслыгыбыз юктыр, шуның өчен һич йөрешмибез,— диде.

Асылда бу карчык үзе дә адәм баласы булган икән. Яшь вакытында аны да бер дию урлап ошбу урманга алып килмеш икән. Шул дию үлгәнче бу карчык аның кулында тормыш икән. Ул дию үлгәннән бирле

үз алдына көн күрә башламыш икән. Шул сәбәптән карчык Баһадиршаһ илә Тимерҗанны үз җенесе (кавеме) итеп бик якты чырай илә кабул итте һәм кулыннан килгән кадәр ярдәм кыйлачак булды.

Баһадиршаһ карчык илә бер-ике сәгать чамасы сөйләштеләр. Тимерҗан һич сүзгә катышмады, карыны бик ачкан иде, ашыйсы киләдер иде. Карчыкның бик күп сөйләвенә эче пошты вә үзенең тупаслыгы, вә мәҗлес күрмәгәнлеге сәбәпле әйтте:

— Абыстай, син бик күп сөйләшәсең икән. Бу кадәр күп сөйләшкәнче, кунакларыңны туйдырсаң бигрәк яхшы булыр иде,— диде.

Тимерҗанның бу сүзләренә карчыкның бик ачуы килде. Ачуы килсә дә заһирән (ачык итеп) һич белгертмәде. Яулыгын селкеп бер төрле тавыш берлә кычкырган иде, морҗадан маймыл төсле берничә вак пәри сикерешеп төштеләр. Һәрберсе икешәр генә карыш буйлы вә бик зур башлы иделәр. Карчык аларга коймак пешерергә кушты. Бер савытта коймакка диеп хәзерләнеп куелган камыр бар иде, шул сәгать пәриләр, берничә табага камыр салып, мич эченә кереп киттеләр. Мичнең түренә кереп, яңа торган күмернең өстенә аякларын ерып утырып, куллары белән табаларын тотып, коймакны кыздыра башладылар. Янә бер-ике пәри пешкән коймакны майлап бер савытка салып, мәҗлескә китереп куя башладылар. Һәркайсы ашый башладылар. Баһадиршаһның да бик карыны ачкан иде. Урманда күп йөрү сәбәпле, мич ашын бик сагынган иде. Тансык аш диеп, Баһадиршаһ шактый ашады.

Карчык илә Баһадиршаһ туйды, ләкин Тимерҗан һич туймады. Коймак бик күп иде, пәриләр һаман пешерә торалар иде. Тимерҗан кызарабүртенә һаман ашый да ашый, һич туя алмый. Бара торгач, коймаклар Тимерҗанның авызына очып-очып керә башладылар. Тимерҗан авызын гына ачып торды. Акрын-акрын Тимерҗанның корсагы үсә башлады. Үсә-үсә өстәлне этә башлады. Тимерҗан һаман туймады, авызын ачып чәйни-чәйни генә торды. Пәриләр көлешә башладылар, камыр беткәнче коймакны пешерделәр. Коймакларның һәркайсы Тимерҗанның авызына кереп беттеләр. Тимерҗан бу эштән бик курыкты. Баһадиршаһ та, бер хикмәт булмаса ярар иде дип, бераз каушады. Асылда бу эш Тимерҗанның әдәпсез сөйләвенең җәзасы иде. Тимерҗанның хәле китеп, егылды. Шуннан соң аны пәриләр, аунатып, тәгәрәтеп, ишектән чыгардылар.

Тимерҗан, елап, карчыкка ялына башлады:

— Зинһар, мине бу хәлдән коткарсана,— диде.

Баһадиршаһ һәм карчыктан үтенде:

— Зинһар, аның тупаслыгын вә мәҗлес күрмәгәнлеген гафу итсәнә,— диде.

Карчык көлемсерәп:

— Ярый алай булса, синең хәтереңөчен гафу итәм,— дип, гафу итте. Пәриләргә Тимерҗанны аунатырга кушты.

Пәриләр кычкыра-кычкыра Тимерҗанны тәгәрәттеләр. Тимерҗан көчкә сулу алды.

Баһадиршаһ карчыктан тутасын алырга бер хәйлә өйрәтүен үтенде. Шуннан соң карчык ошбу сүзләрне сөйләде:

— Әгәр дә минем нәсыйхәтем белән йөри алсаң, шаять тутаңны гыйфрит кулыннан алып шәһәрегезгә кайтырсың, ләкин минем бер шартым бар. Шартым шул ки: син тутаңны шәһәрегезгә алып кайткач, мин ошбу урманнан күчеп, сезнең шәһәргә барырмын. Сез шәһәрегездә миңа бер йорт бирерсез, вә һәм үлгәнче гыйбадәт кылып ятарлык мал бирерсез, вә һәм бер-ике хезмәткәр бирерсез. Әгәр дә ошбу шартларны кабул итәрлек булсагыз, мин сезгә бик яхшы хәйлә өйрәтермен. Мин инде ничә еллар бу урманда тордым, адәмнәрне бик сагындым, кайтасым киләдер, инде бу җеннәрдән, сихер гамәлләреннән бик туйдым,— диде.

Баһадиршаһ:

— Баш өсте, диде. Үзең сораганнардан артыграк итеп кадер итәрбез, гомерең буенча безнең кадерле кунагыбыз булырсың,— диде. Дәхи

әйтте:—Гаҗәеп, син моңарчы ни өчен адәмнәр арасына кайтмый тордың?—диде.

Карчык әйтте:

— Яшь чагымда дию җибәрмәде. Дию үлгәндә бик картайган идем, кулымнан һичбер эш килер хәлем калмаган иде, адәм арасына кайтып, хәер эстәп йөрисем килмәде. Чөнки минем туганнарым һәркайсы үлеп беттеләр, тәрбия кыйлыр кешем юк, мин бу җирдә ничек булса да җеннәремне хезмәт иттереп көн күрә алам. Адәмнәр арасына кайтсам, ул җеннәр миңа һич хезмәт итмиләр. Шуның өчен бу көнгә кадәр адәм арасына кайтмадым,— диде.

Карчык Баһадиршаһка бер кылыч, Тимерҗанга бер сөнге бирде:

— Сез, ошбу коралларны кулларыгызга тотып, ошбу юл белән төн ягы тарафына китегез, берничә чакрым баргач, бер күпергә очрарсыз. Ул күперне тиз генә чыгарга тырышыгыз, чөнки сез чыгып җиткәнче ул күпер җимерелә башлар. Мөмкин кадәр җимерелгәнче чыгып калырга тырышыгыз. Ул күперне чыккач, янә барырсыз, бара торгач, сезгә юлда ике башлы бер бик зур елан очрар. Ул елан сезне үтерергә касд (ният) кыйлыр. Сез аны тиз ошбу коралларыгыз илә үтерегез. Ләкин бик саклана күрегез, бер сукканда башын өзәрлек булыгыз. Бер башына ике мәртәбә суга күрмәгез. Әгәр дә бер башына ике мәртәбә суксагыз, яңадан терелер дә үзегезне һәлак кыйлыр. Ул еланны үтергәч, янә бераз барырсыз. Бер бик зур таш-таулар арасына килеп чыгарсыз. Шул таулар урталыгында бер бик зур мөхкәм (нык) сарай булыр. Синең тутаң шул сарай эчендә булыр. Ул сарай янына барып җиткәнче янә бер зур күпер чыгарсыз, ул күпер дә сез чыгып җиткәнче җимерелер. Сез мөмкин кадәр тизрәк чыгарга тырышыгыз. Ул күпердән чыгып җиткәч тә, күктән ике башлы янә бер зур елан килеп төшәр. Ул елан да сезне үтерергә касд кыйлыр. Ул еланны да ошбу коралларыгыз илә берәр сугып һәлак кыйлырсыз. Сарай янына барып җитәрсез. Сарай янында бер зур бакча булыр. Ул бакча янында бер зур күл булыр. Сез шул күл янына барып карап торыгыз. Көндез өйлә вакытында шул күл янына берничә аккош очып килеп төшәрләр. Сез шуларны яхшы билгеләп карап торыгыз: ул аккошларның арасында берсенең башы бүрекле булыр, шуны бик билгеләп калыгыз. Чөнки ул кош гыйфритнең үз кызыдыр. Янындагы кошлар иптәш вә хезмәтче кошлардыр. Алар һәркөн, гыйфрит йоклагач, шул күлгә килеп коеналар. Ул кошлар күл буена килеп төшкәч тә адәм кыяфәтенә, ягъни кызлар кыяфәтенә керерләр. Һәркайсы чишенешеп киемнәрен күл янында калдырып, күлгә кереп китәрләр. Алар бер сәгать чамасы шул күлдә уйнашып коенырлар. Син, Баһадиршаһ, шул арада, үзең күренмичә генә, бүрекле аккошның чишенгән киемнәрен алып үз кулыңда тот. Тимерҗан, син дә, теләсәң, арадан бер кошның киемен ал. Кызлар, коенып туйгач, күлдән чыгып, киенмәкче булырлар. Сез киемнәрен алган кызлар, киемнәрен таба алмыйча, аптырашып йөрерләр. Сез шул арада ул кызларны тотарга тырышыгыз. Алар, киемнәре булмагач, сезгә һичбер зарар кыйла алмаслар. Сез алардан һич курыкмагыз. Ул кызларны сез һич җибәрмәгез, киемнәрен бирмәгез. Алар сезгә бик ялынып багарлар, сез һич аларны кызгана күрмәгез, чөнки, әгәр дә аларны өчәр мәртәбә ант иттермичә җибәрсәгез, алар сезне хәзер һәлак кыйлдырырлар. Сез аларның һәрберсен өчәр мәртәбә ант иттерегез. Беренче: «Мин синеке булдым»,—диеп ант итсеннәр. Икенче: «Мин сиңа һич зарар итмәм, зарар иттермәм»,—дип ант итсеннәр. Өченче: «Син ни кушсаң, мин шуны эшләрмен»,—дип ант итсеннәр. Һәркайсы ошбу рәвешчә ант иткәннән соң, алар гүя сезнең колыгыз хөкемендә булырлар, һәрвакыт тагать кыйлап (буйсынып) мөмкин кадәр сезнең өчен хәер-хаһ булырлар. Шулай булса да, сез ашыгып җибәрмәгез:

«Ошбу җиргә Гөлбикәне вә палас илә бүрек һәм дәстәрханны китер»,—диегез. Шуннан соң гыйфрит кызы юлдаш кызларының берсенә әмер кыйлыр. Шул сәгать Гөлбикәне вә хасиятле нәрсәләрне китерерләр.

Алар килгәч тә, паласны җәеп, бишәүләшеп өстенә менеп утырыгыз да паласка үз шәһәрегезгә алып кайтырга боерыгыз. Шул рәвешчә икегез өйләнеп, Гөлбикәне алып кайтырсыз. Кайтып җиткәч, гыйфрит кызы сиңа даими итагатьтә булыр, һич каршы килмәс, адәм кызларыннан артыграк хатынлык хезмәтен итәр. Әгәр дә мәхәббәтегез булмаса, һәр икесен азат кыйлып җибәрерсез. Зинһар, бу эшләрне ошбу атна эчендә башкара күрегез, чөнки бу атна гыйфритнең йоклый торган атнасыдыр. Гыйфрит уяу чагында сез һич Гөлбикәне ала алмассыз,— диде.

Карчык кылыч илә сөнгене өшкереп бирде дә:

— Инде сезгә вакыт җитте, тизрәк юлга чыгыгыз, Хода хәерле юл бирсен! — диде.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан, карчык илә күрешеп — бәхилләшеп, юлга чыктылар. Карчык бер-ике пәрине озатып юл күрсәтергә җибәрде. Бернично чакрым баргач, карчык сөйләгән күпергә килеп җиттеләр. Карчык әйткән рәвешчә ул күпердән тиз генә чыктылар. Чыгып җитәм дигәндә күпер җимерелә башлады, күпер тәмам җимерелгәнче сәламәт чыгып җиттеләр. Күпердән чыгып җиткәч тә каршыларына сызгырып, авызларыннан утлар чәчеп, ике башлы бер елан килде. Баһадиршаһ кылычы белән бер башына, Тимерҗан сөнге илә икенче башына сукты. Шул сәгать елан җан тәслим кыйлды. Икенче күперне дә чыктылар һәм икенче еланны да үтерделәр. Икенче елан бигрәк куркыныч кыяфәтле иде.

Сарай янына килеп чыктылар. Бакча артына барып, күл буена килеп утырдылар. Карчык әйткәнчә, сәгать уникедә күл буена унике аккош очып килеп төште. Килеп төшү белән, һәркайсы бик гүзәл кызлар кыяфәтенә керделәр. Һәрберсе чишенеп, суга кереп киттеләр. Баһадиршаһ бүрекле аккошны билгеләп калды. Тимерҗан аның белән янәшә очып килеп икесе бер җиргә чишенгән кызны яратты. Ул кыз гыйфрит кызының дусты иде. Башкалары хезмәтче кызлар иделәр. Кызлар суга кергәч тә, Баһадиршаһ бүрекле аккошның киемен, Тимерҗан аның янында чишенгән кызның киемен кулларына алдылар.

Коенып бетергәч, киенешергә чыктылар. Чыккач, ике кыз киемен таба алмады. Бик кайгырышып, кычкырышып елаша башладылар. Шул арада Баһадиршаһ илә Тимерҗан үзләре билгеләгән кызларын барып тоттылар. Кызлар бик ялына башладылар. Киемнәрен алып егетләрнең кулларыннан ычкынмакчы булдылар. Ләкин егетләр һич җибәрмәделәр, һәр икесе ант итәргә куштылар. Ләкин кызлар бик күп заманга кадәр кабул итмичә тыпырчындылар. Һәрничек булса да, ахырында һәр икесе өчәр мәртәбә ант иттеләр. Баһадиршаһ үз кызына тутасы Гөлбикә илә паласны һәм бүрек илә дәстәрханны китерергә кушты. Гыйфрит кызы хезмәтче кызларының берсенә Гөлбикәне вә палас илә бүрекне һәм дәстәрханны алып килергә кушты. Биш минут эчендә һәркайсын китереп җиткерделәр. Гөлбикәнең һич вакыйгадан хәбәре юк иде. Бакчада энесен күреп, бик гаҗәпкә калды. Һәм, энесе гыйфрит кызын тотканлыгын вә аңа теләгәнчә хөкем кыйлганлыгын күреп, шаккатты. Гыйфрит кызы Гөлбикәгә әүвәлдә һич яхшылап илтифат кыйлмыйдыр иде. Хәзер бик тәгъзыйм кыйлып күреште, гүя үз тутасы кебек якын күргәнлеген белгертте.

Гөлбикә Баһадиршаһтан ни вакыйга булганлыгын, ни рәвештә килгәнлеген сорашмакчы булды. Баһадиршаһ:

— Апа, туктале, күп сорашма, өйгә кайткач сөйләшербез, тизрәк палас эченә кереп бас,— диде.

Паласның уртасына гыйфрит кызы Ләүлияне бастырдылар. Калганнары, ягъни Баһадиршаһ, Гөлбикә, Тимерҗан вә аның кызы — дүртесе, дүрт почмакка басып, һәркайсы паласның бер почмагын тоттылар.

Баһадиршаһ паласка:

— Тиз әткәй вә әнкәйләребез янына фәлән шәһәргә алып барып, сәламәт җиткез! — диеп әмер кыйлды.

Палас күтәрелеп китте. Ләүлиянең хезмәтче кызлары елашып калдылар. Ләүлия күтәрелә башлагач, елап, хезмәтче кызларына әйтте:

— Сез миннән бәхил булыгыз, шаять, берничә елдан соң мин бирегә киявем белән кайтырмын. Әткәй-әнкәйгә ни вакыйга булганлыгын тәфсыйлән (җентекләп) бәян кыйлыгыз, мине гаеп итмәсеннәр,— диде.

Шуннан соң Баһадиршаһ та кычкырды:

— Каенатайга әйтегез: һич зарар касд кыйлмыйча, дуслык белән парлап кунак булып барсыннар. Әгәр дә алар безгә килсәләр, һәр елда без дә бу җиргә килербез,— диде.

Палас, биек күтәрелгәч, Баһадиршаһның аталарының шәһәренә таба алып китте.

Болар палас белән һавадан болытлар арасыннан бара торсыннар, без Баһадиршаһның атасы илә анасының хәлләрен языйк.

Баһадиршаһның атасы вә анасы, угылларын озатканнан соң, бик хафага калдылар. Ахыры һичбер баласыз калдык бугай, дәю, бик хафаландылар. Ашаулары-эчүләре һәм йокылары качты. Һәр икесе бик ябыктылар. «Үзебез картайдык, дөньяда һичбер варисыбыз калмый»,— диеп, һаман икәүләшеп бакчага чыгып, моңаешып утыра башладылар.

Кызының һәм улының бакчада йөргәннәрен уйлап, сагынышып утырыр иделәр. Кызлары да, угыллары да һаман төшләренә керер иде. Бәгъзы (кайбер) көнне бик шат кыяфәттә керер иделәр. Бер ай чамасы узды, һаман улларыннан да, кызларыннан да һич хәбәр юк. Бер көнне падишаһ үзе кызы илә угылын икесен бер җирдә бик шатланышып утырганнарын күрде. Хатыны бакчаларына һавадан биш аккош очып төшкәнен күрде. Шул көнне иртә белән бик шатланышып, бер-берсенә төшләрен сөйләштеләр. Шаять сәламәт кайтмаслар микән дәю, төшләрен хәерлегә юрашкан булдылар.

Бер заман ак болытлар арасыннан бер карамчык күрделәр. Бу ни икән дәю, бик гаҗәпсенеп күп заман карап тордылар. Карамчык һаман зурая иде. Берәр сәгатьтән соң карамчык боларның бакчаларына якынлашты. Бу ни икән диеп гаҗәпсенеп торганда, бер палас илә биш кеше килеп төште. Карасалар: кызлары Гөлбикә һәм уллары Баһадиршаһ, Тимерҗан һәм янә башка ике бик гүзәл кыз.

Баһадиршаһ бер кулына Гөлбикәне җитәкләп, икенче кулына Ләүлияне җитәкләп, атасы вә анасы каршына барды. Һәркайсы әүвәл падишаһ илә, аннан соң хатыны илә, кулларын үбеп, кочаклашып күрештеләр. Бакчада шундый бер шатлык мәҗлесе булды ки, һич сөйләп вә язып бетермәк мөмкин түгелдер.

Иртәгесен падишаһ җәмигы (барлык) вәзирләрен вә шәһәрнең могтәбәр кешеләрен чакырып, вә голәмәсен чакырып, зур мәҗлес ясады. Һәм шул мәҗлестә Баһадиршаһ илә Ләүлиягә вә һәм Тимерҗан илә үзенең алып кайткан кызына никах укытты. Шуннан соң һәркайсы шатлык илә тереклек кыйла башладылар. Берничә көннән соң Гөлбикәне вәзирнең угылына кияүгә бирделәр.

Берәр айдан соң Баһадиршаһларның урманда күрешкән карчыклары килде. Падишаһ аны бик кунак итеп, махсус йорт вә хезмәтчеләр бирде.

Алты айдан соң гыйфрит, кызын күрергә килмәкче булып, илчелеккә бер дию юллады. Ләкин падишаһ ул диюнең йөзен күрәсе килмәде:

— Күрәсе килсә, кызын кунак итеп җибәрербез, берәр ай торып кайтыр, үзенең килүен мәгъкуль күрмимен,— диде.

Шул дию илә Ләүлиягә бер айга рөхсәт биреп җибәрделәр. Ләүлия бу җиргә һәм киявенә бик иярәнгән иде, бик елап, һәркайсы илә күрешеп китте. Бер айдан соң, атасының ризалыгы берлә, янә килде.

Шуннан соң һәркайсы гомерләре буенча бик рәхәт тереклек кыйлдылар. Падишаһ үлгәннән соң, тәхеткә Баһадиршаһ утырды. Баһадиршаһ, падишаһ булгач, бик рәхәт гомер сөрде.

# ШИГЪРИЯТ



## Мидхәт Миншин

### ДҮРТ ҖЫР

#### Дога

Каеннарның яфраклары
Коелмады — кышка калды.
Әллә нинди шомлы уйлар
Йөрәгемне утка салды.
Йокы керми күзләремә —
Таң алдыннан дога кылам:
Имин булсын җир-суларым,
Мәрхәмәтле булчы, ходам!..

Язын боз эреми торса;
Гаепледәй уйный җаным.
Гөнаһлардан сынар сыман
Тоткасы да бу дөньяның...
Йокы керми күзләремә —
Таң алдыннан дога кылам:
Имин булсын җир-суларым,
Мәрхәмәтле булчы, хсдам!..

Болыт килеп яумый китсә,
Киткән кошлар кайтмый калса,
Уч төбенә килә җаным,
Уйларымны хәвеф баса.
Йокы керми күзләремә —
Таң алдыннан дога кылам:
Имин булсын җир-суларым,
Мәрхәмәтле булчы, ходам!..

## Сер бирмә

Таң беләнме иңдең Җиргә —
Син фәрештә минем алдымда.
Син барында мин кайгырмыйм,
Мин барында син дә кайгырма!..
Син дә кайгырма!..

И, син, язмыш, табыштырдың,
Табыштырдың, инде аерма.

Назларымнан, карашыңнан
Иртәнге нур гүя сибелә.
Син барында мин сер бирмәм,
Мин барында син дә сер бирмә!..
Син дә сер бирмә!..

Беркем берүк күпсенмәсен,
«Син минеке!» дисәм — гомергә!

## Фәрештәләр ни әйтә?

Бик бәхетле көннәремдә
Җырлар туса йөрәгемдә,
Фәрештәләр әйтә сыман:
— Йөз чөермә дусларыңнан,
Йөз чөермә дусларыңнан!..

Кайгылардан баш иелсә,
Күзләремнән яшь түгелсә,
Фәрештәләр әйтә сыман:
— Сабырлык ал дусларыңнан.
Сабырлык ал дусларыңнан!..

Үз-үземне күрергә дә
Теләмәгән көннәремдә
Фәрештәләр әйтә сыман:
— Ерак йөрмә дусларыңнан,
Ерак йөрмә дусларыңнан.

Уңышларга сөенсәм дә,
Көтмәгәндә җиңелсәм дә,
Фәрештәләр әйтә сыман:
— Аерылма дусларыңнан,
Аерылма дусларыңнан...

## Гел яхшыга юрыйсың

Уң кашың тартса да,
Сул кашың тартса да,
Һаман да яхшыга юрыйсың.
Биш намаз укысаң,
Биш тапкыр көненә

Ходайдан иминлек сорыйсың.
Әй, әнкәй, син ахры беркайчан
Янмыйча, көймичә тормыйсың.

Яңа ай күрсәң дә,
Тулган ай күрсәң дә,
Сокланып, сөенеп туймыйсың.
Без кулдан китсәк тә,
Чаларып бетсәк тә,
Гел безгә борылган тормышың,—
Әй, әнкәй, син инде беркайчан
Янмыйча, көймичә тормыйсың.

Мендәрең авышса,
Самовар ташыса,
Ашыгып юлларга карыйсың,
Җиде көн, җиде төн,
Җиде ел узса да,
Син безне ерактан таныйсың,
Әй, әнкәй, син инде беркайчан
Янмыйча, көймичә тормыйсың.

## ДРАМАТУРГИЯ

**Илдар**
**Юзеев**



# ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ

МӘХӘББӘТ КЫЙССАСЫ

**КАТНАШАЛАР:**

**Мөнирә Идрисова**
**Сәет Зилаиров**
**Ләлә**
**Өмет Зилаиров**
**Мирсәет Зилаиров**
**Алсу**
**Сафа**
**Яшьләр**

**1940—80 елларда булган хәлләр...**

## Беренче акт

**Сәетнең төше: картайган, ямьсезләнгән Сәет һәм яшь-яшь Мөнирә.**

Сәет. Исәнме-саумы, Гашыйклар тавы! Бу мин — дошманны бик тиз генә җиңеп кайтырга киткән Сәет Зилаиров. Сугышның башыннан алып ахырына кадәр ут эчендә йөреп, әлләничә үлеп, әллә ничә терелеп, мин сиңа әйләнеп кайттым! Әллә инде танымыйсың? Исәнме-саумы, яшьлек серләремне сыйдырган, хисләремне үз иткән, сөю шатлыкларын-газапларын юллаган Таллыкүл урманы! Мөнирә, җиләгем, син, мөгаен, без очрашкан урында мине көтәсеңдер... Мөнирә-әү! Ау-у! Син кайда?!

Мөнирә тавышы. Ау-уу! Син кем?

Сәет. Бу мин... Сәет!

Мөнирә. Ой! Сез кем?

Сәет. Мөнирәм! Җиләгем! Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең... Кил, кочыйм.

Мөнирә. Кит... Кагылма!

Сәет. Танымыйсыңмени, Мөнирә? Әллә онытгыңмы бик яшьли сөйгән ярыңны?

Мөнирә. Минем яшьли сөйгән ярым Сәет... Син... Сәет... түгел!

Сәет. Мин чын Сәет...

Мөнирә. Мин синнән куркам.

Сәет. Мөнирә, исеңдәме... без синең белән шушы болында очраштык...

Мөнирә. Минем Сәетем бөтенләй башка...

Сәет. Нинди иде соң ул?

Мөнирә. Ул яшь иде. Башы горур, күтәренке иде. Чәчләре куе, чем кара иде. Аның битләре алсуланып, ут кебек янып торыр иде. Мондый ямьсез эзләр, килбәтсез кыяфәт...

Сәет. Мөнирә!

Мөнирә. Ой! Якын килмә! Син — качкын!

Сәет. Әйе, мин тегендә немец әсирлегеннән качтым. Әмма үзебезгә качтым, аннан соң да әле сугыштым, яраландым. Мине ядрәләр җәрәхәтләде, ярчыклары битләремне умырды, фашист итекләре, этләре тәнемдә җуелмас эзен калдырды. Мине кистеләр, турадылар, ялгадылар... Шулай да мин, Мөнирә, исән... ышан: мин синең Сәетең.

Мөнирә. Ышанмыйм. Сәетнең нәфис бармаклары гармун уйнау өчен генә яратылган иде...

Сәет. Гармунның үзен биеткән моңлы бармакларымны изделәр, таптадылар, Мөнирә. Мин Сәет... кил әле кочаклыйм үзеңне, элекккечә кочагында югалыйм... Онытыйм бөтен күргән газапларымны...

Мөнирә. Якын килмә! Син Сәет түгел! Хәзер кычкырам! Килгән Юлыңнан кире кит!

Сәет. Кычкырма... зинһар... Күзләремне тутырып бер карыйм да... китәм... мәңгегә, кайтмаска китәм...

Мөнирә. Кит! Кит! Югал!

*(Сәет уяна.)*

Сәет. Мөнирә... Мөнирә! *(Акылына килеп.)* Ләлә...

Ләлә *(кайтып керә)*. Ни булды, Сәет?

Сәет. Болай гына... Саташтыра...

Ләлә. Инсульттан соң ялгыз калдырырга ярамый шул сине...

Сәет. Сул кул кыймылдаганда әле яшәргә була. Концерт ошадымы? «Сагыну» ансамбле миннән башка җырлый аламы?

Ләлә. Синең рухың анда, синең җырың...

Сәет. «Яралы кош»ны җырладылармы?

Ләлә. Аннан башка концерт узамы...

Сәет. Мине искә алалармы?

Ләлә. Очраган берсе сине сорый. Бүген нинди төшләр күрдең?

Сәет. Мин күрәсе төшләремне күреп бетердем, ахры...

Ләлә. Алай димә, Сәет...

Сәет. Сизәм: лампам эчендә май кими.

Ләлә. Кимүен кимеми... Әмма мин башка бер нәрсә тоям, Сәет, сине нәрсәдер миңа әйтергә ярамый торган сер газаплый. Төннәр буе йоклый алмыйсың, йоклап китсәң, саташасың. Ачыл, Сәет, үзенә җинел булып китәр. Минем алдымда гаебең булса да, яшермә, кичерермен...

Сәет. Син изге кеше, Ләлә...

Ләлә. Кем ул Мөнирә? *(Сәет дәшми.)* Кем ул... Мөнирә? Мөнирә кем ул?

Сәет. Мөнирә? Нинди Мөнирә?

Ләлә. Бу сорауны мин сиңа бирәм. Ачуланмыйм, үпкәләмим, әйт, Сәет, кем ул Мөнирә?

Сәет. Син... каян беләсең?

Ләлә. Димәк, Мөнирә чынлап та бар...

Сәет. Син... син... мин...

Ләлә. Саташасың, аны чакырасың. Аның урынына мин киләм.

Сәет. Ләлә, су бир... Утыр... Мин бу сүзне үзем башларга кыймый идем. Мине озак еллар газаплаган серне чишәргә вакыт җитте... Мин аны үзем белән алып китә алмыйм. Мин хәзер сөйли дә алмыйм... Хәтерем әлләни түгел. *(Дәфтәр чыгара.)* Барысы да шунда...

Ләлә *(дәфтәрнең беренче битен ача)*. Ядкарь дәфтәре. Онытма мине! Онытмам син! Ул... Мөнирә?..

Сәет. Мөнирә...

Сәет тавышы. Безнең Таллыкүл авылы Гашыйклар тавына терәлеп тора. Их, Таллыкүл урманнары! Беренче тапкыр мин аны кара урманда күрдем... *(Манзара үзгәрә. Урман-тауларның һәм геройларның яшь чагы.)* Урманчы әтием үлгәч, Таллыкүл участогына мине, унтугыз яшьлек егетне куйдылар.

**Кызлар урманга җиләк җыярга килгәннәр.**

Мөнирә. Кызлар, әйдәгез, ял итәбез!

Кызлар. Ял итәбез, ял итәбез! *(Утырышалар.)*

Беренче кыз. Җиләк җыйдым чиләккә.

Икенче кыз. Берсен аттым...

Өченче кыз. Берсен каптым...

Мөнирә. Яна торган йөрәккә! Их, кызлар, йөрәк чынлап та яна икән ул! Әллә ни булды, акылдан язам!

Беренче кыз. Акылсыз кызны бер егет тә яратмас.

Икенче кыз. Әй, акыл егетләргә генә кирәк ул!

Өченче кыз. Ни сөйлисез, без бит әле укучылар гына...

Мөнирә. Теләсә ни әйтегез: мин... гашыйк булдым! *(Сикереп торалар.)*

Кызлар. Гашыйк булдың?

Мөнирә. Гашыйк булдым.

Беренче кыз. Кемгә?

Икенче кыз. Хыялда?

Өченче кыз. Кинода?

Беренче кыз. Вахитка?

Икенче кыз. Заһитка?

Өченче кыз. Шаһиткә?

Мөнирә. Юк!

Кызлар. Әйт инде, яшермә, Мөнирә?

Мөнирә. Сер булып калсын!

Беренче кыз. Ул үзе беләме?

Мөнирә. Белми шул, кызлар, белми!

Икенче кыз. Онытырсың әле, бала!

Өченче кыз. Канатлана башлаган яшьлекнең җилкенүе!

Мөнирә. Кызлар, бу — шаяру түгел, мәхәббәтнең үзе!

Беренче кыз. Минем дә гашыйк буласым килә! Мөнирә...

Икенче кыз. Әйт әле, ничек гашыйк булырга?

Өченче кыз. Ни ул мәхәббәт?

Мөнирә.

Ни ул мәхәббәт? Үзем дә белмим.
Һичбер сәбәпсез шатланам, көләм.
Сабый баладай дөньяга туам.
Хыялга очам, сагыштан үләм.
Гел үзем генә каласым килә.
Дуслардан качам. Тилерәм, шашам.
Әллә мин җырлыйм, әллә мин елыйм.
Хис урманына кереп адашам.
Белмим үзем дә, йөрәгем аша
Агамы утлар, агамы бозлар?
Түзә алмыйча ачтым серемне,
Әйтегез миңа, нишләргә, кызлар?

Беренче кыз. Әтиең — Сафа абзый сизсә... үтерә бит!

Икенче кыз. Үтерде ди... Аның да яшьлеге булган ич...

Өченче кыз.

Мондый җилкенү бала йөрәктән
Килер дә китәр, сызлар да китәр,
Утлар да сүнәр, бозлар да китәр,
Исең китмәсен, узар да китәр! *(Авызына бармагын куеп, сызгыра.)* Әйдәгез, малайлар булып биибез! *(Бииләр. Мөнирәне дә биетергә тырышалар.)*

Мөнирә. Юк, кызлар, көчләмәгез... Булмый...

Кызлар. Алай булса, җырла!

Мөнирә. Малайкайларым, зинһар дип сорыйм, мине урманда үземне генә калдырыгыз. Бәлки, җырларымны да...

Беренче кыз. Адашсаң, Сафа абзый үтерә бит үзеңне!

Икенче кыз. Соң... калсын әйдә, бик адашасы килсә, адашсын әйдә...

Өченче кыз. Кара аны, адашсаң-нитсәң, кайтып керәсе булма! *(Чыгалар.)*

Мөнирә. Каравылчы килеп чыксын өчен, нишләргә? Әһә! Япь-яшь аккаенны кисеп киткәннәр... Әһей! Каравылчы! Каенынны кискәннәр! Юк, ишетмәде. Ул монда... Урман эченә кереп киткәнен күреп калдым. Кычкыруны ишетмәде... Җырлап җибәрсәм? Аны җыр ярата диләр...

Елмайдым — карамадың,
Юл бирдем — аңламадың,
Кул бирдем — аңламадың,
Син мине санламадың,
Син сине саңламадың...
*(Капланып елый.)*

Сәет *(мылтыгын асып керә)*. Ни булды?

Мөнирә. Берни булмады.

Сәет. Нигә елыйсың?

Мөнирә. Күрмисеңмени... адаштым ич...

Сәет. Әкияттәге үги кызмы әллә син? Кем адаштырды?

Мөнирә. Үзем адаштым ла мин...

Сәет. Курыкмыйча бер үзең урманга килергә ничек батырчылык иттең?

Мөнирә. Җиләккә килгән идем лә...

Сәет *(кәрзингә карап)*. Шулай икән шул. Иптәшләрең ташлап киттеме? Әле генә тавышларын ишеттем.

Мөнирә. Үзем калдым ла мин...

Сәет. Тор, сеңелем, курыкма. Күрсәт әле йөзеңне...

Мөнирә. Әй, оялам ла мин... *(Йөзен ача.)*

Сәет. Сөбханалла, сөбханалла! Буйга житкән кыз икәнсең... *(Текәлеп карап тора.)* Исемеңне дә белик инде?

Мөнирә. Бәй, танымыйсыңмени, Сәет абый?

Сәет. Исемеңне әйтсәң, бәлки, танырмын...

Мөнирә. Мөнирә ич мин.

Сәет. Кайсы Мөнирә? Нишләп мин белмим?

Мөнирә. Түбән оч Мөнирә.

Сәет. Сафа абзый кызымы әллә?

Мөнирә *(соенеп)*. Әйе! Тугызынчы класс укучысы Мөнирә Идрисова!

Сәет. Тугызынчы класс? Укучы? Бала гына икәнсең шул әле...

Мөнирә. Мин балалыктан киттем инде.

Сәет. Аны каян беләсең?

Мөнирә. Әй... оялтмагыз инде...

Сәет. Әле син җырладыңмы?

Мөнирә. Ишеттегезмени? Мин бит әкрен генә. Кеше ишетмәсен дип кенә...

Сәет. Минем колак сизгер. Кош сайравын да биш чакрымнан ишетәм. Димәк, син җырладың?

Мөнирә. Мин җырладым... еладым...

Сәет. Бик тә матур, бик тә моңлы елыйсың икән. Сер булмаса, әйт әле, сеңелем, кызлар кара урман эчләренә кереп, нигә елыйлар?

Мөнирә. Балачак белән аерылышу бер елата, бер җырлата.

Сәет. Хәзер мин синнән сынау алам. Ризасыңмы?

Мөнирә. Риза.

Сәет. Мөнирә Идрисова, менә бу агач төбен кара әле.

Мөнирә. Карадым.

Сәет. Аны төнлә кисеп киткәннәр. Ул нинди агач? Аңа ничә яшь?

Мөнирә. Каен. Аңа унбиш яшь булган.

Сәет. Дөрес. Каян белдең?

Мөнирә. Каенның сырларын санадым.

Сәет. Утыр, Идрисова! Бишле! Шушы каен хәлендә каласың килмәсә, икенче ялгызың урманга чыгасы булма! Аңладыңмы?

Мөнирә. Юк... аңламадым.

Сәет. Курыкмыйсыңмы?

Мөнирә. Әй, курыктым, ди... Каравылчы бар ич...

Сәет. Әнә япь-яшь каенны хәрап иткәннәр. Сезнең кебек тыңлаусыз кызчыкларның һәрберсенә бер каравылчы кирәк. Аңладыңмы?

Мөнирә. Аңладым ла...

Сәет. Мә кәрзинеңне... Әйдә, юлга чыгарып куям... *(Нәни йомшак кулларына кагыла.)*

Мөнирә *(куркып читкә ыргыла)*. Тотмагыз! Үзем дә кайталам...

Сәет *(ягымлы, назлы)*. Мөнирә... Шулай да әйт әле, нигә килдең урманга?

Мөнирә. Әйтимме?

Сәет. Әйт, Мөнирә...

Мөнирә *(оялып, башын иеп)*. Мин... сезне яратам, Сәет абый! *(Йөзен куллары белән каплап, чыгып йөгерә.)*

Сәет. Мөнирә... тукта... *(Китә. Качып тыңлап торган кызлар әйләнеп керәләр.)*

Беренче кыз. Күрдегезме Мөнирәне?

Икенче кыз. Чынлап та гашыйк булган!

Өченче кыз. Нигә аның бәхетенә
Карт егет насыйп булган?

Беренче кыз. Кагылмагыз хисләренә.

Икенче кыз. Бу — бары кызык юктан!

Өченче кыз. Яман юлга кереп бара.
Коткарыйк бозыклыктан!

Беренче кыз. Ул үзе «сөям!» дип әйтте...

Икенче кыз. Ышанмагыз! Шаяра...

Өченче кыз. Чыннан да, язган акылдан!
Коткарыйк, табыйк чара!
Бала бер егеткә гашыйк!

Беренче кыз. Бер дә шаккатмасана!
Икенче кыз. Мәхәббәтен үзе әйтте...
Өченче кыз. Мондый хәл юк дөньяда!
Беренче кыз. Мәхәббәттә өченчеләр Комачаулап йөрмәсен!
Икенче кыз. Кызык! Күзәтик артыннан!
Өченче кыз. Ул-бу була күрмәсен! *(Чыгалар.)*

Мөнирә тавышы.
Нигә генә әйттем «Сөям!» диеп,
Йөрим бер суынып, бер янып,
Кешеләрдән генә түгел, хәтта
Үз хисемнән качып, оялып...

Ләлә тавышы *(Мөнирә ядкарен укый)*. Күзләреңә чалынудан куркып, син узган сукмаклардан, юллардан йөрим, ә хыялым, тагын бер тапкыр гына күрергә ашкынып, без очрашкан зәңгәр болынга тартып китерә. Үзем, алларыма килеп чыксаң, поши баласы кебек, качарга әзермен. Әмма очрашудан качып кына котылу мөмкин түгел иде инде. Язмыш озак көттермәде, тагын кавыштырды. Исеңдәме, Сәет абый, без мәктәптә бәйрәмгә концерт әзерләгән идек. Мине җырлату өчен, гармунчыны читтән чакырдылар.

**Мәктәп сәхнәсе. Залда, алдагы рәттә — Мөнирә, кызлар, уртадарак — Сафа абзый.**

Кызлар. Мөнирә җырласын! Мөнирә! Сорыйбыз! *(Кул чабалар.)*
Мөнирә. Әй лә... Мин гармунсыз җырлый алмыйм ич...
Кызлар. Бар гармунчы! Таптык!
Сафа. Әйдә, кызым, ялындырма. Өйдәге кебек җырла!
Бер кыз. Концертыбызны дәвам итәбез. Таллыкул яшьләренең яраткан җыры: «Җиләккә бармам инде!» Җырлый үзебезнең Мөнирә! Гармунда уйнарга Сәет абыйны чакырдык. Әйдәгез, Сәет абый!
Сәет *(залдан Мөнирә янына килеп)*. Мөнирә?..
Мөнирә *(читкә тартылып)*. Сәет абый? Мин бит белмәдем. Кызлар эше бу. Мин куркам. Әти дә килгән...
Сәет. Курыкма. Үзеңне ялгыз урманга барган кебек хис ит.
Мөнирә. Тавышым чыкса ярый ла...
Сәет. Мин сиңа ярдәм итәрмен, Мөнирә. Башладык!

Мөнирә.
Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым,
Сине күргәч, телсез калдым,
Адаштым дип алдаштым...
Әй, булмый ла... *(Китмәкче була.)*

Сәет.
Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде,
Салкын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.

Мөнирә.
Җиләклеккә бармам инде,
Бармам инде, адашмам,
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашмам...

*(Икесе ике якка ташланалар.)*

Мөнирә тавышы. Сәхнәдән ничек атылып төшкәнемне, кая таба йөгергәнемне дә белмим. Һушыма килгәндә мин өйгә таба түгел, кап-кара төнне япа-ялгызым капкара урманга кереп барам икән. Исеңдәме, Сәет абый, минем исемдә: син дә шунда... басмада, күллә йөзеп йөргән кыр үрдәкләренең тавышын тыңлап, моңаеп утыра идең...

**Сәет, гармунын баш астына салып, күккә карап ята.**

Сәет тавышы.
Күзләрең шомырттай кара ич,
Йөрәкне яндырып ала ич,
Утларга, бозларга сала ич,—
Син әле бала ич, бала ич.
Карашың озата бара ич,
Күңелдә төзелмәс яра ич,
Юк, килмә, бик ерак ара ич,—
Син әле бала ич, бала ич.
Карурман эчләре кара ич,
Җиләкләр тезелеп кала ич,
Үзәкләр өзелеп кала ич,—
Син әле, бала ич, бала ич.

Сәет *(тора, урманны тыңлый)*.
Өлгергән ич димәгез,
Җиләкләргә тимәгез,
Миндәй дивана булырсыз,
Яшь кызларны сөймәгез!

Мөнирә *(керә)*. Сәет абый...
Сәет. Мөнирә...
Мөнирә. Тс...с... Кеше ишетә күрмәсен...
Сәет. Ничек килдең?
Мөнирә. Төне буе йокламадым.
Сәет. Мин дә... сине уйладым.
Мөнирә. Мине? Чынлапмы?
Сәет. Әйе, Мөнирә. Ярый әле килгәнсең...
Мөнирә. Мин бик азга гына. Әти усал минем. Ул иртә таңнан эшкә, мин монда йөгердем. Ой, үрдәк бәбкәләре...
Сәет. Кыр үрдәкләре алар.
Мөнирә. Кара, нигә алар курыкмыйлар?
Сәет. Мин аларны кулга ияләштерәм. Мөнирә, курыкма, кил әле монда... *(Гармун телләренә кагыла.)*
Мөнирә. Ой, уйный күрмәгез!
Сәет. Мин уйнарга уйламыйм, Мөнирә. Әнә күрәсеңме, миңа үрдәкләр дә ышаналар. Бир кулыңны. Кер басмага...
Мөнирә. Кермим, Сәет абый...
Сәет. Нигә?
Мөнирә. Сез мине барыбер яратмыйсыз. Бала дип уйлыйсыз. Мин сезне соңгы тапкыр күрергә дип килдем. Башка күренмим... *(Үзе, тыела алмыйча, басмага керә.)* Әй, егылам!
Сәет *(кочагына алып)*. Мөнирәм...
Мөнирә. Сәет абыкаем, зинһар кагылмагыз...
Сәет. Сулышларым белән тартып алырдай булам. Мөнирәм, җиләгем, сине яратмый мөмкин түгел.
Мөнирә. Сәет абый, кирәкми...
Сәет. Мин нинди бәхетле, Мөнирәм...
Мөнирә. Яктыра... Мин кайтам...
Сәет. Килерсеңме, тагын килерсеңме?
Мөнирә. Килермен... *(Сәет кочагыннан ычкынырга тырыша. Сәет үбә.)*
Сафа *(чыбыркы тотып керә)*. Менә син кайда нишләп йөрисең икән, башсыз

кыз! Ә син... ә син... карт башың белән балигъ булмаган кызны аздырып йөрисеңме? Икенче бергә күрсәммә! *(Чыбыркысын шартлата.)* Ычкын моннан, урман карачкысы! *(Сәет чыга.)* Утыр! *(Мөнирә төп башына утыра.)* Мин сиңа ни дип әйттем әле? Күпме тукыдым син җүләр башка сәгать җидедән соң өйдән атлыйсы булма дип...

Мөнирә. Мин кич чыкмадым... таң атканда чыктым...

Сафа. Әле телеңә салынып утырасыңмы? Таң тишегеннән егетләр эзләп чапкан, оятсыз! Мин әйткәннәрне оныттыңмы?

Мөнирә. Онытмадым.

Сафа. Егетләр белән күрсәм, нишләтәм дидем?

Мөнирә. Үтерәм дидең.

Сафа. Әйттемме?

Мөнирә. Әйттең.

Сафа. Ә син нишләдең? Тыңладыңмы?

Мөнирә. Юк.

Сафа. Кем янына килдең?

Мөнирә. Үзең күрдең ич.

Сафа. Мин синнән сорыйм: ни эзләп зимагор янына чаптың? Шул... шүрәле янына!

Мөнирә. Ул шүрәле түгел.

Сафа. Әле яклап маташасыңмы? Сиңа ничә яшь әле?

Мөнирә. Уналты.

Сафа. Ул карачкыга ничә яшь?

Мөнирә. Белмим.

Сафа. Син әле, болай булгач, аның исемен дә белмисеңдер?

Мөнирә. Сәет.

Сафа. Әле, оялмыйча, авыз тутырып, шуның исемен әйтеп торасыңмы? Үзеңнең укучы бала гына икәнеңне оныттыңмы?! Ир-егетләр алар синдәй ачык авызларны төп башына утыртырга, кәкре каенга terәтергә генә торалар! Әллә инде хәрап итеп тә ташладымы үзеңне? Хәзер үтерәм мин аны! Әйт...

Мөнирә. Юк... ул андый түгел...

Сафа. Әйт соңгы сүзеңне!

Мөнирә. Мин аны яратам.

Сафа. Ә?! Йә ходам, ни ишетәм... Ана карыныннан төшүеңә кайчан... Кабатла әле, ни дидең?

Мөнирә. Мин аны яратам.

Сафа. Менә моны күрәсеңме? Мин моның белән, тыңламаса, җирән кашканы да туры юлга кертәм. Әгәренки шул сүзләреңне тагын бер кабатласаң,— ярам! Мин аны яратмыйм, бүген аның янына бармыйм, диген! Йә?! *(Ярсып Мөнирә өстенә бара.)*

Мөнирә. Мин аны яратам!

Сафа. Ах, син әле шулаймы? Атаңа буйсынмыйсыңмы? Кире беткән нәмәстә! *(Арка тирәсенә йомшак кына итеп суга.)* Яратасыңмы?

Мөнирә. Барыбер яратам!

**Чыбыркы шартлавы һәм Мөнирәнең «Яратам! Яратам!» дигән тавышы ишетелеп тора.**

Мөнирә тавышы. Исеңдәме, Сәет абый, сине, балигъ булмаган кызны ялгыш юлга юнәлтүдә гаепләп, районга чакырып, эт итеп сүктеләр, тагын кабатланса, эштән куу белән янадылар. Әмма бернинди чара да безне аерырлык түгел иде инде. Без сирәк кенә, урманда очрашуны дәвам иттек.

**Басмада Сәет Мөнирәне көтә. Караңгы.**

Мөнирә *(кердә)*. Кыйгак-кыйгак!

Сәет. Бак-бак-бак-бак!

Мөнирә. Мине эзләп тап-тап-тап-тап! *(Кача.)*

Сәет. Мин сине бәйле күзләрем белән дә эзләп табам. Мөнирәм...

**Мөнирә кача, Сәет эзли. Ниһаять, Мөнирә — аның кочагында. Үбешәләр. Сәет юри генә егылган була, Мөнирә аны юри генә күтәреп торгызган була. Музыка.**

Мөнирә.
Әллә кем ни генә әйтсә дә,
Кабатлыйм кадерле исемне,
Кояшым чыкса да, батса да,
Барыбер яратам мин сине!

Сәет.
Арада гайбәтләр йөрсә дә,
Кавышу чарасы табылыр,
Ямансу хәбәрләр килсә дә,
Яратам мин сине барыбер!

Мөнирә.
Язмышым, аерма бәхеттән,
Табигать безне тиң яраткан,
Башканы теләмим яшьлектән:
Барыбер мин сине яратам!

**Гашыйклар тавына күтәрелергә баралар. Шул вакыт җыр өзелә. Алар тау итәгендә туктап калалар.**

Ләлә *(ядкарь дәфтәрен дәвам итә)*. Сугыш башланган елны миңа унсигез яшь тулды. Яуга китү хәбәре сиңа көз көне килде. Йә хода, кавышып та өлгермәдек, аерылышабыз да... Язмышларыбызны бәйләп өлгердек, авыл советына барып язылыштык. Әткәйне урман кисәргә озаткан идек. Исеңдәме, Сәет абый, аерылышу көнебез...

Сәет. Безнең сәгать сукты, Мөнирә...

Мөнирә. Исән йөреп, сау кайта күр инде, Сәет абый...

Сәет. Әй, безгә ни булсын, бер ай да узмас, дошманны үз җирендә, көлен күккә очырып, кайтып җитәрмен.

Мөнирә. Шулай гына була күрсен.

Сәет. Кешеләр генә түгел, киек кошлар да әйләнеп кайталар әле.

Мөнирә. Карале, бу кыр үрдәкләре нигә китмиләр, вакыт ич инде?

Сәет. Алар, киткәч, нигәдер кире кайттылар.

Мөнирә. Әллә юлларын сугыш [illegible]деме? Нигә алар якын килмиләр, алар сиңа ияләшкәннәр иде бит?

Сәет. Кичә мин бер үрдәккә аткан идем, әллә...

Мөнирә. Аттың? Сәет абый, нишләдең? Нигә? Ни өчен?

Сәет. Мин бит урманчы гына түгел, сунарчы да. Аерылу төнендә учак ягып, кыр үрдәге белән сыйланып, Гашыйклар тавында икәү генә утыру иде ниятем.

Мөнирә. Хараплар иткәнсең, Сәет абыкаем... Үтердеңме?

Сәет. Үлмәде бугай. Күлгә килеп төшкәч, эзләгән идем, табалмадым. Мөгаен, яралангандыр. Ана үрдәк булды, ахрысы, балалары...

Мөнирә. Риваятьне онытгыңмы әллә, Сәет абый?

Сәет. Нинди риваять?

Ләлә тавышы. Элекке дәверләрдә Гашыйклар тавында түгәрәк тирән күл булган. Туган җирләрен сагынып, тезелешеп, язларын киек кошлар кайтканнар. Көннәрдән бер көнне шул якның сунарчысы, нәни балалары белән күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да, пешереп ашарга ниятләп, ут өстендәге казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, серле үрдәк казаннан күтәрелеп, зәңгәр һавага очкан... Шул көннән соң Гашыйклар тавының матурлыгы күзгә күренеп сулган, күле корыган... Бик озак еллар дәвамында гына тауның гүзәллеген кире кайтара алганнар...

Мөнирә. Онытгыңмы әллә, Сәет абый?

Сәет. Әй, ышанма иске йолаларга, берни булмас!

Мөнирә. Хәерлегә юрыйк... Менә алар нигә кире кайтканнар... Яралы кошны эзлиләр, таба алмыйлар... Нигәләр аттың, Сәет абый?

Сәет. Юкка борчылма, җиләгем, бер үрдәген югалтканнан Таллыкүл корымас. Без язмыштан өстен яңа чор кешеләре! Кара әле минем күзләремә... Онытмассыңмы мине, әйт Таллыкүл буйлары ишетелерлек итеп!

Мөнирә. Менә ядкарь дәфтәре... Сакла... Онытма мине!

Сәет.
Онытмам сине! *(Җырлыйлар.)*
Сакла мәңгегә истәлегемне,
Исә юл җиле, аерылу җиле.
Сау бул, саф гөлем,
Зәңгәр яшьлегем,
Онытма мине!
Онытмам сине!
Калыр еракта Гашыйклар иле,
Кагылыр килеп яшьлегем җиле.
Кайтыр моң булып,
Әйтер мин булып:
Онытма мине!
Онытмам сине!
Тормыш юлыңда, гомерең соңында
Яшьлек дәфтәрен актарсаң иде...
Күңелең үсәр,
Исеңә төшәр:
Онытма мине!
Онытмам сине!

Мөнирә. Әйдә, гашыйклар тавына күтәрелеп ант бирик!

Сәет. Әби-бабайлар әкиятенә ышанасыңмы? Син яшь бала шул әле...

Мөнирә. Борынгыдан калган гадәт, исеңә төшерәм, Сәет абый.

Ләлә тавышы. Шул тау башына менеп, гашыйклар бер-берсен ташламаска, гомер буе тугры булырга, шул урында кабат очрашырга вәгъдә биргәннәр. Кем дә кем антын боза, нинди дә булса бәла килә: ул адәм йә авырый, йә үлә, йә бәхетсез язмышка дучар була...

Мөнирә. Киттек, Сәет абый!

Сәет. Әйдә, күңелең булсын... *(Гашыйклар тавына меналәр.)*

Мөнирә.
Без икәү — Гашыйклар тавында,
Төн таңны озаткан чагында.
Сәет.
Күзләрне тутырып карыйм бер
Сагышлы аерылу таңында.
Мөнирә.
Аста — күл, үрдәкләр тирбәлә.
Китәргә юллары бүленгән.
Сәет.
Мин барлык көчләремне җиңәрмен,
Мин өстен калырмын үлемнән!
Мөнирә. Онытма бу төнне, бу таңны,
Сәет. Ә мине? Киткәч тә онытырсың...
Мөнирә.
Бөгелә-сыгыла гармун уйный,
Ул ничек онытылсын!
Сәет.
Сагынганда нихәл итәрмен?
Көтәрсеңме мине?
Мөнирә. Көтәрмен!
Сәет. Вәгъдәме?
Мөнирә. Вәгъдә!
Сәет. Очрашу таңнарын без көтик!
Мөнирә.
Көтәрмен. Вәгъдәмне җил алмас.
Сүзләрне җыр белән беркетик!
Сәет. Гашыйклар тавында
Мөнирә. Гашыйклар янында

Бергә. Вәгъдәм дә, ядкарь дә югалмас!

## Вәгъдә җыры

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында,
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.
Без тауның башында,
Мәңгелек каршында —
Гашыйклар кавышкан урында.
Җанда — Ай нурлары,
Хисләр саф, югары:
Биектә — Киек каз юлында.
Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге Җир алдында:
Аерылган көннәрдә,
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

Ләлә *(ядкарь укуны тәмамлап)*.
Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә:
Булыйк гел Гашыйклар тавында...

Ядкарь шунда өзелә...

Сәет. Шул көнне мин фронтка киттем. Аннан соңмы? Окоп, үлеш, кырылыш... Соңыннан гына белдем: бер һөҗүмнән соң өйгә «үлде» дигән хәбәр җибәргәннәр. Дошман тылында йөрдем, үле гәүдәләр өстеннән шуыштым, чәнечтем, үтердем. Гашыйклар тавы яшьлекнең хыялый бер мизгеле булып кына калды. Өстеңә сызгырып бомбалар яуганда, һәр адымда үлем сагалаганда яшьлек хатирәләре сүнә икән. Камышлыкта калып, күпме газап чиктем,

яраландым, әсирлеккә эләктем, качтым, үзебезнең якка чыктым. Өйдәгеләр өчен мин — һәлак булган кеше... Аннан соң госпитальдә синең белән очрашу...

Л ә л ә. Шуннан соң без икебез монда — Себергә минем туган җиргә киттек. Нигә син минем белән киттең, Сәет? Нигә Гашыйклар тавына, Мөниргә кайтмадың?

С ә е т. Әллә әсир дигән хурлыклы тамга белән кайтып күренәсе килмәде... әллә... үзем дә аңлата алмыйм хәзер.

Л ә л ә. Нигәләр генә сөйләттем...

С ә е т. Мин сине алдамадым, Ләлә. Мин сине бик тә ихтирам итәм... Син булмасаң...

Л ә л ә. Ихтирам гына иткәнсең шул...

С ә е т. Еллар узды, җилләр исте — үзебезнең Таллыкүлне искә төшереп, сулар акты — тирбәлеп, атылган үрдәкне, юллары бүленгән киек кошларны хәтерләтеп... тауга менгәндә тын кысыла башлады... без йөгереп менгән Гашыйклар тавын сагындырып... Мин түгелме саф җанлы табигать баласы Мөниргә: «Кайтырмын, көт!» — дигән егет? Гомеремнең соңгы еллары — тоташ газап... Ник кайтмадым Таллыкүлгә, мин бит вәгъдәләр бирдем Мөниргә, Гашыйклар тавына. Гөнаһсыз пакь күңелле яшүсмер, бәлки, мине көткәндер тилмереп... Әллә ничә тапкыр кайтырга, бу фани дөньядан киткәнче Мөнирәдән бәхиллек сорарга ниятләп карадым. Дүрт ел үлем белән көрәшкән һәм җиңеп чыккан солдатның шуңа батырлыгы җитмәде. Хәзер, бик теләсәм дә, кайта алмыйм... Вәгъдәгә хыянәт... Әллә, мин әйтәм, язмыш шуның өчен үземне каһәрлиме? Ярты гәүдәм хәрәкәтсез...

Л ә л ә. Сәет, тынычлан...

С ә е т. Хәзер... бөтен өмет синдә, Ләлә... Әгәр мин... әманәт тапшырсам... син... анда... бара алырсыңмы?

Л ә л ә. Кая?

С ә е т. Гашыйклар тавына. Мөниргә.

Ләлә. Гашыйклар тавына? Мөниргә? Мин?

С ә е т. Әйе. Син.

Л ә л ә. Мине... үзеңнең хатыныңны... аның янына? Юк! Юк!

С ә е т. Ләлә, бу... минем әманәтем. Мин... дөньядан аның бәхиллеген алмыйча китә алмыйм.

Л ә л ә. Мин сине шундый хәлдә ташлап китимме? Юк, Сәет...

С ә е т. Минем өчен борчылма...

Л ә л ә. Юк, Сәет, булмый... Кузгатма иске яраларыңны. Врач буларак әйтәм.

С ә е т. Бу... минем соңгы үтенечем...

Л ә л ә. Мин... нишләргә тиеш?

С ә е т. Таллыкүл... Мөнирә Идрисовага шушы тасмадагы җырны тапшыр...

Л ә л ә. Ярый, Сәет, мин барам.

С ә е т. Мин сиңа ышанам, Ләлә... Сәлам барысына да... Таллыкүл камышларына. Гашыйклар тавына. Зәңгәр яшьлегемә... Хәерле юл!

**«Яралы кош» җыры яңгырый.**

# Икенче акт

**Җәй ахыры. Якында гына шәрә тау. Суы аз гына калган, сазлыкка әверелгән күл. Басма. Анда, аякларын салындырып, Мирсәет белән Алсу утыралар.**

М и р с ә е т. Их, җаныем, суларда...

А л с у. Су чәчрәтеп уйнарга!

М и р с ә е т. Чәчрәтерлек суы да юк...

А л с у. Камышлары бар ич. Мирсәет, күлгә керергә курыкмыйсыңмы?

М и р с ә е т. Медаль аласың киләмени?

А л с у. Нинди медаль?

М и р с ә е т. Суга батучыны коткарган өчен!

А л с у. Аласым килә! Килә!

М и р с ә е т *(балакларын сызганып)*. Бәхил бул, киттем! *(Төшә.)*

А л с у. Кара аны, батсаң-нитсәң, кайтып керәсе булма, җаныңны алырмын!

М и р с ә е т. Минем җаным юк, Алсу!

А л с у. Кайда?

М и р с ә е т. Саклык кассасына салдым.

А л с у. Нигә?

М и р с ә е т. Васыять калдырам. Кайтмый калсам, барып алырсың.

А л с у. Үзең булмагач, синең җаның белән нишлим мин?

М и р с ә е т. Ярар, алайса, үзем белән алып китәм... Коткарыгыз, батам!

А л с у. Әллә чынлапмы?

М и р с ә е т. Валлаһи, батам! Алсу, бир кулыңны!

А л с у. Мине дә үзең белән күл төбенә алып китмәкче буласыңмы? Юк инде... Кара, мин сине шаярасың дип торам... Мә, тот!

**Таяк сузуга, Мирсәет аны үзенә тартып төшерә. Аның кычкырган, бераздан тынган тавышы гына ишетелә. Алар күтәреләләр. Алсу — Мирсәетнең кочагында...**

Әрсез! Мәхәббәтсез! Чәчләрне туздырып бетердең...

М и р с ә е т. Иртәгә китеп югалачак сөйгән ярыңны коткарган өчен! *(Камыш җикәне суза.)* Төсем итеп сакла!

А л с у *(ала)*. Сине сагынып мин дә шулай саргаерга сүз бирәм. Әбәү, кыяфәтсез, ю тәпиләреңне!

М и р с ә е т *(аякларын юып)*. Әллә нясе бар инде бу күлнең? Аяктан тартты...

А л с у. Аяк юарлык суы да булмаган күлгә кем ия булсын...

М и р с ә е т. Алсу!

А л с у. Әү!

М и р с ә е т. Әгәр мине бик сагынсаң, аягыңны суга тык!

А л с у. Ярар. Аягымны гына түгел, башымны да тыгармын, яме?

М и р с ә е т. Ярар. Бу күлнең дә нясе булган, ди...

А л с у. Әкият! Безнең оныклар нинди әкият сөйләгән булырлар икән?

М и р с ә е т. «Борын-борын заманда Таллыкүлдә бакалар бакылдаган, имеш...»

А л с у. Янәсе! Әй, безгә тавы ни дә күле ни... Барыбер китеп югаласы. Син — иртәгә...

М и р с ә е т. Син — бер елдан. Әле шушы кипкән бака күлен дә сагынган булырбыз... Мин бүген шушында узган балачагым белән саубуллашам.

А л с у. Кит аннан, котсыз, минем белән саубуллашырга килгән дисәм... *(Үпкәләп басмадан китә.)*

**Мирсәет.** Тукта инде, үпкәләмә. Аерылышу кичендә булса да, күзләремә караган бул. Яратам ич мин сине...

**Алсу.** Һи, сез тасма телләргә ышансаң... Китәсез дә онытасыз!

**Мирсәет.** Ә сез, кызлар — җилбәзәк күбәләкләр. Без китү белән...

**Алсу.** Ә сез, егетләр... берәр чибәр кыз күрсәгез.....

**Мирсәет.** Ә сез — кызлар...

**Алсу.** Ә сез... егетләр... барыгыз да вәгъдәсезләр!

**Мирсәет.** Кем? Безме вәгъдәсезләр?

**Алсу.** Менә борынгылар ярата да, көтә дә белгәннәр...

## Дуэт

Барсы да узганнар,
Барсы да үткәннәр,
Элек тә кочканнар,
Кочкан-үпкәннәр.
Таһирлар киткәннәр,
Зөһрәләр көткәннәр,
Барсы да узганнар,
Барсы үткәннәр.
Өзелеп көткәннәр,
Түземнәр, сабырлар
Гашыйклар тавында
Мәңгегә калырлар.
Барсы да узганнар,
Барсы да үткәннәр,
Гашыйклар ярларын
Сагынып көткәннәр.
Егетләр киткәннәр,
Яшь кызлар көткәннәр,
Барсы да узганнар,
Барсы үткәннәр.
Өзелеп көткәннәр,
Түземнәр, сабырлар
Гашыйклар тавында
Мәңгегә калырлар.
Ә безнең мәхәббәт
Узмаган, алдадыр,
Гашыйклар тавында
Кавышыр таңдадыр.
Җил булып исәрмен,
Су булып агармын,
Мин сине югалтмам,
Эзләп табармын.
Өзелеп көткәннәр,
Түземнәр, сабырлар
Гашыйклар тавында
Мәңгегә калырлар!

**Алсу.** Мирсәет, куып тот мине! *(Аяк астыннан иске дәфтәрне аңа ата).*

**Мирсәет.** Алсу, тукта! *(Каршыларына Ләлә килеп керә.)*

**Ләлә.** Исәнмесез, матурларым?

**Мирсәет.** Исән булмасак, әллә син доктормы?

**Алсу.** Әссәләм-вәссәләм!

**Ләлә.** Әйе, мин чыннан да доктор. Әйтегез әле, Гашыйклар тавы кайда?

**Мирсәет.** Алдыгызда бит... әнә!

**Ләлә.** Шушымы?

**Мирсәет.** Ышанмасаң — анысы синең эш.

**Ләлә.** Ә Таллыкүл?

**Алсу.** Әллә сез Каф тау артыннанмы?

**Ләлә.** Себердән. Таллыкүл чыннан да шулмы?

**Мирсәет.** Шул димен ич инде!

**Ләлә.** Талы да, күле дә юк икән...

**Мирсәет.** Кирәге дә юк!

**Ләлә.** Мин... Мөнирә Идрисованы эзлим. Аны каян табарга?

**Мирсәет.** Алсушка, аның Мөнирә Идрисова белән сөйләшәсе килә!

**Алсу.** Барсын, сөйләшсен... бик кирәк булгач... Шушы тирәдә Мөнирә Идрисова!

**Мирсәет.** Әнә! Алсушка, йөгер, totам!

**Алсу.** Тоттырмыйм! *(Чыгып йөгерәләр.)*

**Ләлә.** Әллә алдадылармы Гашыйклар тавы дип... Корыган күл, сулган урман... Тукта, нигә соң әле мин үз иремнең сөйгәненә килдем? Кире китәргәме әллә? Юк, мине монда Сәетнең әманәте китерде... Үзенне ничек тә җиңәргә тырыш, Ләлә... Бу нинди чәчәкле-җырлы дәфтәр? *(Ала, укый.)*

Каршылыйк яшьлекнең таңын
Яратып, кочак җәеп...
Онытма мине, Мөнирә!
Онытма мине, Сәет!
Ядкарь дәфтәре... Ташлаганнар... Тынычлан, йөрәк... димәк, көндәшем Сәетне күңеленнән йолкып аткан.

**Яңа салынган өй ягыннан Өмет чыга. Болдырга утырып тәмәке кабыза.**

**Ләлә.** Исәнмесез? *(Өмет дәшми.)* Исәнмесез?

**Өмет** *(теләмичә).* Исән әле.

**Ләлә.** Зилаировларның өе шушымы?

**Өмет.** Шушы булса, ни әйтерсез?

**Ләлә.** Әллә сез Зилаиров нәселеннәнме?

**Өмет.** Булуы да ихтимал. Зилаировның кайсысы кирәк?

**Ләлә.** Сәете.

**Өмет.** Аның исеме генә калды... мәрмәр ташта. Үлгәннәрнең кемгә кирәге бар?

**Ләлә.** Сиңа, миңа...

**Өмет.** Сиңа нигә ул?

**Ләлә.** Мин аны бераз белә идем.

**Өмет.** Белә идегез? Әллә очраштыгызмы?

**Ләлә.** Фронтта. Ул яраланган иде.

**Өмет.** Аннан соң... терелдеме?

**Ләлә.** Терелде. Тагын һөҗүмгә китте.

**Өмет.** Сез аны исән чагында чыннан да күрдегезме?

**Ләлә.** Чыннан да.

**Өмет.** Кайчан?

**Ләлә.** 1945 ел. Май башы... Германия.

**Өмет.** Шуннан соң... сигезенче майда һәлак булды дип, икенче тапкыр үлем хәбәре килде.

**Ләлә.** Кызганыч.

**Өмет.** Нинди иде ул? Төсе, холкы, табигате? *(Аракы алып чыга, өстәлгә куя).* Егылып эчүне ташласам да, бу унай белән әзрәк ярый торгандыр... Утырыгыз... *(Рюмкаларга сала).* Искә алыйк. *(Эчә. Ләлә авыз тидерә).* Элегерәк килсәгез, өстәлдә кыр үрдәкләре булыр иде.

**Ләлә.** Алар ташлап киттеләрме?

**Өмет.** Без, ягъни мәсәлән, нефтьчеләр, аларны кырып салдык. Музейга куярга да калмады.

Л ә л ә. Сездә монда да бик каты сугыш булып узган икән... Табигать белән...

Ө м е т. Әйе. Сугыштык. Без җиңдек! Күкрәк тулы орден-медаль! Капкалап утырыгыз...

Л ә л ә. Сез җырлыйсызмы?

Ө м е т. Без бер генә җыр беләбез: «Салып җибәр салганны, сорама каян алганны! Салып җибәрсәң салганны, баса йөрәк янганны!» Әти кеше җырлый идеме?

Л ә л ә. Аның тавышы бик тә ямансу, моңлы иде.

Ө м е т. Берәр җырын хәтерләмисезме?

Л ә л ә. Онытылган. Искә төшерермен.

Ө м е т. Ул... ниндирәк иде?

Л ә л ә. Күзләрендә ниндидер тирән сагыш... синеке кебек. Чәчләре дә синеке кебек каты... кара иде... Сез әллә аның туганымы?

Ө м е т. Юк. Мин аның туганы түгел. Мин Сәет Зилаировның үзе киткәч туган малае. Ягъни мәсәлән, Өмет...

Л ә л ә. Сәет Зилаировның малае бармыни?! *(Сикереп тора, үзен җыйып, утыра.)*

Ө м е т. Балалары барлыгын белмичә теге дөньяда ятучылар өчен! *(Эчә.)* Аның малае гына түгел, оныгы да бар әле... Әнә үзе килә... ягъни мәсәлән, минем малаем...

М и р с ә е т. Исәнме!

Ө м е т. Нихәл! Менә... бабаңны фронтта күргән кеше килгән.

Л ә л ә. Ә... ә... без таныш инде.

Ө м е т. Бабаңны соңгы тапкыр күргән...

М и р с ә е т. Ну и что?.. Кайдадыр бер гармун ята бугай. Бир әле!

Ө м е т. Иске өйдә. Кереп ал! *(Мирсәет, сызгырып, өйгә керә.)*

Л ә л ә. Нигә ул... әтисе белән шулай...

Ө м е т. Аралар салкын. Әнисе белән калада... аерым...

М и р с ә е т *(гармунда русча кой акыртып чыга.)* Җаны бар әле моның!

Ө м е т. Бабаңның җаны анда... Аны да, мине дә армиягә шул озатты. Хәзер сине...

М и р с ә е т. Хәзер Гашыйклар тавына менәбез.

Ө м е т. Бабай-әбиләрең антны таң алдыннан биргәннәр...

М и р с ә е т. Безгә барыбер! Озатырга киләсеңме? Килмәсәң дә ярый!

Ө м е т. Киләм.

М и р с ә е т. Прощай! *(Гармун уйнап чыга. Өстәлдәге аракыны кесәсенә алып тыга.)*

Ө м е т. Безнең якты киләчәк...

Л ә л ә. Өмет, бу дәфтәр сезгә таныш түгелме?

Ө м е т *(дәфтәрне ала, актара)*. Бу бит әнинең ядкарь дәфтәре. Каян алдыгыз?

Л ә л ә. Җирдә... аяк астында ята иде.

Ө м е т. Әйе... әйе... искә төшә. Димәк, мин аны яңа өйгә күчкәндә, чыгарып атканмын... Дөресен әйткәндә, мин аны, югалтып, эзләп тә карадым... Аннары кул селтәдем... Кызык... Ниләр язды икән?

Л ә л ә *(ядкарь дәфтәрен укый.)*

Йөзләрдә хәсрәте күренер,
Күзләрдә тамчылар күренмәс,
Кошларның юллары бүленер,
Ярымның юллары бүленмәс.
Толымым билемә уралыр,
Өметем кайгыга уралмас,
Киек кош юлларда югалыр,
Сөйгәнем яуларда югалмас!

*(Бер өлешен Өметкә бирә.)*

Ө м е т.

Көйләмә син миңа, авылым,
Яуларда үлгәннәр бәетен,
Туктатып сугышлар давылын,
Барыбер кайтыр ул — Сәетем!

Л ә л ә.

Баламны күкрәккә кысам мин:
Ул синә охшаган шул кадәр!
Әйтмәгез, тыңламыйм, ышанмыйм:
«Үлде!» дип килсә дә йөз хәбәр...

М ө н и р ә *(сабый баласын кулына тоткан)*. Өметем минем, асыл егетем, үчтеки, үчтеки! Әттәне сагындыңмыни, мин дә бик сагындым шул аны.

Хәзер кайтыр, озак көттермәс...

*(Чыбыркы тотып Сафа керә.)*

С а ф а. Көтмә, кызым, кайтмас Сәетең.

М ө н и р ә *(сабый булып)*. Нигә алай дисең, дәү әттә?

С а ф а. Үлем хәбәре килдеме, килде — факт! Тагын бер факт кирәкме? Урман кискәндә берәүне очраттым. Ул Сәетне әсирлектә күргән. Аннан соң кара кәгазь килде.

М ө н и р ә. Ул... үле килеш күргәнме?

С а ф а. Тиресе белән сөяге генә калган иде, ди... Бичара...

М ө н и р ә. Сөйләмә, дәү әткәй, минем әттә бичара түгел!

С а ф а. И кызым, атаң сүзен тыңламый ялгыштың. Әйдә, киттек үзебезнең өйгә, атаң нигезенә. Саргайма яшь-яшь килеш, үлгән иреңне көтеп... Тәрәзәне кадаклыйбыз да...

М ө н и р ә. Ачуланма, дәү әттә, без кайтмыйбыз. Без әттәне көтәбез.

С а ф а. Тач үземә охшагансың, кире беткән нәмәстә, тагы чыбыркы көтәсеңме? *(Селтәнә.)*

М ө н и р ә. Ул кайта, ул монда кайта, без моннан китмибез.

С а ф а. Әй бала, бала... Үзең дә һаман нарасый шул... Чыбыркы түгел, тел тидерергә дә жәл... Теге вакытта чынлап суктырасы калган. *(Чыгарга кузгала)*.

М ө н и р ә *(чыбыркыны ала)*. Әткәй!

С а ф а. Акылыңа килдеңме әллә?

М ө н и р ә. Онытып калдыргансың...

С а ф а. Балалы өйнең матчасында чыбыркы булсын! *(Чыга)*.

Ө м е т *(дәвам итә)*.

Синнән тик бер ядкарь-дәфтәрең...
Югалтмый кадерләп сакладым.
Төшемдә күрәм дә сагынам
Өметнең яшь бала чакларын.

М ө н и р ә. Өмет балам, нишләдең?

Ө м е т. Берни дә эшләмәдем.

М ө н и р ә. Кил әле, кил. Күлмәгең ертылган, борының канаган. Сугыштыңмы әллә?

Ө м е т. Сугыштым ла...

М ө н и р ә. Кем белән?

Ө м е т. Түбән оч малайлары белән.

М ө н и р ә. Кем башлады? Алармы? Хәзер әниләренә барам.

Ө м е т. Үзем!

М ө н и р ә. Нигә?

Ө м е т. Мыскыл итмәсеннәр.

М ө н и р ә. Ни дип мыскылладылар?

Ө м е т. Мине үрдәк диләр...

М ө н и р ә. Шуңа ачуландыңмы?

Ө м е т. Тагын бер әйтеп карасыннар!

Мөнирә. Дөрес әйткәннәр, Өмет. Без чынлап та үрдәкләр.....

Өмет. Син дә мыскыл итәсеңме?

Мөнирә. Туктале, тыңла мине... «Үрдәк» дигәнгә бер дә үпкәләмә. Нәселебезгә мәңге чәпәлгән кушамат ул. Шәҗәрәбездә җиденче бабабыз да, аннан элгәреләре дә — үрдәкләр. Иң әүвәлге Әнкәбез — Гашыйклар тавындагы Серле үрдәк. Аны явыз бәндәләр атып Җиргә төшергәннәр. Канатлары сынган яралы кош Җирдә тормыш итә башлаган. Барыбер гел-гел сагышланып зәңгәр күккә караган. Шуңадыр без — яралы, моңлы нәсел. Үрдәкләр без!

Өмет. Минем үрдәк буласым килми!

Мөнирә. Буласың киләме, килмиме, син дә үрдәк, балам. Табигать язган язмышны син генә үзгәртә алмыйсың.

Өмет. Бел: кеше маймылдан килеп чыккан!

Мөнирә. Каршы килмим. Кайбер адәмнәр, чыннан да, маймылдан яралгандыр. Без — Таллыкүллеләр — кошлар нәселеннән...

Өмет. Каян алып әйтәсең моны, әнкәй?

Мөнирә. Хыялда да, төштә дә гел кош булып очам. Маймылдан яралган булсам, агач башына үрмәләүдән узмас идем. Нигә соң мин биеккә — кошлар югарылыгына күтәреләм дә уяна-уяна гына Җиргә төшәм?..

Өмет *(укый)*.
Нинди уй бу газиз башымда:
Берсе дә аңламый иделәр.
«Өметең унсигез яшендә,
Әллә син хыялый...» — диделәр.

Ләлә.
Кыен ул йокысыз төннәрдә
Җилләр дә тәрәзә чиртмәсә...
Хәсрәтем сөйләргә кемнәргә?
Өметем-балам да читләшә?

Өмет.
Өметем-баламның һәр сүзе
Ут булып йөрәккә уелган.
Кул тартмый бу хакта язарга...
Гашыйклар тавына ни булган?

Бульдозер гөрелтесенә халыкның шаушуы кушыла.

Мөнирә. Тукта! Сүндер моторыңны!

Өмет тавышы. Ни кирәк сезгә?

Мөнирә. Гашыйклар тавын мәсхәрәләргә без рөхсәт итмибез!

Өмет. Рөхсәт итмисез?! Сез? Безгә?! Монда бораулау эшләре башлана. Приказ!

Мөнирә. Без аны дөрес түгел дип табабыз!

Өмет. Китегез юлдан!

Мөнирә. Тапта! Үткәрмибез!

Өмет. Дәүләт планын өзгән өчен җавап бирерсез! *(Танып)*. Әнкәй?! Син?! *(Юлдан күтәреп ала)*.

Мөнирә. Йа алла... Өмет?.. Син?! Өздең өметләремне... Ник шуңа ризалаштың?

Өмет. Мин кушканны үтим. Туктале, нишләп юкка тавыш куптарасың? Котыртып, халыкны күтәргәнсең...

Мөнирә. Беләсең ич Гашыйклар тавының изге икәнен. Ул — Таллыкүлнең иманы.....

Өмет. Изге... иман... Муллалар сүзен сөйлисең.

Мөнирә. Мәңге искермәскә тиешле йолалар бар. Гашыйклар тавы...

Өмет. Җитте! Монда дини картлар корбан чалалар. Димәк, бу урын, начальник әйткәнчә, искелек калдыгы. Без аны тармар итеп, хәрабәләрендә яңа тормыш корабыз!

Мөнирә. Гашыйклар тавында нефть юк!

Өмет. Син беләсеңме, безме?

Мөнирә. Тау астында су агып ята.....

Өмет. Нәрсәгә таянып әйтәсең?

Мөнирә. Риваятькә! Үрдәк киткәннән соң аның күле тау астына качкан.

Өмет. Дин әкиятләре!

Мөнирә. Борынгылар хак әйткәндер: тавын ташлап киткән үрдәк менә шуңа күрә кайтмый да инде...

Өмет. Хыялый! Гомерең буе кайтмаган иреңне көтеп картайдың. Җүләр син, әнкәй! Без — эш кешеләре! Эш! Эш! Йолага килгәндә, аңла: чор — башка, җыр — башка, яшьләр, машиналары булмаса, тауга күтәрелергә иренәләр. Кайда туры килә... шунда...

Мөнирә *(Өметнең яңагына суга)*. Оятсыз!

Өмет. Ах, шулаймы?! Барыбер безнеңчә булыр!

Ләлә *(укый)*.
Очалмый төшкәндер — яралы...
Таллыкүл суында киек кош.
Хәбәр бу — юллары урауды,—
Көтәрмен унар җәй, унар кыш.

Өмет.
Күзәтәм киек кош эзләрен,
Китәрдәй булам ла кушылып,
Уянып язларын, көзләрен
Күңелем җилпенә кош булып...

Ләлә.
Карурманда юри адашулар
Калды, ахры, матур төш булып,
Үзең кайталмасаң, төшләремә
Кайтчы, зинһар, очар кош булып...

Мөнирә. Сә-е-т!

Сәет. Әү-ү!

Мөнирә. Син кайда?

Сәет. Әллә кайларда!

Мөнирә. Тавышың кайтты, үзең — юк!

Сәет. Кичер, Мөнирә, мин әлегә кайталмыйм!

Мөнирә. Сине шундый күрәсем килә, Сәет...

Сәет. Мөнирәм, көт!

Мөнирә. Исән генә бул, Сәетем, сабыр канатларым сынганчы көтәрмен.

Сәет. Мин Серле үрдәк белән бергә кайтырмын!

Мөнирә. Син әле үзең киткәч туган улың Өметне дә күрмәдең. Ул инде ир-егет, үзеңә охшаган...

Сәет. Улым? Өмет? Күзләре нинди? Чәче?

Мөнирә. Тач үзең инде.

Сәет. Каян алдың шундый ягымлы исемне?

Мөнирә. Әллә... үзеннән үзе... ихластан...

Сәет. Әй гармунымны сагындым, Мөнирә. Аңа тузан кунып, телләре кугәреп беткәндер инде.

Мөнирә. Сайраплар тора. Оныгың уйный.

Сәет. Минем оныгым да бармыни? Исеме ничек?

Мөнирә. Мирсәет.

Сәет. Тагын бер Сәет?

Мөнирә. Мин аңа тугач ук шулай дип дәштем. Башка исем юк.

Сәет. Их, Мөнирәм, гармунда уйнап, сине җырлатып, Таллыкүл урманнарында адашырга!

Мөнирә. Әйдә, адашыйк соң...

**Яшьлектән, ап-ак томан эченнән, ап-ак күлмәк кигән кызлар пәйда була.**

Беренче кыз. Мәхәббәтең кайда? Сәетең?

Икенче кыз. Калды дәфтәр битендә...

Өченче кыз. Ялгыз саргаюлар читен лә...

Беренче кыз. Яшьлегеңне зая үткәрдең...

Өченче кыз. Их, Мөнирә, бик тә ялгыштың...

Мөнирә. Араларны Өмет якынайта. Әнә! Әнә! Сәет! Ул кайта! *(Җырлый)*.

Карурманга барган идем,
Юри генә адаштым,

Сәет.

Мине күргәч, телсез калдың,
Адаштым дип алдаштың.

Мөнирә.

Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде... Сәет, элекке кебек җырла!

Сәет. Тырышам бит...

Мөнирә. Без элек тырышып җырламадык, үзеннән үзе...

Сәет. Ничек җырлый идек соң без, онытылган.

Мөнирә. Дәртле, сөенечле, өметле иде җырыбыз. Хәзер авыр хәсрәт тавышында. Әйдә, элеккечә җырлыйк...

Сәет. Җиләклеккә барма инде,
Барма инде, адашма...
*(Үзе дә, тавышы да югала)*.

Мөнирә. Сә-ет! А-у-у! Син кайда?! Ник дәшмисең?..

Өмет *(укый)*.

Өмет балам, икәү генә белик.
Уйга калып, таугa менәрсең...
Язу авыр моны: бер укырсың,
Акылыңа килеп, миннән соң...

Мөнирә *(тәсбих тартып, мөнәҗәт әйтә)*.

Халык китәр уңга-сулга,
Изге гамәл һич кылмаслар,
Ләкин мал күп булыр кулда,—
Менә шундый заман җитәр...

Өмет. *(кызмача кайтып керә)*. Һо, абыстай! Абстайновка шундый диген, ә?

Мөнирә. *(дәвам итә)*. Ил гыйльменә уку бетәр...

Өмет *(бер торгәк акча чыгарып ыргыта)*. Ал!

Мөнирә. Мәктәпләрне вәйран итәр...

Өмет. Ал дим! Премия!

Мөнирә. Галимнәрдән чалма китәр...

Өмет *(аракы чыгарып)*. Стакан!

Мөнирә. Менә шундый заман җитәр...

Өмет. Закуска!

Мөнирә. Хатыннардан оят китәр!

Өмет. Нәрсә мыгырданасың?

Мөнирә. Балалардан шәфкать китәр...

Өмет. Өеңдә динне пропагандалаган өчен эшеңнән кудылар. Мине, партийный кешене, позорить итәсең!.. Акчаны азсынасыңмы?!

Мөнирә. Миңа хәрам акчалар кирәкми.

Өмет. Нәрсә, хәер акчалары китерәләрме әллә?

Мөнирә. Мин беләм: сез эшләмәгән эш өчен, алдап, премия аласыз...

Өмет. Син аңла, алла бәндәсе, алдамасаң, премия тоттырмыйлар. Дәүләт безне алдый, без — дәүләтне! Ике як та канәгать. Тормыш — ул бер-береңне алдау. Менә вот син месеннә дә алдаганнар... Ярар, булган тәк булган... Но мине бу дөньяга алдап китергәнсез икән... ник әле мин алдамаска тиеш?! Хәләл ни, хәрам ни — безгә барыбер! Прощай, мамаша, не горюй, не грусти, пожелай нам доброго пути! *(Чыга)*.

Ләлә *(укый)*.

Авылдан шәһәргә күчәләр.
Өмет тә күченә. Мин калам.
Берсе дә аңламый ич алар:
Юлларга чыгам да тукталам.
Язмышым нигезен калдырып,
Юк, китә алмыйм мин авылдан,
Сәетем, югалтып, каңгырып,
Эзләсә Гашыйклар тавыннан?
Өнемдә, эшемдә, төшемдә,
Аңымда, җанымда, хисемдә...
Ауларга озаткан кичемдә
Әйтелгән вәгъдәләр исемдә.

Өмет *(укый)*.

Син уяткан яшьлегем дә монда,
Вәгъдәләшкән тавым шушында.
Еракларданн тоям сулышыңны
Таллыкүлнең синсез кышында.

Өмет. Әнкәй, исәнме?

Мөнирә. Ничек килдең, балам, күз ачкысыз буранда?

Өмет. Сине кар күмеп китмәдемени әле? Әйдә, киттек! Машинамны Зирекледә калдырдым.

Мөнирә. Зиреклегә кадәр юл йөрерлекме?

Өмет. Йөрерлек! Киттек!

Мөнирә. Рәхмәт төшкерләре, юлны ачкансыз икән.

Өмет. Биклә ишегеңне!

Мөнирә. Кыстама, балам, мин моннан китмим.

Өмет. Таллыкүлдә бер җан әсәре дә юк... синнән башка... Яңа калада яңа квартирда уты балкып, кайнар суы агып, газы янып тора... Йә, әнкәй...

Мөнирә. Үзегезгә ошый икән, рәхәтләнеп яшәгез.

Өмет. Киттек!

Мөнирә. Китмим. Бер йомышым гына бар барын...

Ө м е т. Әйт.

М ө н и р ә. Атнага бер булса да, юлын ачып тора алмассыз микән?

Ө м е т. Монысы нигә тагын?

М ө н и р ә. Әткәң кайтканда юлда адашыр...

Ө м е т. Их, әнкәй, саташасың түгелме?

М ө н и р ә. Бер дә саташмыйм, балам, әткәң юлга чыгарга җыена.

Ө м е т. Каян синдә шундый уй?

М ө н и р ә. Бүген төшемдә Гашыйклар тавындагы күлне күрдем. Серле үрдәк, төшәргә ниятләп, күл өстендә әйләнә, имеш. Бер канаты каерылса да, кайткан, җанаш... Кайта болай булгач әткәң, әзерлән!

Ө м е т. Бичара. Төшкә ышанасың...

М ө н и р ә. Ул исән. Күңелем тоя: ул кайтырга әзерләнә...

Ө м е т. Әнкәй, уян!..

Л ә л ә. Үрдәкләр төшмичә китәләр.
Таллыкүл чалт аяз... юк томан.
Минутлар, сәгатьләр үтәләр
Кавышалмый Сак белән Сок сыман.

Ө м е т. Бу ялгызлык ник картайта икән,
Аңлат миңа шуны, төшендер.
Ядкарь булып калсын оныкларга:
Бу төш, бәлки, соңгы төшемдер...

М ө н и р ә. Сәет, зинһар, төшемдә булса да, биш минутка гына кайт. Соңгы тапкыр сорыйм...

С ә е т. Исәнме, матурым?

М ө н и р ә. Әлегә исән. «Матурым» дидең... Сине көтә-көтә әллә картаям да инде... Матурлыгым, исәнлегем улыма, оныгыма күчте, ахры...

С ә е т. Карт көнендә нигезеңдә ялгызың калгансың түгелме соң? Балаларыбыз — Өмет, Мирсәет кайдалар?

М ө н и р ә. Киттеләр. Барысы да киттеләр. Таллыкүлдә — бер үзем.

С ә е т. Әллә бөтенләй ташладылармы үзеңне?

М ө н и р ә. Өмет күпме ялварды — күчмәдем. Рәнҗемим. Хәлемне белеп тора.

С ә е т. Хәлең ничек, Мөнирә?

М ө н и р ә. Минем хәлем ярыйсы ла ул... Таллыкүл өчен җаным әрни. Яшьләр Таллыкүлне ташладылар, бабаларыбыз калдырган юлдан каерылдылар: риваятькә, изге Җиребезгә хыянәт иттеләр. Матурлыгын файдаландылар да, картайтып, ямьсезләтеп, алыр нәрсәсе калмагач, ташлап киттеләр. Ничек сызланмыйсың: ничә гасырлар сыналган иң асыл гадәтләрне, мең еллар сабыйлар бишеген тирбәткән моңны-телне ташладылар...

С ә е т. Чыннан да, Таллыкүлгә ни булган? Таныйрлык та түгел. Кыр үрдәкләре кайткан вакыт... Берәү дә күренми... Әллә мин гаепле соң? Теге вакытта...

М ө н и р ә. Без һәммәбез дә гаепле Әнкәбез-Табигать алдында!

С ә е т. Нигәләр генә аттым? Ник аттым?

М ө н и р ә. Синең вөҗданың сау, димәк... газапланасың... Кайтып керсәң, җаннарың тетрәр... Шәфкатьле җаннар яудан кайтмадылар шул...

С ә е т. Нинди хозур иде Таллыкүл буйлары!

М ө н и р ә. Их, Сәет... Табигать шәрәләнеп калгач, адәмнәрнең җаны ярлыланды, тупасланды, мәхәббәтләре сүрәнләнде, туган җиреннән суынды.

С ә е т. Мин суынмадым. Мин элеккечә яратам, Мөнирә...

М ө н и р ә. Мин китәм шул инде, Сәет. Нигә элегерәк кайтмадың? Шулай да мин өметне өзмим... Өметем кала, Мирсәетем кала... Сау бул, Сәет, мин китәм...

С ә е т. Тукта! Китмә! *(Мылтыгын алып, ата...)*

М ө н и р ә. Их, харәп иттең... Нигә аттың?

С ә е т. Мин үрдәккә аттым.

М ө н и р ә. Үрдәк мин бит инде, Сәет...

С ә е т. Янымда гына җан бирергә яткан яралы кош... синме, Мөнирә?

М ө н и р ә. Мин, Сәет... Барыбер мин бәхетле, сине күреп, кайнар кулларыңда, туган җиремдә җан бирәм...

С ә е т. Мөнирә, кичермә мине, бәхилләмә, каргап кит!.. Юк, ташлама мине, мәңге көтәргә дип, Гашыйклар тавында вәгъдә бирдең...

М ө н и р ә. Мин вәгъдәмә туры калам, Сәет, көттем, көтәрмен анда да! Сау булыгыз, исән булыгыз, ике Сәетем, исән бул, Өмет!..

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ө м е т. Мин... исән... Нигә мин исән?!

Л ә л ә. Ул... үзе кайда? Минем аның үзен күрәсем килә. Аңа гына тапшырасы әманәтем бар.

Ө м е т. Минем дә аның янына бик барасым килә. Башымны күкрәгенә куеп гафу сорыйсым килә... әмма...

Л ә л ә. Димәк?..

Ө м е т. Әйе... Шул басмада керләр чайкаганда... Васыятен әйтеп өлгерде: Гашыйклар тавының ташын куегыз... Шулай дип язгыз:

«Сәет!
Кайтырсың, шушында табарсың...
Өзмимен өметне. Мин көтәм.
М ө н и р ә.»

Ник, нигә бер сүз дә дәшмисез... Йә... сүгегез эт итеп... кыйнагыз, типкәләгез «нинди ананы югалткансың!» дип... Сез бит сүгәргә, акыл өйрәтергә оста! Миңа хәзер бер коточкыч, аяктан егарлык сүз кирәк, үзәккә үтәрлек бер сүз! Сез бит сүз осталары, табыгыз бер сүз! Миңа ул сүзне әйтергә атам булмады... Әнием нечкә күңелле, юаш иде... Яңакка сугуы да иркәләү кебек кенә иде. Үтергеч бер сүз әйтегез миңа!

Л ә л ә. Өмет...

Ө м е т. Ялгышкан әнкәй. Мин Өмет булалмадым...

Л ә л ә. Өмет, миңа синең үзеңнән соң нинди ядкарь кала?

Ө м е т. Нинди ядкарьме? Миннәнме! *(Өйгә кереп чыга).* Менә ниләр кала: күмгәндә алдан кайгырган булып күтәреп барырга орден, медальләр, күкрәк киереп президиумда тагып утырган тимер-томыр, значоклар, олау-олау мактау кәгазьләре! Премия бирү турында приказлар! Тагын ниләр калаԥмы? Кала... Актарылган таулар, сазлыкка әверелгән тирән күлләр, сүнгән чишмәләр, тар-мар ителгән куе урманнар, таланган Таллыкүл, бала хәсрәтен күтәрә алмыйча егылган ана туфрагы... мәхәббәтсез гаилә... куылган хатын... башында җилләр уйнаган бала... и бердәнбер куаныч биргән шушы...

хәмер... кала... кала... Әгәр дә булсаң, ник сукмыйсың син мине, Алла?! Күзләрдән яшь ага дип уйламагыз, әче аракы тамчылары алар!.. Иң авыры шул. Таллыкүлне мәсхәрәләүдә катнашкан бәндәләрнең берсе — мин! Рекорд артыннан куып, табигатьнең иң нәфис, иң илаһи җиренә *(әнкәй сүзләре)* бәреп кергәнбез. Әнә шулай Таллыкүлне таркаттык. Нигезендә бер әнкәй торып калды. Уйладым-уйладым да, соң булса да, әнкәй нигезендә йорт кордым. Иске өйгә дә кагылмыйм: аның ядкаре. Гашыйклар тавына чияләр утырттым. Басмага карасам, әнкәм һаман керләр чайкый кебек. Шул кыяфәттә төшләремә керә... Әнкәй яраткан шушы басмага кер чайкарга төшкәнмен, имеш...

Мөнирә тавышы. Өмет балам, бир, керләреңне үзем чайкап бирим.

Өмет. Әнкәй, кайттыңмыни?

Мөнирә. Мин әле кайтмадым. Керләреңне чайкашырга бик азга гына килдем.

Өмет. Кайда соң син? Тавышың бар — үзең юк...

Мөнирә. Бәй, улым, танымыйсыңмыни, алдыңда торам ич...

Өмет. Алдымда... үрдәк... син — юк...

Мөнирә. Шул үрдәк мин булам бит инде, балам.

Өмет. Серле үрдәк... син?

Мөнирә. Нигә гаҗәпләндең? Керләреңне бир әле, балам, анда юма, пычратасың ич. Менә монда су чистарак...

Өмет. Рәхмәт, әнкәй, якынрак кил, башыңнан бер сыйпап алыйм инде. Исән чакта бер генә дә иркәли алмадым.

Мөнирә. Юк, килмим. Мин адәмнәрдән куркам...

Өмет. Нигә куркасың?

Мөнирә. Адәм балаларының риваятьтәге явыз аучыдан аермалары юк.

Өмет. Без сиңа тимәбез, Серле үрдәкәнкәм... Кайчан кайтырсың соң?

Мөнирә. Гашыйклар тавындагы күлне үз урынында күрмичә, Таллыкүл урманнары шауламыйча, кешеләргә шәфкать иңмичә, кайта алмыйбыз! Кайта алмыйбыз!

Өмет *(тоштән өнгә кайтып, сикереп тора)*. Үрдәк! Кыр үрдәге! Кайта! Кайта! Төшсә ярар иде! Тагын бер үрдәк... ике...

Ләлә. Әллә берсе яралы инде... бик авыр... газапланып оча...

Өмет. Төшләр... Яралы кошның исән калган балалары... Алар аерылу алдыннан күлләре белән саубуллашырга килгәннәр... Их, әнкәй белән әткәй генә күрмәделәр шушы көнне!.. *(Шулвакыт Ләлә магнитофонда Сәетнең «Яралы кош» җырын җырлата башлый)*.

## Сәет җыры

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн: ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман:
Кайтыр юлларымны югалттым.

Өмет. Кем җырлый?! Тавышы әллә нинди... таныш кебек...

Ләлә. Бу... әманәт...

Өмет. Әманәт? Нинди әманәт?

Ләлә. Тыңла.

## Сәет җыры

«Туган якларыңа кайт! Кайт!» диеп,
Киек кошлар тезелеп киткәндер...
Кайта диеп өзелеп көткәндер дә
Көтә-көтә түземе беткәндер...

Өмет. Кем ул җырлый шулай җанны айкап?

Мөнирә. Өмет, бу әманәт-җырны мин Мөнирәгә, бары тик Мөнирәгә тапшырырга тиеш идем. Ул — юк. Җырлаучы — Сәет Зилаиров...

Өмет. Сәет... Зилаиров? Әткәй? Ул исән?! Башта ук мин нидер тойдым. Сез нидер яшерәсез. Әйтегез, ул исәнме? Кайчан җырлады ул? Фронттамы?

Ләлә. Юк.

Өмет. Соңгы һөҗүмгә керү алдыннанмы?

Ләлә. Юк. Сугыштан соң.

Өмет. Димәк... ул чыннан да исән?!

Ләлә. Әйе. Ул бүгенгесе көндә исән.

Өмет. Минем әткәм исән!.. *(Таугa йөгереп менә.)* Һәй! Таллыкүл! Гашыйклар тавы! Ишетәсезме?! Минем әтием Сәет Зилаиров исән! Әнкәй аны юкка гына көтмәгән!

Ләлә. Мин васыять-җыр тапшырырга килгән идем. Теләгеңне үти алмадым, Сәет... Яшьлегең, хисләрең давылланган Гашыйклар тавы белән очрашкач, синең миннән яшерелгән газапларыңны үз йөрәгемә алдым. Син миңа тагын да якынрак, кадерлерәк... Бәхиллә, Мөнирә, фани дөньяның язмыш урманнарында адашкан әрнүле бер җанын. Синнән соңгы язмышында аның тән һәм җан яраларын җиңеләйтергә тырышкан мине дә бәхиллә. Кичер, Мөнирә, хатынкыз буларак, мине дә аңла: юлга чыгу алдыннан мин сине килешә алмаслык көндәшем итеп тойдым... Яшермим, күкрәгем тулы шик, йөрәгем тулы авыр тойгы иде. Мин синең илаһи хис белән Сәетне көтүеңне белмәдем. Кичер, Мөнирә, Сәетнең тоткарлануында, бәлки, минем дә гаебем бардыр. Язмыш безнең өчебезгә дә газаплы мәхәббәт юллаган.

Өмет. Кайда ул? Мин аны хәзер барып алам!

Ләлә. Ул еракта... Себердә...

Өмет. Әллә кайда, каторгада булса да, алып кайтам. Минем аны эзләп табып, күзләренә туры карап, сорыйсым килә: «Әткәй, нигә син безгә исән булуыңны хәбәр итмәдең, шулкадәр көтүгә кайтмыйча ничек түздең син?»...

## Сәет җыры

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр,
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

**Үзәк өзгеч тавыш белән кыр үрдәкләре кычкыра...**

*Тәмам.*

*1965—93.*

## КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

# ТАТАРСТАНДА ҖИНАЯТЬЧЕЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШ ЧАРАЛАРЫ

Республикабызда куркыныч җинаятьләрнең үсә баруы сәбәпле, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен җинаятьчел гамәлләрдән саклау йөзеннән чыгып, Татарстан Республикасы Югары Советы 1993 елның март аенда, барлык көчләрне һәм чараларны бергә тупларга кирәклекне күздә тотып, «Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча комплекслы Дәүләт Программасы» кабул иткән иде. Әлеге Программаны һәм күп кенә закон актларын, шулардан «Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча гадәттән тыш чаралар турында» Татарстан Республикасы Законын һәм тагын административ җаваплылык турында кайбер законнарны кабул итү; 1993 елда Татарстан Президенты Указы нигезендә җинаятьчелеккә һәм коррупциягә каршы көрәш буенча ведомствоара республика комиссиясе төзелү; шулай ук җинаятьчелеккә һәм башка хокук бозуларга каршы көрәшне җайга салу турында Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасындагы килешүләргә кул кую үзенең уңай нәтиҗәләрен, һичшиксез, күрсәтте инде.

Кабул ителгән Программа, тискәре тенденцияләрнең сәбәпләренә нәтиҗәле йогынты ясарлык хокук тәртибе дәрәҗәсенә күтәрелә, шул рәвешле гражданнарның һәм дәүләтнең мәнфәгатьләрен яклауга бәйле киң даирәләрне үз эченә ала. Аның төп максаты — шәхес хокукларын хакыйкый яклауга ирешү, җәмгыятьтә законнарга карата ихтирам уяту, социаль һәм икътисади үзгәртеп корулар өчен ышанычлы алшартлар булдыру.

Хакимият органнары белән хокук саклау органнарының гамәлләрен килештерү җинаятьчел элементларны контрольдә тотарга мөмкинлек бирде. 1993 ел белән чагыштырганда, 1995 ел йомгаклары буенча, ягъни ике ел эчендә республикада җинаятьчелек 5,7 процентка кимеде. Алдан уйлап-исәпләп оештырылган үтерешләр, бик авыр тән җәрәхәтләре ясаулар, көчләүләр, мөлкәткә каршы җинятьләр, хезмәт белән төзәтү учреждениеләрендәге һәм балигъ булмаганнарның җинаятьләре саны да сизелерлек азайды.

Шушы Программа нигезендә хокук саклау органнарының матди-техник базасы ныгыды, аларның саны артты, яңа бүлекчәләр, тәрбия-профилактика учреждениеләре төзелде, хокук саклау системасы үзгәртеп корылды. Бу Программа финанс ягыннан тәэмин итүнең кыен шартларында алып барылса да, алга китешнең күзгә күренерлек булуы күңелгә куаныч өсти.

Шул ук вакытта, финанслауның җитмәве аркасында, Программаның махсус оператив-техник чаралары, оператив-криминология техникасы, элемтә чаралары, хокук саклау системасы хезмәткәрләре өчен индивидуаль саклану чаралары һәм башка техника, кораллар сатып алу, хокук саклау органнары өчен объектлар проектлаштыру һәм төзү кебек мөһим эшләр хыялда гына кала бирә. Әлегә кадәр яшүсмерләр өчен махсус укыту-тәрбия учреждениесе юк, торыр урыннары булмаганнарга төн кунып чыгу өчен йортлар ачылмаган, административ кулга

алынганнар өчен махсус кабул итү пунктлары һәм медицина айныткычлары жирле бюджеттан республика бюджетына күчерелмәгән. Хокук саклау органнары өчен кадрлар әзерләү мәсьәләсе дә кискен проблема булып кала бирә, республикада яшәүчеләр турындагы белешмәләрнең автоматлаштырылган банклары оештырылмаган һәм тулысынча компьютерлаштыру да юк әле. Шулай да Россия Федерациясендә һәм БДБ илләрендә беренчеләрдән булып әзерләнгән һәм кабул ителгән Программабыз үзенең төп ролен — җинаятьчелекнең үсешен туктату, җинаятьләрне күбрәк ачу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү эшен үтәде һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә нык нигез булдырды.

Мәгълүм булганча, 1994 елның май аенда Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцин да «Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча Федераль Программа» дигән Указга имза салды. Иминлек Советы төзегән бу документ нигезендә дистәләгән ведомстволарның җитәкчеләре Программаның үтәлешен тәэмин итәргә, хокук саклау органнарының штатларын арттырырга, билгеләнгән суммаларны үз вакытында бүлеп бирергә тиешләр иде. Программа өчен биш триллион сум таләп ителә һәм ул шулай каралган да иде. Россия белән Татарстан җинаятьчелек мәсьәләләре буенча килешү төзегәндә, Татарстан әлеге Программаны гамәлгә ашыру өчен җитәрлек дәрәҗәдә финансланырга тиеш иде. Әмма Россия Федерациясенең Финанс министры акчаларның күп өлешен Программа өчен бүлеп бирмәде, аны Чечнядагы хәрби максатларга исраф итте. Мәсәлән, Эчке эшләр министрлыгында штатларны, оешкан төстәге җинаятьчелеккә каршы бүлекчәләрне арттырасы урынга, ОМОНнар һәм «спецназ»лар нытытылды, шуннан соң ук аларны Чечняга җибәрделәр. Шулай итеп, безнең дәүләт тарафыннан яклануыбыз да бюджетның калдык-постык финансланучы статьяларына гына бәйле булып калды.

Татарстан Республикасындагы крименоген вәзгыять һаман да катлаулы әле. Кайбер шәһәрләрдә һәм районнарда аеруча куркыныч җинаятьләр саны арта бара. Җинаятьчел оешмаларның берләшүе дәвам итә, алар территорияләрне һәм җинаятьчел «бизнес өлкәләрен» үзара бүлешәләр. Рецидив, ягъни кабат ясалган җинаятьләрнең дә артуы күзәтелә. Балигъ булмаганнарның җинаять кылулары да ешая. Икътисади җинаятьчелек дәрәҗәсе үсә, бигрәк тә тышкы икътисади эшчәнлек, хосусыйлаштыру, акционерлаштыру, финанс-кредит мөнәсәбәтләре өлкәсендәге җинаятьләр дә кимергә җыенмый. Гомуми җинаятьчелек кысаларында икътисади җинаятьләр аерым урын алып тора, алар гаять оешкан төстә башкарыла, алдан җентекләп әзерләнә һәм ул җинаятьләрдә предприятиеләрнең җитәкче хезмәткәрләре катнаша. Мондый җинаятьләрне башкару рәвешләре һәм ысуллары шактый күп төрле, шуңа күрә аларны ачу да кыенлаша бара һәм алар аркасында республика казнасына миллиардлаган суммаларда зыян килә. Бу җинаятьләрнең хәвефлеге шунда ки, алар торган саен күбәя баралар һәм еш кына очракларда мафиози төркемнәрнең канлы бәрелешләре белән, ришвәт бирү һәм алу, башка төрле алдан җентекләп исәпләнелгән җинаятьләр, көчләүләр белән тәмамланалар.

Гамәлдәге хокукый актлар мондый икътисади мөнәсәбәтләрне җайга сала алмыйлар, бик күп кирәкле законнар әле кабул ителмәгән. Хокук органнарында җинаятьчелекнең категориясен үз вакытында һәм нәтиҗәле итеп аңлатып бирерлек квалификацияле кадрлар да җитешми.

Икенче яктан караганда, бу өлкәдә болай гына уңышларга ирешү бик кыен, шуңа карамастан, республикада социаль-икътисади һәм хокукый тотрыклылык тәэмин итү төп бурычларның берсе булып кала бирә.

Әмма бу тотрыклылыкны урнаштыру буенча һәрбер эш-гамәл алдан җентекләп планлаштырылган программа нигезендә алып барылырга тиеш. Без җинаятьчелекнең иң тирән социаль-икътисади һәм башка механизмнарын һәм җинаятьчелекнең конкрет чагылышын ачып бирерлек яңа программа әзерләргә һәм аны кабул итәргә тиешбез. Шунсыз сизелерлек уңышларга ирешү мөмкин булмаячак.

Шушы максатлардан чыгып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе инициативасы буенча, хокук саклау органнары, дәүләтнең башка органнары һәм оешмалары, җитештерү предприятиеләре, банклары һәм финанс учреждениеләре катнашында җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча Республика Фонды оештырыла.

Фондның бурычы — җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча республика программасын гамәлгә ашыру. Бу катлаулы һәм җаваплы эш хокук саклау органнарының матди-техник нигезен ныгыту чараларын өстәмә рәвештә финансла-

удан, шулай ук җинаятьчелек турында мәгълүматлар җыюдан һәм аларны системалаштырудан, аларга һәрьяклап анализ ясаудан, хокук саклау органнарына мәгълүматлар бирүдән һәм методик ярдәмнән, җәмгыятьтәге социаль куркыныч күренешләргә һ.б. каршы көрәш төрләрен һәм ысулларын камилләштерү буенча фәнни нигезләнгән гамәли тәкъдимнәр әзерләүдән һәм аларны тормышка ашырудан гыйбарәт булачак.

Фонд, беренче нәүбәттә, гомуми җинаятьчелеккә каршы, шулай ук аерым төр җинаятьләргә каршы көрәшнең төп беренчел юнәлешләрен билгеләргә тәкъдим итәчәк.

Икътисади җинаятьләр өлкәсендә Фондның эше күпмедер дәрәҗәдә житештерүне тотрыксызландыручы, тулаем республиканың һәм аерым предприятиеләрнең, оешмаларның финанс-икътисади хәлен яхшыртуны һәм аны үстерүне тоткарлаучы төп сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдереләчәк.

Фонд эшчәнлегенең мондый юнәлеш алуы очраклы түгел. Барыбызга да мәгълүм ки, җитештерүнең түбәнәюе, предприятиеләрнең финанс хәле начараю дәүләтнең гомуми икътисади хәленә генә, ул предприятие җитәкчеләренең яңа шартларда финанс хәлен нигытуны нәтиҗәле оештыра алмауларына гына да бәйләнмәгән, ә бәлки идарәнең бөтен системасын күрәләтә җимерүгә, хисапның һәм хисап тотуның барлык төрләрен аңлы һәм максатлы рәвештә бутауга бәйләнгән. Шулай итеп, предприятиенең хәлен ахыргача начарайтучы идарәчелек барлыкка килү, моның белән килешә алмаган югары белгечле кадрларның эштән китүе җинаятьчел шәхесләргә урлашулар, үзләштерүләр һәм башка явыз ниятләр өчен иң уңай шартлар тудыра. Шул рәвешле, мондый катлаулы шартларда әлеге предприятиеләрнең җитәкчеләрен алыштыру мөмкинлеге булмау турында ясалма фикер туа. Әлеге җитәкчеләр исә мондый хәлдән бик оста файдаланалар һәм үзләренең җинаятьчел гамәлләрен дәвам иттерәләр.

Татарстан Республикасы халык депутатлары, комплекслы Дәүләт Программасының 1993—1995 елгы йомгаклары буенча фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә 1996—1997 елларда җинаятьчелеккә каршы көрәшнең яңа Программасын әзерләргә һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына кертергә тәкъдим иттеләр.

Бу Программаның асылын түбәндәге концептуаль нигезләмәләр тәшкил итәргә тиешләр.

Хәзерге шартларда җинаятьчелеккә нәтиҗәле каршы тору чараларын әзерләгәндә һәм тормышка ашырганда, җинаятьчелекнең күп төрле факторларга нигезләнгән булуыннан чыгып эш итәргә кирәк. Беренчедән — бу бөтендөнья бергәлегенә хас социаль процесслар һәм күренешләр (алкоголизмның, наркоманиянең һәм башка тискәре күренешләрнең киң таралуы). Икенчедән — безнең җәмгыятьтә хокукый тәрбиянең тиешле дәрәҗәдә булмавы, төрле рәвештәге иҗтимагый һәм хокукый тикшерүләрнең кимүе, хокук бозуларны булдырмый калуның гадәттәге системасы җимерелүе; законнарның һәм хокук саклау органнарының алар хакындагы объектив булмаган мәгълүматлар аркасында абруе төшү. Социаль, этник, дини бәрелешләр кебек криминоген факторлар да кинәт кенә көчәеп киттеләр. Күрсәтелгән факторлар белән беррәттән, геосәяси факторларны да исәпкә алырга кирәк, моңа түбәндәгеләр керә: чикләрнең ачыкланмаган статусы, миграция, транзит гамәлләренең мөмкинлеге; халыкның шактый өлеше икътисадтагы яңа шартларга яраклашканда килеп чыгучы социаль-сәяси конфликтлар. Җинаятьчелекнең үзендәге төп үзгәрешләрне дә истән чыгарырга ярамый, бу үзгәрешләр оешкан һәм профессиональ җинаятьчелекнең үсүе белән аңлатыла. Яңа программа төп көчләрне оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәшкә юнәлтүне тәэмин итәргә тиеш. Шул ук вакытта ул гомуми җинаятьчелек кысаларында өстенлек итүче гадәти көч куллану һәм мөлкәт җинаятьләреннән халыкны саклау һәм яклау буенча өстенлекле юнәлешләргә яраклаштырып әзерләнергә һәм гамәлгә ашырылырга тиеш.

Дәүләтнең һәм җәмгыятьнең җинаятьчелектәге тискәре тенденцияләрне булдырмаслык, әкренләп аны киметү һәм аның ахыргы нәтиҗәләрен йомшартуны тәэмин итәрлек мөмкинлекләре бар. Бу исә — үзара мөнәсәбәттә булучы социаль, икътисади, тәрбияви, оештыру, мәгълүмати-аналитик, хокукый төстәге гамәлләр; федераль, төбәк һәм җирле кимәлдәге гамәлләр; ведомствоара һәм ведомство гамәлләре. Кичектергесез һәм озак вакытка исәпләнгән чаралар әзерләү һәм аларны тормышка ашыру таләп ителергә тиеш. Шул ук вакытта, җинаятьчелеккә каршы көрәшне «полиция» кысаларына кертмичә, хокук саклау органнарының нормаль эшчәнлеге өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк.

Бүгенге шартларда иң мөһиме — җинаятьчелеккә каршы көрәшнең хокукый нигезе, гражданнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен, җинаятьчелеккә каршы көрәш һәм кеше хокукларын саклау өлкәсендә Россиянең халыкара-хокукый бурычларын үтәгән килеш, ышанычлы яклау нигезе буларак үсүе әһәмиятле.

Шулай ук җинаять корбаннарының законлы мәнфәгатьләрен өстенлекле яклау танылырга тиеш.

Оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәштә, аның коррупцияләнгән барлык элементларен өзү чараларын күреп, җинаять эшчәнлегенең яңа төрләре һәм рәвешләре өчен җаваплылыкны, җинаять юлы белән җыелган байлыкны һәм мөлкәтне оператив рәвештә тартып алуны тәэмин итү дә сорала.

Җинятьчелеккә каршы көрәшкә юнәлеш бирүгә дә, хокук бозуларны булдырмау һәм җәмәгатьчелекнең аңа каршы көрәштә катнашу системасын торгызуга һәм үстерүгә дә аерым игътибар итәргә бурычлыбыз.

Программада каралган чаралар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мөмкинлекләреннән файдаланып, финанс, матди-техник ресурслар һәм кадрлар, мониторинг һәм фаразлау белән хакыйкый тәэмин ителергә тиеш.

**Рәшит ВӘГЫЙЗОВ,**
ТР Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык,
хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе рәисе.

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ!

**Айдар Хәлим**

## КЫЙБЛА


ХИКӘЯДӘН ӨЗЕК

«1942 елның декабрендә Гарифулласының хәбәрсез югалуы турында хәбәр килде. Өммегөлсем өчен кояш сүнде. Елгалар корыды. Үләннәр кара көйде. Аның бердәнбер өмете, юанычы булып әтисенең йөзен дә күрмәгән Тансыгы калды. Үләннәр кебек үзе дә кипте-корыды Өммегөлсем. Төннәрен елый-елый шешенеп бетә дә, иртәсен йөзе һәм маңгаендагы җыерчыкларны җылымса су белән тигезләп, эшенә йөгерә. Шулай очны-очка ялгап яшәп ятканда, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, хатын-кызны гына ээәрлекли торган бер афәт килеп чыкты — яшь, эшчән, көче-дәрте ташып, чибәрлеге әллә кайлардан күзгә бәрелеп торган һәм, хәзер инде, күпләр уйлавынча, тол калган хатынга үзбәк ирләре тәмам юл бирми башлады. Алар бит Рәсәй тарафларыннан килгән хатын-кызга аеруча каныгалар, күзләрен тоҗырайталар да, кайда мөмкин, шунда тозак куеп, ээәрлекләргә тотыналар һәм еш кына үзләренең түбән ләззәтләренә ирешмичә туктамыйлар. Авыр кабул итсәләр итәрләр, инде дистә еллар аша шунысын да әйтми калдыралмый Өммегөлсем: үзбәк өчен хатын-кыз чүпрәк-чапрактан да ваграк мәсьәлә. Җитмәсә, мәктәп директоры, сөйләүләре буенча, ришвәт төртеп, фронттан котылып калган Абдулла әкә аңа тәмам тынгы бирми башлады. Үзбәк өчен түрә хакы — тәңре хакы. Бер яклаучысыз калып, намусын күз карасыдай саклаган хатынны үзенеке итү өчен нинди генә түбәнлекләргә бармады ул кабәхәт җан. Эшеннән куу белән яный башлады явыз. Фатирыннан сөреп чыгару белән куркытты мәртәт. Кая, кемгә барып егылырга? Эч серләреңне кемгә бушатырга? Чит җирнең кичке шәфәгы, иртәнге таңы биздерә башлады...»

Китап күзәтү

# ТӨРКИЯДӘН БҮЛӘК

Габдулла Тукай бер татар халкының гына горурлыгы түгел, ул — барча төрки халыкларның сөекле улы. Аның әсәрләрендә, татар белән бергә, казакъ, үзбәк, кыргыз, башкорт, төрекнең дә моңы-гаме, кайгы-хәсрәте чагыла. Тугандаш милләтләрнең күп кенә олуг шагыйрьләре Тукай мәктәбендә тәрбияләнде. Бүген дә Тукайны ерак илләрдә яшәгән тел һәм дин кардәшләребез яхшы белә, укый, өйрәнә.




Тукайга югары бәя һәм тирән ихтирам билгесе булырдай бүләкләрнең берсе соңгы вакытта Төркиядән килде. Бу — доктор Фатма Өзканның «Габдулла Тукайның шигырьләре» исемле кыйммәтле хезмәте. Ул Анкарада Төрек күлтүрене араштырма институты карары белән 1994 елда басылган. Миңгә якын биттән гыйбарәт булган бу саллы хезмәт өч кисәктән тора: Тукайның тормышы һәм иҗатына бәяләмә, Тукай шигырьләренең латин (төрек) әлифбасындагы транскрипциясе һәм төрек теленә тәрҗемәсе. Транскрипция, тәрҗемә һәм анализ өчен Габдулла Тукайның 369 шигъри әсәре алынган. Моңа кадәр төрек укучысының бу кадәр санда Тукай әсәрләрен үз телендә уку мөмкинлеге булмаган иде. Фатма Өзкан ханым искиткеч зур эш башкарган, аның тырышлыгына, эзләнүчәнлегенә сокланмый мөмкин түгел. Чын галимнәргә генә хас төгәллек һәм сабырлык белән ул һәр әсәрне бөртекләп өйрәнгән, Тукай кулланган һәр сүзне шагыйрь яшәгән замандагы мәгънәсен саклап, нәкъ Тукайча итеп тәрҗемә итәргә тырышкан. Китапны укыганда авторның татар телен, татар халкы тарихын камил белүен күреп хәйран каласың, Төркиядә Тукай иҗаты буенча шундый зур белгеч барлыгына сөенү хисе юлдан-юлга, сәхифәдән-сәхифәгә арта бара.

Автор, сүзен турыдан-туры Тукайдан башламыйча, башта Казан татарлары турында кызыклы тарихи мәгълүматлар бирә һәм, әйтергә кирәк, хезмәтнең кереш өлешендә тарихи күзәтү ясау бик тә урынлы. Чөнки Төркиядә бик күпләр «татар» дигән төрки милләт барлыгын белсәләр дә, аның үткәнен, ни өчен болай аталуын, Кырым татарларыннан Казан татарлары аерыламы-юкмы икәнен белмиләр. Казан татарлары килеп чыгышына, дәүләтчелек тарихына кагылышлы сорауларга Ф. Өзкан, гыйльми чыганакларга таянып, тәфсилле җавап бирә. Татар укучысында да бу тарихи белешмә кызыксыну уята, чөнки автор, совет чорында чыккан китаплардан тыш, Төркиядә яшәп иҗат иткән абруйлы татар галимнәре Рәшит Рәхмәти Арат, Габделбари Баттал Таймас, Әхмәт Тимер, Әгъдәс Нигъмәт Курат, Надир Дәүләт хезмәтләрен дә гыйльми чыганак итеп ала. Гомумән, әлеге китапның фәнни аппараты шактый көчле, автор Татарстанда, Төркиядә, Рәсәйдә чыккан китаплардан тыш, Англиядә, Японияда басылган хезмәтләрдән дә файдалана. Мәсәлән, ул Җамал Вәлидинең Токиода басылган «Габдулла Тукай. Мәҗмугаи әсәре» (1933 ел) китабына еш мөрәҗәгать итә. Киң катлау татар укучысына бик билгеле булмаган бу китаптан һәм Зәкия Рәсүлева әзерләгән җыентыктан («Тукай эзләреннән», Казан, 1985) алынган истәлекләр, фикерләр Тукайның тормыш һәм иҗат юлын тулы һәм ачык итеп күзалларга

ярдәм итәләр. Хезмәтенең кереш өлешендә XIX гасыр азагы — XX гасыр башында татар халкының иҗтимагый һәм мәдәни тормышына характеристика биреп, Тукайның остазлары яки замандашлары булган Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ибраһим Хәлфин, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Садри Максуди кебек күренекле кешеләребез белән төрек укучысын шактый якыннан таныштыргач кына, автор Тукайның үзен, аның тормыш юлын таныштырга керешә. Шунысы игътибарга лаек, хезмәттәге материал тыгыз һәм мул итеп бирелгән, кирәкмәгән гомумиләштерүләргә, кабатлануларга урын калмаган, шул ук вакытта галимә күзеннән Тукай биографиясенең бер генә әһәмиятле детале дә, Тукай шигъриятенең бер генә мөһим үзенчәлеге дә читтә калмаган.

Галимә Тукай әсәрләрен нигездә ике ноктадан: идея-проблематика һәм тел-стиль, форма үзенчәлекләре ягыннан алып тикшерә. Идея, тема, эчтәлек буенча ул әсәрләрне түбәндәге темаларга бүлеп анализлый: гыйшык-мәхәббәт шигырьләре, милләт һәм миллиятчелек, хөррият, дин һәм мәгърифәт темаларына язылган һәм балалар өчен иҗат ителгән әсәрләр. Үз хезмәтенең бу бүлегендә Ф. Өзканның беренче итеп Тукайның мәхәббәт темасына язылган шигырьләрен анализлавы, аның тапталган иске юлдан китмәвен, татар галимнәре моңа кадәр калыплаштырып бетергән Тукай иҗатына бәя бирү формасын кабатламавын күрсәтә.

Билгеле булганча, Тукайның гыйшык шигырьләре сан ягыннан күп түгел, ул, күпчелек шагыйрьләрдән аермалы буларак, иҗатының беренче чорында ук иҗтимагый мәсьәләләргә багышлап шигырьләр яза башлый. Ләкин, гыйшык шигырьләре аз булса да, алар Тукайның шәхсиятен, рухи халәтен аңлау юлында әһәмиятле чыганак булып торалар. Тикшеренүче нәкъ менә шул җәһәттән лирик шигырьләрне алгы планга чыгара да. Тукайның мәхәббәт шигырьләрендәге төп мотив — сагыш, гыйшык хисе тудырган газап. Ф. Өзкан фикеренчә, Фөзүли әсәрләрендәге кебек, Тукай шигырьләрендә газап эстетик элемент буларак урын ала. «Ифтиракъ соңында», «Мәхәббәт» шигырьләрендә шагыйрь чыннан да үзенең сагыш-газаптан ләззәт алуы турында сөйли:

> Җан якан азарыңа һич кинәсез мәфтүнеңем;
> Һәр заман идәм тәләззез аһе әхзаныңла бән.
> (Җан яндыргыч кыйланышыңа бары тик сокланам,
> Синең хәсрәтле аһыңнан һәр заман ләззәт алам.)
> *(«Ифтиракъ соңында»)*

яки:

> Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну!
> *(«Мәхәббәт»)*

«Ифтиракъ соңында», «Гыйшык бу йа!», «Мәхү идәрмисән», «Дәрдемәнд дәгелмием?» шигырьләрендәге стиль берлеге, символика, төп тема булган аерылу газабы, сөйгән ярның вафасызлыгы Ф. Өзканга Тукай шигърияте белән төрки әдәбиятлардагы диван шигырьләре эстетикасы арасында охшашлыкларны табарга ярдәм итә. Шулай булуга да карамастан, аның фикеренчә, асылда иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр белән ныграк кызыксынган шагыйрь, әлеге шигырьләрендә мәхәббәт газабында янган күңелнең самими тойгыларын сурәтләүгә караганда, күбрәк мәдрәсәдә шигырь техникасы буенча алган белемнәрен тормышта кулланып карау өчен язганга охшый. Чынлыкта Тукайга эчке тыйнаклык, серләрен күңел түренә яшереп саклау сыйфаты хас, ди автор (42 бит).

Гыйшык-мәхәббәт шигырьләрен язганда Тукай бары Лермонтов, Пушкиннарга гына иярмәгән, ди автор һәм бу тип шигырьләрдә («Сөеклемнең кабер ташында», «Булмаса», «Берадәранә нәсихәт һ.б.) Шәех Галиб, Гашыйк Вәйсәл, Габделхак Хәмит кебек төрек шагыйрьләре әсәрләре белән аваздаш урыннарны да таба.

Тукай, автор фикеренчә, ниндидер бер идеальләштерелгән яр тасвирлау ягында түгел. «Хур кызына» шигырендә хур кызын сурәтләп, мактаганнан соң, «Син ни кадәр гүзәл, мөкатдәс һәм мөхтәрәм булсаң да, мин сине түгел, җир йөзендәге кызны сөям» дигән сүзләреннән шагыйрьнең мәхәббәтне реалистик аңлавын күрәбез, ди.

Тукай үзенең иң гүзәл мәхәббәт шигырьләрен Казанда танышып, гашыйк булган Зәйтүнә Мәвлүдовага багышлап язган. Ф. Өзкан Тукайның «...гә», «Кулын» шигырьләренең язылу тарихын матур итеп, җылы хисләр белән, Зәйтүнә туташ истәлекләрен файдаланып тасвирлый. «Кызык гыйшык» шигыренә бирелгән анализда исә Тукайның яшь туташлар янында үзен бик кыюсыз тотуын, оялчан булуын, тойгыларын башкалардан яшерүен яшьләй ана мәхәббәтеннән

мәхрүм калган шагыйрь характерының бер сыйфаты буларак бәяли. Гомумән, фәнни, җитди хезмәт эчендәге бу бүлек үзе дә, нинди дер бер лирик әсәр кебек, дулкынландыргыч итеп язылган.

Милләт, миллиятчелек темаларына язылган шигырьләрен тикшергән вакытта Ф. Өзкан Тукайның иҗтимагый-сәяси карашларының эволюциясен күзәтә. «Ислам милләте» проблемаларыннан башлаган шагыйрьнең идеаллары безнең алда торган саен конкретлаша бара:

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын,— ди шагыйрь.
*(«Үз-үземә», 1906)*

Башлангыч дәвер әсәрләрен госманлы төрекчәсенә якын тел белән язган шагыйрьнең теле дә торган саен гадиләшә, «татарлаша» бара һәм ул Мостафа Ширванский кебек, татарчаны Төркия төркичәсе белән берләштерергә омтылучыларга («Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа»), милләт-миллият маскасын киеп, халыкны алдау белән шөгыльләнүчеләргә («Милләтчеләр») каршы чыга.

## Ŭ̈ZǏLGEN Ŭ̈MİT

*Küz karaşımda ḫezǐr üzgerdǐ eşyalar tŭ̈sǐ,*
*Sizǐle: Üttǐ yeş vakıtlar, çittǐ gŭ̈mrǐm yartısı.*

*Küz tǐgǐp baksam eger de tŭ̈rmışımnıñ kügǐne,*
*Yeş hilal urnında anda tulgan aynın yaktısı.*

*Nindi dert bǐrlen kalem sızsam da kegaz ŭ̈stǐne,*
*Ŭ̈çmıy evvelgǐ yüler, saf, yeş meḫebbet çatkısı.*

*İy mŭ̈katdes, mŭ̈ñlı sazım! Uynadıñ sin nik bik az?*
*Sin sınasıñ, min sŭ̈nemǐn, ayrılabız aḫrısı!*

*Ŭ̈çtı dŭ̈nya çitlǐgǐnnen tarsınıp küñlǐm kŭ̈şı,*
*Şat yaratsa da, cihanga yat yaratkan Rabb'ısı.*

*Küp mǐ mŭ̈ñlansam kunıp milli agaçlar ŭ̈stǐne,*
*Barsı kŭ̈rgan, bǐr gǐne yuk canlısı, yafraklısı.*

*Bulmadıñ altın yarım, salkın yarım sin de minǐm,*
*Bǐr tebessǐm bǐrle de tŭ̈rmış yulım yaktırtkıçı!*

*Küz yeşǐñ de kipmiyçe yıglap vafat bulgan eni!*
*Gailesǐne cihannıñ nik kitǐrdǐñ yat kǐşi?!*

*Üpkenǐñnen birlǐ, enkey, iñ aḫırgı kerre sin,*
*Her işǐkten sŭ̈rdǐ uglıñnı meḫebbet sakçısı.*

*Bar küñǐllerden cılı, yŭ̈mşak sinǐñ kabrǐñ taşı,*
*Şunda tamsın küz yeşǐmnǐñ iñ açı hem tatlısı!*

Тукайның татар милләтенең артта калу сәбәпләрен эзләү процессын Ф. Өзкан, шигъри әсәрләр белән генә түгел, «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» кебек чәчмә әсәрләре ярдәмендә дә аңлата. Тукайның милләт мәсьәләләрендә мәгърифәтчеләргә, төрек шагыйрьләре Мәһмәт Акиф Эрсой һәм Тәүфикъ Фикрәткә якын торуын күрсәтә. Алдагы бүлектә телгә алынган эстетик ләззәт алу темасын тәмамлап, автор, шагыйрьнең чын ләззәт-тәмне милләтенә хезмәттә табуын ачыклый.

«Хөррият» темасы астына тупланган шигырьләрдә Ф. Өзкан Тукайның 1905 елгы революциягә карата мөнәсәбәтен («Дусларга бер сүз», «Хөррият хакында», «Иттифак хакында» һ.б.), хатын-кыз азатлыгы хакындагы фикерләрен («Эштән чыгарылган татар кызына», «Татар кызларына» һ.б.) анализлый. Ләкин 1905 ел революциясе белән килгән ирекләр озак яшәми. «Дуслар мәҗлесендә хөррият белән шатлык рәис булуын» («Мәҗлес») теләгән Тукайның хыяллары реакция елларында җимерелә, аның иҗатында пессимистик рух арта («Хөррияткә» һ.б.)

XIX йөз ахыры — XX йөз башында да әле татарларда уку-укыту эше ислам дине белән тыгыз бәйләнештә алып барылганга күрә, Ф. Өзкан хаклы рәвештә Тукайның дини һәм мәгърифәтчелек карашларын бер бүлек эченә алып тикшерә. Җамал Вәлиди истәлекләренә, шагыйрьнең «Исемдә калганнар»ына таянып, автор Тукайның кечкенәдән үк байларны яратмавын, мәдрәсәдә укыганда, башка шәкертләр кебек, ашларга йөрмәвен, Казанга килгәч тә, андагы могтәбәр байлар белән дуслык корудан качуын, иске фикерле мулла-мунтагайларны тәнкыйть итүен, шагыйрьнең йомык характеры, күңелендәге ятимлек, юксыллык тойгылары белән генә түгел, ә бәлки шул чорда иҗтимагый мәйданында барган кадимчелек-җәдитчелек көрәше белән дә аңлата. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Дусларга бер сүз», «Муллалар», «Ишан», «Мулланың зары», «Сорыкортларга» кебек шигырьләрендә Тукайның татарлар арасында шул чорда шактый артып киткән ялган суфи-ишаннардан, азгын-бозык, надан муллалардан, искелек тарафдарларыннан көлүен галимә ассызыклый. Ф. Өзкан, безнең кайбер татар тикшеренүчеләреннән аермалы буларак, Тукайның аерым дин әһелләренә карата булган нәфрәт хисләрен бер дә шагыйрьнең ислам диненә булган мөнәсәбәте белән бергә бутамый. «Дин һәм гавам» шигырендә Тукай үзе үк бу мәсьәләгә ачыклык кертә кебек:

Дин хәзер — иске, аварга торгучы чергән дивар,
Аз гына, уйнап кына бармак белән төртсәң — авар.

Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар;
Былбыл урнына оя тоткач башында каргалар!

Төркия галиме урынлы рәвештә Тукайның вафатыннан соң басылган шигырь китапларына дини карашларын чагылдырган әсәрләренең кертелмәвен, совет чорында аны атеист итеп күрсәтергә маташуларны зур ялгышлык дип атый. Дини эчтәлекле «Тәэссер», «Васыятем», «Мигъраҗ», «Кадер кич» исеме астындагы шигырьләренең бар икәнен белмәгән очракта да, ди ул, башка шигырь һәм нәсерләрен диккать белән тикшергәндә, Тукайның милләтенә һәм милләтенең диненә ни кадәр бәйле булуын күрмәү-аңламау мөмкин булмас иде, ди (71 бит). Әлеге шигырьләрне галимә үз китабына урнаштыра һәм югары бәя бирә.

Балалар өчен язылган шигырьләрен өйрәнеп, Ф. Өзкан Тукайның балалар психологиясен яхшы белүче, үтемле үгет-нәсихәтләр бирүче, чын дәрәҗәдәге балалар язучысы булуын күрсәтә.

Тукайның тел, стиль, жанр үзенчәлекләрен Ф. Өзкан безнең өчен яңа бер тарафтан якын килеп өйрәнә. Ул Тукай шигырьләрендәге Истанбул төрекчәсенә кергән сүзләрне бер төркемгә, гарәп һәм фарсы телләреннән алынганнарын икенчегә аерып бирә. Тукай телендә шактый күп госманлы төрекчәсе элементларын табып, «яисә» («яки») урынына «яхут» сүзен кую («Шәкерт, яхут бер Тәсадеф) «Пушкинга» урынына «Пушкинә» дию, «Гыйшыкмы соң бу!» диясе урынга «Гыйшыкмы бу йа!», «түгел» урынына «дәгел» («Дәрдеманд дәгелмием?») дип язу күренешләрен галимә шагыйрь иҗатына Танзимат дәвере төрек әдәбиятының көчле тәэсире белән аңлата. Ул Тукайның төрек теленә бик якын язылган егермедән артык әсәрен аерып күрсәтә.

Бу урында Ф. Өзкан игътибарга бик тә лаек булган бер фикер әйтә: «Тукайның башлангыч чор иҗатына караган һәм Төркия төркичәсе йогынтысында язылган шигырьләрен гарәп хәрефләреннән кириллицага күчергән вакытта, ди

ул, кайбер хаталар да киткән. Мәсәлән, төрекчә «долаш» (татарча «йөр» мәгънәсендә) фигыле — «дулаш» дип, «ол» (татарча «бул») фигыле — «ул» дип, «гәл» (татарча «кил» (фигыле — «кәл» дип күчерелгән, ди. Аеруча «Мәхү идәрмисән?» шигырендә «Инләрем аh-ваh идеб, мән насыйри, мән маили» юлындагы «инләү» фигыле, шигырьнең кирилл хәрефле иң әүвәлге басмаларындагы кебек, 1985 елгы соңгы басмасында да «икләрем» формасында ялгыш бирелгән, ди. Югыйсә, ди ул, шигырьнең гарәп хәрефле текстында «сагир кәф» (саңгырау «к») урынына «ң» укылырга тиеш (84—85 бит).

Тукай әсәрләренең шигъри төзелеше, рифма, рәдиф, вәзен мәсьәләләренә дә махсус тукталып, Ф. Өзкан гаять әтрафлы анализ бирә. Бу бүлектә шулай ук автор Фуад Күпрүле кебек танылган галимнең шималь төрекләрендә әдәбиятның шигырь төзелеше, сәнгатьчәлеге ягыннан камиллектән ерак булуы турындагы фикерен китерә һәм Тукай әсәрләренә карата бу фикернең бер дә дөрес булмавын дәлилли. Шул рәвешле, Фатма Өзкан ханым тагын бер мәртәбә Казан татарларының телен һәм әдәбиятын яратуын, тирән белүен күрсәтә.

### ...GE

*Şagıyrǐm! Kǚdsiyetǐñ bulsın sinǐñ küñilǐñde sǐr;*
*Dǚnyadan şagıyr ikenǐñnǐ yeşǐr, dustım, yeşǐr.*

*Bǐlmesǐnner, kaysı cirden agıla bu kǚdretǐñ.*
*Sin, letıyf tenner kǐbi, kürsetmegǐl çın suretǐñ.*

*Hervakıt, her cirde sin başka kiyimnerge tǚrǐn:*
*Ya yüler bul, ya mezekçǐ bǐr kǐşǐ tǚslǐ kürǐn.*

*Birme sǐr hiçkǐmge, sǚyleşseñ, sǚyleş ǚsten gǐne;*
*Kǚl, karañgı yǚz birü ançak kilǐşmesten gǐne.*

*Çitke bǚr, süz kilse karşıñda şigırler babına;*
*İpteşǐñ şagıyr ğǐne bassın ayak miḫrabıña.*

*İtme üz tǚrmışnı, tap başka cihan, başka ḫeyat;*
*Dǚnyanıñ buş şav̇-şuv̇ı şagıyrge çit, şagıyrge yat.*

*Kǐm gine bulsañ da bul, yuk ansına hiçbǐr süzǐm,*
*Tik süzǐm şuldır siña: Saklan buludan üz-üzǐñ.*

*Bǐl: Kilǐşmiydǐr siña bu vak megıyşet, vak tǚrış,*
*Çǚnki meñgǐge ǚçalmas, yǚrtta küp asralsa kǚş.*

*Feyzı bakıy, tac-ǐ şagıyr meñgǐge bulmas siña,*
*Vaksınıp sin tǚşseñ altın şıltırav̇ı astına.*

*Baş iyme, zur sin, bu edna canlılar dǚnyasına;*
*Padişah sin! Bik kirekse, baş iysǐn dǚnya siña.*

*Taş yürekler kırsalar küñlǐnnǐ, tüz, ǐndeşme sin;*
*İşlerǐ şul: Bǚlgasınnar, eyde, zemzem çişmesǐn!*

Алда әйтелгәнчә, автор Тукайның шигъри әсәрләрен транскрипцияли һәм төрекчәгә тәрҗемә итә. Әсәрләрнең урнаштыру тәртибе, Тукай җыентыкларының кайсыларыннан файдалануы да безне бик кызыксындырды. Бу турыда автор «Сүз башы» өлешендә үзе күрсәтеп китә: әсәрләр номерланып бирелә, 343 нче санга кадәрге шигырьләр 1955 елгы дүрттомлыкның 1 һәм 2 нче томнарыннан тәртип буенча алынган, ә 343 нче саннан башлап килгән шигырьләр 1985 елда чыккан биштомлыктан алынган. Кул астында яңарак, фәнни яктан ныграк тикшерелгән, тулыландырылган 1985 елгы басма була торып та, ни өчен галимәнең нигездә 1955 ел басмасы белән эш итүе, безне бераз гаҗәпкә калдырды. Чөнки, мәгълүм булганча, шигырьләрнең язылу вакытын мөмкин кадәр төгәл билгеләү, аларны хронологик яктан дөрес урнаштыру шагыйрьнең иҗатын дөрес бәяләү өчен зур әһәмияткә ия. Вакытында күренекле әдәбият белгече И. Нуруллин язганча, Тукай әсәрләренең 1975—1976 елгы дүрттомлыгын, элекке еллар басмасы белән чагыштырганда, «фәннилек ягыннан алга таба бер адым китү» дип санарга мөмкин, чөнки анда нәкъ менә шигырьләрнең язылу, нәшер ителү вакытын дөрес билгеләүгә зур игътибар бирелә. Биш томлык итеп төзелгән җыентык исә тагын да тулырак, төгәлрәк, төзүчеләре язганча, «бу басмага Г. Тукайның дүрттомлыкларга керми калган һәм моңа кадәр анықы икәнлеге ачыкланып җитмәгән яки билгеле булмаган әсәрләре дә кертелә» һәм мөмкин кадәр хронологик тәртиптә бирелә. Ф. Өзкан тәрҗемә өчен алган әсәрләр белән 1985 елгы басманың беренче ике томындагы шигъри әсәрләрне чагыштырып карау хронологиядә яки әсәр исемнәрендә шактый аерымлыклар булуын күрсәтә. Шулай булмый хәле дә юк, чөнки автор ирексездән, 1955—1956 елларда чыккан басмалардагы киткән хаталарны кабатлый.

Югарыда әйтелгәнчә, 343 нче саннан башлап, әсәрләр 1985 елда чыккан җыентыктан алына һәм шулай итеп, 1913 елда язылган «Буш вакыт», «Мәктәп» шигырьләреннән соң, яңабаштан бернинди дата күрсәтелмичә, Тукай иҗатының башлангыч чорында язылган «Шигырь», «Алла гыйшкына», «Хәзерге хәлемезә даир» кебек 1905 елда дөнья күргән, нигездә корама иске әдәби телдә язылган әсәрләр тезелеп китә. Әлеге әсәрләрнең җыентыкның ахыр өлешенә туры килүе, ә әсәрнең язылу вакыты күрсәтелеп тормавы сәбәпле, җыентыкны кулына алган укучы, бу чуар телдә язылган, чын сәнгатьчә югарылыкка җитеп бетмәгән әсәрләрне бөек Тукайның соңгы елларда язылган әсәрләре дип кабл итүе мөмкин.

Фатма Өзканның «Габдулла Тукайның шигырьләре» җыентыгы «Кадер кич» (1911), «Кичке азан» (1906), «Таян аллага» (1909) кебек дини мотивларны үзәккә алган әсәрләр белән тәмамлана. Әлбәттә, әсәрләрне ничек урнаштыру җыентык авторының үз эше, әмма Тукай иҗатын үсеш-үзгәрештә, идея югарылыгы һәм сәнгатьчә осталыгы үсү-арту җәһәтеннән караганда, бу хәл дә азмы-күпме кыенлык тудырырга мөмкин.

Татар тәнкыйтендә, Тукайны өйрәнү фәнендә 70—80 елларда дөнья күргән дүрттомлык, аеруча биштомлык, Тукай иҗатын өйрәнүнең яңа бер биеклеге буларак кабул ителде. Әмма моның белән аның әсәрләрен барлау тукталды, шагыйрь биографиясенә караган яңа фактларны ачыклау эше бетте дигән сүз түгел. Тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Н. Юзеев сүзләре белән әйткәндә, «яңа рухи-идеологик атмосфера Тукай иҗатына да яңача карарга мөмкинлек тудырды. Шуңа күрә дә әдәбиятчыларның шагыйрь иҗатына яңача күз салулары, әсәрләрен бүгенге караштан барларга омтылулары, газета-журналларның исә... шагыйрь турындагы яңа материалларга «яшел ут» ачулары бик табигый күренеш саналырга хаклы».

Әмма шуның белән бергә, соңгы елларда матбугатта басылган мәкаләләрдә Тукайның биштомлыгында анықы булмаган әсәрләр урын алуы яки Тукайныкы булуы дәлилләнеп бетмәгән әсәрләрнең бирелүе һ.б. хакында да фикерләр әйтелде, материаллар бирелде. Төркиядән килгән хезмәттә безне сокландырганы — мөхтәрәм авторның бу бәхәсләрдән хәбәрдар булуы. Әмма Төркиядән торып, татар вакытлы матбугатында чыккан һәр язма белән танышып бару да бик җиңел түгел. Авторның алга таба эшләү дәверендә искә алу мөмкинлеген күздә тотып, шуңа күрә монда кайбер фактларны искәртеп китүне кирәк саныйбыз. Мәсәлән, доктор Фатма Өзкан үз китабында Тукайның «Доносчы колагына хор белән әйтелер», «Йолдыз һәм Кояш», «Бичара Бибиҗиһан» исемле шигырьләренә дә урын бирә. 1985 елгы басмада төшерелеп калдырылган бу шигырьләрнең беренче икесе «Мирас» журналының 1994 елгы 4 нче санында Ф. Ибраһимованың «Шагыйрь мирасыннан» дигән мәкаләсендә Тукайныкы дип яңадан тәкъдим ителгәннәр иде. Әмма матбугатта Ф. Ибраһимованың бу шигырьләрне Тукайныкы

дип дәлилләргә омтылуы ышандырып бетермәве турында да әйтелде. Н. Юзеевның югарыда күрсәтелгән «Тукай шигырьләреме?» («Ватаным Татарстан», 15. VII. 1994.) мәкаләсендәге сүзләр белән әйтсәк, мондый шигырьләр әлеге «текстологларны уйландыра, эзләндерә торган шигырьләр рәтендә генә йөри алалар».

Фатма Өзкан ханым җыентыгында урын алган «Сөй гомерне, сөй халыкны...» шигыре моңа кадәр дөнья күргән басмаларда чыннан да Тукай әсәре дип бирелә иде. Әмма Н. Юзеевның шул ук мәкаләсендә әйтелгәнчә, соңгы еллардагы эзләнүләрдән бу шигырьнең Тукайныкы булмыйча, Сәгыйть Сүнчәләйнеке булуы ачыкланды.

Ә менә җыентыкка ни өчен Тукай әсәрләре арасына биштомлыкта аныкы булуы ихтимал шигырьләр рәтендә генә бирелгән (башка җыентыкларга бөтенләй кертелмәгән), зур әһәмияткә ия булмаган «Приемныйның ишекләре...» шигыре урнаштырылган, без монысын аңлый алмадык.

Без монда Тукай шигырьләренең төрек-латин хәрефләре белән бирелгән транскрипциясен һәм төрек теленә тәрҗемәсен җентекләп тикшерүне аерым максат итеп куймадык. Бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә фикер-эчтәлекле азмы-күпме аерымлыклар булмый калмый, әлбәттә. Әйтик, Ф. Өзкан тәрҗемәсендә «Нәсихәт» шигырендәге «Каты сүзләр сөйләп, инсаниятен син таптама» дигән юл «Начар сүзләр сөйләп, инсанлыктан ерак калма» дип бирелә. «Доносчы колагына хор белән әйтелер» шигырендәге «хор» сүзе ялгыш «хур» дип алына һәм «хурлау, начар итеп сөйләү» мәгънәсендә тәрҗемә ителә. «Китмибез!» шигырендәге «Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?» дигән юл төрекчә «Бу гүзәл җирне ташлап...» рәвешендә бирелә һ.б.лар. Бу очракта, әлбәттә, мәгънә бераз бозыла. Ләкин мондый кимчелекләр шул кадәр вак һәм аз санлы ки, шуңа күрә алар хезмәтнең кыйммәтенә зур зыян китерми, галимәнең татар телен мөкәммәл белүендә һич шик тудырмый. Киресенчә, Фатма Өзкан ханым китабының һәр юлыннан Тукай иҗатына, татар теленә, татар халкына мәхәббәте, хөрмәте сизелеп тора. Бу хезмәтне язып бастыру өчен галимәнең ни кадәр гомерен сарыф итүе безгә билгеле түгел, әмма бөтен күңелен биреп эшләгән гаять җитди бу хезмәте белән аның татар әдәбиятын өйрәнү фәненә һәм, гомумән, тюркологиягә кыйммәтле өлеш кертүе бәхәссез. Аңа алга таба да иҗади уңышлар телибез. Татар галимнәренә исә олуг шагыйребезгә мәхәббәт-ихтирам билгесе булган «Габдулла Тукайның шигырьләре» исемле саллы хезмәт авторы Фатма Өзкан алдында түбәнчелек белән баш иярга генә кала.

**Наил ЛАИСОВ,**
**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА**
Алабуга, 1996.

*ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ*
*СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ВАФАТЫНА УН ЕЛ*

**Бу олуг шәхеснең җылысын, игътибарын, йогынтысын тоймаган берәр исән-сау язучы калдымы икән үз заманында?**

**Гомеренең ахыргы көннәренә кадәр «Казан утлары» журналының даими редколлегия әгъзасы булып, Сибгат ага Хәким иренмичә-нитмичә, һәр биргән кульязманы укый, кемнең кем икәненә карамыйча, кыска-тыйнак җөмләләр белән бәя бирә килде. Ул әйткән сүз хак иде, аның белән берәү дә бәхәскә керә алмас иде...**

**Вакытлар үтә... Сибгат ага Хәкимнең вафатына да июльдә ун ел тулды. Безнең татар халкында шәхеснең вафатын яд итү гореф-гадәте сакланып калган. Аллага шөкер, күркәм гадәтебез.**

**Бу санда без Татарстанның халык шагыйре, Россиянең М. Горький, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләкләре иясе олуг шагыйребез Сибгат Хәкимне зурлап искә алабыз. Быелның декабрендә аңа 85 яшь тулган булыр иде.**

**Татарстан китап нәшрияты, бик зур кыенлыклар белән булса да, Сибгат Хәким турында «Таныш өяңкеләр» исемле истәлекләр китабы нәшер итәргә җыена. Төзүчеләре — Сибгат Хәкимнең хатыны Мөршидә ханым Вильданова-Хәкимова һәм улы Рафаэль Хәкимов. Рәхмәт аларга: шагыйрь үзе вафат булгач, ике томлык шигъри әсәрләрен һәм бер томлык мәкаләләрен туплап укучыга җиткерүчеләр дә алар булдылар.**

**Без бүген әлеге китаптан Сибгат Хәким турындагы бер истәлекне укучыларыбызга тәкъдим итәбез.**

**Рәхим итеп, кабул кылыгыз!**

# САГЫНДЫРА...

Сибгат Хәким...

Хәсән Туфан арабыздан китеп баргач, бердәнбер таянычыбыз булып Сибгат ага Хәким калган иде. Әмма — ни аяныч! — үзенең дә гомере санаулы гына булган икән. Җан дусты, фикердәше-сердәше Туфансыз калгач, Сибгат ага ятим баладай боекты, суырылды, биреште. Болай да сәламәтлеккә туймаган шагыйребез еш авырый башлады. Шулай булмыйча соң... Торгынлык сөреме баскан дөньяга җаны әрнеп-кыйналып яшәгән Сибгат Хәким өчен Хәсән Туфан бердәнбер аклык-пакьлек нуры иде. Әрнегән күңелен бары тик аңа гына бушата ала иде ул. Шул ак нур сүнгәч, Сибгат Хәким дә озак тормады — биш ел дигәндә китеп барды.

1953 ел.

Без — төрле яклардан җыелган авыл балалары — Казан дәүләт педагогия институтына керү имтиханнары тапшырып йөрибез. Без — абитуриентлар. Студент исеме әле безнең өчен зәңгәр хыял. Күбебезнең күзләребездә курку катыш шик-шөбһә, өмет дигәнең әле бик тирәндә, күңел түрендә үк ята. Урысчалары такы-токы гына булган авыл балаларын имтиханнарда кырып кына салалар.

Шуна күрә кемнәр өчендер әлеге өмет инде бөтенләй сүнгән: аларны беренче имтиханда ук, «начар» билгесе куеп, кисеп төшергәннәр...

Бүген менә Раильне дә «кистеләр». Урысча сочинение язганда абынды Раиль. Урысчасының ни чама икәнен шуннан белергә була: «август» сүзен ул йомшаклык билгесе куеп «августь» дип язган.

Татардан битәр чегәнгә охшаган — кечкенә буйлы, чем-кара чәчле, кара күзле бу егет Әгерҗе-Красный Бор якларыннан килгән иде. Авыл малае булса да, кыю-тәвәккәл үзе. Имтихан кәгазендәге «неуд» сүзенә карап-карап торды да, күзләрен челт-челт йомгалап, җилкәсен сикертеп куйды:

— Барыбер керәм! — диде Раиль бер үҗәтлек белән.— Әйдә, Сибгат абый янына барабыз!

— Нинди Сибгат абый ул?

— Сибгат Хәким! — диде Раиль, янә җилкәсен сикертеп.— Ул Язучылар союзында булырга тиеш...



Татарстан язучыларының сигезенче съезды (1974 ел). Съезд президиумында: *(сулдан уңга)* КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табеев, шагыйрьләр Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким.

Без Сибгат Хәкимне эзләп киттек.

Бардык Бауман урамындагы Матбугат йортына. Кердек. Мин Раильгә ияреп кенә йөрим — энәгә тагылган җеп шикелле генә. Ә ул үзен бик ышанычлы тота. Баксаң, аның берме-икеме шигыре «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылып та чыккан икән. Ул Сибгат Хәким белән хатлар да алышкан. Аңа укырга керергә дә Сибгат Хәким тәкъдим иткән булган.

Сибгат Хәкимне без кайсыдыр бер бүлмәдә очраттык.

Әйе, мин моңа кадәр «Күз карашым минем уйчанланды, син беләсең микән, юк микән?..» дип моңаеп җырлап йөргән җырны язучы, күңелне кытыклап торган «Мари кызы чибәр Улина»ны язучы, бер укуда ятлап алынган:

Тәмәкемнең бүген беткән көне,
Өмет итмә берне урарга:
Мә кулымны, чибәр чегән кызы,
Риза булсаң бушка юрарга,—

дигән сихри-романтик юлларны язучы шагыйрь Сибгат Хәким иде ул. Какча юка гәүдәле бер абый икән... Минем әтием дә шундый чандыр-тәбәнәк буйлы, какча кеше иде. Сугышта — Калинин фронты сазлыкларында ятып калды ул. Сибгат

Хәкимнең дә мин укыган кайбер шигырьләре астына «Калинин фронты» дип язып куелган. Бәлки, әтиемне күреп тә беләдер әле, бәлки, бергә сугышканнардыр... Бер утырып, иркенләп сөйләшәсе иде Сибгат абый Хәким белән! Ләкин моңа минем кыюлыгым, ай-һай, җитәрме икән?..

Раиль ашыга-кабалана үз хәлен сөйләп биргәч, Сибгат абый тын гына уйланып утырды. Аннары миңа ымлады:

— Син дәме?..

Бу сорауны ике төрле аңларга була иде: «Син дә «неуд» алдыңмы?» дип тә, яки: «Син дә шигырьләр язасыңмы?» дип тә.

Мин Сибгат абыйны тынычландырырга ашыктым:

— Юк-юк...— дидем. Гәрчә «шигырь җене» миңа да кагылган, бер-ике әйберем Казан матбугатында басылып чыккан булса да, шулай дидем. Бу очракта миңа ярдәм кирәкми, Раильгә булышсагыз иде, дигән мәгънә салынган иде минем җавабымда.

Сибгат абый аңлады шикелле.

— Кайсы яктан?— дип икенче соравын бирде. Үзе һаман нидер уйлана, Раиль өчен борчыла иде булса кирәк.

— Минзәләдән,— дидем мин.— Педучилищедан...

Сибгат абыйның күзләрендә кызыксыну чагылды:

— Мөхәммәт Гарифуллин укыттымы?

— Әйе... Әдәбияттан...

— Әдәбият түгәрәгенә дә йөрдеңме?

— Әйе...

(Соңыннан белдем: Сибгат Хәким безнең укытучыбыз Мөхәммәт абый Гарифуллин белән институтта бергә укыган, алар дуслар булганнар икән.)

Сибгат абый артык сүз озайтмады. Телефоннан шылтыратырга тотынды. Аның йөзе бик җитди иде.

Үзен бөтенләй оныттылар дип, турсаебрак торган Раиль миңа карап башын кагып куйды: «Болай булгач, эш пешә...»— янәсе.

Сибгат абый телефоннан кем беләндер шактый озак сөйләште. Ашыкмый гына, салмак-сабыр гына сөйләште ул:

— Шигырьләр яза... Урысчасы начар... Сәләтле егет... Укытасы иде... Югалтмыйсы... Әдәби алмаш кирәк...

Аннары Сибгат абый Раильгә бер язу язып тоттырды:

— Бар,— диде.— Туишевка тапшыр... Үзе сөйләшер...

Туишев Казан дәүләт педагогия институтының директоры (ул вакытта «ректор» сүзе юк иде әле) иде.

Раиль, шулай итеп, Сибгат Хәким булышлыгы белән тәки студент булды бит! Институтны бергә тәмамладык. Әлү кагы калынлыгында гына булса да, ике шигырь китабы да бастырып чыгарган иде Раиль. Кызганыч, үсеп китә алмады, югалды...

Хәзер уйлыйм да хәйран калам: Сибгат Хәкимгә ул вакытта нибары кырык ике яшь булган! Ул әнә шул беренче күрүемдә үк минем күңелемә әтием белән бергә Калинин фронтында сугышып йөргән солдат булып, шунда ятып калган әтиемне алыштырырдай кеше булып, кырыс, әмма ышанычлы таяныр кешем булып кереп калды. Шушы тойгы мине гомер буена ташламады. Шуңа күрәдер дә, Сибгат ага Хәким белән безнең мөнәсәбәтләр һәрвакыт тыенкы-тартынулы, сабыр булды. Ата белән бала мөнәсәбәте шикелле... Моның шулай икәнен Сибгат ага үзе дә сизенә иде. Бервакыт мин аңа мондый шигырь укыган идем:

> Миңа инде кырык җитеп килә,
> Әти җитми һаман, әти юк:
> Кырык... илле... Гомер яшәсәң дә
> Кыса икән, кыса ятимлек...

Сибгат ага тын гына тыңлап торды да, көттереп кенә әйтеп куйды:

— Ржев тирәләрендә бик күп югалттык... Татарлар күп иде...— диде.

Бу сүзләр миңа ничектер: «Әтиең дә шунда ятып калды, егет...»— дигән кебегрәк яңгырады. Ләкин ул артыгын әйтмәде...

Соңгы елларда — 1982 елның июнендә Сибгат ага минем «Ак тынлык» исемле китабымны укып чыккан да, күңелендә туган хис-фикерләрен хат итеп өйгә язып җибәргән. Дүрт битлек шактый озан хат. Тулысы белән китереп, мактанасым килми. Баягы фикеремне куәтләргә кирәк булган бер өзек кенә китереп узам. Менә ул: «...«Ак тынлык»та иң көчле шигырь «Күңелемә, әткәй, кайтып кер». Бөтен җыентыкның рухы шушы түбәндәге юлларда:

...Шулармыни бүген оныттым?!
Онытмадым...
Бары курыктым...
Әткәй, синнән калган ул утның
Анда сүнүеннән курыктым,
Канда сүнүеннән курыктым.
Хәтеремне шуңа яңарттым,
Тормыш ваклыклары каралткан
Тутык күңелемне агарттым.
Рәхмәт, әткәй!
Ешрак кайтып тор,
Күңел бикле булса,
Ватып кер!

Бер шигырь генә түгел, калган шигырьләр дә бер сулыш белән, бер кичереш белән язылганнар. Бер бөтен хис кала...»— дип язган иде Сибгат ага Хәким.

Әйе, Сибгат ага миңа кырыс әти кебек булды, әмма һәрвакыт игътибарлы булды.

1958 елда Хәсән ага Туфан белән якыннан таныштыручы да ул иде. (Бу хакта Х. Туфан турында истәлекләремдә тәфсилләп язган идем инде. Кабатланасым килми. «Ак чәчәк атар иде» исемле китапны укучылар хәтерлиләр булыр.) Минем Татарстан радиокомитетында эшләгән елларым иде ул.

Ничектер бервакыт радиокомитетның музыкаль тапшырулар редакциясе бүлмәсендә без, Минзәлә педучилищесында укып чыккан егетләр, бергә җыелдык: музыкаль тапшырулар редакторы Ләбиб Айтуганов, «Чаян» журналы хезмәткәре Газиз Мөхәммәтшин, радионың дикторы Эльс Гаделев һәм мин. Минзәләдән соң барыбыз да Казан педагогия институты тәмамлаган егетләр, барыбыз да яшь язучылар саналабыз. Ләбиб Айтуганов, җитмәсә, матур-матур көйләр дә яза. Сөйләшер сүзләребез күп. Берәр сәбәбе булдымы икән, әллә, эш сәгате беткәннән соң болай гына, очраклы гына җыелган идекме икән — хәзер инде тәгаен генә әйтә алмыйм.

Шулай шаулашып-көлешеп утырганда, кемнеңдер тамак кыруын ишетеп, борылып карадык. Ишек төбендә хәйләкәр елмаеп Сибгат Хәким белән композитор Исмай Шәмсетдинов басып тора! Ничек сездерми килеп кергәннәр, диген?!

Билгеле инде, без ярамаган эш өстендә тотылган кешеләр шикелле, бик уңайсызландык.

Мин Сибгат ага белән бергә чыктым, юлыбыз бер якка иде. Сөйләшми генә атлыйбыз. Миндә әле һаман да уңайсызлану бетмәгән. Бераз баргач, Сибгат ага әйтеп куйды:

— Сиңа китап керткән идем... Урысча китабым... Мәскәүдә «Детгиз» чыгарды...— диде.

— Рәхмәт, Сибгат ага!— дидем мин.

— Өстәлеңдә калдырдым...— Сибгат ага ни өчендер миңа үпкәле кебек тоелды.

Мин, үзем дә сизмәстән, аклана башладым:

— Язып булмый, Сибгат ага! Көндәлек тормыш изә... Әллә бөтенләй ташлыйсы инде язу дигәнен!

Сибгат ага сынаулы авыр карашы белән мине сөзеп алды:

— Ташлый алмассың... Үземнән беләм. Якаңнан бер бөтереп алгач, ташлатмый ул!— диде.

Аерылышырга кирәк иде.

Сибгат ага туктады:

— Ә бу... болай утыруларыгыз күпкә китсә...— диде. Аннары сүзен әйтеп бетермичә, кулын селтәп куйды.

Күңелсез генә аерылыштык.

Миңа бик оят иде...

Ә Сибгат аганың калдырган китабы «Дневник беспокойной души» дип атала икән. Татарча әйтсәң, «Тынгысыз җан көндәлеге»... Никадәр тирән мәгънә. Әле менә эзләп алдым да, автографының датасын карадым: 1960 елның 24 мае булган икән ул көн.

1961 елның башында мине кабат чыга башлаган «Яшь ленинчы» газетасының әдәбият-сәнгать бүлегенә мөдир итеп күчерделәр.



«Казан утлары» журналы редакциясенең редколлегия утырышы (1970 еллар). Рәсемдә: *(сулдан уңга)* шигърият бүлеге мөхәррире, шагыйрь Нури Арслан, публицистика һәм очерклар бүлеге мөхәррире, язучы Кояш Тимбикова, редколлегия әгъзасы, шагыйрь Сибгат Хәким, журналның баш мөхәррире, шагыйрь Зәки Нури.

Бер очравында Сибгат ага:

— Әйбәт булган,— диде.— Язучыларга якынрак. Күбрәк яза башларсың...

Чынлап та шулай булды. Озакка сузылган авыр эзләнү чоры узды шикелле. Мин ышанычлырак яза башладым. Бер-бер артлы «Җирән Конрад», «Сине эзлим», «Кына гөле» кебек поэмаларым языдлы. Аларны Сибгат ага Хәкимгә укырга бирә идем. Иренмичә ала, укый. «Кына гөле» поэмасын укып чыккач, кульъязма астына ул болай дип язып куйган: «Без көтмәгән яктан ачылган бу шагыйрь, кызык шагыйрь, яңа шагыйрь. С. Х.» Монысы 1962 елда икән.

Алтмышынчы еллар башында әдәбиятка күр тавышлы яшьләр килде. Соңыннан Равил Фәйзуллиннар, Ренат Харислар буыны дип аталып йөртеләчәк бу буын илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр дулкынында шаулап күтәрелде. Әдәбиятка Г. Ибраһимовлар, Х. Туфаннар, К. Тинчуриннар һәм башка күп язучыларыбыз әйләнеп кайткан иде инде. Шифалы яңарыш чорының башы иде бу.

Яшьләр бездән нык аерылып тора иделәр. Без, традицион калыплардан бигүк чыкмыйча, як-ягыбызга каранып кына, тыенкы гына иҗат иткән бер вакытта, Равил, Ренатлар, Рәдиф, Рөстәмнәр канунлашкан кыса-калыпларны җимереп ташладылар. Матбугат битләрендә ирекле шигырь, ак шигырьләр турында шаулы бәхәсләр куерды. Әнвәр Давыдов, Шәрәф Мөдәррис кебек шагыйрьләр яшьләрнең «искене җимерү» омтылышын кайнар яклап мәкаләләр язып чыксалар, Хәсән Туфан кебек аксакалыбыз бу күренешләргә Тукай-Җәлил традицияләрен җимерү дип карады, шигырьне вату-сындыруны аның вөҗдүе күтәрә алмый иде.

Ә Сибгат Хәким?

Сибгат Хәким бер дә сабырлыгын җуймады, кайнарланып-каударланып бәрелмәде. Аның фикере бер булды: «Эзләнсеннәр...»

Равил, Ренатлар, Рәдиф, Рөстәмнәр «Яшь ленинчы» редакциясенең әдәбият-сәнгать бүлеге бүлмәсендә еш кайнашалар иде. Миңа да алар белән әвәрә килүе кызык-күңелле. Һәр яңа шигырь кычкырып укыла, шунда ук сүтеп ташлана, яңадан җыела. Кайнар бәхәсләр... Үпкәләп ишек бәреп чыгып китүләр дә булмады түгел.

Хәсән Туфан боларның берсен дә өнәми. Ул рәсми булмаган бу «шигъри студиядә» яшьләр бозыла гына бара дип карый. Аның бәхетенә Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәт исеме калкып чыкты. Алар да «Яшь ленинчы» битләреннән күтәрелделәр. Болар традицион шигырь тарафдарлары иде, Хәсән Туфан күңеленә май булып яттылар.

Сибгат Хәким безнең редакциягә еш керә. Күбесенчә көтмәгәндә килеп керә ул. Тавыш-тынсыз гына килеп керә дә, гаҗәеп тере күзләре белән генә елмаеп исәнләшә:

— Исәнме!

— Исәнмесез, Сибгат ага, исәнмесез! Әйдәгез, утырыгыз!

Сибгат ага ашыкмый гына килеп утыра, кулы белән сирәк-кыска чәчләрен сыпырып куя.

— Менә кердем әле...

— Ни хәлләр соң, Сибгат ага? Шигырьләр китердегезме?

— Авылда торып килдем әле. Авыл күңелне чистарта. Анда әйбәт языла...

Сибгат аганың шулай салмак-тын гына сөйләнеп утыруыннан аңлап аласың: ул үзенең яңарак язылган шигырьләрен күңеленнән кичереп утыра, шигырьләренең кайсыдыр юлларын сүз арасына кыстырып җибәрә, аларны сынап карый шикелле. Юк, ул шигырь укымый. Ул сиңа күңелдәгесен генә сөйли.

Менә әле дә ул авыл турында, тегермәннәр турында, яңгырлар турында, үзалдына сөйләнгәндәй генә итеп, сөйләшеп утыра. Ә бераздан аның яңа шигырьләре басылып чыга:

Монда да язмасаң: куаклар
Чыкларын өстеңә бөркесен...
Төртелсәң, кошчыклар әйтәләр
Җырының иң кирәк бер төшен...

«Тегермән стенасындагы язулар», «Англиягә барып кайт син...», «Болында көтүләр...», «Юат син шуларны» һ. б.— болар барысы да авыл шигырьләре. Шагыйрь аларны авылдан алып кайткан. Сибгат Хәким иҗатына төп илһамны авылдан ала, туган җиреннән ала. Елның һәр җәендә, гадәттә сабан туйлары вакытына туры китереп, ул авылга кайта. Анда ул һәрвакыт үз кеше. Көтеп алынган кадерле кунак.

Бөтенләем белән Җирнеке мин,
Минем барлык нәсел-нәсәбем —
Игенчеләр. Җирдән төртеп чыга
Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем...

Нәкъ шулай бит!

Күңелен бушатып бетергәч, Сибгат ага урыныннан кузгала. Сүз уңаеннан гына әйтеп куя:

— Рәдиф шигырьләрен укыткан иде. Синең усаллыгыңнан зарланды...

Сибгат ага артыгын әйтми. Шушы ике җөмләдән үзең аңлап алырга тиешсең: Рәдиф Гатауллин — әйбәт шагыйрь, сәләтле. Тик ул Равил Фәйзуллиннар, Ренат Харислар кебек каты сынлы түгел. Рәдиф — йомшаграк, романтик, нечкә хисле, аның күңеле тиз яралана. Димәк, нәтиҗә шул: Рәдифкә саграк, ягымлырак бул, диюе Сибгат аганың.

Инде ишек төбеннән тагын бер-ике сүз өсти:

— Аларны шушында җыюың әйбәт. Үзең дә үсәсең...

— Сез шулай дисез дә, Сибгат ага, Хәсән ага Туфан өнәп бетерми бит менә! — димен. Күңелемне кырып йөргән уемны әйтәм.

Сибгат аганың күзләрендә хәйләкәр елмаю кабына. Ул җавап бирми, кулын гына селтәп куя да чыгып китә.

Шагыйрь өздереп җавап бирмәсә дә, күңел тынычланып кала, үзеңә, кылган эшләреңә ышаныч арта.

Әйе, Сибгат ага Хәким минем иҗатыма да, үземә дә игътибарлы булды. Күтәреп алып мактаган чаклары аз булды, әмма ул мине бер дә күз уңыннан төшермәде. Әле 1958 елда ук үзенең бер мәкаләсендә ул: «... хәзер тәҗрибәле олы шагыйрьләр рәтенә кайберләре инде тәмам формалашкан, кайберләре әле үзен яңа табып килгән» Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Әдип Маликовлар янына Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Хисам Камалов, Илдар Юзеевлар белән бергә, Марс Шабаев дип, минем дә исем-фамилиямне кыстырып куя. Рәтле-юньле яза алмаганыңа үртәлеп, үз-үзеңне кая куярга белми йөргән бер вакытта олы

шагыйрьнең әнә шулай сине дә исәпкә-санга кертүе күңелне күтәреп җибәрә. Әле бит Сибгат ага «боларның һәрберсендә иҗатларының берәр матур ягын, берсен-берсе кабатламый торган үзенчәлекле ягын табарга мөмкин» дип тә өсти. Димәк, без дә төшеп калганнардан түгел икән!

Соңрак елларда Сибгат Хәким минем иҗатым турында «Яшел җикәннәр җыры» («Социалистик Татарстан», 15 июль, 1973), «Правдивость и человечность» («Комсомолец Татарии», 4 апрель, 1976) кебек аерым мәкаләләр белән дә чыкты. «Ищу тебя» исемле урысча беренче китабыма да (1974) кереш сүзне ул язды. Аның «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» исемле әдәбипублицистик мәкаләләр китабында да (1979) үз иҗатыма кагылышлы фикерләрне күп очраттым.

Бу урында Сибгат ага Хәкимнең бер хатыннан өзек китерәсем килә.

«Марс!

«Калевала»дан тәрҗемәләреңне укып сөендем. Әсәр үзе искиткеч, тәрҗемәләр дә шәп. Татарча агып тора, син талантлы тәрҗемәче дә икәнсең әле. Саф татарча, теле бай, төртелми. Мондый әсәрне һәркем эшли алмый. Синең табигать дөньясын ятратуың булышкандыр дип уйлыйм. Менә халыкның хыялы ничек бай һәм ничек уйный. Зур эш башкаргансың. Киләчәктә бер китап булыр, ахырына җиткер...»

Бу хатны Сибгат ага 1984 елның 17 ноябрендә язган. Мин карел-фин халык эпосы «Калевала»ны тәрҗемә иткән чорда. Аксакал шагыйрьдән шундый хат алгач, ничек куанмыйсың да, ничек сөенмисең! Тәрҗемә — авыр шөгыль, үз әсәреңне язудан да авыр. Сибгат аганың бу хуплавыннан янә көч-куәт алдым шикелле. Кыска гына вакыт эчендә «Калевала»ның берничә табагын тәрҗемәләп чыктым. Аның бер өлеше «Казан утлары» журналында дөнья күрде.

Бүген безгә бер-беребезнең иҗатына карата әнә шундый кырыс һәм гадел игътибарлылык җитенкерәми. Мактасак, күкләргә күтәреп мактыйбыз — кешесенә карап. Яманласак, бөтенләй бетереп ташлыйбыз — анда да кешесенә карап. Хәсән Туфаннар, Сибгат Хәкимнәр гаделлеге җитми.

Җитмешенче еллар башы.

Чаллы якларында КамАЗ шау-шуы башланган еллар. Аңа кадәр күп элек, әле Никита Сергеевич Хрущев заманнарында ук, Түбән Кама ГЭСы төзү мәсьәләсе кузгатылган һәм күпмедер эшләр дә башлап куелган иде. Шуңа бәйле рәвештә иген басулары өстендә Түбән Кама каласы калкып чыкты.

Язучылар-шагыйрьләр шул якларга ябырылдылар. Тиз арада кемнәрдер калын-калын романнар язды, кемнәрдер шигырьләр, поэмалар сырлады. Язганнарының күбесе, кем әйтмешли, «Ура!» да «Яшәсен!» рухындарак иде.

Мин, шул якларда туып, Чулман-Ык суларын эчеп үскән кеше, никтер кабынып китә алмадым. Тамагыма төер утыра иде...

КамАЗларга кадәр үк әле, Түбән Кама ГЭСын төзү башлангач, су астында калып харап буласы Ык буе әрәмәләрен, болын-күлләрне янә бер күреп, күңелгә сеңдереп калу нияте белән без — бер төркем ир-егетләр — 1967 елда Ык буенча салда сәяхәт оештырган идек. Аннары икенче җәйдә Казаннан Тымытыкка кадәр ике көймәдә күтәрелдек. Бу хакта җәелеп сөйләп тормыйм: укучылар «Салда сәяхәт» дигән повестемны укый алалар. Шул елларда «Җикән камыш» дигән шигырьләр циклым да тупланып, аерым бер китап булып өлгереп җитте.

Сибгат Хәким минем иҗатымдагы бу әйберләрне яхшы белә. «Җикән камыш» циклыннан аерым бәйләмнәрне «Казан утлары» журналына үзе сайлап биргән кеше. Аның Ык буйларында күп йөргәне бар, ул да безнең якның табигатенә гашыйк кеше иде.

КамАЗ шаукымы, шагыйрь буларак, Сибгат Хәкимнең дә күңелен кузгатты. Ул Чаллы якларын кат-кат урады. Нәтиҗәдә аның «КамАЗ көндәлеге» дигән шигырьләр циклы һәм «Дәверләр капкасы» дигән поэмасы дөнья күрде. Поэмасында:

КамАЗ белән бары намаз гына
Рифмалашмый калган заманда,
Мин дә йөрдем, йөрдем КамАЗда,—

дигән юллар да бар. Шагыйрьнең үзенең дә конъюктурадан читтә кала алмаганына ишарә юллар бу.

Дөресен әйтим, «Дәверләр капкасы» поэмасын мин үзем тулысынча кабул итә алмадым. Фикерләрем каршылыклы иде. Һич сүз юк: әсәр әдәби яктан тел-теш

тидерерлек түгел. Ул Сибгат Хәкимгә хас осталык белән язылган — кыска-җыйнак. Әмма гомуми шаукым, гомуми эйфория аксакал шагыйрьне дә читләп үтмәгән иде:

Урамнары буйлап Илбактының —
Киләчәге буйлап ил бәхетенең
Гиздe уем... Карап сокланырга
Мендем таңда Кама сыртларына...

Мин исә, балачактан шунда аунап-тәгәрәп үскәнгәдер инде, актарылып-кубарылып ташланган Кама сыртларына карап һич кенә дә соклана алмый идем. Минем җаным елый иде...

Ә менә Сибгат аганың «КамАЗ көндәлеге» циклындагы байтак шигырьләрендә яралы күңелемә аваздаш аһәңнәр бар иде. Анда — сүтеләчәк йорт өстендә зарын сөйләп тургай тора; анда — күчәргә тиешле өйне саклагандай, йөз яшьлек карт тирәк утыра, шагыйрь исә «җәлләп чебешне кран-тилгәнгә тамак кыра»... Сибгат Хәким яңа шәһәрдә утыртылган яшь юкәне күреп тә борчыла: «Китәрме? Белмим, ни әйтер туган җирнең туфрагы?» — ди ул. Ә туган җирнең туфрагы кызыл балчыгына кадәр актарып-кырып алынган... Чал сакаллы Чаллы карты: «Тукта, ни булды дигән күк, карап тора Чаллыга».

Көннәрдән бер көнне Сибгат ага Хәким, гадәтенчә, шыпырт-тын гына минем эш бүлмәмә килеп керде. Өстендә — кыска җиңле ак күлмәк, башында — җиңел, җәйге эшләпә. Әйтергә кирәк, ул һәрвакыт пөхтә йөрер иде.

Көннәрнең бик тә эссе торган чагы иде. Җәй уртасы. Мин, эшемне түгәрәкләп, Идел буендагы дачама ычкынырга атлыгып утыра идем.

Сибгат ага минем уй-ниятемне сизенгән диярсең! Исәнләшкәч, урындыкка килеп утыргач:

— Эссе...— дип куйды.— Су буйларына китәсе иде...

— Әйдәгез соң, Сибгат ага!— дип күтәреп алдым сүзен.— Киттек безнең дачаларга! Мөршидә апага шылтыратып әйтеп куябыз да... Идел буе — су буе...

— Су безнең Аккош күлендә дә җитәрлек!— Сибгат ага тынып тора. Тирәнгә яшеренгән тере күзләрендә аңа гына хас хәйләкәр очкыннар кабына.— Ык-Кама буйларына китәсе иде...

Монысы инде минем авырткан җиргә килеп тия: Ык-Кама турында сүз чыктымы, мин кайнарлана башлыйм:

— И, Сибгат ага, күңелне кузгатмасагызчы! Анда кайтып, кубарылып ташланган зиратлардан ата-бабаларыбызның сөякләрен җыеп йөримме? Бетте бит ул Ык буйлары! Актарып бетерделәр!

Сибгат ага авыр көрсенеп куя:

— Шула-а-ай...— Тагын тынлык. Аннары: — Мәхмүткә хат язган идем...— ди.

— Мәхмүт Хәсәновкамы?— Мин Сибгат аганың Мәхмүт Хәсәнов белән дустана мөнәсәбәтен беләм. Азнакай-Тымытык якларына — Ык буена Хәсән Туфан белән бергә барып, Мәхмүттә кунак булганнарын да ишеткәнем бар. Мәхмүт мактанып-мактанып та, балык эләкмәгәч: «Борчакны күбрәк сибеп ташладың, ахры, Мәхмүт...» — дигән, имеш, Сибгат Хәким. Бу вакыйга язучылар арасында үзенә бер кызык мәзәк итеп сөйләнеп йөртелә иде.

— Әйе, Мәхмүткә.— Сибгат ага көттереп кенә өсти.— Ык тамагын күрәсем килә иде. Син язган Ык тамагын...

Минем «Җикән камыш» циклында, чынлап та, «Ык тамагы» дигән шигырь-балладам бар.

Кояш егыла
Чиркәү өстенә.
Кояш егыла,
Йөзләре кандай...
Күңелдә калка
Бәхтияр Канкай,—

дип тәмамлана ул баллада.

Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасында исә:

Пугачевның ярда быргылары
Уйнады күк...—

дигән юллар бар. Бу инде без сөйләшеп утырган җәйге көннән соң бер ел үткәч язылган юллар.

— Мәхмүттән нигәдер җавап юк әле...— Сибгат ага миңа текәлеп карый. Әйтерсең, Мәхмүтнең җавап бирмәгәненә мин дә гаепле.

Мин түзмим:

— Август айларында, ял алгач кайтып булса гына инде, Сибгат ага...— дим.

Сибгат ага җанланып китә:

— Әйдә, булдыра алсаң, оештыр әле!— ди.— Бәлки, үзең дә яза башларсың. Анда син генә белгән, син генә язардай нәрсәләр күптер...

. Мин өстәл тартмасын ачып, бер дәфтәр чыгарам. Аны Сибгат агага курыкмыйча күрсәтергә була: ул сөйләнеп йөрмәячәк. Дәфтәр битләрен актаргалап, үземә кирәкле битен тапкач, аны сүзсез генә Сибгат агага сузам.

Ул алмый, сүрән генә итеп:

— Үзең укы...— ди.

Күренеп тора, Сибгат аганың бу эсседә һич тә шигырьләр тыңлап утырасы килми. Юк инде, Сибгат ага, үзең кузгаттың күңелне! Тыңларга туры килер...

Мин дулкынланып укый башлыйм:

Югаласыз бигрәк әрәмәгә лә,<br>
Балачагым үткән әрәмәләр!<br>
Диңгез төпләрендә сез каласыз...<br>
Мин каңгырыйм, гүя кош — баласыз...

Тавышым калтырап чыга. Еламсырак тавышымны җиңәргә тырышып дәвам итәм:

Югарыда — түрә-гигантоман!<br>
Кирәк, имеш, аңа гигант һаман.<br>
Бу якларга килеп КамАЗ корды —<br>
Ата-бабам җирен кырды...<br>
Кырды...

Шигырь шактый озын, урыны-урыны белән әле эшләнеп тә бетмәгән. Мин андый җирләрендә төртелеп калам. Аннары, икенче юлларга күчеп, яңадан укып китәм...

Ниһаять, шигырь укылып бетә.

Сибгат ага, гадәтенчә, көттереп кенә телгә килә:

— Шула-а-ай...— дип суза ул.— Язасың икән! Кабатла әле теге «яшел башлар» дигән төшен...

Мин кабатлап укыйм:

Диңгез йотар сезне, дулкын ашар,<br>
Ислам байрагыдай яшел башлар...

Бераз сөйләшми утырабыз. Һәр икебез үз уе белән мәшгуль. Бераздан мин ачынып:

— Менә шундый шигырьләр языла, Сибгат ага!— дим.— Кайда бастырасың аларны?

— Үзең баш редактор бит!— дип шаяртмакчы була Сибгат ага. Аннары үзе үк өстәп куя:— Басмаслар шул... Вакыты ул түгел. Ә син барыбер яз!— дип, кулы белән һаваны кисә ул.— Бер чыкмаса, бер чыгар әле...

Аксакал шагыйрь хаклы булган икән: бер чыкмаса, бер чыга икән. «Ык әрәмәләренә карап моңлану» дигән бу шигырь безнең сөйләшүдән соң уналты ел үткәч — 1989 елда «Гомер уты» исемле китабымда басылып чыкты. Шундыйрак шигырьләрне күбрәк язасы калган да икән бит... Әмма шигырь ул, шул ук хатын-кыз шикелле, нәзберек нәрсә. Йә син аны яулыйсың, яки алданасың...

Без шулай байтак кына сөйләшеп утырабыз. Ниһаять, август айларында булса да, Ык тамагына — Чаллы якларына барып кайтырга килешеп, аерылышабыз.

Кызганыч, бу вәгъдәне үтәп булмады. Кирәк бит: шул эссе җәй көннәренең берсендә мин, үпкәмә салкын тигезеп, шактый вакытка больницага кереп яттым...

Ә Сибгат ага Хәкимнең «КамАЗ көндәлеге»ндәге шигырьләрендә:

Экскаваторның чүмечендә —<br>
Чәбәләнде ае Болгарның —<br>
Болгандың син, Кама, болгандың...

кебек борчылу-моңсу юллар арта төште булса кирәк.



Шагыйрьләр Марс Шабаев һәм Сибгат Хәким. Татарстан әдипләренең X съезды (1984 ел.)

— Татарның иң үзәге булган яклар бит... Син шигырьләрең белән мине андагы хәлләргә башкачарак карарга булыштың...— диде Сибгат ага, «КамАЗ көндәлеге» басылып чыккач.

Сибгат Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап» исемле китабын (1983) мин редакцияләдем. Китап кульязмасының беренче битенә салынган шигырь үк мине тетрәндереп җибәргән иде. «Сугышның дәһшәте, көче» дигән юллар белән башланган бу шигырь Сибгат аганы яңадан сугышның ут-давыллары эченә — Дугаларга алып кереп китә:

Кычкыра карлыккан тавыш:
«Алгарак утны күчер!»

«Ата-анасы белән» сүгенеп кычкырган бу рота командиры минем күз алдыма Сибгат Хәкимнең үзе булып килеп баса: Ржев тирәләрендә һәм Курск дугасында барган канкойгыч сугышларда ул бит нәкъ менә рота командиры булган.

Ата-анасы белән сүгенә дигәннән, Сибгат ага бер дә сүгенә белми иде, әшәке теллелекне аның җаны күтәрмәде. Бик тә әрнегән, бик тә ачуы килгән чакларда ул: «Әй,... әбиләрен!»— дип, кулын гына селтәп куяр иде. Аның бу «әбиләрен!»е шул кадәр йомшак кына, әкрен тавыш белән әйтелә — аны һич кенә дә сүгенү итеп кабул кыла алмыйсың.

Һәм менә карлыккан тавыш белән кычкыручы рота командирының сүзләре шигырьнең соңгы юлларында безгә кайтаваз-васыять булып яңгырый:

Онытма шигырь утыңны
Алгарак күчерергә!

Шигырь 1979 елда язылган. Халык шагыйре Сибгат Хәкимнең безгә — калган шагыйрьләргә васыяте...

Күләме белән артык зур булмаган әлеге китапка Сибгат аганың гаҗәп шигырьләре тупланган иде. Аны редакцияләү минем өчен үзенә күрә бер бәйрәм кебек булды. Шигърият бәйрәме, шигырь бәйрәме!

Шул ук вакытта күңелгә ниндидер аңлатып булмаслык моңсу сагыш та иңә... Аксакал шагыйрь тикмәгә генә Дуга сугышларыннан алып соңгы көннәренә кадәр булган бөтен тормышын хәтереннән үткәрми шикелле. Йомгак ясый шикелле...

Әйтсәләр: Хәким малае
Үлде, вафат, кулыйн[1],— дип,
Ышанма, белеш, мари дус,
Селтә бары кулыңны,—

дип, үз-үзен дәртләндерсә дә:

Кардәшлек, дуслык хакына
Кичерер, бәлки, кулыйн,—

дип юанса да... Юк... Бу дөньяда мәңгелеккә калмак юк...

Шагыйрь шуңа күрә дә күңелендә булган уй-хисләрен түгеп калырга ашыга. Хәтерен барлый.

Менә бер шигырьдә «чәчәкләргә гашыйк Хәсән Туфан һәр ел шулай, һәр ел бер вакытта» Тукайга чәчәкләр куя:

Шунда тәмам кушылып бетә кебек
Тукай белән Туфан арасы...

Бу юлларны хәзер инде «Тукай, Туфан, Хәким арасы» дип укырга да буладыр шикелле.

Китабы басылып чыккач, Сибгат ага Хәким автографын язып бүләк иткәндә болай диде:

— Рәхмәт! Үзем теләгән соңгы шигырьләремнең барысы да сыйды монда...

Автографы: «Марска! Минем соңгы китапларымның берсенең редакторына. Хөрмәт белән — Сибгат Хәким. 28/VI—83».

Шагыйрьнең вафатына өч ел калган булган икән... Күңеле шулай бик алдан сизенде микәнни соң? Шулайдыр. Шагыйрь күңеле бит ул, әүлия күңел!

Туган якта һәр тал җырлый,
Җырлый таллар үзенчә.
Җырлый таллар, нишләр ярлар,
Бер көн җырлар өзелсә?..

Аның җырлары өзелде... Ул яраткан җәйге айларда өзелде... Юк, өзелмәде! Алар безнең белән, безнең күңелдә, безнең җанда. Тын гына елмаеп килеп керергә яраткан шагыйребез үзе генә юк. Ышыкланыр кешебез юк... Сибгат ага Хәким юк...

Сагындыра, бик тә сагындыра...

**Марс ШАБАЕВ**

---

[1] Кулыйн — марича «үлде» мәгънәсендә.

## Китап күзәтү

# МУЗЫКА СҮЗЛЕГЕ

Татар музыкасы тарихында беренче мәртәбә «Русча-татарча музыкаль терминнар сүзлеге» (Краткий русско-татарский словарь музыкальных терминов. Казань, изд-во «Таң—Заря», 1995.—124 стр.) дөнья күрде. Сүзлек музыка белгече И. Алмазов һәм тел белгече Д. Рамазанов тарафыннан төзелгән.

Тормышыбызның бөтен өлкәләрендә дә, шул исәптән музыкада да туган телебез үзенең хокукын акрынлап булса да яулый бара. Мондый яңарыш күп кенә проблемалар да тудыра. Мәсәлән, 60—80 елларда татар балаларын үз туган телендә музыкага өйрәтү өчен һәртөрле ярдәмлекләр бик аз чыкты. Дәреслекләр, методик кулланмалар, ноталы басмаларның җитмәве, алай гына да түгел, юк дәрәҗәдә аз булуы музыка белемен татар телендә алып баруда авырлыклар тудырды. Халкыбызның милли музыкаль мирасын, хәзерге композиторларыбызның бай иҗат җимешләрен шушы эштә мөмкин кадәр тулырак һәм нәтиҗәлерәк файдалану өчен дә һәртөрле ярдәмлекләр булу зарури.

Әлбәттә, соңгы елларда музыка өлкәсендә эшләүчеләр тарафыннан шактый гына кулланмалар эшләнде. Мәсәлән, Казан педагогия университеты профессоры С. Рәимова тарафыннан татар материалына таянып сольфеджио дәреслеге төзелде. Казан консерваториясе профессоры В. Спиридонова татар фортепьяно сәнгате буенча, Р. Еникиев, Р. Зарипов, А. Луппова h.б. лар композиторларыбызның ноталарыннан җыентыклар чыгардылар. М. Нигъмәтҗанов, И. Алмазов, А. Хәйретдинов, В. Дулат-Алиевлар да бу юнәлештә эш алып баралар һәм озакламый укучыларга төрле-төрле ярдәмлекләр тәкъдим итәчәкләр. Шунсы сөенечле: мондый эшләр шактый оешкан төстә алып барыла. Төгәлрәк әйткәндә, Җөмһүриятебезнең Мәдәният министрлыгы каршындагы Музыкаль һәм сәнгати белем бирү методик кабинетының зур ярдәме белән башкарыла бу эш. Ул кабинетны Н. Аршинова җитәкли.

Әлеге «Русча-татарча музыкаль атамалар сүзлеге дә» шушы кабинет ярдәме белән чыгарылды.

Сүзлекне төзүчеләр — үз өлкәләрендә инде күп еллар буенча нәтиҗәле эшләп килә торган галимнәр. Алар татар халкы мәдәниятендә актив һәм нәтиҗәле эшчәнлек алып баралар.

Әйтергә кирәк, биредә авторлар бик авыр мәсьәләне хәл итүгә алынганнар, аларга шушындый сүзлек төзүдә беренче бураэнаны ярырга туры килгән.

Татар теле белемендә һәртөрле сүзлекләр төзү һәм гамәли, һәм фәнни яктан нык үстерелгән булса да, музыка өлкәсендә хәзергә кадәр сүзлекләр эшләнгәне юк иде әле. Икенче яктан, җитмеш ел буе татар теленең кулланылышы чикләнеп килү дә әлеге эшне читенләштерә. Чөнки ул чорда телебезнең байлыгы үстерелмәде, яшәеш кысалары аны төрле яклап тарайта килде. Фән, мәдәният һәм шул исәптән музыка алгарышының хәзерге дәрәҗәсен чагылдыра торган терминнар эшләнмәгән. Яисә аларның бер өлеше гарәп-фарсы сүзләре буларак кысрыкланган һәм рус терминнары белән алмашынган.

Авторлар исә бу сүзлектә теге яки бу терминны татар теленә тәрҗемә итеп кенә калмыйлар, ә бәлки терминның эчтәлеген мөмкин кадәр төгәлрәк ачарга тырышалар. Моның өчен инде кулланылыштан төшеп калган яки искергәннәр рәтендә йөри торган сүзләрне дә яңартып, кулланылышка кертеп җибәрәләр. Эш барышында төзүчеләр күп кенә башка сүзлекләр белән танышканнар, революциягә кадәр һәм борынгы чорда иҗат ителгән әдәби әсәрләребезгә һәм башка төрле басмаларга да мөрәҗәгать иткәннәр. Алар үз туган телебезнең байлыгына таянып

яңа терминнар ясау бурычын да куялар.

Мәсәлән, биредә авторлар әдәби мирасыбызның тутыкмас җәүһәрләрен язып калдырган Хисам Кятибтагы (XIV гасыр) мондый сүзләргә игътибарны юнәлтәләр: чаң (хәзерге телебездә чаң сугу), кубызчы, найчы, табыл, оргы, чалгы чалу, дәф (чалу?), чимбал ору, кәф ору, мөтрибче һ. б.

Әйе, тарихи байлыгыбыз, һичшиксез, яңартылырга тиеш. Авторларның бу юнәлештә дә эзләнүләр алып баруы сүзлекнең әһәмиятен тагын да арттыра.

Билгеле булганча, музыкаль атамаларның шактый зур өлеше халыкара мәйданда урын алган инде. Авторлар моны да аңлап эш итәләр. Мәсәлән, сүзлектә соната, мордент, альт, тетрахорд, секунда һ. б. атамаларны тәрҗемә итү максаты куелмый. Һәм бу дөрес тә.

Шул ук вакытта стиль (өслүб), композитор (аһәнче, музыкачы), тутти (дәррәү) скрипка (кәмән) һ. б. атамаларга татар телендә эквивалентлар табу, безнеңчә, шактый уңышлы хәл ителгән.

Бер төркем атамаларга эквивалентларны әлегә тәкъдим рәвешендә генә калдыру шулай ук авторларның эзләнүен күрсәтә. Мәсәлән: трио — өчәү, өчәүләшеп; триоль — өчләч, квартоль — дүртләч, һ. б. ш.

Хезмәтнең тагын бер әһәмиятле ягын күрсәтмичә мөмкин түгел. Максатка ярашлы рәвештә, (сүзлек музыка мәктәбендә укучыларга ярдәмлек-кулланма рәвешендә төзелгән) күп кенә атамаларга кыскача гына аңлатмалар да китерелә. Бу исә балага да, аны өйрәтүче педагогка да өстәмә уңайлыклар тудыра. Атаманың эчтәлеген тирәнрәк ача һәм балага да, сүзлеккә мөрәҗәгать иткән башка кешеләргә дә киңрәк мәгълүмат бирә.

Гомумән, авторлар сүзлекнең мәгълүматлылыгын баетуга зур игътибар иткәннәр. Атамаларның кайсы телдән алынуы турындагы фактлар да бик кызыклы. Төрки халыклар, шул исәптән безнең борынгы бабаларыбыз да, бай мәдәниятле булганнар, күрше халыкларга да йогынты ясаганнар. Мәсәлән, рус телендәге барабан, балалайка, набат, курай, кубыз (комуз, шуннан украиннардагы кобза) атамалары төрки атамалар икәнлеге фәндә күптән мәгълүм, ә лютня сүзе исә гарәп теленнән кергән.

Атамаларның сүзгә сүз тәрҗемәсен урнаштыру да хезмәтнең эчтәлеген баета, аны фәнни яктан да югары күтәрә.

Әлбәттә, авторлар әлеге мәсьәләне тулысынча хәл ителде дип санаудан ерак торалар. Алар бу беренче «бразнаны» тирәнәйтү, яхшырту һәм баету юнәлешендә эшләүләрен шулай уңышлы дәвам итсәләр иде.

**Тәнзилә АЛМАЗОВА,**
музыка белгече.

# УТЛЫ ЮЛЛАРНЫ УЗЫП

Бүгенге татар әдәбияты кызыклы шәхесләргә бик тә бай. Аның кайсы гына тармагын алып карасаң да, кабатланмас иҗатка ия һәм гыйбрәтле тормыш юлы үткән әдипләрне очратасың.

Бу айда үзенең 70 яшен тутыручы Габдулла Шәрәфи дә укучылар күңелендә үз урынын алган танылган прозаик, без яратып укый торган күп санлы әсәрләр авторы.

Габдулла Шәрәфи 1926 елның 29 июлендә Татарстанның Биектау районы Кече Битаман авылында крестьян гаиләсендә туган. 1936 елда алар гаиләләре белән Казанга күчеп киләләр. Габдулла Шәрәфи урта мәктәптә укыганда дәреслекләр авторы Шакир Нигъмәтуллин җитәкләгән әдәби түгәрәккә йөри. Шул чорда аның «Батыр егет» исемле әкият-поэмасы «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга.

Бөек ватан сугышы башлангач та Габдулла Шәрәфи, укуын ташлап, эшкә урнашырга мәҗбүр була. Аннан — солдат язмышы. Габдулла Шәрәфи Япониягә каршы сугышу хәрәкәтләрендә катнаша, совет гаскәрләре составында Монголия далаларын, Гоби чүлен, Хинган тауларын кичә.

Армиядән кайткач, ул биш ел Казанда электромонтажчы булып эшли, кичке урта мәктәпне, читтән торып укып университетның рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Аннан соң Габдулла Шәрәфи озак еллар «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә бүлек мөдире вазифасын башкара, 1962—64 елларда Мәскәүдәге югары партия мәктәбендә укый. 1967 елдан башлап ул «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы редакциясендә җаваплы секретарь, соңрак редактор урынбасары булып эшли.

Сугышка кадәрге шигъри әсәрләрен исәпләгәндә, Г. Шәрәфи — тулысы белән проза жанрында иҗат итүче автор. Аның балалар өчен язган «Кәҗәләр, кыяр һәм без» исемле беренче хикәясе 1962 елда «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыга. Аннан «Энҗе бөртекләре», «Тәфтиләү», «Мут Галләм», «Зәңгәр шәл», «Мирас», «Хат» исемле хикәяләре, кече яшьтәге балалар өчен «Хикәяләр» җыентыгы, япон самурайларына каршы совет солдатларының сугышчан походын тасвирлаган «Сусыз дәрья» исемле повесте, балалар һәм олылар тормышыннан алып язылган «Аккошлар кайтыр әле», «Күрше малае» кебек повестьлары дөнья күрә. «Сусыз дәрья» повесте рус теленә тәрҗемә ителеп, «Через Большой Хинган» исеме белән ике мәртәбә (Казанда һәм Мәскәүдә) дөнья күрә.

Габдулла Шәрәфи хәзер дә тынгысыз иҗади тормыш белән эшли. Соңгы елларда ул «Тормыш арбасы» дигән зур повесть тәгәлләде. Аның кызыклы-кызыклы язмалары көндәлек матбугатта да басыла килә.

Каләмдәш дустыбызны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз һәм аңа ныклы сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар телибез!

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ХӘТЕР ҺӘМ КАЙГЫ КӨНЕ

1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы корбаннары, шулай ук Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барлык сугышларның корбаннары истәлегенә хөрмәт күрсәтеп, Россия Федерациясе Президенты Б. Ельцин Указы нигезендә, «22 июнь — Хәтер һәм кайгы көне» дип игълан ителде.

Шул уңайдан, бу көнне мәркәзебез Казанның М. Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында сугыш корбаннарын искә алу митингысы үткәрелде.

## ТАТАРСТАННЫҢ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

Җөмһүриятебезнең Фәннәр академиясе Президиумы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих, археология, этнография, иҗтимагый фикер тарихы, Исламны өйрәнү бүлекләре нигезендә мөстәкыйль Тарих институтын төзү турында тәкъдим керткән иде. Шуны искә алып, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтын төзү турындагы Указга кул куйды. Бу Татарстан һәм татар халкы тарихы өлкәсендә фәнни тикшеренүләрне стимуллаштыру, югары квалификацияле кадрлар хәзерләү максатында эшләнде. Тарих институтының директоры итеп Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе Рафаэль Сибгат улы Хәкимов расланды.

## ҖӘЛИЛ ТУГАН ЯКЛАРДА

22 июнь көнне Оренбур шәһәре үзәгендә татар халкының мәшһүр улы — каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең бронзадан коелган һәйкәлен ачу тантанасы булды. Шул уңайдан бирегә Татарстаннан Җөмһүриятебезнең Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев житәкчелегендәге делегация килде. Делегация составында Казан каласы мэры К. Исхаков, М. Җәлилнең кан кардәше Т. Корбанов, Татарстан Дәүләт Советының даими комиссия рәисе, шагыйрь Р. Миңнуллин, «Татарстан» журналының баш мөхәррире, язучы Р. Мостафин һәм журналистлар бар иде.

Тантана барышында Оренбур шәһәре мэры Г. Донконцев Җәлил һәйкәлен коюда зур булышлык күрсәткәннәре өчен казанлыларга, скульптура авторы — Татар рәссамнарының Бөтендөнья ассоциациясе вице-президенты К. Җәмитовка ихлас рәхмәтен белдерде. Митингта шулай ук М. Җәлилнең бертуган сеңлесе Хәдичә ханым, Оренбург өлкәсе губернаторы В. Елагин һәм Татарстаннан килгән кунаклар чыгыш ясады. Соңыннан хәрби парад булды.

## КҮРШЕЛӘР КУЛ КЫСЫША

18 июнь көне Чувашстан Республикасының көньягында урнашкан Батыр, Комсомол, Шомыршы, Яльчик районнарында һәм башка төбәкләрдә яшәүче татарлар өчен зур бәйрәмгә әверелде. Бу көнне Батыр районның Озын Куак авылында Татарстан телевидениесе программаларын кабул итү өчен төзелгән ретрансляция корылмасын, Батыр авылында сафка бастырылган типография бинасын һәм республика күләмендә беренче булып татарча чыга башлаган «Вакыт» газетасын тәкъдир итү булды. Тантанада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе рәисе Т. Сәгыйтов, Буа районы хакимияте башлыгы Г. Хәйруллов, Чувашстан Республикасы Президенты Н. Федоров, Президент аппараты житәкчесе П. Краснов, Мәгълүмат һәм матбугат министры Ф. Шарков, Батыр районы хакимияте башлыгы В. Петров һ. б. катнашты.

## ЧАЛЛЫДА — ЖУРНАЛИСТЛАР «ДЕСАНТЫ»

21—23 июнь көннәрендә Татарстан һәм Россиянең вакытлы матбугаты, радио һәм телевидениесе журналистларының зур бер төркеме Чаллыда кызыклы очрашулар үткәрделәр. Бу чараны Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы әлеге шәһәр хакимияте белән бергәләп оештырган иде. Журналистлар Чаллының бүгенге тормышы белән якыннан таныштылар, шәһәр хакимияте башлыгы Р. Алтынбаев белән очраштылар.

Соңыннан алар Сабантуе бәйрәмендә катнаштылар.

## ТАТАРСТАН МЭРЛАРЫ — ҖИҢҮЧЕ

Ел буе дәвам иткән «Россия мэры — 95» конкурсы тәмамланды. Аның беренче турында 300 дән артык шәһәрдән катнашканнар иде. Соңгы турда исә аларның саны 50 гә калды. 18—19 май көннәрендә Мәскәүдә үткәрелгән финалда исә Казан һәм Чаллы шәһәрләре мэрлары Камил Исхаков белән Рәфкать Алтынбаев Россиянең иң яхшы ун мэры арасына кертелде. Бирегә алар тарафыннан оештырылган зур ярминкәгә һәм концерт-тамашага да югары бәя бирелде.

*ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

## ТУКАЙ ТӨРКИЯДӘ ДӘ КАДЕРЛЕ

15 июньдә Төркия Җөмһүриятенең башкаласы Анкарада төрки телле дәүләтләрнең уртак мәдәни-сәнгати оешмасы ТӨРКСОЙның Генераль идарәсе, татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тууына 110 ел тулуга багышлап, фәнни конференция уздырды. Анда Төркия галимнәреннән профессорлар Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт, шулай ук Фатма Өзкан, Мостафа Өнәр, Фазыл Агиш, бүген Измир шәһәрендә аспирантурада укучы шагыйрь милләттәшебез Рөстәм Сүлти һ. б. чыгыш ясады. Татарстаннан килгән Казан дәүләт университеты профессоры Резедә Ганиеваның «Тукай һәм төрки әдәбиятлар» һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Зөфәр Рәмиевнең «Тукай һәм чордаш татар шагыйрьләре» дигән темаларга ясалган докладлары да зур игътибар белән тыңланды.

Конференциядә катнашучыларны Төркиянең мәдәният министры Агаһ Октай Гүнәр, ТӨРКСОЙның генераль директоры — Әзербайҗанның мәдәният министры Полад Бүлбүлогълы котлады. Шулай ук Татарстанның Мәдәният министры Марсель Таишев, күренекле төрек сәясәтчеләре Нәҗметдин Эр-Бакан, Таңсу Чилләрнең котлау телеграммалары укылды.

## ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗГӘ БАГЫШЛАП

Мәшһүр шагыйрьләребездән Г. Тукайның тууына — 110, М. Җәлилнең дөньяга килүенә 90 ел тулу юбилейларын Казан дәүләт педагогия университеты галимнәре һәм студентлар, зурлап билгеләп үттеләр. Аларга багышлап, әдәби-музыкаль кичәләр уздыру белән бергә, кайбер диплом эшләре дә шушы олуг шәхесләргә, аларның тормыш юлларын, иҗади эшчәнлекләрен яңача яктыртуга багышланган иде. Шулар арасыннан Гүзәлия Шәйдуллинаның «Г. Тукай иҗатында дини һәм дини-мифологик образлар», Альмира Тимершинаның «М. Җәлил һәм җәлилче шагыйрьләр» дигән хезмәтләре (фәнни җитәкчеләре — Э. Галиева, Ф. Галимуллин) «бик яхшы» билгесе белән бәяләнде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР САФЫНА

20 июньдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда әдәбият галиме — филология фәннәре докторы, профессор Хатип Миннегулов, шагыйрә Рифә Рахман, драматург һәм артист Әмир Камалиев (Аманулла), юстиция органнарында эшләүче прозаик һәм публицист Флюр Баһаветдинов Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Гамил ага Афзалның 75 яшьлек олуг юбилее Әлмәтнең үзендә һәм район авылларында — мәктәпләрдә, китапханәләрдә, мәдәният йортларында зурлап билгеләп үтелде. Әлмәт шәһәре һәм район хакимияте башлыгы И. Гәрәев, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Р. Галиев, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Р. Вәлиуллин, «Хәзинә» газетасы мөхәррире, шагыйрь Н. Әхмәдиев исә юбилярны өенә барып котладылар, истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

* * *

Лениногорск шәһәрендә шул ук районның Сугышлы авылында туып-үскән шагыйрь һәм прозаик Җәүдәт Дәрзаманның 50 яшьлек юбилее да оешкан төстә, җанлы үтте. Техника сараенда уздырылган иҗат бәйрәмендә талантлы язучыны райондашлары кайнар котладылар. Тантанада Җ. Дәрзаманның әнисе Сәгыйдә апа да кызыклы чыгыш ясап, кичәне тагын да ямьләндерде.

Мөмкинлектән файдаланып, юбиляр район авылларында, шул исәптән Сугышлыда да булды. Сабантуе көннәрендә ул, композитор Сафьян Ибраһимов һәм халкыбызның атаклы җырчысы Габдулла Рәхимкулов белән берлектә, авыл клубында чыгыш ясады, туган авылына махсус атап язылган җырын бүләк итте.

## КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Заманында Чаллыдагы «Ак бүре» киностудиясендә эшләгән, вакытсыз арабыздан киткән талантлы шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинны хезмәттәшләре онытмыйлар. 24 майда, җомга көнне, алар, әлеге киностудиянең генераль директоры Тәбрис Гыймалетдинов җитәкчелегендә, шагыйрьнең туган ягында — Балык Бистәсе районының Кече Укмас авылы зиратында булып, каберенә истәлек ташы куйдылар. Шул уңайдан бергә К. Сибгатуллинның якыннары һәм балалары да кайткан иде.

## САРА САДЫЙКОВА ТУРЫНДА ФИЛЬМ

Милләтебез сандугачы — атаклы композитор һәм җырчы Сара ханым Садыйковага багышлап, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе документаль музыкаль фильм төшерә башлады. Сценарий авторлары Гөлшат Зәйнашева, Идмас Үтәгәнов (ул — бер үк вакытта режиссер да), оператор Юрий Гвоздь, фильмның директоры — С. Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов, кинокартина героинясы эзләреннән инде Мәскәүдә булып, аның студиядә укыган елларына кагылышлы эпизодларны, истәлекләрне төшереп кайттылар. Хәзер киногруппа республикабызның Сара ханым эшчәнлегенә бәйле авыл районнарына чыгып китте. Фильмны шушы елның ноябрендә тамашачылар хөкеменә тапшыру планлаштырыла.

# КЫРЫГЫНЧЫ КӨН...

Туксанынчы еллар башында туган рухый күтәрелеш чоры Аурупа һәм Азия буйлап сибелгән татарларны мәдәни яктан бер зур мохит, мең төрле риваятьләрдән торган эпос, тарих сукмакларында бер заман югалып, ниһаять, кайтарылып-табылган, контурлары шактый чамаланган, барланган, бары тик бәдәни, физик яктан җан өрәсе, тәзеклисе, бер мәрҗәнгә тезәсе якты бер цивилизация итеп танырга мөмкинлек бирде. Бу кабатланмас тереклекнең үзәгендә, һичшиксез, бүгенге бөек тарихи хезмәте нәтиҗәсендә узганы тагын да күләмлерәк, эчтәлеклерәк күренгән Казан, аның гөлләнү-көлгәйләнү, «кубарылу» вакыйгалары, моңы, сагышы, йөрәк тибеше... киләчәккә адымнары. Сынлы сәнгатьтә бу теманы кабызучылар — Казан рәссамнары.

Казаннан ераграк яшәп тә үзен татар итеп тойган, милләтенең бәхетенә, космик киләчәгенә, язмышына ышанган «тышкы татарлар» исә «татар дөньясын» кинрәк итеп алып, кайчандыр татар кавеме орлыгы һәм сулышы белән сугарган иксез-чиксез җирне Ватан дип санап, бу тирәлекне тагын да мавыктыргычрак һәм күптөрлерәк, күпаһәңле һәм күптөсле итеп, бераз төркирәк, мәҗүсирәк, көчәбә (күчмә) һәм җирле, шәһәрле һәм тирмәле, мәчетле вә далалы, болгарлы һәм урдалы, арупи (баты) һәм монгол-кыпчак йөзле итеп сурәтләделәр. Бу ике рухый тирәлек бер-бере белән тартышып, магнитлашып торган бербөтен мәдәният тудырды. Шулай итеп, туксанынчы еллар уртасында, фән белән синхрон рәвештә, сәнгатьтә (татар мәдәниятендә) генә борыңгы уртаклыкны һәм тарих борылышында туган яңа төсмерләр, кушымталар, диалект һәм сәнгать үзенчәлекләрен туплаган, бүгенге көн теоретикләры өчен уйдырма, мираж булмаган, нигезле рәвештә иске тамырларына һәм халыкның бүгенге омтылышларына таянган — галәм каршысында ниндидер үҗәтлеге, эчке энергетикасы — тарихи һәм генетик потенциалы нәтиҗәсендә — тәрәккый иткән татар дөньясының яңа җисеме-төшенчәсе туды. Билгеле сәбәпләр буенча, ул беренче нисбәттә, татар сынлы сәнгатендә чагылыш тапты... Зур-зур күләмле образларга яңа сәнгати панорамалар, портрет галереяләре, цикл-серияләр туура сәбәп булды. Бу мохитнең тереклеге заманында милли идиллия-этнографиягә нигезләнеп туган декоратив сәнгать төбәкләренә дә икътисади, фәлсәфи эчтәлек өстәде, эзлеклелек, концептуальлек билгеләрен тәэмин итте.

Бу унъеллыкта шушы ике җирлектә туган татар сәнгатенең реформалары, аның «Күл мәктәбе» мистиклары һәм романтиклары, шаман һәм масоннары — суфыйлары — бертөрле катып калган реализм калыпларын инкарь итүче һәм какшатучы кешеләр Уфа рәссамнары булды. Алар: Н. Латфуллин, Р. Әхмәтвәли, Р. Хасанов, Р. Харис, В. Ханнан, Н. Байбурин, Р. Кадыйри, З. һәм И. Гаяннар, И. Әхмәтвәли, Р. Гарифуллиннар иделәр... Аларның күбесе турында махсус мәкаләләр язылды, иҗат тенденцияләре ачыкланды, рәсем тезмәләре басылды. Ә менә шул төркемнең типик иҗаткяре Хәйдәр Колбарис турында бу беренче сүз. Ул авторның Милли мәдәният үзәгенең «сәнгать җәүһәрләре» дигән экспозициясендә эленеп торган, «Кырыгынчы көн» әсәре хакында.

Бу әсәрендә рәссам гаҗәеп эчке җегәрлектә, тышкы лаконизм, кырыслык һәм фигураларны бераз деформацияләү алымнары артында яшеренеп яткан эчке киеренкелек аша, мәҗүси чор образлары алтын болан — гаилә, ыруг башы, Илаһы һәм немец экспрессионизмның шактый катгый, шомлылык тудыру алымнарын берләштереп, халкыбыз багынган һәм кабилә, мәхәллә, гаилә, дини, милли туганлыкның үзәген тәшкил иткән иман йоласын тасвирлаган.

Кырыгынчы көннең шомлы кырыслыгын төйнәгән «боланлы нагышь» — безне ташлап, тормыш упкыннарына төшеп киткән, күңел сөйгән, җан таланган кайтмас бәндәләрне сагынудан туган тантаналы дога итеп кабул ителә.

Узган гомернең тәмен татып өзелгәннәргә җәннәт җимешләрен насыйп ит, Тәңрем, монда калганнарга сабырлык һәм иминлек, түземлек бир...

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** «Кырыгынчы көн» — рәссам Хәйдәр Колбарис картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы һәм публицист Рашат Низамиев.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**На стыке континентов и цивилизаций** (Дәверләр китабы). Төзүчесе — И. Б. Мөслимов. Мәскәү. 1996 ел. 768 бит. Тиражы — 30 мең данә.




Мәскәүнең «Инсан» нәшрияты рус телендә «На стыке континентов и цивилизаций» дип исемләнгән гаҗәеп бер китап бастырып чыгарды. Татар тарихына караган олуг хезмәтләрнең болай бер кулга җыеп басылганы моңа кадәр булмагандыр.

Китапка — «Әхмәт ибне Фадланның Иделгә сәяхәте һәм болгарларның Исламны кабул итүе», Эренҗен Хара Дауанның (Л. Гумилев, В. Ермолаев кереш сүзе белән) «Гаскәр башы буларак Чыңгыз хан һәм аның мирасы», М. Сәфәргалиевнең «Алтын Урданың таркалуы», М. Худяковның «Казан ханлыгы тарихы» кебек фундаменталь хезмәтләр кертелгән.

Супертышлыклы китап бик шәп кәгазьгә басылган, тарихи карталар, борынгы китаплардан алынган төсле рәсемнәр белән бизәлгән.

Нәшер итүчеләр, табыш алуны максат итмичә, изге нияттән чыгарганга күрә, бу кыйммәтле китапка бәяне дә бик арзан куйганнар. Үз тарихына, хәтеренә битараф булмаган һәммә кешенең өстәлендә торырга тиешле әлеге китапны Татарстан Милли китапханәсендә сатып алырга мөмкин.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)